ӘГЪЗАМ ФӘЙЗРАХМАНОВ



# ШӘКЕРТ АБЫЙ

Казан • «Мәгариф–Вакыт» нәшрияты • 2017

**УДК 74.200.51**
**ББК 001**
**Ф17**

**Фәйзрахманов, Ә.Ф.**
Ф17 Шәкерт абый. — Казан: Мәгариф — Вакыт, 2017. — 247 б.
ISBN 978-5-906894-00-0

Күренекле журналист Әгъзам Фәйзрахмановның бу китабында Татарстан Фәннәр академиясенең академигы һәм вице-президенты, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, республиканың фән һәм техника өлкәсендәге лауреаты Рүзәл Юсуповның гыйбрәтле тормыш юлы, игелекле гыйльми-педагогик һәм иҗтимагый-сәяси эшләре тасвирлана.

ISBN 978-5-906894-00-0

© Фәйзрахманов Ә.Ф., 2017
© «Мәгариф–Вакыт» нәшрияты, 2017

# ОЛЫ ЮЛНЫҢ БАШЫ

## МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕККӘ ТӘҮГЕ АДЫМ

Ул, кайсы якка китәргә белмичә, бераз гына вокзал каршында басып торды. Казанга беренче тапкыр килүе аның. Урам халык белән тулы. Бер-бер артлы машиналар узып тора. Авылдан әти-әнисе әйтеп җибәргән адресны исенә төшереп алды: «Колхоз базары, түгәрәк баганалы капкалы йорт, шунда Зөләйха апаң булыр». Урамның исеме дә, йортның номеры да билгесез. Табып кара син кирәкле кешеңне таныш булмаган шәһәрдә! Әтисе белән әнисе сирәк-мирәк кенә Казанга килгәндә шунда кунгалап китсәләр дә, урам исемен дә, йорт номерын да хәтерләрендә калдырмаганнар. Әле ундүрт яше дә тулмаган улларын озатып куйсалар да яраган булыр иде дә бит, килә алмадылар шул. Авылда кызу эш өсте. Ул елларда колхозларда тәртип бик каты була. Җибәрмәгәннәрдер, күрәсең. Хәер, әтиләре малайларын кечкенәдән үк һәрнәрсәне мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтеп килә. Үз башың белән ныклап уйлап, тәвәккәлләп эш итсәң, нәтиҗәсе яхшырак була, тормыш авырлыкларын тизрәк җиңәргә өйрәнәсең, ди.

Ярый әле колхоз базары вокзалдан ерак түгел икән. Кешеләрдән сораштырып, Нариман урамы буйлап бераз баргач, малай колхоз базарына килеп тә җитте. Әмма Зөләйха апа өен шактый озак эзләргә туры килде. Чөнки базарның ике ягыннан сузылган урамда түгәрәк баганалар белән ясалган капкалы йортлар берничә булып чыкты. Көн инде кичкә авышып килә, караңгы төшәргә дә күп калмады. Зөләйха апаны табып булмаса ни эшләргә? Төнне кайда үткәрергә? Соңгы поезд белән авылга кире кайтып китсәң генә инде. Ләкин техникумда уку теләге зур иде малайның. Бу фикер аны берничә ел элек үк бимазалый башлады. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, һөнәр училищеларына китеп барган дусларына иярмәде ул. Югыйсә анда ашаталар, киендерәләр, торырга урын да бирәләр, һөнәр алып чыгып, эшли дә башлыйсың. Бер уйлаганда, балалык елларын фәкыйрьлектә, ачлы-туклы үткәргән авыл баласына нәрсә кирәк тагын?

Юк инде, ул, теләгенә ирешмичә, һич кенә дә кайтып китмәячәк. Зөләйха апаны бүген тапмаса, иртәгә тагын эзләр. Төнне вокзалда уздырып торыр. Букчасында әнисе салып җибәргән ипи белән пешкән йомырка бар бит әле. Түгәрәк баганалар белән ясалган капкалы йортларны тагын әйләнеп, сораштырып чыга ул. Һәм, ниһаять, шундый бер капка төбендә кем беләндер сөйләшеп торган мөлаем бер апаны күреп ала. Якынрак килеп аннан: «Сез Зөләйха апа түгелме?» — дип сорый.

— Мин, — ди ханым. — Ә син үзең кем буласың соң, энем?

— Кышкарның Йосыф Габдуллаҗаны улы Рүзәл мин. Техникумда укырга дип килдем...

— Әйдә, алайса, өйгә керик. Сөйләшербез, киңәшербез...

Хуҗабикә Зөләйха ханым, уртача зурлыктагы агач өендә торучылары күп булса да, Рүзәлгә үзендә сыену урыны таба. Икенче көнне малай техникумны эзләп китә. Ул вакытта Казанда техникумнар шактый күп була. Авиация, механика-технология, химия-технология, энергетика техникумнары иң абруйлылардан санала. Шуларның берсенә керергә хыялланып йөри Рүзәл. Мәктәпне «бишле» билгеләренә тәмамлап, мактау грамотасы алып чыкканнар урта махсус уку йортларына имтиханнарсыз гына кабул ителә. Димәк, мәктәпне «бишле»гә тәмамлаган Рүзәл дә теләгән техникумына керә ала.

Ләкин, гөнаһ шомлыгы, техникумнарга гаризалар кабул итү вакыты тәмамланган булып чыга. Рүзәлнең соңга калып килүенең сәбәбе шул була: имтиханнар беткәч, Рүзәлгә таныклык белән бергә мактау грамотасы тапшырырга онытканнар икән. Мәктәп секретаре озак вакытка авылдан каядыр китеп барган. Аның кайтуын шактый озак көтәргә туры килә...

Игъланнарга күз салып, кешеләрдән сорашып шәһәр буйлап йөри торгач, әле яңа ачылган кооперация техникумында гаризалар кабул итүнең дәвам итүе ачыклана. Беренче ел гына ачылган булганлыктан, халык аны белеп тә бетермәгәндер әле. Сайлап тору мөмкинлеге калмаганлыктан, Рүзәл документларын шушы техникумга тапшыра. «Товар белгече» («товароведение») дигән бүлеккә. *«Мин ул чакта «кооперация»нең нәрсә икәнен дә белми идем әле. Техникум булгач, ярар инде, дип уйлаганмындыр, күрәсең»,*— ди Рүзәл Юсупов, гомеренең ул мизгелен искә алып.

Әле ундүрт яше дә тулмаган Кышкар малае, шулай итеп, мөстәкыйль тормышка аяк баса. Торыр урын табу, туклану, киенү, кыскасы, көнкүреш мәсьәләләренең барысын да моннан ары инде аның үзенә хәл итәргә туры килә.

## КЫШКАР — ТАРИХИ АВЫЛ

Укулар башланганчы берничә көн авылына кайтып тора Рүзәл. Техникумга укырга керү зур шатлык булса да, авылдан аерылу ничектер моңсу тоела. Кат-кат авыл урамнарын әйләнә, үзенә белем биргән мәктәп ишегалдын урап чыга. Күңеленә якын шул аның туган авылы Кышкар. Данлыклы авыл була ул. Авылның бай тарихын да, бабасы Йосыфҗанның авыллары мәчетенең мөәзине булганлыгын да эти-әниләреннән ишетеп белә Рүзәл. Гомумән, авыл малайлары гадәттә кызыксынучан була, һәрнәрсәне белергә тырыша, кечкенәдән үк төрле эшләргә өйрәнеп үсә бит.

Кышкар авылының тарихы Казан ханлыгы чорыннан ук башлана. Аның турында, Алат юлы өстендә утырган авыл буларак, шул дәвердән сакланып калган та-



*Кышкар авылы мәчете. (Рүзәл укыган мәктәп бинасы)*

рихи документларда искә алына. Казан өязенең 1602—1603 еллардагы мәгълүматлар тупланган теркәү кенәгәсендә бу авылда йомышлы татарлар яшәгәнлеге әйтелә. Татар энциклопедиясендә авыл турында мондый сүзләр язылган: «Кышкар авылы, Арча районында, район үзәгеннән 31 километр төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы Симет суының югары агымы буенда урнашкан. Аңа Казан ханлыгы дәверендә нигез салына, 1789 елда 317 кеше (татарлар) яши. Халыкның төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. XIX йөздә аяк киеме тегү кәсепчелеге, күн эшкәртү, кирпеч сугу, комач тукыма туку һөнәрчелеге, XVIII йөз башыннан алып 1918 елга кадәр мәдрәсәсе булганлыгы мәгълүм. Мәчете — XVIII йөзнең икенче яртысы архитектура истәлеге».

Кышкар — күренекле дин, мәгърифәт әһелләре яшәгән, үзенең зыялылары белән элек-электән дан тоткан, кыйммәтле архитектура һәйкәлләре булган сирәк авылларның берсе. Ул барыннан да бигрәк мәдрәсәсе белән данлыклы. Кышкар мәдрәсәсе иң бай сәүдәгәрләрнең берсе, Россиядә һәм Урта Азиядә сәүдә иткән, берничә сабын заводы тоткан Баязид бине Госман әл-Кышкари тарафыннан салынган. Ул һәм аның варис оныклары Муса бине Нәзир, Мортаза бине Нәзир әл-Кышкарилар мәгърифәтчелек файдасына юмарт иганәчелек белән шөгыльләнгәннәр. Иганәчеләренең, мөгаллимнәренең тырышлыгы нәтиҗәсендә мәдрәсә атаклы уку йортына, мөдәррислек мәктәбенә әверелгән. Кышкарга Казаннан, Оренбургтан, Семипалатинскидан, Касыймнан һәм башка төбәкләрдән укырга килгәннәр. Мәдрәсәдә белем алучылар арасыннан күп кенә татар зыялылары, атаклы мәдәният әһелләре чыккан. Татар мәгърифәтендә, әдәбиятында абруйлы урын тоткан шагыйрь Габделҗаббар Кандалый, драматург Фатыйх Халиди, язучы Әхмәт Уразаев-Кормаши, Габдулла Тукайның әтисе имам-хатыйб Мөхәммәтгариф Тукаев,

Санкт-Петербург имамы, Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы хезмәткәре Гатаулла Баязитов, Тукайның шагыйрь булып китүенә этәргеч биргән Мотыйгулла Төхфәтуллин кебек күренекле шәхесләрнең Кышкар мәдрәсәсендә укыганлыгы үзе генә дә бу авылның тарихи-мәдәни әһәмиятенең зурлыгын ачык күрсәтә.

Кышкар авылына зур ямь биреп торган архитектура истәлеге — аның уртасына урнашкан ике катлы, биек манаралы мәһабәт таш мәчете. Урамның икенче ягында Екатерина II указыннан соң ачылган, берничә бинадан торган мәдрәсә комплексы урнашкан булган. Мәчетне дә Баязид бине Госман әл-Кышкари төзеткән. Ул барокко стиленең Казан мәктәбе ысулында эшләнгән. Төзү өчен җирле материаллардан файдаланганнар. Кышкар мәчете матурлыгы белән башка мәчетләрдән аерылып торган. Мәчетнең иң күркәм урыны — намаз укый торган заллар өстендәге ике гөмбәзе. Андый гөмбәзләр Каһирәнең, Дәмәшкънең, Истанбулның иң мәшһүр саналган мәчетләрендә генә бар, диләр.

Баязид бине Госман әл-Кышкариның балалары һәм оныклары йөз ел буена диярлек Кышкар мәчетен карап, төзәтеп һәм зурайтып торганнар. Октябрь революциясеннән соң Кышкар мәдрәсәсе ябыла. 1930 елда ВКП(б) һәм совет хакимияте органнары мәчетнең бөтен тирә-якка ямь биреп торган манарасын җимерәләр. Мәчет мәктәп итеп үзгәртелә. НКВД хезмәткәрләре Баязид бине Госман бай нәселеннән булган кешеләрне, мәдрәсә укытучыларын сөргенгә сөрәләр.

Габдуллаҗан улы Рүзәл дә шушы элекке мәчет бинасында урнашкан мәктәптә белем ала. Аның кешеләр язмышын кайгыртып, авырлыклар алдында тез чүкмичә, гомер юлын зур казанышлар белән бизәгән олуг шәхес булып формалашуына, оста оештыручы, күренекле галим, фән докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, республиканың атказанган фән эшлеклесе, дәүләт премиясе лауреаты кебек дәрәҗәләргә ирешүенә Кышкар мәдрәсәсенең изге традицияләре, авылының саф һавасы, якташларының тырыш хезмәт үрнәкләре, акыллы киңәшләре уңай йогынты ясагандыр. Кышкардан чыгып китүенә алты дистәдән артык вакыт үтеп китсә дә, Рүзәл бүген дә якташларының тормышы, көнкүреше белән даими кызыксынып яши. Аның 2014 елда «Сүз» нәшриятында авылдашлары Гөлнара Ибраһимова, Ләйсән Шәфигуллина туплаган материаллардан файдаланып язылган «Бар Казан артында бер авыл — Кышкар диләр...» исемле китабы дөнья күрде.

Бу китаптан Кышкар авылы халкының, кырыс табигать шартларында яшәп тә, авыл хуҗалыгында зур уңышларга ирешүе, колхозлашу елларындагы, дәһшәтле сугыш чорындагы михнәт-җәфаларны зур түземлек, сабырлык белән кичерүе, ир-егетләрнең Ватан сугышы фронтларында дошманга каршы батырларча көрәшүе белән танышып, мондый фидакарьлекнең татар уллары һәм кызларының барысына да хас икәнлеген аңлаган хәлдә, халкыбыз өчен горурлык хисләре кичерәсең. Алар

кебек яуда батыр, эштә уңган кешеләрнең бәхетле яшәргә лаеклы булулары хакында уйланасың.

Китапта сурәтләнгән вакыйгалар, Кышкар авылында туып-үскән, яшәгән мәртәбәле шәхесләрнең тормышы яшь буын өчен зур гыйбрәт. Үрнәк алырлык кешеләр, игътибарга лаеклы хәлләр күп монда. Кечерәк кенә бер татар авылыннан никадәр күренекле затлар, орден-медальләр белән бүләкләнгән фронт һәм хезмәт батырлары, мактаулы исемнәр алган шөһрәтле шәхесләр, җитәкчеләр, галимнәр һәм башка күркәм кешеләр чыккан.

Кышкар җире халкыбызга ике академик биргән. Аның берсе күренекле тел галиме, җәмәгать эшлеклесе Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов булса, икенчесе — физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе президиумы әгъзасы, математика, механика һәм машина төзелеше буенча академик-секретаре, Татарстан һәм Россия Федерациясенең атказанган фән һәм техника эшлеклесе Илтөзәр Гыйззәт улы Терегулов. Аның күпьеллык хезмәтенең йомгагы буларак, «Шуучанлыгы булган тышчаларны бөгү һәм аларның тотрыклылыгы» исемле күркәм монографиясе дөнья күрә. Ул — физика һәм геометрия алымнарына нигезләнеп, тышча теориясе проблемаларының гомуми мәсьәләләрен системалы рәвештә бәян иткән дөнья күләмендә күренекле хезмәтләрнең берсе. Бу галим үзенең фәнни казанышлары белән Казан механиклар мәктәбенең дәрәҗәсен күтәрде, югары уку йортларында механика фәнен укытуны югары нәтиҗәле итүгә этәргеч бирде. Илтөзәр Терегулов шәкертләреннән дистәләгән кеше кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклады. Кышкарда туган галимнәр турында сөйләгәндә, шуны да искәртеп үтәр идем: республикада халкыбызга ике академик биргән башка бер генә авылны да белмим мин.

«Бар Казан артында бер авыл — Кышкар диләр...» китабы белән танышкач, бу авылдан чыккан хәрби офицерларның күп булуына игътибар итәсең. Шуларның берсе Хәмит Вәлиев (Апакашев) — гыйбрәтле, ачы язмышлы шәхес. 1930 елда, Хәмиткә сигез яшь чагында, бернинди судсыз-нисез, аларның гаиләләрен, барлык мөлкәтләрен тартып алып, Себергә сөрергә, дигән әмер килә. Гаиләдә бер яшьтән ундүрт яшькә кадәр алты бала була. Хәмитне, апасы Гөлсем һәм энесе Мәҗит белән бергә, әтисенең абыйсы Әхмәтҗан һәм җиңгәләре Шәмсенур үзләрендә алып кала. Әтиәнисе өч баласы белән Кытай чигенә җибәрелә. Әниләре, балаларын ияртеп, Кышкарга бары 16 елдан соң гына әйләнеп кайта, әтиләре Габделвәли Себердә үлеп кала.

Рәхимсез тормыш сынаулары балаларның рухын сындыра алмый. Кышкарда калган балаларның өчесе дә, абый-җиңгәләренең рәхим-шәфкате, үзләренең тырышлыгы белән аякка баса, белем ала. Сугыш болытлары куерып килгәндә, Хәмит хәрби хезмәткә чакырыла. Күп тә үтми артиллерия училищесына укырга җибәрелә.

Киеренке уку-өйрәнү айларын узып, яшь офицер Хәмит Вәлиев инде дәһшәтле 1942 елның июль көннәрендә борынгы рус шәһәре Воронеж каласы янында сугыш чирканчыгы ала. Шуннан соң ул Дон далалары, Белгород кырлары, Украинаның яндырылган авыл-шәһәрләре, чал Днепр аша рәхимсез сугыш юлын уза.

Хәмит Вәлиев үзенең дивизионын Вислага, аннары Берлинга һәм Прагага китереп җиткерә. Көчле һәм рәхимсез дошманны җиңү өчен, зур батырлык янына хәрби һөнәрне яхшы белү, кешеләргә ышаныч белән карау да кирәк була. Сугыштан соң гвардия полковнигы Вәлиев Кызыл байраклы Прикарпатский хәрби округы гаскәрләрендә хезмәт итә. Ул анда артиллерия берләшмәсе начальнигы була. Хезмәтен Камчаткадагы артиллерия һәм ракета гаскәрләре командующие булып тәмамлый.

Хәмит белән бергә үскән энесе Мәҗит тә 1942 елның августыннан 1945 елның 9 маена кадәр фронтта совет армиясе командиры була. Сугыштан кайткач, Казан финанс-икътисад институтын тәмамлап, Арча районы оешмаларында баш бухгалтер, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында бүлек мөдире булып эшли, Татар иҗтимагый үзәгендә Татарстанның дәүләт суверенитеты өчен актив көрәшчеләрнең берсе була.

1926 елда Кышкарда туып үскән Габделфәт Газизулла улы Шәфигуллинга да сугыш җәфаларын күрергә туры килә. Ул ике тапкыр каты яралана. Сугыштан соң Вильнюс шәһәрендә Эчке эшләр министрлыгының югары мәктәбендә укып, лейтенант исеме алып чыга. Аннары күп еллар Үзбәкстанда милиция системасында эшли. Бик җаваплы һәм катлаулы оешмаларның җитәкчесе була. Лейтенанттан полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

Кышкарның икенче бер егете Фаил Садыйров чирек гасыр төрле хәрби фәнни-тикшеренү институтларында эшли. Подполковник дәрәҗәсендә запаска чыккач та, «Звёздный» ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры вазифасын башкара.

Китапта республика, шәһәр күләмендәге җитәкче урыннарда күп көч куеп эшләгән кышкарлылар турындагы язмалар да шактый. Рәис Төхфәтуллин, мәсәлән, КПСС өлкә комитетының милли эшләр буенча инструкторы булып эшли. Соңрак Казан шәһәренең мәдәният идарәсен, аннары Татарстан радиосын җитәкли. Министрлар Кабинеты аппаратында мәдәнияткә, сәнгатькә, спортка бәйләнешле оештыру эшләре белән шөгыльләнә.

Әнәс Абдуллаҗан улы Юсупов, абыйлары кебек кырыс тормыш юлы узып, зур хәрби предприятие — Казан моторлар төзү берләшмәсенең генераль директоры урынбасары вазифаларын башкара, эшеннән аерылмыйча диссертация яклап, икътисад фәннәре кандидаты һәм доцент була.

Икенче бер Кышкар егете Фоат Усман улы Гомәров Казан шәһәре Ленин районының коммуналь хуҗалыгы мөдире, аннары, тәҗрибәле белгеч буларак, Татарстан Министрлар Кабинетының бүлек мөдире булып эшли.

«Казан арты төбәгенең бәрәкәтле җирендә туып-үскән бөек мәгърифәтчеләр, күренекле фән һәм сәнгать эшлеклеләре, танылган белгечләр һәм җитәкчеләр, илебезнең төрле почмакларында яшәп, халкыбызга фидакарь хезмәт иткән Арча районы халкы күркәм традицияләрен бүгенге көндә дә дәвам иттерә, туган ягының данын еракларга тарата», — диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Арча районы оештырылуның 75 еллыгы уңаеннан. Бу сүзләр — Арча халкына лаеклы бәя. Рөстәм Нургали улы бу төбәкне республиканың беренче җитәкчесе буларак кына түгел, ун елга якын шушы районда эшләгән, халык белән көн дә аралашкан кеше буларак та яхшы белә. Шунлыктан Р.Н.Миңнехановның арчалыларга зур хөрмәт белән каравы гаҗәп түгел.

Тарихтан күренгәнчә, Арча төбәге татар халкының мәгърифәте, мәдәнияте үсешендә зур урын тота. Ул — халкыбызга Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави, Шәмсетдин Күлтәси кебек мәшһүр мәгърифәтчеләрне, бөек Габдулла Тукайны, Галиәсгар Камал, Гомәр Бәширов, Мәхмүт Галәү, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев кебек олуг әдипләрне, 150 дән артык фән докторын, Зөләйха Богданова, Гөлзадә Сафиуллина, Айдар Фәйзрахманов, Габделфәт Сафин, Люция Хәсәнова, Рөстәм Закиров кебек сәхнә йолдызларын, «Таттелеком» берләшмәсенең генераль директоры, запастагы полковник Лотфулла Шәфигуллин кебек дәүләт идарәсенең, хуҗалык һәм фәнни оешмаларның дистәләрчә җитәкчеләрен һәм йөзләрчә башка күркәм затларны биргән төбәк. Республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, шушы районда туып-үскән Марат Әхмәтов тикмәгә генә: «Арча яшәү рәвеше белән дә татарның йөзек кашы булып тора», — димәгәндер шул. Шагыйрь Наил Касыймов исә туган ягына үзенең хисләрен шигъри юллары белән белдерә:

Ямьле Арчам — данлы Казан арты,
Улларыңны белә дөнья халкы.
Талантлы син, илһам канаты син,
Бер үзеңдә күпме йолдыз балкый.
Туган ягым минем, ямьле Арчам,
Сиңа кайтам юллар йөреп арсам,
Туган ягым минем гүзәл Арчам,
Кайтмас идем, синсез яши алсам!

Бу хисләрне мин, күптән түгел Кышкарда үткәрелгән «Бар Казан артында бер авыл — Кышкар диләр...» дигән китапны тәкъдим итү кичәсендә катнашып, нык

сизеп утырдым. Мине анда кешеләрнең бер-берсе белән ничек җылы аралашуы, якын мөнәсәбәте, үз-үзләрен тотышлары сокландырды. Китапны тәкъдим итү чын мәгънәсендә зур бәйрәмгә әйләнде. Тантанага бүген илнең төрле җирләрендә яшәүче кышкарлылар да кайткан иде. Алар, бергәләшеп, яшьлек хатирәләрен яңарттылар, җырладылар-биеделәр, чәй эчтеләр. Соңыннан авыл урамнарын әйләнделәр. Һәркемнең күңелендә якты хисләр, хатирә-сагышлар уята туган авылы.

## БЕЗ — СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ

Рүзәлнең балачагы һәм үсмер еллары Ватан сугышы алдыннан татар авылларында туган меңнәрчә малайларныкы кебек. Ул чор балаларының язмышы уртак булды: фәкыйрьлек, ятимлек, авырлык.

«Хатирәләремне яңартып...» дигән китабында Рүзәл Юсупов ул елларны менә ничек искә ала: *«Ул вакыттагы михнәт-җәфаларны, илдәге миллионлаган балалар кебек, мин дә җитәрлек татыдым. Аларның эзләре күңелгә гомергә бетмәслек булып уелып калды. Ул көннәрдәге шөбһәле, тетрәндергеч кичерешләр хәзер дә, җиде дистәдән артык елдан соң да, күптән түгел генә булып узган кебек, хәтердә ачык саклана.*

*Бигрәк тә кышкы караңгы көннәр искә төшеп үзәкне өзә.*

*Миннән ике яшь чамасы гына кечерәк энем Әнәс белән икебез көннәр буе салкын өйдә ач килеш утырып чыгабыз. Әни, бер капчык ашлык салган чана тартып, утыз чакрым ераклыктагы Арча элеваторына яки Дөбьяз тирәләрендәге Алат авылына киткән була. Миннән берничә яшькә олырак Равил һәм Наил абыйлар мичкә ягарлык әйбер хәстәрләү эше белән мәшгуль: я басуда кар югарак урыннардан*



*Рүзәлнең әтисе белән әнисе*

*әрем җыялар, яки су буендагы тал чыбыкларын чабып алып кайталар, яки авыл тирәсендәге эскертләрдән йолкып алып салам ташыйлар. Алар эшләрен тәмамлап, көннең кай вакытында кайтып, ашарга нәрсә юнәтә торган булганнардыр, хәтерләмим. Хәер, без ул елларда бәрәңгедән һәм аерткан, ягъни сепаратордан чыгарылган сөткә умач салып пешергән аштан башка ризыкны белмәдек тә. Үзәккә үтәрлек салкын, буранлы көннәрдә утызар чакрым арага йөк төягән чана өстерәп барып, безнең әниләр өйгә кайчан кайтып җитә торган булганнардыр. Анысы минем истә калмаган. Әмма гел ашыйсы килеп, туңып, көне буе сәкедә тилмереп утырганыбыз хәтергә нык сеңеп калган.*

*Беркөнне шулай, өйдә Әнәс белән икебез генә булганда, ишекне бәреп ачып, өйгә мөгезле сарыктырмы, тәкәдерме җитәкчелегендә берничә сарык килеп керде. Кыю-кыю басып, иснәнеп, күрәсең, ашарга эзләп йөрделәр болар. Тышта кыш бит. Чи чыбык-чабык, әрем, салам яккан өйдә болай да суык. Шуның өстенә ишек ачык: сарыкларның берсе мөгезе белән төртеп ачып керде керүен, ә ябарга кирәклеген белми... Ниһаять, берникадәр вакыттан, монда ашарлык нәрсә юк икән дип булса кирәк, чыгып киттеләр болар. Мин шуннан соң сәкедән төшеп, ишекне ябып куйдым.*

*Абыйлар таба алган ягулыкларын алып кайтып, өйгә алып кереп бушаткач, аны мичкә ягу гамәле башлана. Монысы инде минем өйдәге күп санлы вак-төяк эшләрнең берсе иде. Әмма ул җиңел шөгыль түгел: чи чыбык тиз генә янмый, чыш-пыш килеп пыскып утыра. Әрем дә тиз генә янмый: ул да кипмәгән. Салам булса, монысы, киресенчә, мичкә тыгуга гөлт итеп кабынып яна да бетә, бер-бер артлы бик еш тыгып, озак ягарга туры килә. Мич барыбер кызып, өй җылынып җитми. Салам бөтен өйгә тарала. Аны себереп чыгару — шулай ук минем эш.*

*Салам ягуның куркыныч ягы зур: өйдә янгын чыгу ихтималы адым саен сагалап кына тора. Ягучы кеше кечкенә малай гына бит: сәләте, игътибары җитеп бетми, мич авызыннан янып торган салам кыйпылчыклары идәнгә килеп төшә дә, анда чәчелеп яткан салам дөрләп янып китәргә генә тора. Сүндереп өлгерү зур җитезлек һәм кыюлык таләп итә. Бер тапкыр куркыныч хәл булып алды: идәндәге саламда дөрләп киткән ут, кроватька сикереп менеп, юрганга капты. Ярый әле абыйлар өйдә иде, югалып калмадылар, юрганны тиз генә урамга алып чыгып, карга салып таптадылар. Янгын чыкмый калды.*

*Фронттан еш килеп торган шомлы хәбәрләр истә. Кышын хатын-кызларның, җыелып, кич утырулары гадәткә кергән иде. Ул еллардагы фәкыйрьлекне сөйләп бетерерлек түгел. Ризык, кием-салым җитмәү, ягарга булмау гына түгел, ширпы-керосин кебек әйберләргә дә кытлык зур иде. Учакка ягып җибәрү өчен, кешеләр бер-берсеннән, мичләре янып торган берәр йорттан утлы күмер алып чы-*

*галар. Безнең авылда бу шөгыльдә аерылып торган, үзенә күрә бер батыр кеше — Газизә апа бар иде. Ул күршеләреннән утлы күмерне ялан учына салып кына алып чыга икән, дип сөйләгәннәре исемдә калган.*

*Безнең абыйлар исә утны таш гасырдан калган ысул белән дә табалар иде. Ике чакма ташның берсенә мамык бәйлиләр дә ташларны очкын чыгып мамыкка ут эләккәнче бер-берсенә бәреп торалар. Шулай суккалый торгач, Ходай рәхмәте, ниһаять, бер очкын мамыкка килеп эләгә. Малайлар, еш-еш каты итеп өреп торып, мамыкка ут кабызалар. Шуннан учак чырасын үрләтәләр.*

*Ут табуның тагын бер заманчарак ысулыннан да файдаланалар иде. Монысы — җәй көне утны лупа ярдәмендә кояштан алу. Лупаны җиңел янып китәрлек берәр нәрсә өстенә юнәлтеп озак кына тотып торалар да, теге нәрсә әкренләп көйри башлый... Аннан ут учакка күчерелә.*

*Өйдә ут бик кирәк вакытларда гына яндырыла, анда да ярым караңгы җиделе лампа. Керосинга экономия булсын өчен, хатын-кызлар кичләрен бер көнне берсенең өендә, икенче көнне икенчесенекендә җыелып утыралар. Һәркайсының кулында — йон җебе белән бәйләү энәсе: кайсысы бияләй, кайсысы оек-носки бәйли. Сөйләшү, әлбәттә, күбрәк фронттагы хәлләр, аннан килгән хәбәрләр турында: безнекеләр кая барып җиткән, кайсы шәһәрне алган... Аннары соңгы көннәрдә сугыш кырында һәлак булган, яраланган, аяксыз-кулсыз калган авыл ир-егетләрен барлап чыгалар. Ә андыйлар җитәрлек: безнең Кышкар авылыннан фронтка китеп барган 200ләп кешенең яртысы сугыш кырларында мәңгегә ятып калган.*

*Шулай кич утырган әниләр, апалар, үлем хәбәре килгән кешеләр турында сөйләп, кайгырып, елашып, җырлашып алалар. Ул җырларның сагышы, моңы шулкадәр тәэсирле булган: әле дә колагымда яңгырап тора кебек.*

*Апалар безнең өйдә утырган кичне әнине башлап җырлатырга тырышалар иде: «Лотфикамал, әйдә, җырла әле, синең тавышың матур!» Әни җырлый, чыннан да моңлы итеп җырлый иде. Ул чактагы әниләрнең, апаларның җырларындагы моң, сагыш күңелемә гомергә сеңеп калган: мин хәзер дә радио-телевидениедән халык җырларын, бөтен эшемне ташлап, әсәрләнеп тыңлыйм, аеруча моңлы җырлардан күзләремә яшьләр килә.*

*Фронттан килгән шомлы хәбәр безнең йортны да читләтеп узмады. Беркөнне әни, өчпочмаклы хат тотып, елап кайтып керде: «Их, балаларым, ятим калдыгыз бит, әтиегез үлгән ич!» Мин әле ул чакта әнинең бу сүзләреннән безгә никадәр зур фаҗига килгәнлеген аңлап бетермәсәм дә, әнинең кайгыдан бик өзгәләнгәнен күреп, еларга керештем, парланып торган тәрәзә пыяласын бармакларым белән ышкый-ышкый үксеп тордым. Ярый әле безнең бәхет булган: әтинең үлеме турындагы хәбәр ялгыш булып чыкты, берникадәр вакыттан соң аның үзеннән хат*

*килеп төште! Хәл болай булган икән. Безнекеләр һөҗүм иткәндә, әти, каты яраланып, аңсыз ятып калган. Сугыш барган җир немецлар кулына эләккән. Безнең часть командованиесе әтине үлеп калган дип исәпләп, безгә шул турыда хәбәр итеп тә өлгергән. Әмма совет хәрби часте тиздән, контратака ясап, калдырып торырга мәҗбүр булган җирләрне яңадан үзенә кайтара, һәм шунда яраланып яткан безнең әтине дә табып алып, госпитальгә салалар. Бераз хәле рәтләнгәч, әти безгә хат язып җибәрә.*

*Михнәтле көннәр, айлар, еллар уза торды, һәм, ниһаять, сугыш афәте дә бетүгә якынлашты. Без, бер әни кулындагы дүрт малай, ничек җан саклап калганбыздыр, бер әни үзе генә белгәндер инде аны. Сугыш бетәр алдыннанрак кына безнең әти кайтып төште. Ул, яраланып, куллары җәрәхәтләнгәнлектән, җиңү көненнән аз гына иртәрәк кайткан. Аның кайтып керүе шулай исемдә калган: мин иртән, мичкә салам ягып бетереп, идән себереп йөрим. Кинәт өйгә форма кигән бер ир кеше килеп керде. Әнине кочаклап алды. Әни шатлыктан пышык-пышык елый... Шуннан аның безнең әти икәнлеген аңладым, югыйсә, әлбәттә, танымый идем. Без малайлар өчен иң әһәмиятлесе — күчтәнәче бар иде: ялтыравыклы картон тартмада Америка җибәргән шикәр. Безнең аңарчы күрмәгән диярлек ризык.*

*Әти кайтты кайтуын, Аллага шөкер. Әмма безнең тормыш, ул кайтып, тиздән сугыш тәмамлангач та, күп еллар буе, сизелерлек яхшырды, дип әйтерлек булмады әле.*

*Тиңдәшсез сугыштан калган җимереклектән арыну, җәрәхәтләрне төзәтү, тәмам бөлгенлеккә төшкән илне аякка бастыру тиз генә һәм җиңел генә булмагандыр шул.*

*Сугыш вакытын әйтеп торасы да юк инде, сугыштан соңгы елларда да шәһәр халкына да, авыл халкына да бик авыр булды, ләкин авыл кешесенә шәһәрнекеләргә караганда да авырракка туры килгәндер. Авыл тормышын яхшы беләм: үз җилкәмдә татыдым.*

*Совет чорындагы крестьянның хәле патша Россиясенең крепостное право заманындагыга караганда да начаррак иде. Ныклабрак уйлап карасаң, башка сыймаслык изүдә булган авыл халкы. Бер сыер, өч-дүрт сарык яки кәҗә, берәр оя каз, унар тавык тотарга рөхсәт ителде крестьянга. Артыгын ярамый. Әмма иң гаҗәбе шунда: мал-туар, кош-кортның шушы кадәресен асрарга да мөмкинлек юк диярлек иде.*

*Безнең авыл мул җир-сулы түгел: болыннар да, урман, елга-күлләр дә юк. Кечкенә инеш кенә (Симет елгасының башлангычы) бар. Өй салырга агач, ягарга утын табу — мең бәла. Мал асрау өчен, чабарга печән юк. Авыл тирәсендәге бер-ике коры елганың печәненә исәп тотып булмый: алар колхоз маллары өчен.*

*Халык җәфаланып асрады терлеген. Сыер тота алмаган кешеләр дә бар иде. Ә сыерың булмаса, ачка үләргә генә кала. Безнең әниләр басуда утаган чүп үләнен, төйнәп, берничәшәр чакрымнан җилкәләренә салып алып кайталар иде. Ә без энем Әнәс белән, кул арбасы тартып, басу буенча йөреп, межалардагы, басу кырыйларындагы үлән калдыкларын чабып ала торган идек. Аны да, председатель күрмәгәе дип, качып-посып, курка-курка гына алып кайтабыз. Кайбер көннәрне өчәр-дүртәр километр араны узып, икешәр рейс ясый торган идек. Ашау — аертылган сөттән оеткан катык белән бәрәңге генә, ул тиз «төшеп» бетә, эч суырыла. Хәл бетеп, ятып ял итеп алабыз...*

*Кузгалак, акбаш, какы, сәрдә, тагын ниндидер үләннәр белән карынны тутырабыз... Кышын әти-әнинең иң зур хәсрәте: мал-туарны язга — көтү чыкканчыга кадәр исән килеш саклап чыгып булырмы икән, дип борчылу иде, чөнки мең бәла белән әзерләнгән терлек азыгы җәйгә кадәр җитми.*

*Шулай михнәтләнеп асраган малының игелеген күрдеме соң крестьян? Юк шул, бөтен хикмәт тә шунда. Ул чакта авыл халкына зур күләмдә ит, сөт, май, йон, йомырка налогы салалар иде. Шуның өстенә, көчләп, заем алдырталар. Аңа акча кирәк. Налог түләгәннән калган азык-төлекне әти-әниләр базарга алып барып саталар. Җиде кешегә (әти-әни, биш малай: бишенчесе — Мөнир — сугыштан соң туды) кием-салым алу өчен, бары тик шул налог түләүдән калган продуктны сатудан килгән акча гына. Ул акча, әлбәттә, җитми. Шуңа күрә тишелгәнне ямап, беребездән калганны икенчебез киеп яшәдек. Шуның өчен, кием туздырасыз, дип, урамга чыгып уйнау да катгый «лимит» белән — атнага бер тапкыр гына иде; уйнаганда кием дә тизрәк туза, ашарга да күбрәк китә, ди иде әни. Ничек җиткермәк кирәк...*

*Бер кызык һәм кызганыч хәл истә: әни Наил абыйга, казанга салып манып, капчык тукымасыннан чалбар тегеп бирде. Мануы ялгышрак булган, күрәсең: чалбар ала-кола булып чыккан. Абый, әлбәттә инде, мондый ямьсез чалбар кияргә теләми. Әни ачуыннан аны тотып кыйный. Әни мәрхүмә күп төннәрен, йокымсырый-йокымсырый, хан заманындагы Зингер машинасы белән безгә күлмәк-ыштан тегеп, безнең ертыкларны ямап утыра торган иде.*

*Балачагымның (минеке генә түгелдер, әлбәттә) иң ямьсез, иң караңгы көннәре кышларын иде. Мичкә күбесенчә салам ягканлыктан, өй җылынып җитми, салкын, тәрәзәгә боз ката, пыяласыннан эреп аккан су тәрәзә бусагасына аскан шешәгә җыела, аны еш-еш түгеп торабыз. Болай да кечкенә генә тәрәзәләргә тышкы яктан яртылаш такта кагылып, пыяла белән ике арага ашлык кибәге тутырылган, бу, аз булса да, салкыннан саклану өчен шулай эшләнә. Өй көндез дә ярым караңгы, баз кебек. Бердәнбер агач кроватьта әти белән әни йоклый, Әнәс*

*белән мин сәкедә, Равил, Наил абыйлар идәндә. Бераз үсә төшкәч, Әнәс белән мин дә идәнгә төштек: аяклар сәкедән асылынып тора башлады.*

*Ниһаять карлы-буранлы, салкын, караңгы кышлар узып, язгы кояш карый башлагач, тәрәзәләргә каккан такталарны кубарып алгач, без малайлар өчен беренче бәйрәм, зур шатлык була: өй яктыра, кояш төшә. Аннары инде көндезләрен карлар эри башлап, башта кара каргалар, бераздан сыерчыклар килгәч, шатлык тагын да арта. Беренче карганы һәм беренче сыерчыкны күргәч, карга ятып ауныйбыз: йоласы шундый. Яз — яз шул инде ул, балаларда да, олыларда да яшәү дәрте уята, тормышның яхшыруына, яктыруына өмет уты кабыза».*

## ШӘКЕРТ АБЫЙ

1945/46 уку елында Кышкарда Рүзәл яшендәге балаларның берсе дә укырга кермәгән була. Әмма Рүзәлдә уку дәрте уянган була инде. Ул укучы абыйларыннан, аларның китапларыннан укырга-язарга, санарга өйрәнә һәм әти-әнисен, мәктәпкә йөримче, дип йөдәтә башлый. Инде кышкы каникул узган була. Шулай да атасы аның турында мәктәп директоры белән сөйләшә. Ул исә: «Алай теләге зур булгач, йөреп торсын, бераздан сүрелер, туктар, киләсе ел өчен әзерлек булыр», — ди.

Рүзәлгә абыйлары фанердан, кызыл буяуга буяп, сумка ясап бирә. Һәм Рүзәл, фанер сумкасын күтәреп, мәктәпкә юл ала. Беренче класс бүлмәсен табып, иң арттагы бер партага барып утыра. Шулай итеп, ул укучы булып китә. Шул ук елны, беренче классны «дүртле» һәм «бишле» билгеләренә тәмамлап, икенче класска



*Юсуповлар гаиләсе. Уңнан беренче басып тора — Рүзәл, утырганнар — әтисе белән әнисе, сулдан басып тора — Әнәс, уртада — Мөнир, артта — күрше кызлары*

күчә. Уку аның өчен кыен булмый, җидееллык мәктәпне «бишле» билгеләренә генә тәмамлый. Аңа бигрәк тә математика фәннәре — алгебра, геометрия җиңел бирелә. Укытучы Шамил абыйлары Рүзәлнең үзенә генә, өйдә чишеп карау өчен, авыррак саналган мәсьәләләр биреп җибәрә. Малай аларны җиңел генә чишеп килә. Укытучының күңеле була. Ул аны хәтта, җиденче классны тәмамлаганда, классташларының математикадан язма имтихан эшләрен тикшерүдә дә катнаштыра. Соңыннан, күп еллар узып, Рүзәлнең Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәнне белгәч, Шамил абыйсы, ачуланып: «Их Рүзәл, кая кергәнсең, син математик булырга тиеш идең бит!» — ди. Ул үзенчә хаклы булгандыр. Әмма язмыш Рүзәлне икенче юлдан алып киткән шул.

Рүзәл бик истәлекле бинада — 200 елдан артыграк тарихлы данлыклы Кышкар мәдрәсәсенең ике катлы таш мәчете бинасында укый. Бәлки, аңа изге урында белем алуның шифасы тигәндер.

Бу мәчет бинасында бишенче-җиденче классларда республиканың күренекле мәдәният эшлеклесе, Татарстанның халык артисты Габделфәт Сафин, «Таттелеком» берләшмәсенең генераль директоры, запастагы полковник Лотфулла Шәфигуллин һәм башка абруйлы затлар туып үскән Симетбаш авылы балалары да укый. Кышкы карлы-буранлы, шатырдаган суык көннәрне, кар ерып, өч чакрым юл йөреп укый кечкенә малайлар-кызлар. Түзәләр, тырышып укыйлар, юньле кешеләр булып чыгалар.

Рүзәл Юсупов укыган сугыштан соңгы авыл мәктәбендә ул чордагы совет халкының тормышы ачык чагылыш таба. Беренчедән, укучыларның искә төшкәндә йөрәкләрне сыкрандырырлык авыр матди хәле, фәкыйрьлеге. Күбесенең, шул исәптән Рүзәлнең дә, өстендә искергән (ямаулары да була) бишмәт, телогрейка, аякта чабата, кайберәүләрдә генә киез итек. Ашау мәсьәләсе — тагын да зуррак проблема. Һәркайсының диярлек төп ризыгы — бәрәңге. Ипи юк. Укучылар мәктәпкә (5—6 дәрес бит!) тамак ялгарга мичтә тәгәрәтеп пешергән кабыклы бер-ике бәрәңге алып килә.

Рүзәлнең ул еллар турындагы истәлекләреннән:

*«Безнең гаиләдә, мин мәктәпнең соңгы классларында укыганда, угычта уылган бәрәңге кушып ипи пешерә башлаганнар иде инде. Болай ипи салу — үзе бер гыйбрәтле күренеш. Безнең гаилә зур: әти, әни һәм биш малай. Ике олысы Равил белән Наил, унбиш чакрым ераклыктагы Кенәр авылына йөреп, урта мәктәптә укыйлар. Әнәс белән мин — авылдагы җидееллык мәктәптә, төпчек энебез Мөнир әле кечкенә — укымый. Бу кадәр халыкка ипи җиткерү ул чакта җиңел эш түгел иде: колхоз көне буе эшләп ирешкән бер хезмәт көненә көзен дәүләткә тапшырганнан (дәүләткә ашлык тапшыру планын авыл халкына бер грамм икмәк калмаса да*

*үтәү мәҗбүри: үтәмәсәң, башың Себер китәргә мөмкин) һәм чәчүлеккә дип бүлеп калдырганнан соң, елның ничек килүенә һәм хуҗалыкның хәллелек дәрәҗәсенә карап, 300—400 граммнан алып 1әр килограммга кадәр ашлык бирә. Берәр килограммнан биргән колхоз бай хуҗалыклардан санала. Башка бер тиен акча да, бернәрсә дә юк.*

*Менә шушы бер гаиләгә тигән дүрт-биш капчык ашлыкны тегермәндә тарттырып он итеп, ел буена җиткерергә кирәк. Ул чактагы крестьянның, шул исәптән биш балалы Юсуповларның да хәлен менә шуннан аңларга була инде. Шулай булгач, бәрәңге кушып пешергән ипи ашап торырга да бик риза буласың. Җиде кешегә атнага бер мич ипи китә. Аны пешерү өчен, тимерче алачыгында эшләнгән бик зур (кибеттәге гадәти чиләктән ике тапкыр зуррак) ике чиләк бәрәңге уарга кирәк. Угыч калын калайны игәү очы беләнме, юан кадак беләнме тишеп ясалган. Аның тишекләре озын булып тырпаеп торган тешле-тешле. Бер чиләкне Наил уа, икенчесен — Рүзәл. Наил дүрт яшькә олырак һәм, сугышка кадәр шактый алдан туып, мөгаен, тамагы туйганчы ашап, берникадәр үсеп калган булганлыктан, аңа үз чиләгендәге бәрәңгене уу бик үк авыр булмагандыр. Миңа исә — ябык кына кечкенә малайга — ул зур бер чиләк бәрәңгене уу михнәтле шөгыль, үзенә күрә бер җәза иде. Утырып, җайлап кына уарга көч җитмәгәнлектән, миңа тезләнеп яки басып, көчәнеп уарга туры килә. Угычның ыржаеп торган тешләре бармакны тишкәләп бетерә. Бер атна вакыт узып, бармаклар тазарып килгәндә, яңадан ипи салыр вакыт җитә, яңадан иләмсез угычта шыксыз зур бер чиләк бәрәңге уу бәласе килә.*

*Бу, кем өчендер, беренче карашка, вак нәрсә кебек тоеладыр. Әмма мин, бала чагымда үзем кичергән андый «вак-төяк»ләрнең (берничә мисалны алга таба да китерермен әле) артык күп булуын исемә төшереп, шуны әйтәм: ул елларда безнең крестьян тормышында ата-аналарда балаларны кызгану хисе, балага бала итеп карый белү сыйфаты булмаган, булса да бик аз гына булгандыр, дигән нәтиҗәгә киләм. Мин балаларга карата артык кырыслык, каты бәгырьлелекнең ул чактагы тормышның ифрат авыр булуыннан килүен аңлыйм, әлбәттә. Ата-аналарның үзләренә дә бик авыр булганлыгын үзем күреп үстем. Безнең әнинең биш малайны үстерү өчен күргән җәфаларын сөйләп бетерерлек түгел. Бик кызганыч. Кайбер күренешләрне тасвирлап күрсәтермен әле. Әмма шулай да балаларына, тормыш авырлыгын сылтау итеп, рәхимсез булуны, аларны кызгана белмәүне аклавы кыен.*

*Менә йөрәгемдә төер булып утырып калган тагын бер-ике хәл.*

*Уникеме-унөчме яшьләремдә җәйге иртәдә, сәгать дүрт-бишләрдә, әни, мине уятып, кулыма яулыкка төргән бер кадак йон тоттырып, аны сатарга дип, унбиш-уналты чакрымдагы Әтнә базарына җибәрде. Җәяү. Әтнәгә килеп җитәрәк ике-өч чакрымнар кала, бер абзый атына утыртып алып барды. Егерме биш сум-*

*нан сатарга кушты әни. Йонны тотып йөрим базарда. «Күпмедән бирәсең?» — дип сорайлар. «Егерме биш сум», — дим. «Егерме сумнан бир», — диләр. Мин сатмыйм, әлбәттә. Шулай йөри торгач, базар бетә, халык тарала башлады. Мин, егерме биштән алучы булмагач, егерме сумнан биреп җибәрдем йонымны. Җәяүләп авылга кайтып җитеп, акчаны әнигә бирдем. Шуннан соң әнинең кычкырып сүгүе әле дә күз алдымда: «Һай җаным, нәрсә эшләдең?! Йонны суга салгансың икән! Мин бит сиңа егерме биш сумнан сатарга куштым!» Таң тишегеннән торып, унбиш-уналты чакрымдагы базарга җәяүләп барып, егерме биш сум урынына, ул бәядән алучы булмагач, егерме сумга йон сатып кайткан малайны шундый усал итеп сүгәргә кирәк бит!*

*Мин ул чакта үземә карата шундый гаделсез кыланыштан гарьләнеп еладым... Исемә төшкәндә, әле дә йөрәгем авыртып куя».*

Җәй көннәрендә Рүзәл белән Әнәс өстенә төшкән эшләрне санап чыгу да шактый зур урын алыр.

Әниләре, иртән иртүк колхоз эшенә киткәндә, Рүзәлне уятып, эшлисе эшләрне әйтеп калдыра. Савыт-саба юу, идән себерү, ат кузгалагы җыеп кайтып, аны турап, көрпә белән бутап, тавык-казларга әчетке әзерләп ашату, бозауны авыл читенә алып барып арканлап кайту, төшке ашка эти-әниләре эштән кайтуга, бакчадагы бураздан, тамырын өзмичә генә, яшь бәрәңге актарып алып, юып, әрчеп, пешереп, баздан катык алып чыгып, чәй кайнатып, табын әзерләп кую.

Төшке аштан соң, шулай ук бакчадан бәрәңге алу, бозауны алып кайту, көтүне каршы алып, әниләре сыерны саугач, аны авыл кырыена алып чыгып ашатып кайту, чөнки сыерлар көтүдән туеп кайтмый. Кайчак, шулай ук көтүдә туймаганлыктан, сарыклар кайтмый кала, аларны эзләп табып алып кайту да — малайлар бурычы. Язларын абзардан тирес чыгару, зур бакчаны кул белән казып чыгып бәрәңге утырту, аннары бәрәңге тишелгәч, аның чүбен утап, төбенә өю, көзен бәрәңге алу — тагын әллә нинди һәм әллә никадәр эшләр — барысы малайлар өстендә була.

Шул дистәләгән эшләр арасыннан берәрсен, онытып, башкармый калдырсаң, әниләре тарафыннан моның җәзасы җитди була... Кыен күбрәк әниләреннән эләгә. Аңа үпкә саклап та булмый, бу — каһәр төшкән замана галәмәте. Әтиләреннән җәза сирәк эләгә. Шулай да бер тапкыр, ишегалдындагы янгыннан саклану өчен куелган сулы мичкәгә төшеп үлгән бер чеби өчен, әтисе каешы белән яхшы гына сыпыртып ала Рүзәлне. Янәсе, чебине сакламаган. Аның эшләре чеби саклау гына буламы соң?! «Менә шундый гаделсез хөкемнәр йөрәктә кала», — дип искә ала Рүзәл.

Колхозда эш бик кызу чагында, гадәттә, урак өстендә, малайлар кечкенә чактан ук колхоз эшләрендә катнашып киләләр. Атлы эшләр, әлбәттә, аларның күңеленә хуш килә.

*«Иртән иртүк Хафиз абый Әнәс белән миңа (безнең әти дә бригадир, ләкин ул икенче бригадада) эш кушарга керә,* — дип искә ала Рүзәл. *«Берегезгә — Шахтёр, икенчегезгә — Пионер. Бүген эскерткә салам ташырга чыгасыз». Колхоз атларының күбесе ябык: эшләре авыр, ашарларына җитми. Без көррәк, ягъни тазарак ат булсын иде, дип телибез, югыйсә, ябык атка атланып йөргәндә арт шәрәфләр авырта. Әмма безгә, малайларга, яхшы атлар эләкми шул: Шахтёр тазарак, ләкин ялкау, Пионер тырыш, ләкин арык, сырт сөякләре нык чыгып тора. Хәер, без шулары өчен дә шат. Бетмәс-төкәнмәс өй эшләренә караганда, колхоз эше безнең өчен бик кулай инде ул.»*

Төрле эшләр кушалар иде малайларга. Ул елларда комбайннар юк. Ашлыкны хатын-кызлар урак белән урып, көлтәләп бәйлиләр (аны «учма бәйләү» диләр) һәм чүмәләләргә өеп куялар. Ирләр, егетләр һәм малайлар көлтәләрне ат арбасына төяп, кырдан авыл янындагы әвенгә алып кайтып бушаталар. Берничә тапкыр бу эш Рүзәлгә дә эләгә. Арбага биек итеп көлтә төяү җиңел эш түгел, зур осталык таләп итә: көлтәләрне арбаның ике ягына тигез итеп салмасаң, кайтканда олау бер якка янтаеп ава. Бер тапкыр мондый «гөнаһ» Рүзәлдә дә була: кайтканда олавы авып төшә, кечкенәрәк була шул әле, дөрес төямәгән, күрәсең.

Соңга табарак ашлыкны ат тартып йөри торган ургыч-лабогрейка белән урдыра башлыйлар. Теземнәрдәге игенне, көлтәләр итеп бәйләп, чүмәләгә өю, аннары әвенгә кайтару элеккечә үк башкарыла.

Әвендәге ашлыкны сугыш елларында дүрт ат тартып йөреп әйләндерә торган «пиравать» (привод) ярдәмендә хәрәкәткә китерелгән машина белән суктыралар. Түгәрәк буенча чыбыркы белән атларны куып йөртү орчык башы кадәрле малайлар вазифасы була. Рүзәлнең колхозда эшли башлаган иң беренче эше шуннан гыйбарәт. Ул чакта әле укырга да кермәгән була.

Аннары Рүзәлләрише «чебеш малайлар» өчен тагын бер «җиңел» эш була ул чакта. Колхозның фермалары искергән, стеналары ишелеп төшә бара. Яңартырга кирәк, ләкин кирпеч тә, агач та юк. Саман кирпечтән стена салырга булалар. Аны җәйнең кояшлы эссе көннәрендә сугалар. Моның өчен, унбиш-егерме метрлы радиуслы түгәрәк ясап, кызыл балчыкның өске катламын казып, йомшартып чыгалар, шуңа ваклаган салам салалар да су сибеп җебетәләр. Түгәрәкнең эченә бер кечкенә малайны атландырган ат кертеп, салам белән балчыкны катнаштырып издерәләр. Малай, йөгән белән идарә итеп, атны түгәрәк буенча тегендә-монда йөртеп, балчыкны таптата. Берничә мәртәбә мондый эшне башкарырга Рүзәлгә дә насыйп була.

Аннан әвендә ашлык суктырганнан чыккан саламны чүмәләгә өеп, ат белән эскерт салучыларга ташу. Көндезге һәм төнге ат көтүенә чыгулар да, башка төр-

ле эшләр дә башкарырга туры килә. Шулай итеп, Рүзәл ундүрт яшенә кадәр, җиденче классны тәмамлап, техникумга укырга киткәнче, өчәр ай җәйләрен колхоз эшләрендә катнашып йөри. Бу, сүз дә юк, яхшы тормыш мәктәбе була.

*«Минем балачагым, мәктәп еллары гел эштән, укудан гына тормады, әлбәттә,* — дип сөйли Рүзәл Юсупов. — *Аз гына булса да, күңелле, шатлыклы мизгелләр дә бар иде. Көзләрен инеш өстендәге бозда коньки, кышларын тауда чана шуу, чабатага яки киез итеккә өйдә ясалган калын авыр чаңгы киеп, кырга «куян куарга» чыгулар җанга зур рәхәтлек бирә иде. Җәйләрен эштән бушап торган сирәк кенә вакытларда инештә су коену, балык тоту безнең өчен зур хозур иде. Балык дигәне ташбаш кына инде, билгеле. Ләкин аның чиртүләре, эләккәч, аны тартып чыгарулары ни тора! Вак балыкны, баш-койрыкларын өзеп тормыйча гына, табада кыздырып аласың. Безгә, гел ашыйсы килеп йөргән балаларга, ул «деликатес» иде инде.*

*Без бала чакта да, үсеп җиткәч тә, хәзерге кебек, ай саен, атна саен өчәр-дүртәр көн бәйрәм булып тормады: җигелеп эшләргә, халык хуҗалыгын, илне аякка бастырырга, тормышны яхшыртырга кирәк иде. Октябрь бәйрәме, май бәйрәме һәм татарлар өчен иң зур, иң олы бәйрәм — сабан туе булды. Яңа ел башлануны да хәзерге кебек дәррәү кубып бәйрәм итмәделәр. Аны, нигездә, укучылар өчен мәктәп оештыра иде. Клубка чыршы куялар, без, укучылар, аны кәгазьдән уенчыклар ясап бизибез. Беренче январь көнне анда ата-аналары белән бергә укучы балаларны җыялар. Башта мәктәп директоры беренче яртыеллык укуга йомгак ясап китә, яхшы укучыларны мактап, начар укыганнарны «чеметеп» телгә ала. Алдынгыларны дәфтәр, каләм, карандаш кебек әйберләр белән бүләклиләр. Мактаулылар һәм бүләкләнүчеләр арасында һәр елны Рүзәл Юсупов та була торган иде.*

*Уку турында сүз чыккач, балачак белән бәйләнешле бу хикәятемнең башында, ул чордагы яшәү рухы мәктәп тормышында да чагыла иде, дигән фикеремне төгәлләп куйыйм әле.*

*Без үскәндә, укыганда, эшләгәндә, зур авырлыкларга карамастан, халыкның рухы күтәренке, яшәү дәрте көчле иде. Менә ул безнең ярым ач, ертык, тишекле, ямаулы кием кигән килеш укуыбызны, укытучыларның, балаларга тиешле белемне бирик дип, чын күңелдән укытуын, авыл халкының ачлы-туклы килеш бушка диярлек иртә таңнан караңгы төнгә кадәр җиң сызганып эшләвен алыйк — барлык кеше булсын дип эшләде, иртәгәсе көнгә өмет белән яшәде. Без, балалар, тырышып укыдык, заманы өчен ярыйсы ук белем алдык. Укытучылар да, югары белемле булмасалар да, безгә тиешле белемне бирделәр. Безнең кечкенә генә авыл мәктәбендә белем алып чыккан балалар, соңыннан техникум, институтларда укып, кирәкле белгечләр булдылар, илгә, халыкка намус белән хезмәт иттеләр. Кышкар авылы-*

*ның, Жданов колхозының алга баруын, ныгуын, кешеләрнең тормышы елдан-ел яхшыруын күреп, белеп тордым. Хәзер укуда да, укытуда да, җитештерү эшендә һәм башка төрле хезмәт өлкәсендә дә ул вакыттагы кебек үк бирелеп, яхшы булсын дип эшләү, киләчәккә зур өмет белән яшәү юк.*

*Халыкка яшәү рухы өстәп, безнең кырыс балачагыбызны ямьләндереп җибәргән бәйрәм ул, әлбәттә, Сабантуй иде. Мин Әтнә янындагы Каенсар дигән кечкенә генә урман аланлыгында уза торган районыбыз Сабантуен бик бәләкәйдән үк хәтерлим. Дәһшәтле сугыш елларында да үткәрә иделәр булса кирәк аны. Әмма минем әле дә күз алдымда торганнары — сугыштан соңгы еллардагылары.*

*Без, малайлар, Сабантуйга әзерлекне бер айлар кала ук башлый идек. Үзебез җигеп барасы атка, конюх биргәнгә өстәп, печән бирәбез яки аны авыл читенә алып чыгып, чирәмле җир табып ашатабыз. Максат — атны тазартып, көрәйтеп, Сабантуйга Каенсарга узышып барганда алга чыгу. Сабантуйга бару да көрәш рухында уза. Йөгән, шлеяләргә тәңкәләр, чуклар тагып, атларыбызны матуррак итеп бизәргә тырышабыз.*

*Каенсар урманы безнең авылга сигез-тугыз чакрымнар ераклыкта. Без кечкенә чакта әти-әниләр белән, үсә төшкәч, ат арбаларына малайлар-кызлар аерым төялеп, юл буенча җырлашып, шаярышып-көлешеп барабыз.*

*Каенсарга барып җитәрәк бер чакрымнар кала Иске Мәңгәр дигән авыл урнашкан. Матур урында, бай тарихлы авыл. Россиянең эчке эшләр министры, армия генералы Рәшит Нургалиевнең әтисе Гомәр абзый туган авыл. Ә миңа ул безнең әни туып үскән, әби-бабабыз яшәгән авыл буларак кадерле. Җәләлетдин бабай бик әйбәт, сабыр, тыныч холыклы кеше иде. Тишелгән киез итекләребез астына калын олтан тегеп бирүче ул булды. Каенсарга барышлый, атларыбызны бабайларга кертеп тугарып, Сабантуйга иркенләп җәяү генә барып җитә торган идек. Бабай атларыбызны ашатып-эчертеп, карап тора.*

*Әбиебез дөнья бәһасе кеше — бик тә уңган, юмарт карчык иде. Җәен Күшәр болынындагы куаклыкка төшеп, күп итеп шифалы үләннәр җыеп куя да ел буена авыл халкын шул үләннәр белән төрле авырулардан дәвалый, им-том итә. Әби безгә кунакка килсә, без аларга барсак, безнең өчен бәйрәм була. Изге кешеләр иде, урыннары оҗмахта булсын.*

*Сугыштан соңгы Сабантуй шатлыклы да, сагышлы да, үзенә күрә бер төрле гаҗәеп күренеш булып исемдә калган. Шатлыгы аңлашыла инде: мәйдан тирәсендә җыр-биюләр, гармун уйнаулар, ат чабышлары.... «Сагышлы» диюем менә шул: ул чакта агач протез аяклы, кулсыз сугыш инвалидлары күп иде. Шуның өстенә, минем күңелгә бигрәк тә сеңеп калганы: ирләре, сөйгән егетләре сугыш кырларында ятып калган хатын-кызларның, өзгәләнеп елый-елый, үтә дә*

*моңлы җырлар җырлап утырулары... Ул җырлардагы сагыш моңнары әле дә күңелем түрендә.*

*Үткәннәрне искә алып яза һәм сөйли башласаң, балачак хатирәләре өермә булып күңелдә яңара. Михнәт-җәфалы булса да, минем балалык чорым, туган авылымда үткән 14 ел гомерем йөрәгемдә мәңге җуелмас якты-сагышлы хисләр булып сакланып калды.*

*Ниһаять, мәктәп еллары артта калды. Җиде классны тәмамлау таныклыгы кулда. Билгеләр «бишле» генә. Ләкин ниндидер сәбәп белән мактау грамотасы бирелми калган. Сигезенче класста бездән унбиш-уналты чакрым ары Әтнә мәктәбенә яки шундый ук ераклыктагы Яңа Кенәр мәктәбенә йөреп укырга кирәк. Безнең класстан өч малай Казандагы һөнәр училищесына укырга керде. Матди яктан бик әйбәт инде анда: ашаталар, киендерәләр, бушлай тулай торакта яшәтәләр. Нәрсә кирәк тагын, ул еллар өчен оҗмах! Укы, өйрән, квалификацияле һөнәр иясе буласың. Ләкин минем максат икенче — техникумга кереп уку. Мәктәпне «бишле»гә генә тәмамлаган кеше буларак, мин теләсә кайсы техникумга, мәсәлән, ул чакта абруйлылардан саналган Казан авиация техникумына, Казан механика-технология техникумына укырга керә ала идем. Ләкин, кулымда мактау грамотасы булмау сәбәпле, техникумга имтихансыз кабул итмәделәр. Ә имтиханнарны русча бирергә кирәк. Саф татар авылында яшәп, татарча укыган малайның, русча имтиханнар биреп, конкурстан уза алуы бик шикле. Мәктәп секретареның озак вакыт авылда булмавы аркасында, мин мактау грамотасын соң алдым. Шулай да, бәхетемне сынап карарга дип, Казанга юл тоттым. Энеләрем Әнәс белән Мөнир: «Сау бул, шәкерт абый, Казанда укырга кергәч, безне онытма!» — дип озатып калдылар».*

## ТҮЗӘРГӘ, ЧИГЕНМӘСКӘ

Рүзәл өчен бик җитди дәвер — малайлыктан егетлеккә күчү, мөстәкыйль яшәргә өйрәнү, белгечлек алу, яңа авырлыклар кичерү һәм кыенлыкларга бирешмәскә өйрәнү чоры була бу.

Рүзәлләр өч елда урта мәктәп программасын үзләштереп, белгечлеккә караган «товароведение промышленных товаров», «товароведение продовольственных товаров», «бухгалтерский учёт», «планирование», «политэкономия» кебек фәннәрне өйрәнеп, икенче һәм өченче курсларда Красный бор сельпосында һәм Азнакай райпотребсоюзында ай ярымшар практика да узалар. Һәр елны кышкы һәм җәйге сессияләрнең имтиханнарын тапшырасы. Уку рус телендә, дәресләр һәр көнне алтышар-җидешәр сәгать. Шуның өстенә, татар мәктәпләрен тәмамлап килгән дүрт

укучы өчен, шул исәптән Рүзәл өчен дә, ел буена һәр атнаны рус теленнән икешәр-өчәр өстәмә дәрес үткәрелеп килә: тизрәк яхшы итеп русча өйрәнергә кирәк була.

Уку шартлары кырыс, белем алуга таләпләр югары. Өч елдан Рүзәл кебек малай-шалайларны, урта махсус белемле белгеч итеп, Россиянең теләсә кайсы өлкәсенә җитди эшкә җибәрәчәкләр бит. Техникумның тулай торагы юк: читтән килгәннәр, үзләре табып, квартирда торалар. Ул чордагы яшәү шартлары турында Рүзәл Юсупов менә ничек яза:

*«Бердәнбер яшәү чыганагы — стипендия. Авылдан, өйдән бернинди дә ярдәм юк: андагыларның үзләренең дә хәлләре мөшкел. Стипендияне, һәр тиененә кадәр исәпләп, бер айга бүлеп куясың. Туклану болайрак: иртән — маргарин яккан ипи белән чәй, көндез — техникум ашханәсендә итсез аш, итсез ботка һәм чәй (ипине өстәлгә бушлай куялар иде, рәхмәт яугырлары!), кич — яңадан маргарин яккан ипи һәм чәй. Шуңа өстәп нәрсәдер алырга акча калмый. Кайчакта авылдан берәр кадак (бер кечкенә түгәрәк) атланмай җибәрәләр. Квартир хуҗалары аш, бәрәңге кебек ризык пешереп ашаганда, борынга тәмле ис кереп, кәефне боза. Үземдә бәрәңге һәм итсез генә булса да аш пешереп ашау уе булмаган, бәлки, рөхсәт тә итмәгәннәрдер. Соңыннан, күп еллар үткәч, шул вакытлар исемә төшеп, гаҗәпләнеп куя торган идем: нишләп әти-әни берме-яртымы капчык кына булса да бәрәңге китереп куймагандыр, Казанга бер дә килми тормыйлар иде, югыйсә.*

*Стипендияне җиңел генә бирмиләр. Аның өчен кышкы һәм җәйге сессияләрдә дүрт-биш имтиханның барысын да «дүртле» һәм «бишле» билгеләренә генә тапшырырга кирәк. Бер генә фәннән «өчле» алсаң да («икеле» турында сүз дә булырга мөмкин түгел инде), семестр (ярты ел) буена стипендия ала алмыйсың.*

*Бер тапкыр андый драматик хәл миндә дә булды. Беренче курсның кышкы сессиясендә рус теленнән имтиханны «өчле»гә бирдем. Дүрт-биш ай гына элек татар мәктәбен тәмамлап, русча сөйләшергә өйрәнеп кенә килгән чак бит әле. «Өчле» алганга да «молодец!» дияргә кирәк булгандыр, бәлки, рус теле укытучысы Тамара Лазаревнага, аванс белән «дүртле» куйса да, гөнаһ булмаган булыр иде, югыйсә. Шул бер балл аркасында минем яшәү чыганагыннан мәхрүм ителүемне аңларга кирәк иде аңа. Таләпнең, катылыкның да чиге буладыр, ләбаса. Ярый әле әти ул ярты елда, такы-токы гына булса да, азык-төлек җибәргәләп торды. Ничектер очны-очка ялгап чыкканмын ул елны. Шөкер, аннан ары мондый хәл булмады: «дүртле»-«бишле»гә генә укыдым, техникумны тәмамлап чыкканда, дүрт дәүләт имтиханының берсен генә «дүртле»гә, өчесен «бишле»гә тапшырдым.*

*Техникумда каты режимда уку шулкадәр чыныктырган: хәтта миңа соңыннан, шактый еллар узгач, университета гел «бишле»гә уку да техникумдагыга караганда җиңелрәк тоелды. Без бу техникумда ел ярымда урта мәктәп програм-*

*масын нигездә узып бетереп, имтиханнар тапшырдык. Хәер, рус телен өч курс беткәнче укыдык. Һәм беренче семестр сессиясендә рус теленнән миңа «өчле» куйгач бик ачуым чыккан булса да, соңыннан мин Тамара Лазаревна Чудновскаяга рәхмәтле булдым. Ул рус телен шундый итеп өйрәтте: мин бу фәннән алган белемнәремнән гомерем буе уңышлы файдаландым, хәтта СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институтында рус-татар телләре буенча докторлык диссертациясе якларга насыйп булды. «Бер рәхәтнең бер михнәте» дигән әйтемне, киregә әйләндереп, «Бер михнәтнең бер рәхәте» дип әйтү дә дөрес булыр иде. Техникумда укуның җәфалары, имтихан биргәндә «өчле» генә булмаса ярар иде, дип куркып йөрүләр бушка китмәде, соңыннан тормышымда файдасы тиеп торды.*

*Безнең техникумның тулай торагы булмаса да, квартир хуҗаларына аена җитмешәр сум акча түләп тордылар. Бу безнең өчен зур ярдәм иде, әлбәттә.*

*Минем квартирда яшәвемнең тарихы да гыйбрәтле, һәм монда ул чактагы Казан халкының тормышы ачык чагыла.*

*Беренче елны, әйтеп үткәнемчә, Казанга килгәч тә мине үзләренә сыендырган Зөләйха апалар өендә яшәдем. Уртача зурлыктагы агач йорт. Аның аерым ишекле бер бүлмәсендә хатыны белән бер рус милиционеры яши. Калган өлешенең тактамы-фанермы белән бүлеп алган бер почмагында даими рәвештә өч кыз (квартирда) тора (Дөбьяз районыннан килеп мех фабрикасында эшлиләр). Кыш көне Битаманнан килеп ат белән сезонлы эштә эшләүче ике ир кеше дә яшәде. Шулай ук кышын вакытлыча Кавказдан алма сатарга килгән азәрбәйҗан кешесе торды (алмасын поезд белән алып килә дә Зөләйха апаның сараенда тота, шуннан алып-алып, базарга чыгарып сата). Шуның өстенә, кайбер төннәрне, Казанга нәрсәдер сатарга килгән, башка барыр урыннары булмаган авыл кешеләре йоклап кала. Зөләйха апа үзе һәм мәктәптә укый торган ике баласы бар. Мин икенче сменада укыганлыктан, соң гына кайтам да, идәндә тезелешеп яткан кешеләрне аралап кереп, үземә берәр буш урын табып, шунда урнашам.*

*Хуҗа ханымның Отары, Победилово авылларыннан төрле яшелчә сатарга килгән таныш урыс-марҗалары Зөләйха апаның ишегалдына көндезләрен атларын куеп торалар. Кайчак ул атлар астын җыештыру вазифасы миңа да йөкләнә торган иде.*

*Зөләйха апаның хәле җиңел түгел. Аның ялгыз башына төшкән йөк, — өйдәге мәктәп яшендәге улы белән кызыннан тыш, Свияжски төрмәсендә утырган ире белән кызы. Ул айга бер тапкырмы, бер-ике ай саенмы, азык-төлек төяп, шунда барып кайта, шуларга ярдәм итеп тора иде.*

*Төрмә мәсьәләсе гаҗәпләнерлек хәл түгел. Ул елларда мин белгән кадәресе: төрмәдә күп кеше утырган. Мәсәлән, мин аннан соң яшәгән ике квартирның да*

*берәр кешеләре төрмәдә утыра иде. Сәбәбе бар, әлбәттә. Ул чакта вак-төяк өчен дә төрмәгә утыртканнар. Сугышта әсирлеккә эләгеп, егерме бишәр елга утыртылганнар да шактый күп иде.*

*Мин техникумда укыган елларда куркыныч хәлләр, ямьсез күренешләр турында шактый күп ишетеп торырга туры килде. Хулиганлык, урлау, кеше үтерү кебек җинаятьләр, Сталин үлеп, хөкүмәт җитәкчесе итеп Маленков куелуы уңае белән амнистия булганнан соң, бигрәк тә күбәйде, чөнки күп кенә җинаятьчеләр, иреккә чыккач, элек кылган кара эшләренә яңадан керешкәннәр. Төнлә йөрү куркыныч иде. Минем белән бергә квартирда торган апалар, икенче сменадан эштән кайтканда, өченче сменага эшкә барганда бик куркып, берничә кеше бергәләшеп кенә йөрделәр. Кешеләрнең ишегалларында кибәргә элгән җирдән керләрен җыеп алып китәләр иде хәтта. Кечке Арча поездыннан төшеп минем янга килгәндә, бер тапкыр безнең әнинең дә миңа дигән күчтәнәчләрен талап алып калганнар иде.*

*Казан малайлары арасында хулиганлык еш таралган күренеш иде. Кичен укудан кайтышлый, минем үземә тик торганда малайлар белән «сибешергә» туры килгәләде. «Сибешү» — аларча, сугышу. «Пахан» (әти), «махан» (әни), «дохан» (акча), «дүкәш» (ике сум), «сикәш» (өч сум) кебек жаргон сүзләре дә бар иде аларның.*

*Без укый башлаганда, кооперация техникумының үз бинасы булмады: беренче елны Кабан күле буендагы Комсомольская (хәзерге Мәрҗани) урамында урнашкан җиңел промышленность техникумы бинасында укып тордык. Алар — беренче, без икенче сменада. Уку кичке сәгать сигез-тугызларда бетә.*

*Монда укыганда истә калган вакыйга — Сталин үлеме. Бик зур кайгы дип хәбәр иттеләр. Безне актлар залына җыеп, речьләр сөйләделәр. Укытучылардан елаучылар да булды. Без, укучылар, бик борчылдык дип әйтә алмыйм. Илгә яңа җитәкчеләр (Маленков һәм башкалар) килгәч, шатлыклы вакыйгалар булгалап торды: берничә мәртәбә әйберләргә бәяләрне киметтеләр. Авыл кешеләре өчен тагын да шатлыклы вакыйга Хрущёв җитәкчелек иткән чорда булды: үзәккә үткән авыл хуҗалыгы продуктларына налогны, мәҗбүри займ түләү системасын бетерделәр, тагын ниндидер уңайлыклар булдырылды. Авыл халкына паспорт бирү тәртибе кертелде, һәм авыл кешеләре иркенрәк сулыш ала башлады. Шәһәр халкы өчен дә яхшылыклар эшләнде. Мәсәлән, берничә елда тиз темплар белән күп кенә панельле йортлар төзеп, торыр урыны булмаган күп меңнәрчә кешеләрне фатирлы иттеләр. Югыйсә, ул елларда шәһәр кешеләренең торак шартлары бик начар иде: коммуналь квартирларда бер бүлмәдә унар кеше, хәтта подвалларда яшәделәр. Өченче курста укыганда бер ел миңа да подвалда яшәргә туры килде.*



*Кооперация техникумының беренче курсын тәмамлаганнан соң. 1953 ел, Казан.*
*Беренче рәттә уртада — Рүзәл*

*Һәр эшне дә эшли башлау авыр була. Безнең укуда да шулай — беренче ел бигрәк тә авыр булды. Русча начар белү, дөресрәге, белмәү үзәккә үтте. Беренче курсны тәмамлаганда, ярыйсы ук сукалый башлаган идем бугай инде. Җәйге имтиханнар сессиясен «дүртле» һәм «бишле» билгеләре белән тәмамладым. Димәк, стипендия булачак. Алда — каникул, өйдә торасы. Җәй айлары стипендиясенә үземә арзанлы гына байка тукымадан спорт костюмы сатып алдым, өйгә күчтәнәчләр алдым. Шатлык зур. Үзебезнең группа укучылары белән, Кольцодан өстәрәк урнашкан Эрмитаж бакчасына кереп, карточкага (фотога) төштек. Миңа да бераз адәм төсе керә башлаган кебек тоелды. Югыйсә, укырга килгәндә бигрәк йолкыш малай идем.*

*Җәйге каникул вакытында берникадәр колхозга булыштым, Әнәс белән өй эшләрен эшләдек. Бераз гына ял да эләккәндер инде, шәт. Иң әһәмиятлесе: минем инициатива буенча, малайлар белән кул арбалары, тачкалар, носилкалар ярдәмендә балчык, иске салам, чыбык-чабык ташып, үзебезнең бәрәңге бакчасы астындагы инеш суында шактый зур буа будык. Су күбәйде, кайдандыр тагараклар табып алып килеп, аларны көймә итеп йөрдек...*

*Зөләйха апаларда кешеләр бик күп булганлыктан, икенче елны тору урынын үзгәртергә булдым. Бәхет елмайды: Каюм Насыйри урамының Татарстан урамына җитәрәк ике катлы агач йорттагы квартирларның берсендә торучы Нәҗия апа мине үзенә сыендырды. Күркәм, мөлаем, йомшак итеп кенә сөйләшә иде. Вафат инде. Урыны җәннәттә булсын. Ике улы, бер кызы бар. Иркен генә квартир такта белән өчкә бүленгән. Бер кечкенә бүлмә — Нәҗия апаның каенанасыныкы. Бер бүлмәдә хуҗа хатын үзе. Өченчесендә — балалар. Шунда минем кроватька да урын таптылар. Коридор ишегеннән кергәч тә, бер почмакта — тар гына ашарга пешерү, ашау-эчү, юыну урыны.*

*Колхоз базарындагы квартирдан соң бу минем өчен бик яхшы иде инде. Уллары да минем чама: Рафаэль — миннән ике яшькә генә олырак, Шамил — бер яшькә кечерәк. Рафаэль — рус мәктәбендә, Шамил татар мәктәбендә укый. Акыллы, тыйнак малайлар. Мине үз иттеләр. Дуслар булып яшәдек. Сеңелләре Әлфия әле кечкенә, укырга йөрми. Ул да миңа абыйлары кебек якын итеп карый.*

*Нәҗия апа, үзенең сөйләве буенча, еракта — Соцгородтагы китап кибетендә эшли. Үкенечле хәл: ире төрмәдә. Ничек эләккән булгандыр, белмим. Нәҗия апа, яратып, хөрмәт белән сөйли иде аның турында. Тиздән чыгарырга тиешләр, дип әйтә иде, көтте. Кыскасы, мин укуымның икенче елында, ашау-эчүнең генә такы-токы булуын исәпкә алмаганда, ярыйсы гына яшәдем.*

*Нәҗия апаларда торганда, минем тормыш кызыклырак, мәгънәлерәк булып китте. Рафаэль, Шамил һәм күрше малайлары мине үз компанияләренә алдылар. Бергә киноларга, катокларга йөргәлибез. Ул вакытта ярлы гаиләдәге балаларга яшәү өчен мөмкинлекләр булдыру күздә тотылган иде. Фәкыйрьлек чоры булса да, халык өчен бушлай спорт түгәрәкләре, секцияләре эшләде, прокатка спорт инвентаре, коньки, чаңгы кебек нәрсәләр, спорт костюмнары биреп тордылар. Безнең техникумда да бар иде мондый тәртип. Казанда шәһәр үзәгендә — Черек күлдә, Динамо стадионында, Спартак стадионында, тагын кайлардадыр катоклар эшләп торды. Билет бәяләре арзан гына. Дөрес, безнең андыйларын алырга да акчабыз юк: катокның коймасыннан үрмәләп менеп сикереп төшәбез. Кайчакта, төшкәндә, милиционерлар тотып алып, арт якка бер-ике тапкыр кундырып, куып чыгарып җибәрәләр. Без, үпкәләмичә генә, икенче урыннан тагын килеп керәбез. Шул кышны мин, шактый кызыклы фигуралар ясап, артка таба шуарга өйрәндем. Бер-ике мәртәбә хәтта, күрше кызлары белән барып, парлашып та шуып кайттым. Рәхәт була, матур, нәфис хисләр туа. Егет булырга җыена башлаган булганмын, күрәсең...*

*Сирәк булса да киноларга баргаладык. Бу мәсьәләдә дә җае чыкты. Мех комбинаты, сабын заводының, механика заводының үз эшчеләре өчен клублары*

*бар, шунда бик арзанлы-символик кына бәядән кино күрсәтәләр. Без дә шунда йөрибез.*

*Җәй көннәрендә инде халыкны үзенә Кабан күле чакыра. Аһ, ул вакытта андагы күңеллелекләр, рәхәтлекләр! Кабан күленең шәһәр үзәгендәге өлешендә ике як ярда берничә көймә станциясе эшли. Безнең Рафаэль байдарка, җилкәнле көймә спорты белән шөгыльләнә, кайчакта үзе белән Шамилне һәм мине дә ала, җилкәнле көймәдә йөреп кайтабыз.*

*Күл өстендә — күп санлы ишкәкле, җилкәнле көймәләр, байдаркалар. Яр буенда, хәзерге Академия театры урынында хатын-кызлар кер чайкыйлар, малайлар балык тоталар, су коеналар. Инеш суында чыпырдап кына ятып өйрәнгән малай — мин дә, батыраеп, Кабан күленең бер ягыннан икенче ягына йөзеп чыгып, аннан кире йөзеп, су коенырга өйрәндем. Су чиста. Шулай данлыклы Кабан җәй көне Казан халкының ял итә, хозурлана торган урыны иде. Кыш көнендә исә анда чаңгы шуалар, ярышлар уздыралар. Кабан күле ул — безнең кыйммәтле хәзинә. Без аннан акыллы итеп файдалана гына белмибез. Чит илләрдә шәһәр уртасында андый күл булса, аңа табыналар, аны йөзек кашы кебек кадерләп тоталар.*

*Бу урында шуны искәртеп китү мәгъкуль булыр. Мин яшәгән Каюм Насыйри урамы Иске татар бистәсенә керә, ягъни ул — күп йөзләрчә еллар татарлар яшәгән урын. Шул чын татар рухы мин анда торганда нык сакланган иде әле: Болакның, Кабан күленең бу ягында нигездә татарлар яши, һәм алар, шул исәптән яшьләр, балалар да, һәркайсы рәхәтләнеп, руслар булганда да тартынмыйча, саф татарча сөйләшә. 80нче, 12нче һәм тагын берничә мәктәптә барлык фәннәрне дә татарча укыталар. Гомумән, милли рух татарларның бөтен яшәешендә ачык чагылып торды. Анда яшәгән рус балалары да татар малайлары белән татарча шактый иркен сөйләшә иде. Үзенчә яшәү ул тирәдәге топонимика исемнәрендә дә күренеп тора. Мәсәлән, Тукай урамындагы Тукай кинотеатрын (хәзер ул урында «Бәхетле» кибете) Чаткы кинотеатры дип йөртәләр иде.*

*Кызык кына туры килү хәлләре була бит тормышта. Мине язмыш нәкъ ярты гасырдан соң, гаиләм белән, элек техникумда укыганда торган урынга — Каюм Насыйри урамы тирәсенә күчеп килеп яши башларга дучар итте. Хәзер мин шул тирәдәге урамнардан узганда һәрчак дулкынлану хисләре кичерәм, ул вакыттагы элекке татар архитектурасы буенча салынган йортларны исемә төшерәм. Үкенечле хәл: хәзер инде аларның күбесен юкка чыгарып өлгерделәр. Каюм Насыйри урамындагы мин торган ике катлы матур агач йорт та юк инде. Аның урынында — таштан салынган бойлер бинасы. Бездә тарихи истәлекләрне кадерләп саклау сәләте зәгыйфь шул.*

*Шулай да минем өчен кадерле бер бина саклангaн. Ул — Мәрҗани урамындагы иске стильдә төзелгән дүрт катлы зур, матур таш йорт. Анда хәзер дә җиңел промышленность өчен урта махсус белемле белгечләр әзерлиләр. Моннан егерме еллар элек аның фасадын бик матур фирүзә төсенә буяп куйдылар. Шуннан үрнәк алып, ректор булып эшләгәндә, мин дә Казан педагогика университетының барлык биналарын фирүзә төсенә буяткан идем. Шәһәргә ямь биреп тордылар. Казан башлыгы Камил Исхаков та: «Болак тирәсендә иң матур биналар сезнеке», — дип мактап алган иде. Инде Исхаков та мэр түгел, Юсупов та ректор түгел, элекке пединститутны да бетерделәр, аннан калган биналар да матур төстә түгел.*

*Казанның моннан алтмыш еллар элек булган рәвеше бик нык үзгәрде, шәһәр шактый төзекләндерелде, күп яңа йортлар пәйда булды. Әмма элекке мохит, милли рух — татар рухы да шактый нык югалды. Хәзер шәһәрдә, Иске татар бистәсендә дә урамнарда, җәмәгать урыннарында татарча сөйләшкән кешене очрату кыен, татар мәктәбе дип саналган берничә генә мәктәптә дә уку-укыту нигездә рус телендә бара.*

*Мин кайткан-киткәндә урамда, әһә, татарча сөйләшүчеләр бар икән әле, дип шатланып куйсам, азәрбәйҗанча сөйләшәләр булып чыга. Алар хәзер безнең шәһәрдә шактый (без яшәгән микрорайонда аеруча күп), алар үз телләрендә иркен сөйләшә. Афәрин, әзәриләр! Безгә, татарларга, үзебезчә сөйләшергә алардан үрнәк алырга кирәк.*

*...Өченче курска күчеп укый башлагач, минем Нәҗия апалардагы күңелле тормышым өзелде, ашка таракан төште. «Таракан» бу очракта минем Наил абый булды. Ул, авылдан килеп, ун класс белеме белән кайсыдыр техник уку йортына укырга керде һәм минем янда тора башлады, тулай торaклары булмагандыр, ахрысы. Хуҗа хатын каршы килергә базмадымы, әллә аз булса да өстәмә акча булыр дипме, каршы килмәде. Минем тимер челтәрле бер кешелек кроватьны өстенә фанер куеп киңәйтеп, икебез шунда йокладык. Кысан булды, әлбәттә. Абый бит, куып чыгарып булмый.*

*Шулай бер-ике ай яшәгәч, Нәҗия апа көннәрдән бер көнне болай ди: «Рүзәл энем, мин сине яраттым, балалар да үз иттеләр. Ләкин Заман абыең (ире — Р.Ю.), тиздән кайтырмын инде, дип язган. Ул кайтканда җиткән егет Наилнең бездә яшәп ятуын ошатмас. Үзең генә булсаң, сүз юк, әмма абыең белән бергә тота алмыйм». Бик үкенеч, әмма берни дә эшләп булмый. Абый, үзем генә чыгып китәм, димәде. Бергәләп икенче тору урыны эзләргә керештек. Квартир табу җиңел булмады. Эзли-эзли, хәерчеләр, тагын әллә нинди кешеләр яши торган бүлмәләргә килеп эләгеп беттек. Ниһаять, йөри торгач, Островский урамында*

*элекке республика ДАИсе янындагы бер янкорма квартирга килеп кердек. Шунда торырга ризалык алдык.*

*Бу — ишегалдындагы төп йортка өстәп салган, уртача зурлыктагы ярымподвал бер бүлмә-квартир иде. Такта белән урталай бүленгән. Бер ягында әби белән бабай — хуҗа хатын Зифа апаның кайнанасы белән кайнатасы. Өйдән чыгып йөрмиләр. Әби өй эчендә генә йөри, бабай исә урыныннан бөтенләй тормый. Бөтен хаҗәтләрен урынында гына башкара. Зифа апа үзе дә авыру, өйдән чыгып йөрерлек хәлдә түгел. Аның буй җиткән ике улы бар. Мәктәпкә барсалар баралар, бармасалар юк. Олысы йорт күгәрченнәре тота, ничә карасаң, тышта шулар янында.*

*Өйдә тагын Дөбьяз районыннан ике җиткән кыз тора: Роза белән Рушания. Кайсыдыр фабрикада эшлиләр. Һәм шулар өстенә Наил белән Рүзәл килеп кушылды. Кечкенә генә бер торакта тугыз кеше. Ул вакытларда болай яшәү гадәти күренеш иде дисәң дә ялгыш булмастыр.*

*Өйнең кечкенәлеге әле бер хәл. Башка кыен яклары да бар иде шул. Ярым караңгы: җиде кеше яши торган бүлмә тәрәзәсенең яртысыннан гына якты төшә. Ишек ике катлы: берсен ачканда — икенчесе ябык, икенчесен ачканда беренчесе ябык була. Шулай итеп, тыштан һава ишек ачканда да керә алмый. Форточканы ачу юк: өйдә авырулар. Ишектән килеп керүгә, тын кысыла, буыласың, тынчу.*

*Менә шундый шартларда яшәргә туры килде миңа укуымның өченче елында. Монда Нажҗия апалардагыдан гына түгел, Зөләйха апалардагыдан да начаррак иде.*

*Хәер, берникадәр вакыттан Наил абыйны армиягә алып киттеләр. Әмма соң иде инде, мин укып бетергәнче шул квартирда торып калдым: гел күчеп йөреп булмый бит.*

*Ниһаять, техникум чоры да узып китте. Дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, бик кыланмыйча гына чыгарылыш кичәсе уздырып, товаровед дипломын кесәгә салып, эшкә китәргә әзерләнә башладык».*

## СЕБЕР КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ

Рүзәл Курган өлкәсе потребсоюзына юллама ала. Ул вакытларда урта махсус һәм югары уку йортларын тәмамлаган яшьләргә билгеләнгән урында кимендә өч ел эшләү мәҗбүри була. Тегенди-мондый сылтау табып китми калу уе башына да килми егетнең.

Арча станциясе аша уза торган поездга утырып, Курган шәһәренә юл тота яшь

товаровед. Өстә — шактый киелгән арзанлы гына костюм (кыйммәтлесе кайдан килсен!), куртка, пальто кебек нәрсә юк, иске чемоданда — әнисе биргән мендәр.

Августның егермеләре. Иртәнге якта Курган вокзалында поездадан төшә Рүзәл. Чемоданын тотып, вокзал каршындагы мәйданга чыгып баса. Тирә-юньгә күз салып, берничә минут хисләргә чумып басып тора. Менә ул тарихи мизгел! Әле моннан өч ел гына элек кечерәк кенә бер татар авылы мәктәбен тәмамлап, өч ел Казан шулпасын ашап, товаровед дигән җитди эш эшләргә ниятләнеп, күз күрмәгән, колак ишетмәгән калага килеп төшсен әле унҗиде яше дә тулмаган малай-егет! Алданиләр көтә аны?! Ниләр күрәсе бардыр аның башкайлары?!

Сорашып-белешеп, Курган облпотребсоюзын эзләп таба Рүзәл. Кадрлар бүлеге начальнигына керә. Путёвканы алып укыгач, начальник беравык аңа сәерсенеп карап тора. «Ничек эшләр икән бу малай?» — дип уйлап торгандыр, мөгаен. «Эшлисе урыныңны ачыклаганчы, бераз көтеп торырга туры килер», — ди. Аның «бераз» дигәне ике көн була. Ике төнне бер эш бүлмәсендәге өстәл өстендә черем итеп чыга яшь кадр.

Һәм, ниһаять, начальник чакырып ала да Рүзәлгә аның булачак эш урынын игълан итә: «Син иң интернациональ районда эшләячәксең, анда, руслардан тыш, казахлар да, украиннар, молдаваннар, немецлар, татарлар да, башка төрле милләт вәкилләре дә яши». «Ярый, миңа барыбер», — ди Рүзәл. Эшлисе урын Усть-Уйский дигән район, административ үзәге Ново-Кочердык авылы була.

Шумиха дигән кечкенә генә шәһәргә кадәр поезд белән барасы, аннан калган юлны — машина белән. Ул вакытта җиңел автомобильләргә утырып йөрү дигән нәрсә юк, йөк машинасының кузовына утырып бара ул. Ново-Кочердык — Шумихадан йөз дә ун километр. Килеп җитә. Эшлисе райпотребсоюзга килеп керә. Ял көне була, шунлыктан анда бер генә кеше, соңыннан билгеле булганча, райпотребсоюз председателе урынбасары — завторг Анатолий Александрович Катаев кына була. Юсуповның киләсен әйтеп, Курганнан шалтыратып куйганнар булса кирәк. Рүзәл, исәнләшеп, кем икәнлеген әйткәч, завторг елмаеп: «Бигрәк яшь товаровед икәнсең», — дип куя. Руслар: «Молодость — не порок», — дисәләр дә, товаровед булып эшләү өчен «порок»лы була шул әле егет ул чакта. Унҗидесе дә тулып җитмәгән, ә товар белән, матди әйберләр белән эш итү закон буенча унсигез яшькә кадәр рөхсәт тә ителми. Ләкин бу турыда уйлап торучы булмый, Рүзәл Юсупов Усть-Уйский райпотребсоюзының товароведы булып эшкә керешә.

Бу район — Чиләбе, Свердлов өлкәләре һәм Казахстанның Кустанай (хәзер Целиноград булса кирәк) өлкәсе белән чиктәш Көнбатыш Себернең бер төбәге. Элек Себер казаклары яшәгән Ново-Кочердык авылына район үзәге, бик чиктә урнашкан булганлыктан, ул киләсе елны гына казак станицасы Усть-Уйкадан күчерелгән

булган. Район үзенә күрә бер сөрген урыны булган, дисәң дә ялгыш түгелдер. Югарыда әйтеп үтелгән милләт вәкилләренең кайберләре, мәсәлән, немецлар Идел буеннан күчереп утыртылган, украиннар, молдаваннар — Ватан сугышы алдыннан ватаннарыннан сөрелгән кешеләр. Татарлар бу районда бик аз гына, казахлар шулай ук, Казахстан чигендә булганлыктан, бер-ике авыл гына була. Усть-Уйка — урман-сулы, зур, матур, бай авыл. Ново-Кочердык исә бар яктан да аннан калыша. Хәер, бу яклары Рүзәл өчен бик әһәмиятле булмый. Аны борчып торган нәрсә — алда торган билгесез, җаваплы эш.



*Рүзәл — товаровед.*
*Курган өлкәсе, 1956 ел*

Товаровед эше, кыскача гына сурәтләгәндә, менә нiләрдән гыйбарәт була.

Шумихадагы районара базасыннан (межрайбаза), Кургандагы универсаль базадан (универбаза) һәм башка поставщиклардан килгән һәм райпотребсоюз үзе барып алып кайткан товарларны (промышленность товарларын — халык өчен кирәкле бар нәрсәне дә) һәм азык-төлек товарларын, райпотребсоюз складларында счет-фактуралар буенча склад мөдире һәм упаковщик белән бергә тикшереп, җитмәгән, ватык, бозылган әйберләр булса, аларга акт төзеп, аны тиешле кешеләргә, шул исәптән район башкарма комитеты вәкиленә кул куйдырып, поставщикка, ягъни товар җибәргән оешмага, предприятиегә дәгъва документы (претензия) әзерләп җибәрү. Поставщик, җитмәгән, ватык һәм бозылган товарга райпотребсоюзның дәгъвасын хаклы дип тапса, аны канәгатьләндерә — тиешле товарны җибәрә яки акча күчерә, дәгъва белән килешмәсә, сәүдә оешмасы таләп иткән товарны бирүдән яки акча күчерүдән баш тарта. Андый очракта мәсьәлә суд аша хәл ителә. Бу эш — күләмле һәм четерекле: район зур, товар күп килә.

Товаровед складка кабул итеп алган товарны, разнарядка төзеп, районның сельпо һәм совхозрабкооп дигән сәүдә оешмаларына җибәрүне оештыруда катнаша һәм товарның, складка кабул ителеп, ул оешмаларга җибәрелүе өчен җавап бирә.

Болары — даими эшләр. Аннары Рүзәлне, вакыт-вакыт, сельполарның, аларга караган кибетләрнең эше белән танышып, андагы сатып алучыларның товарга

булган ихтыяҗын, ягъни нәрсәләр кирәклеген өйрәнеп, белеп кайту өчен авылларга җибәрәләр. Кайчакта аңа йөк машиналары белән Шумихадан, Курганнан һәм башка шәһәр-районнардан күп итеп — миллионнарча сумлык товар алып кайту эшен йөклиләр. Башка төрле эшләр дә була. Шунда булган бер-ике драматик хәл турында сөйләп китик.

Яшь белгечкә башта өч яшәү мәсьәләсен: ягъни тору, ашау-эчү, кием-салым мәшәкатьләрен хәл итү белән шөгыльләнеп алырга туры килә.

Тору өчен «тулай торак» дип аталган барак тибындагы озынча агач йорттан бер бүлмә бирәләр. Утын яга торган миче бар. Башка бернәрсә дә юк: өстәл дә, урындык та, кровать та, урын-җир дә, савыт-саба да — берни дә, бары тик буш бүлмә. Менә шулай тереклек итә башлый Рүзәл. Кайлардандыр өстәл-урындык, иске тимер кровать, тагын вак-төякне юнәтә. Ул йортта гаиләле кешеләр дә, мәсәлән, бер Себер татары белән молдаван хатыны яши. Алар да, яшь егетне кызганып, кайбер вак-төяк кирәк-яракларны бирәләр. Ә менә юрган белән матрасны Рүзәл үзе юнәтә. Складта бер-ике урыннан ертылган одеял белән матрас күреп ала да (ертык әйберне сатуга куеп булмый бит инде!) аларны үзе акт төзеп списать итә һәм, алып кайтып ямап куеп, әйбәт кенә урын-җирле була. Әнисе биреп җибәргән мендәре бар бит инде. Шулай итеп, йокларга урын-җир хәстәрли.

Хәзер өс киеме проблемасы килеп туа. Сентябрь аенда салкынайта башлый. Ә егетнең өстенә кияренә юк, кием алырлык акчасы да юк. Хезмәт хакын алдан биреп торуларын сорап, райпотребсоюз председателе янына керә. Бирми, юньсез. Ярый әле дөньяда игелекле кешеләр дә бар: баш бухгалтер аның проблемасын белеп алган да, үзе чакырып алып, берникадәр акча яздырып (аванс итеп) бирә. Рүзәл шул акчага телогрейка белән кирзовый итек сатып ала. Шулай итеп, монысы да хәл ителә. Хәзер инде өйне (бүлмәне) җылыту мәсьәләсе алга килеп баса. Җан биргәнгә юнь бирә, диләр. Райпотребсоюзда Равил исемле җирле татар егете эшли икән. Шуңа мөрәҗәгать итә. Ул ярдәм итә, рәхмәт төшкере. Пычкы алып, аның белән урманга утын әзерләргә китәләр. Ул якларда урманнар күп. Берничә каен агачын кисеп аударып ваклап куялар да, Равил машина алып килеп, агачларны төяп алып кайталар. Шулай итеп утынлы да була Рүзәл.

Ашау-эчү ялгыз яшь егетнең бик мактанырлык була алмый инде ул. Үзе аш-бәрәңгеләр дә пешергәли, ашханәгә барып та ашаштыргалый, коры-сары белән чәй эчеп тә йөри. Шулай да техникумда укыгандагы кебек булмый инде: 600 сум хезмәт хакы ала бит. Чагыштыру өчен: ул вакытта инженерларның окладлары 800—900 сумнардан башлана торган була.

Кыш кергәч, Шумихадан товар алып кайтканда, буран күмеп киткән юлларда сәгатьләр буенча өшеп утырган чаклары да була Рүзәлнең. Әмма моннан да кыенрак бер психологик киеренке эш йөкләнә аңа.

Өлкә потребсоюзыннан, барлык районнарда да махсус белемнәре булмаган кибетчеләр өчен (ә андыйлар, әлбәттә, күп була), райпотребсоюзлардагы урта махсус белемле белгечләр көче белән, күпмедер сәгатьлек курслар оештырырга, дигән күрсәтмә килә. Усть-Уйка райпотребсоюзы председателе Н.И.Калугин үзендәге техникум тәмамлаган белгечләргә, кибетчеләргә тиешле курс программасы буенча дәресләр уздыру өчен, сельполар бүлеп чыга. Техникум дипломлы кеше буларак, Р.Юсуповка да өлеш чыга, әлбәттә. Ул район үзәгеннән утыз километр ераклыкта урнашкан (Көнбатыш Себердә авыллар бер-берсеннән ерак урнашкан) Матвеевка сельпосына караган авыллар кибетчеләренә, атна саен бер тапкыр барып, дәресләр уздырып кайтырга тиеш була. Менә сиңа мә! Әле кайчан гына рәтләп русча да сөйләшә белмәгән унҗиде яшьлек татар егете (малай дисәң дә була) үзеннән ике-өч тапкыр олырак рус хатыннарына сәүдә итү теориясе буенча сабак бирергә тиеш! *«Минем өчен моннан да авыррак задание булмагандыр, мөгаен,* — дип искә ала Р.Юсупов ул хәлләрне. — *Башыңа төшкәч, башмакчы буласың, диләр. Бу дәресләр, безнең төп эшкә зыян килмәсен өчен, ял көннәрендә үткәрелергә тиеш иде. Аллага тапшырып, үзем чанага ат җигеп, беренче дәресемә Матвеевка авылына юл тоттым. Искә төшерсәм, хәзер үзем дә шаккатам. Кыюлык күбрәк булгандырмы ул чакта миндә, әллә тыңлаучанлыкмы, әллә икесе дә ме?! Барып җиттем сельпога. Күрәм: атлы чаналарга утырып, төрле авыллардан уннан артык хатын-кыз килгән. Исәнләштек, таныштык. Максатны аңлаттым. Һәм эшкә керештем. Минем өчен бу хәзер дә җиңел эш булмас иде. Ә ул чакта! Бер сәгатьләп утырганбыздыр, ниләр сөйләгәнмендер мин аларга, ничек уздырганмындыр ул вакытны! Ул уңайсызлануларым, ул оялуларым минем анда! Хәзер моны искә төшерү — куркыныч төшне хәтердә яңарту белән бер. Хәер, мин, үземчә, ниндидер китаплар табып укып, техникумда алган белемемнән аз булса да файдаланып, күпмедер әзерләнеп килгән идем. Әмма барыбер бик авыр булды минем өчен, чын экзекуция, билләһи әгәр. Шулай җәфаланып тагын ике-өч дәрес үткәрдем дә, ничектер шуның белән тәмамланды ул минем кибетчеләр укыту одиссеясе, шөкер».*

Ел ярымнар эшләү дәверендә Ново-Кочердыкта яшь белгечнең башына төшкән сынаулар шактый күп була. Шуларның бер-икесен — кофе белән чүпрә кыйссаларын бәян итеп китик.

Март аеның икенче яртыларында булса кирәк, Рүзәлне Шумиха межрайбазасына товарлар алырга җибәрәләр. Райпотребсоюзның үз машиналары товарны базалардан алып кайту һәм сельполарга тарату өчен җитми. Шумихага берәр машина белән барып, шундаУсть-Уйка районының станциягә йөк алып килеп бушаткан машиналарын тотып, шофёрларны «кодалап» дигәндәй базага алып килеп, шундагы төрле складлардан төрле-төрле — энәдән камытка кадәр — товар төяп, райпотребсоюзга озатырга туры килә. Кайбер шофёрлар, машиналары буш кайтмасын өчен,

базага үзләре килеп чыгалар. Кайбер көннәрне, төрле складлардан төяп, дистәгә якын машина товар җибәрә Рүзәл. Машинадагы ящик, капчык, пакет исәбен күрсәтеп накладной яза да, шофёрга кабул итеп алганлыкка кул куйдырып, машинаны кайтарып җибәрә. Шофёр товарны шул накладной буенча райпотребсоюзга кайтарып, склад мөдиренә тапшыра.

Товаровед берүзе. Грузчик юк. Алдан яздырып алган счёт-фактура буенча товарны тикшереп, санап алу да, машинага төяү дә үзенә. Кайчак кайбер шофёрлар, аны кызганып булса кирәк, булышалар, ләкин бу һәрчак булмый. Кайбер шофёрлар бик тупас кыланалар, тизрәк ал, тизрәк төя, дип кычкыралар, акыралар, сүгенәләр... Ниндидер бер татар малае кем инде ул алар өчен?! Тәрбиясез кешеләр күп бит кайда да.

Рүзәл шулай берничә көн үзе Шумихада торып райпотребсоюзга шактый күп товар җибәргәч, кайтып, шофёрлар кайтарып калдырган товарны счёт-фактуралар буенча тикшереп, санап, склад мөдиренә тапшыра. Бер тапкыр, базадан төрле товарлар төяп озатканда, накладнойга биш ящик кофены, ялгышып, язмый калдыра. Шофёрлар, гадәттә товарны санап, төпченеп тормыйлар, склад мөдиренә путёвкаларына товарны китергәнлеккә кул куйдыралар да китеп баралар. Бу юлы да шулай булган. Склад мөдире накладнойда язылмаган кофены складның кеше тапмаслык почмагына яшереп куйган, ә Рүзәл, кайтып, товарларның барысын да счёт-фактура буенча тапшыра башлагач, анда күрсәтелгән кофе юк булып чыга. Склад мөдире: «Мин алмадым, машинада башка әйберләр арасында кофе юк иде», — ди. Аның берничә меңлек суммасын Рүзәл түләргә тиеш була. Ул, мәсьәләне аңлап алып, автохуҗалыкка барып, кофены алып кайткан шофёрны табып, аны складка бушатып калдырганлыгын раслата. Исендә калдырган булган, рәхмәт яугыры, хәзер склад мөдире янына барып, кофе салган ящикларның хәтта машина кузовының кайсы урынында торганлыгын әйтеп бирәм, ди ул. Рүзәл райпотребсоюз председателеннән, комиссия төзеп, бик тиз генә складтагы барлык әйберләрне тикшереп чыгуларын таләп итә: «Кофе складта, тапсыннар», — ди. Аның кискен сөйләшүе нәтиҗәсез калмый, склад мөдире бераздан: «Кофе табылды, аны кичә генә теге шофёр китереп китте», — ди. Ялганлый, әлбәттә. Кофе башта ук шунда булган, склад мөдире, Рүзәлнең ялгышуыннан файдаланып, аны үзләштереп калырга уйлаган булган.

Чүпрә вакыйгасы. Март урталарында Рүзәл межрайбазадан районга бер машина чүпрә төяп җибәрә. Үзе калып, тагын берничә көн товарлар җибәреп тора. Кайтып, райпотребсоюз складына барып керсә, ул җибәргән чүпрә ящикларында җебеп утыра, идән буйлап агып киткән. Ничә мең сумлык, халык өчен бик кыйммәтле дефицит әйбер әрәм булган. Сәбәбе: склад мөдире, аны тиз генә сельполарга җибәрәсе урында, ваемсызланып йөргән, вакытны уздырган. Ул арада көннәр

кинәт кенә җылынып китә дә, менә шундый хәл килеп чыга. Ул чакта складта суыткычлар булмагандыр, күрәсең.

Бозылган, ватылган товарга акт төзү товаровед вазифаларына керә, диелгән иде. Рүзәл җебегән чүпрәгә акт төзеп, тиешле кешеләрдән, шул исәптән җирле власть — район башкарма комитеты вәкиленнән дә кул куйдыра. Сәбәбен, дөресен әйтеп, чүпрә көннәр җылынгач, складта озак торып бозылган, дип күрсәтә. Андый очракларда зыян күргән товар суммасын списать итәләр. Бу юлы да шулай булыр дип уйлап йөри Рүзәл, борчылмый. Чүпрәнең бозылуында аның гаебе юк: ул базадан алып җибәргән көнне әле салкын, температура минус була. Әмма хәлләр ул уйлаганча килеп чыкмый.

Бу вакыйгадан соң бер-ике айлар узгач, Рүзәл, ниндидер эш белән барып, Курган шәһәреннән кайтып кына төшкән көнне, бухгалтериядә эшләүче бер ханым аңа шундый хәбәр җиткерә: райпотребсоюз председателе теге «бозылган чүпрәнең бәясен Юсуповтан түләтергә» дигән карар чыгарган. Ә ул сумманы түләр өчен, Рүзәлгә дүрт-биш ай бушка эшләргә кирәк булачак. Чит җирдә берүзе яшәп, тырышып эшләп йөргән егеткә гаепсезгә ни өчен шундый рәхимсез җәза бирергә кирәк булган икән? Кешенең канын эчүдән тәм таба торган бәндәләр була шул, Рүзәлгә үз гомерендә андыйларның зәхмәтен берничә мәртәбә татырга туры килә әле.

Райпотребсоюзда андый «материаль җитешсезлек»не кире кайтаруның өч юлы була: яки тиешле сумманы райпотребсоюз кассасына кертәсең (ә андый акча Рүзәлдә юк), яки хезмәт хакыңны тотып баралар (аның моңа ризалыгы юк), яки ул сумманы халык суды карары белән тартып алалар.

Рүзәл проблеманы үзенчә (суд ярдәме белән) хәл итү юлына керешә. Метеорология хезмәте учреждениесеннән базадан чүпрә алып җибәргән көннең температурасы турында документ соратып алдыра. Аның чүпрә төяп ятуын шул вакытта Шумиха межрайбазасына ниндидер эш белән килеп чыккан райпотребсоюз председателенең урынбасары Анатолий Александрович Катаев белән Рүзәлгә утын әзерләшкән Равил карап киткән булалар. Алар чүпрәнең яхшы сыйфатлы икәнлеген күрәләр. Рүзәл алардан бу күренешкә шаһит булуларын үтенә. Тегеләр риза булалар.

Суд утырышына җыелалар. Гадәти процедура. Түрдә — биеклектәге үз урында судья ханым. Ике ягында — халык утырышчылары. Залда дәгъва белдерүче (истец) якның вәкиле — райпотребсоюзның баш бухгалтеры, җавап бирүче (ответчик) товаровед, шаһитләр һәм тагын бер-ике кеше.

Судта гомум кабул ителгән тәртип буенча, судья башта дәгъва белдерүченең судка мөрәҗәгате — эшнең асылы белән таныштырып чыга. Аннары дәгъва белдергән як вәкиленә сүз бирә. Баш бухгалтер судка мөрәҗәгатьне бәян итә. Шуннан соң судья Рүзәлгә тиешле сорауларын бирә. Исем-фамилиясен, туган елын, кем бу-

лып эшләвен сорый. Рүзәл туган елын һәм эшен әйткәч, судья, елмаеп: «Бигрәк яшь товаровед икән», — дип куя. Хөкемдар шундый ягымлы сүз әйткәч, Рүзәлнең эченә җылы керә, күңелендә суд карарының аның файдасына буласына өмет уты көчәя.

Сораулардан соң судья җавап бирүчегә карала торган мәсьәлә буенча аңлатма бирергә куша. Рүзәл кыскача гына эшнең асылын сөйләп бирә, үзенең гаебе юк икәнлеген исбатларга тырыша. Ул сөйләгәндә судья шаһитләргә залдан чыгып торырга куша. Аның сөйләвеннән соң шаһитләрне чакырып кертә һәм судта карала торган мәсьәлә буенча фикерләрен белдерү өчен, башта Катаевка, аннан Равилгә сүз бирә. Менә бит ул, бер якта — гаепсез кешене гаепле итеп, аңа җәза бирдерергә омтылучы явыз җаннар, икенче якта — бәлагә тарган кешегә, үзенә авырлык алып булса да, ярдәм кулын сузучы кешеләр: бер якта — вампир Калугин, икенче якта — шәфкатьле җан Катаев. *«Анатолий Александровичның, кызып-кызып, мине яклап сөйләве бүген дә, алтмыш ел үткәннән соң да, күз алдыма килеп, колагыма ишетелеп тора сыман»*, — ди Рүзәл, ул елларны искә алып. «Бу мәсьәләдә Юсупов түгел, Калугин үзе гаепле, тиешле сумманы аннан түләтергә кирәк», — ди Катаев, нәфрәтләнеп. Гаделлек өчен үзен аямый торган катгый принципиаль кешеләр дә бар шул: председатель урынбасары, гаделсезлек белән килешеп тора алмаганлыктан, бернинди дә шәхси мәнфәгатьләре булмаса да, үзенең начальнигына каршы чыга, аны намуссызлыкта гаепли. Менә ул чын кешелекле кеше!

Катаевтан соң чыгыш ясап, икенче шаһит Равил дә бу эштә Рүзәлнең гаебе булмауны исбатларга тырыша. Милләттәшен яклап чыга.

Шаһитләрнең чыгышларыннан соң, судья халык утырышчылары белән киңәшләшергә эчке бүлмәгә кереп китә. Озак тормыйлар. Яшь товаровед өчен җәфалы минутлар була алар. Кем белә? Алла сакласын: «түләргә» дигән карар чыгарсалар, нишләрсең?! Аллага шөкер, бу юлы гаделлек җиңә: судья, залга чыгып, карарын игълан итә: «Суд райпотребсоюзның Рүзәл Юсуповка дәгъвасын нигезсез дип таба һәм кире кага». Менә ул шатлык!

Соңрак, еллар үтеп, бераз акылы-белеме арткач, Рүзәл шуңа төшенә: аңа суд оештыру, алай гына түгел, аның өстенә миллионнарча сумлык матди җаваплылык йөкләү үзе үк законсыз гамәл булган. Аңа әле ул чакта унҗиде яшь кенә бит: балигъылыкка да җитмәгән булган икән.

Курганда эшләү дәверендә Рүзәлне тагын берничә тапкыр алдарга маташып караулар һәм аңа карата башка төрле гаделсезлек гамәлләре кылу очраклары була. Әмма шунысы бәхәссез: мөстәкыйль яшәү, эшләү тәҗрибәсе кырыс шартларда узса да, ул анда җитди чыныгу ала. Аның гомерендәге Курган чоры алдагы тормышы өчен ныклы нигез салырга ярдәм итә.

Алда Рүзәлне икенче бер кырыс тормыш — армия тормышы көтә.

## ӘФГАН ЧИГЕНДӘ

Менә атнадан артык инде Рүзәл юлда, товар поездында. Хәрби хезмәт урынына китеп барышы. Вагонда эссе, бөркү, шакшылык, йоклау өчен урын-җир кебек нәрсә бирмиләр, өч катлы сәндәрәнең коры тактасында аунап барырга туры килә. Сугыш вакыты түгел бит, булачак солдатларны пассажир поездында алып барырга да мөмкин иде, югыйсә. Совет хакимиятендә кеше турында кайгырту дигән нәрсә юк шул, солдат турында бигрәк тә.

Хәрби комиссариатта комиссия үткәндә, кайсы гаскәрдә хезмәт итәчәге белән кызыксынган иде Рүзәл. «Кавалерист булачаксың», — диләр аңа. Хәзерге заманда техника җитәрлек бит: танклар да, самолётлар да, артиллерия дисеңме… Солдатны атка атландырып йөртүнең нигә кирәге бар икән? Авыл малае булуын белеп шаяртканнардыр, бәлки. Бала чагында атка күп атланып йөрде инде ул. Дәү абыйсы Равил армиядә хезмәт итеп кайтты, әмма кавалерия турында телгә алганы булмады. Кече абыйсы Наил Ерак Көнчыгышта флотта хезмәт итте. Хәзер менә эстафетаны абыйларыннан Рүзәл кабул итеп алды. Аның хәрби хезмәт чоры башлана. Ул да сынатмас. Юсуповлар нәселе сыната торганнардан түгел.

Юл газабы — гүр газабы, диләр. Дөрес сүз бу. Казахстан, Үзбәкстан җирләрен узганда коточкыч бөркү була. Ашарга коры паёк кына бирелә. Вагонда юыну, туалетка чыгу урыннары юк. Поезд туктаган арада, егетләр кайда урын таба шунда йөгерә. Станцияләрдә, паровоз гидрантларын ачып, салкын су белән юынып алалар. Поезд бераз бара да тупикка кереп туктый. Кайчак яртышар көн тора.

Казаннан чыгып китеп, унике көн узгач, ниһаять, состав Кыргызстанның Ош шәһәренә килеп туктый. Юлның поезд белән барасы өлеше шунда тәмамлана. Хәзер инде Таҗикстанның Таулы Бадахшан автономияле өлкәсенең административ үзәге Хорог шәһәренә кадәр машинада барырга кирәк: хәрби хезмәтне шунда үтәргә туры киләчәк икән.

Булачак солдатларга иске туннар, иләмсез калын, зур киез итекләр тараталар. Машиналарга утырырга команда бирелгәч, рекрутлар, берсен-берсе этә-төртә, машиналарга мөмкин кадәр алгарак менеп урнашалар. Элек-электән сабыр, әдәп саклап, башкаларга юл куярга, каударланмаска гадәтләнгән Рүзәлгә урын кузовның иң артында гына эләгә. Машинада утыргычлар юк: кем чүгәләп, кем кырын ятып бара. Җитмәсә, машина төтене арттан кузовка тула, башны әйләндерә, укшыта.

Ош-Хорог юлы дөньяда иң биек трассалардан санала. Ул Памир тауларыннан уза: тау сыртлары аша, серпантин булып, әле өскә менә һәм кинәт кенә аска төшә. Тау-ташны чокып ясалган бормалы-сырмалы юл дүрт-биш километр биеклектәге тау сыртларыннан бара. Кузов брезент белән капланган, һава җитми. Әле август

ае гына булса да, тауларда салкын, урыны-урыны белән кар төшкәләп тора. Тукталышларда юлның як-ягында убылган каберләр, кеше сөякләре күренеп тора — басмачылар белән сугыш истәлекләре.

Ике ярым тәүлектә биек таулар арасыннан 838 километр юл узыла. Беренче төнне, 1944 елда туган җирләреннән сөрелгән чеченнар авылында туктап, рекрутлар машиналарында аякларын бөкләп я чүгәләп утырган килеш төн уздыралар. Чечен халкының язмышы — гаделсезлекнең ачык мисалы. Сталин әмере белән, тулы бер милләт туган җиреннән куып җибәрелә, СССРның яшәү өчен уңайсыз булган төрле почмакларына таратыла. Күбесе юлда үлеп кала. Миңа, Мәскәүдә телевидение хезмәткәрләренең белемен күтәрү институтында укыганда, Чечен-Ингушетия республикасы телевидениесенең баш мөхәррире Җәмлихан Хасбулатов белән бер ай буе бергә яшәргә туры килде. Ул миңа гаиләләренең Төньяк Казахстанга куылуы, ничек кимсетелүләре турында елый-елый сөйли иде. Шунысы игътибарга лаек: Җәмлиханның бертуган энесе Руслан Имран улы Хасбулатов соңрак Россиянең Югары Советын җитәкләде. Миңа, Мәскәүдә укып йөргәндә, Җәмлихан белән бергә Русланның фатирында берничә тапкыр булырга туры килде. Аның халыкара мөнәсәбәтләр институтында докторлык диссертациясе яклап йөргән вакыты иде. Шуннан соң күп тә үтмәде, ул депутат булып сайланды.

Чечен халкын кимсетү, мәсхәрәләү соңрак та дәвам итте әле. Халык кулына корал алырга мәҗбүр булды. Чечняда кан коюлы сугыш күп елларга сузылды.

Чечен авылында төн кунганда булган бер маҗара турында сөйләгән иде миңа Рүзәл:

*«Безнең автомобиль эшелонында, Татарстаннан килә торган төркем белән бергә, йомшак «г» авазы белән сөйләшә торган Наволочка, Жуйборода кебек кызык фамилияле Кубань, Краснодар тирәләрендәге русларлмы, әллә Көнчыгыш Украинадан килгән украиннармы баралар иде. Кич, караңгы төшеп, без төн кунарга туктагач, шул рус-украин төркеменнән берничә егет авыл клубы янында җирле чечен егетләре белән бәйләнешеп, бәргәләшеп алганнар. Низагка кергән егетләр, машиналардагы рекрутлар янына йөгереп килеп, безгә, «солдатларга кул күтәрделәр!» дип, кычкырып аваз салдылар. Шуннан мәхшәр башланып китте. Барлык рекрутлар, машиналарыннан сикерешеп төшеп, дәррәү авыл клубына таба чабалар. Безнең машинадагылар да, тавышлар ишетеп, шунда китте. Клуб тирәсендә халык мәш килә, шаулаша, кычкырыша, бәргәләшә. Ул арада рекрутлар клубка бәреп керәләр. Сәхнәдә борынгы милли киемнәр киенгән һәвәскәр артистлар (спектакль куеп яткан булганнардыр) чыр-чу килә. Күрәсең, ярсыган рекрутлар аларга да һөҗүм иткәннәр. Анда нәрсә булганлыгын аңларлык түгел иде. Кыскасы, безнең, булачак солдатларның, шундый ямьсез хулиганлык күренеше булып алды.*

*Ярый әле ул арада тиз генә безне озата баручы солдатлар һәм офицерлар килеп җитеп, тәртип утнаштырдылар, рекрутларны машиналарына алып киттеләр. Без дә үзебезнең машина кузовына менеп кунакладык, туныбыз якасы эченә башыбызны тыгып, чүгәләп утырып төн кундык».*

Ниһаять, рекрутлар эшелоны, зур җәфалар чигеп, Таулы Бадахшан милли өлкәсенең административ үзәгенә — сигез мең кешелек Хорог шәһәренә килеп җитә. Монда Урта Азия чик буе округының Хорог отряды урнашкан. Рүзәлләр шушында өч ай буе чик сакчыларының әзерлек курсын узачак. Хорог бер яктан җиде-сигез километр биеклектәге Ленин пигы дип аталган, икенче яктан шундый ук биеклектәге Коммунизм пигы дип йөртелә торган таулар арасында өч километр биеклектә утыра. Кояш көндезге сәгать ун-унберләрдә генә күренә дә кичке дүрт-бишләрдә тау артына кереп югала. Җир ташлы, дөресрәге җир үзе күренми дә диярлек, һәркайда таш та таш. Шулай да берникадәр яшеллек бар: таулар арасындагы тар гына үзәнлекләрдә көньяк агачлары күренә, таштан чистартып, үгез җигеп, бер төрәнле сука белән сукалап ясалган түтәлләрдә үсемлекләр үсә. Бер як тау битендә чик буе отряды урнашкан.

Килеп җитеп, машиналардан төшкәч тә, егетләрнең чәчләрен машинка белән кырып алалар, өсләрендәге гражданский киемнәрне — күбесенең иске-моски кемнәрен салдырып, ярым суык мунчага кертәләр. Ике атна буе, юынмыйча, юлда килгәннән соң, анысы да ярап тора. Мунчадан чыгуга чик буе солдаты формасы бирәләр. Ул форма армия формасыннан берникадәр аерыла: фуражка, панама һәм яшел төстәге погоннар, яловый итек (калын күннән тегелгән), гимнастёрка өстеннән ат шлеясе кебегрәк итеп тасмадан эшләнгән кылыч тагу өчен җайланма һәм кылыч үзе. Рекрутларны монда шушы отрядка кергән чик буе заставаларында хезмәт итү өчен әзерлиләр. Заставалар дүртәр-бишәр километр биеклектәге тауларда урнашкан. Ә анда чикне саклаганда атка атланып йөриләр. Шуның өчен яшь солдатларга кавалерист формасы белән шпага бирәләр һәм һәркайсына берәр ат беркетеп чыгалар. Әзерлек курсы вакытында, атарга өйрәнү, чиктә хезмәт итү, политик белем бирү дәресләре белән бергә, атка атланып йөрү (тик йөрү генә түгел), атта чабып барганда киртәләр аркылы сикерү, кылыч чабу, ат өстендә күнегүләр эшләү дәресләре дә керә. Ул дәресләрдә һәркем үзенә беркетелгән атта йөри һәм ул атны ашатып-эчертеп, кардасын һәм үзен дә чистартып тора: үз аты өчен җавап бирә.

Атлар өйрәтелгән, команданы төгәл үтиләр, билгеле бер араларда тезеп куелган шактый биек киртәләрдән (махсус эшләнеп, күчереп йөртә торган) җиңел сикереп чыгалар. Тик атта йөри белмәгән курсантлар, ялгыш команда биреп һәм сикергәндә дөрес утыра белмичә, атларны бозалар.

Рүзәл, авыл малае булганлыктан, атка атланып йөри, чаба белә. Әмма барысында да бер җитди проблема: арт яклар чиләнеп, курслар беткәнче диярлек тазарып җитә алмый. Чөнки бер-ике көн саен атта йөрү дәресләре булып тора, шунлыктан утыра торган җирнең кипшерә башлаган кутыры кубып төшә дә, яңадан каный, яңадан чиләнә.

Әзерлек курсын узу шартлары кырыс кына түгел, хәтта рәхимсез. Безнең Россия армиясендә солдатка кеше итеп карау, аны кызгана белү юктыр, ахрысы. Анда солдатны авыр сугыш шартларына әзерлибез, чыныктырабыз, күнектерәбез дип, кирәкмәгән, артык, аның сәламәтлегенә зыян китерерлек экстремаль шартлар тудыралар.

Рүзәлләрне тышта температура минуслы, салкын булганда да җылытылмаган автомобильләр гаражында йоклаталар. Шундый салкында да өсләренә кияргә шинель бирмиләр, гимнастёркадан йөртәләр. Солдатларның күбесе авырый. Температураң утыз тугыздан узмый торып, санчастька да салмыйлар. Рүзәлгә дә температуралы килеш шактый вакыт дәресләргә йөрергә туры килә. Артың канап, чиләнеп йөрүе командирларны борчымый, ярдәм күрсәтүче, чарасын күрүче юк, дәресләрдән азат итмиләр. Стройда күбрәк я җырлап йөрергә, җырларга теләмәсәң, йөгереп барырга кирәк: җырлыйсы да килми, бөтен снаряжение белән тау-таш арасыннан (юллар, сукмакларның барысы да эре-эре ташлы) йөгерү дә авыр. Шуның өстенә, ашау да җитми. *«Мин олы гәүдәле һәм күп ашаулы булмасам да, гел карыным ачып йөрде, ашханәдән ашап чыкканда тамак туеп җитмәгән була,* — дип искә ала Рүзәл ул вакытларын. — *Кече командирларның да ямьсез кыланышлары, урынсыз төрле җәзалар биреп шаярулары — гадәти күренеш. Мәсәлән, йөгергәндә бер-ике кеше хәлсезләнеп артта калса, бөтен подразделениене (отделениене) кире борып, йөгереп барып, артта калган кешене алып килү практикасы киң таралган. Иртәнге подъёмны да кешечә генә эшләмиләр. Киенеп бетәргә минут ярым вакыт бирелә. Шул арада портянканы чорнап, итекләрне киеп, шпага тага торган «шлея»не киеп өлгереп, стройга басарга кирәк. Аркылы-торкылы берничә ременьнән торган «шлея» ашыкканда чуала... Кайбер солдатлар, подъёмда өлгерә алмаудан куркып, кроватька итекләрен салмыйча гына менеп яталар. Сержант, бу хәйләне фаш итеп, теге мескен солдатка җәза бирә.*

*Бу уңайдан шуны әйтәсем килә: улыбыз Фәнис армиядә хезмәт иткәндә, әнисе, сеңлесе белән янына барып, хәлен белеп кайткан идек. Казармаларына кереп карадык. Температура ун градустан югары түгел иде. Солдатлар катып-туңып йоклыйлар. Шуңа күрә улыбыз еш кына йөткереп йөри торган булып кайтты армиядән».*

Ниһаять, чик буе сакчысы курсы тәмам. Чикне саклау программасына кергән өйрәнүләр буенча зачёт-экзамен кебек нәрсә уздырыла, билгеләр куялар. Рүзәлгә

курс программасының барлык төрләреннән дә «бишле»ләр куела. Аны бу күрсәткечләре белән котлап, өйрәнү заставасының «молния»сен чыгаралар. Шуңа күрә дә аны, чик буе заставасына җибәрмичә, Сталинабадка (хәзерге Дүшәмбе шәһәре) сержантлар әзерли торган мәктәпкә җибәрәләр. Ярты ел укып сержант исеме алгач, хезмәтне дәвам иттерергә яңадан Памирга — Хорог отрядындагы заставаларның берсенә китәргә тиеш була ул.

Рүзәл белән бер төркем солдатлар ноябрь урталарында Сталинабад шәһәренә юл алалар. Памир юлы май аена кадәр бөтенләйгә ябылачак икән. Юлны калын кар баса, машина йөрерлек булмый, Хорог белән олы җир арасында, көн әйбәт булганда, кечкенә самолётлар (кукурузниклар) белән генә йөриләр.

Сталинабад — Таҗикстан республикасының башкаласы.

Таҗикстан (хәзер мөстәкыйль дәүләт) беренче барып күргән кешегә чит ил кебек. Анда экзотика (үзенчәлекле, гадәти булмаган нәрсәләр) шактый күп. Ул — борынгы культураны, Иран мәдәнияте йогынтысын, ислам динен һәм милли традицияләрне нык саклаган ил. Таҗикларның яшәү рәвешләре, кием-салымнары, каралты-куралары, аш-сулары бездәгедән шактый нык аерыла. Рүзәл хезмәт иткәндә Европа цивилизациясе анда азрак үтеп кергән була әле.

Аларда гомумән көнчыгыш халыкларына хас гореф-гадәтләр көчле. Бу олыларга, хатын-кызга мөнәсәбәттә аеруча нык чагылыш таба. Олы кешеләргә ихтирам зур. Хатын-кызларны катгый кысаларда тоту кебек борынгыдан калган гадәтләр көчле. Таҗик хатын-кызларында, мәсәлән, бот күрсәтеп йөрү юк: барысы да тубыкка кадәр бөтен аякны каплап торган чәчәкле шаровар кияләр, пәрәнҗә үк япмасалар да, битләрен ир-ат каршында яулык чите белән каплап йөриләр, башларына махсус матур хатын-кызлар түбәтәе кияләр.

Авылларда (кышлакларда) өйләрнең урам ягында тәрәзәләре булмый, йортлар балчыктан ясалган коймалар белән әйләндереп алынган. Чәйханәләр, пылаулар, табында утырган кешеләрнең түгәрәк буенча бер савыттан (касәдән) чәй эчүләре кебек үзенчәлекле күренешләр хөкем сөрә. Халыкның, нигездә, кырда дөге игүе, үсемлек-агачларны сугаруның таулардан агып төшкән су (арык системасы) ярдәмендә башкарылуы, җиләк-җимешнең мул булуы һәм башка шундый күренешләр дә һәркемгә мәгълүм булса кирәк. Яшәүчеләрнең иң зур күпчелеге — таҗиклар. Әлбәттә, берникадәр руслар һәм башка милләт вәкилләре дә яши. Сталинабад — уртача зурлыктагы шәһәр. Җәй көне матур, яшеллек күп. Таҗикстанда май аеннан алып октябрь-ноябрьгә кадәр яңгыр яумый. Саташып килгән болыт булса гына инде. Җәен, әлбәттә, бик эссе. Күләгәдә еш кына кырык градустан артып китә. *«Бу хәл гимнастёрка, итек киеп йөри торган солдатның хәлен бик авырайта,* — дип сөйли Рүзәл. — *Кайчакта судан чыгарып ташланган балык хәлендәрәк буласың. Төннәрен тәбәнәк түшәмле, ике катлы кроватьлы армия казармаларында йоклау*

*аеруча кыен. Бик бөркү була. Дневальныйга простыня өстенә су бөркергә куша торган идек. Ул да бик тиз кибеп бетә.*

*Россиядәге кебек кышлар булмый. Пальто, тун, җылы калын курткаларның кирәге юк. Шулай да ноябрь белән март арасында кайчакта җепшек кар яугалап ала. Җирдә җыелып торган җепшек кар итекне чылатып, аякны яхшы ук туңдыра торган иде. Атларыбызны юганда кул да бик туңа иде».*

Рүзәл хезмәт иткән сержантлар мәктәбе Сталинабадтан алты-җиде километр ераклыктагы Риссовхоз дигән посёлокта урнашкан. Совет властеның беренче елларында хәзерге хәрби часть биналарында авыл хуҗалыгы белгечләре әзерли торган булганнар. Памир тауларыннан цивилизация күрмәгән таҗик егетләрен алып килеп укытканнар.

Сержантлар мәктәбендә, Хорог отрядындагы кебек, Рүзәлләр заставасының начальнигы — капитан — юньле кеше була, кайбер командирлар кебек команда бирүдән башканы белми торган зат булмый. Рүзәлне баштан ук үз итә, «милок» дип кенә эндәшә: «Татарлар — яхшы егетләр, әйбәт хезмәт итә алар», — ди ул. Ничектер курсантларга бер ат җитми калгач, капитан Рүзәлгә үз атын бирә. Ул бик яхшы өйрәтелгән, ярышларда катнашып, призлар алган, аерым кардада тора. Монда да булачак сержантлар атларын үзләре ашаталар-эчертәләр, юалар, сөртеп корыталар, торган урыннарын җыештыралар һәм, әлбәттә, үз атлары белән күнегүләр үткәрәләр.

Курсантлар чик саклауның серләренә төшенәләр, коралларның төзелешен өйрәнәләр, аларны куллану техникасын, личный состав (солдатлар) белән командалык итү алымнарын үзләштерәләр. Кече командирлар сәяси яктан әзерлекле булырга тиеш. Шуның өчен политдәресләр үткәрүгә зур игътибар бирелә.

«Сержантлар мәктәбе» дип аталса да, ул урта мәктәптәге, югары уку йортында уку түгел, билгеле. Армия ул: подъём, отбой, стройга тезеп, иртәнге тикшерү, кичке тикшерү, сафка тезелеп ашарга бару-кайту, йөгерү, төрле физик күнегүләр, хуҗалык эшләре (үз күлмәк-ыштаныңны, гимнастёркаңны, портянкаңны үзең юасың, казармада һәм башка җирләрдә дежур торасың һ.б.). Кыскасы, тик тотмыйлар, нинди дә булса шөгыль табып кына торалар. Солдат тормышын — гади солдатмы, курсантмы, сержантмы ул, барыбер — күңелле, рәхәт тормыш дип әйтеп булмый. Режим, муштра, ирексезлек, бертөрлелек. Увольнениегә аз чыгаралар — бигрәк тә шунысы ачуын китерә солдатның. Нишлисең бит, шуңа күрә дә «армия» диләр инде аны. Һәркемнең Ватан алдындагы бурычы, дип йөрисең, түзәсең. Зур чыныгу аласың: физик яктан да, психологик яктан да һәм ирекнең кадерен белергә өйрәнәсең.

Рүзәлнең хезмәте әйбәт бара. Иҗтимагый актив, мактаулы егетләрдән була ул. Подразделениенең стена газетасы редакторы, комсомол бюросы әгъзасы ке-

бек җәмәгать эшләре башкара, Таҗикстан ЛКСМының мактау грамоталары белән бүләкләнә һ.б. Һәм нәтиҗәдә хәрби частьның партия комитеты аңа партия сафларына басарга тәкъдим итә, аны яхшы белгән офицерлар рекомендация бирәләр. Башта бер ел кандидат булып йөри, димәк, сынау срогын уза. Бер ел узгач, аны партия әгъзасы итеп кабул итәләр.

Шул вакытлардан бирле Рүзәл Юсуповка күп еллар төрле җаваплы җәмәгать эшләрендә катнашып, партия заданиеләрен үтәп яшәргә туры килә.

Армиядә ел ярымнар булганнан соң, әйбәт хезмәт иткәне өчен, Рүзәлгә зур бүләк — отпуск бирәләр. Инде товар вагонында түгел, пассажир поездында өйгә кайтып, кунак булып килә ул. Олы абыйсы Равил ул киткәндә, армиядән кайтып, Северный поселогында өй сала башлап калган була, ул кайтуга, әти-әни, башка туганнар ярдәме белән, өйне җиткереп кергәннәр. Авылдагы йорт-җирне, сыер-бозауны сатып, төпчек энесе Мөнир белән әти-әниләре дә күчеп килгән. Равил абыйсы өйләнгән, Наил абыйсы армиядән кайткан, Әнәс энеләре китәргә әзерләнә. Конвейер: егетләр күп, берсе кайта, икенчесе китә...

Армия сабакларын татып караганнан соң, өйдә, ирektә булуның кадерен яхшырак беләсең икән... Армиягә киткәндә авыр булмый Рүзәлгә, отпускада булып, яңадан китү кыен була. Ләкин нишлисең, хезмәт итеп бетерергә кирәк бит.

Дүшәмбе шәһәрендәге сержантлар мәктәбе белән янәшәдә генә шаулап аккан Пәнҗ елгасы көч бирә кебек тоела Рүзәлгә. Елга юлында очраган һәр нәрсәне алып китәрдәй ашкынып ага. Салкын саргылт су сине шунда ук аяктан егар кебек. Рүзәл аз гына эләгә торган буш вакытларында шул елгага кереп коенып алырга, көчле агымга каршы барырга, аның белән ярышырга ярата. Елга аны үзенең көчле агымына каршы барырга гына түгел, гомумән тормыштагы авырлыкларны җиңәргә, туктаусыз алга барырга да өйрәтә сыман. Хәер, Пәнҗ кебек тау елагаларының гына түгел, без яшәгән заманның агышы да гаять көчле. Ихтыярсыз, юаш булсаң, сине аяктан ега да үзенең чоңгылларына алып кереп китә ул. Аннан чыгып кара син! Бер егылсаң, кабат аякка басу бик авыр ул!

*«Армия елларында мин, беренчедән, физиологик яктан үсеп, психологик яктан ныгып киткән булсам, икенче яктан, үземдә рухи яктан үзгәрешләр дә барганлыгын сиздем,* — дип сөйли Рүзәл. — *Кызык һәм гыйбрәтле күренеш: яшьтән үк туган җирдән аерылып, читтә руслар арасында яшәп алу, аннары өч ел армиядә булу миндә туган җирне, милләтемне, татар культурасын, телемне хөрмәт итү хисләре көчәя баруга сәбәп булды.*

*Мин, Курган өлкәсендә эшләгән чакта ук, Мәскәү радиосыннан сирәк-мирәк кенә ишетелгән татар җырларын йотлыгып тыңлый идем, туган җирләрне сагынып, хисләнеп, каләм тибрәтә — шигырьләр язгалый башладым. Мондый хисләр*

*армиядә дә кимемәде, көчәя генә барды. Берничә шигырь дә язып куйдым. Армиядән кайту (демобилизация) вакыты җитә башлагач, башыма, алга таба нәрсә белән шөгыльләнергә, дигән сорау килә торган булды. Хәер, мин бу хакта күп уйламадым кебек, максатны тиз билгеләдем — укырга, югары белем алырга. Ә кайда? Кем булырга? Менә монда инде минем әле генә сөйли башлаган милли хисләрем җитди төс ала башлады. Татар мәктәбендә җиде генә класс укып калганлыктан, татар телен тулы итеп белмимдер кебек, хәлбуки, мин үз телемне, татар әдәбиятын яхшы белергә тиеш. Димәк, Ленин университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә кереп укырга тиешмен! Бу мәсьәләне үзем өчен шулай хәл итеп куйдым. Бу әле уйда гына, теләк кенә иде, әлбәттә. Максатка ирешү юлында биек киртәләр бар: анда керү өчен, рус теле һәм тарихтан тыш, татар теле һәм әдәбиятыннан ун класс программасы күләмендә кабул итү имтиханнары тапшырырга кирәк булачак. Ә мин татар мәктәбенең сигезенче — унынчы классларында укымаган. Техникумны тәмамлаганга да биш ел, татарча җиде классны укып бетергәнгә сигез ел узган. Әмма миндә ул чакта үҗәтлек барлыкка килгән иде инде — чигенмәскә, тырышырга, максатка ирешергә!*

*Минем бәхеткә, армиядән аз гына алдан кайту мөмкинлеге килеп чыкты: май аенда инде өйдә идем. Димәк, укырга керергә әзерләнү өчен өч ай вакыт бар. Татар теле һәм әдәбиятыннан сигезенче, тугызынчы, унынчы класслар дәреслекләрен укып, тарихны искә төшереп (рус теле минем өчен проблема түгел иде инде), имтиханнарга өлгергән кадәр әзерләндем дә университетка гариза бирдем. Конкурс шактый зур, керәсе егетләрнең барысы да диярлек шактый җилле күренә: татар урта мәктәбендә укыганнан соң, армиядә хезмәт итеп кайтканнар. Кызлар да икешәр-өчәр ел эшләп килгәннәр. Шигырь язып йөргән егетләр дә бар.*

*Әмма мин теләгемә ирештем. Кабул итү имтиханнарын «дүртле», «бишле» билгеләренә тапшырып, беренчеләрдән булып, керүчеләр исемлегенә эләктем.*

*Менә шулай итеп, В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты булдым. Ленин исемен йөрткән ак колонналы данлыклы университетта уку зур шатлык иде, әлбәттә.*

*Мин кергән бүлектә киләчәктә халык шагыйре буласы Равил Фәйзуллин, шулай ук республикада мәгълүм шагыйрь булачак Шамил Маннапов, булачак фәннәр докторлары, профессорлар Фарсель Зыятдинов (ул язучы, журналист та), Әнвәр Шәрипов (ул да шагыйрь), Фирдәвес Гарипова, Флера Әхмәтова (соңрак Баязитова), фәннәр кандидаты, Тукай премиясе лауреаты Ленар Җамалетдинов, атказанган культура эшлеклесе Роза Гатиятова (Ханнанова) һәм башка күркәм затлар бар иде».*



*Памирда (Армиянең беренче көннәре). Рүзәл — уңнан икенче булып басып тора*



*Рүзәл хезмәттәшләре белән. Сталинабад (Дүшәмбе) шәһәре, 1959 ел. Рүзәл уңнан беренче — чүгәләп утырган*



Рүзәл — чик сакчысы



Грамотаи
ФАХРӢ

ЦК ЛКСМ Таджикистана награждает
настоящей грамотой

ефрейтора войсковой части 2050,
за отличные показатели в боевой
и политической подготовке, в
связи с 40-летием Ленинского
Коммунистического Союза Молодежи.

Сталинабад 1958 г.

Мактау грамотасы



*«Хәрби отличник»лар слётында катнашучылар. Сталинабад, 1958 ел.*
*Рүзәл — беренче рәттә уңнан өченче*

## АЛЬМА-МАТЕР САБАКЛАРЫ

Зур тарихлы, абруйлы уку йорты, бусагасын атлап керүгә үк, һәркемдә күтәренке хисләр уята. Аның һавасы, мохите үк ниндидер игелекле, күркәм гамәлләр кылырга дәртләндереп, канатландырып тора. Кайчандыр бөек Ленин йөргән коридорлардан узу, яшь Ульянов утырган аудиторияләрдә дәресләр алу Рүзәл Юсупов кебек социализм, коммунизм идеяләре рухында тәрбияләнгән яшьләргә тылсым буларак тәэсир итә.

*«Ленин университетында уку минем кебек авыл малайлары өчен бәхет иде. Мин җиң сызганып, бөтен тырышлыгымны җигеп, күңелемне салып, ашкынып дигәндәй укырга керештем. Һичшиксез, университет минем киләчәк тормышымның, алда торган җаваплы эшләремнең ныклы нигезе булды,* — дип яза Р. Юсупов бер мәкаләсендә. — *Ул вакытта белем алуга караш җитди иде. Күп укыдым, белем алыйм, күпне белим дип, чын күңелдән йөрдем. Дәресләр беткәч, ашханәдә ашап чykканчы, китапханәнең уку залына кереп, үзебезгә урын алып куя идек. Югыйсә буш урын калмаска мөмкин. Ял көннәрендә дә университетның уку залында утырабыз. Кирәкле китап булмаса, республика китапханәсенә керәбез. Хәзер укуга караш шактый үзгәрде...»*

Белем алу мәгърифәтле, тәрбияле булуга ярдәм итә. Югары уку йортында уку бигрәк тә зур белем бирә, зыялылык та өсти, җәмгыятьтә лаеклы булып яшәүгә нигез сала. Шуңа күрә бик күпләр, үзләрен зур авырлыкларга дучар итеп булса да, балаларына югары белем бирергә тырышалар. Япония дәүләте, мәсәлән, бөтен кешеләргә дә югары белем бирүне максат итеп куя, диләр. Япония — һәр яктан да башка илләргә үрнәк.

Рүзәл университетта укыган чорда программалар заман таләпләрен дә, милли мәнфәгатьләрне дә исәпкә алып төзелгән була. Татар теле һәм әдәбиятына караган фәннәрдән тыш, югары белемле белгечләрнең барысы өчен дә әһәмиятле гуманитар фәннәр укытыла. Дәресләр ике телдә бара. Татар теле һәм әдәбияты курслары ана телендә, ә башкалары рус телендә. Моның отышлы ягы шунда: ул студентларга ике телне дә яхшы белергә мөмкинлек бирә.

Тормыш сынауларын узып, авырлыкларда чыныгып килгән Рүзәл Юсупов белем алу өчен үзен аямый, барлык имтиханнарны «бишле» билгеләренә генә тапшыра. Җәмәгать эшләренә дә кереп чума. Аны тарих-филология факультетындагы комсомол оешмасы секретаренең идеология буенча урынбасары итеп сайлап куялар. Факультет зур, дүрт бүлектән тора: тарих, рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты, татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыту бүлекләре. Комсомол комитеты секретаре тарих бүлеге студенты, бүген инде республикада

мәгълүм шәхес, зур галим, академик Индус Таһиров була. Аның диплом эше язар вакыты җиткәч, секретарь итеп Рүзәл Юсуповны сайлап куялар.

Ул чорда университетта «бишле»гә генә укып, зур җәмәгать эшен башкарган студентларга исемле стипендияләр бирү тәртибе бар иде. Рүзәлгә Ленин стипендиясе алу бәхете әләгә: өченче курсның башыннан алып укып бетергәнче, инженер окладыкүләмендә стипендия алып бара ул. «Бишле»гә генә укып, зур җәмәгать эше башкару җиңел булмый аңа, әлбәттә. Һәр көнне шәһәр читендәге Северный бистәсеннән өч транспортта, мең бәла белән, иртәнге сәгать сигезгә укырга килеп җитәргә кирәк. Кичен соң кайтыла, чөнки һәр көнне диярлек төрле чаралар үткәрелә. Рүзәл укыган тарих-филология факультетында студентлар тормышы кайнап тора. Фән, иҗат түгәрәкләре актив эшли. Уку отличнигы, комсомол активисты буларак, Р.Юсупов та аларның күбесенә йөрергә тырыша. Тел түгәрәгендәге конференциядә ясаган докладлары өчен бүләк итеп бирелгән китапларны әле бүген дә кадерләп саклый ул.

Әдәби түгәрәк утырышларында иҗат лабораториясе мәсьәләләренә карата кызыклы фикер алышулар була. Студентларның шигырьләре, хикәяләре тикшерелә. Кызып-кызып бәхәсләшәләр, һәркем фикерен белдерергә тырыша. Түгәрәк утырышларында Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким кебек мәшһүр язучылар катнаша. Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин (Гаташ) — бүгенге көндә күренекле шагыйрьләр — студентларның шул иҗат түгәрәге утырышларында әдәби осталыкларына ныклы нигез салалар, каләмнәрен чарлыйлар.

Ул елларда студентлар, бүгенгеләрдән аермалы буларак, белем, фән, сәнгать нигезләрен мөмкин кадәр тулырак үзләштереп калырга омтылып, бер көнне дә бушка уздырмаска тырышып, янып яшиләр. Рүзәл Юсупов, фәнни, иҗат түгәрәкләре эшендә катнашудан тыш, үзенең группадашлары Фарсель Зыятдинов, Ленар Җамалетдинов, Шәрифҗан Асылгәрәевләр белән бергә, бал биюләре түгәрәгенә йөри, ДОСААФ секциясендә шофёрлыкка укып, права алып чыга, университетның үзешчән сәнгатендә катнашырга да вакыт таба.

Рүзәлләр группасында томышка җитди карашлы, эшлекле, сәләтле егетләр һәм кызлар тупланган була. Фарсель Зыятдинов, Ленар Җамалетдинов, Шамил Маннапов, Шәрифҗан Асылгәрәев, Кәлиф Вәлитов кебек егетләр университетка солдат киемнәрен салырга да өлгермичә килгәннәр. Кызларның да күбесе укырга килгәнче берничә ел эшләп алган. Аларның барысын да монда белем алуга омтылыш, туган телгә мәхәббәт китергән, дисәк, хата булмастыр. Бердәм булып, күп кенә игелекле эшләр башкаралар алар. Шәһәрне төзекләндерү, чистарту буенча даими үткәрелә торган өмәләрдә катнашалар. Урып-җыю чорында аларны төрле район хуҗалыкларына ярдәмгә — борчак чабарга, бәрәңге, чөгендер алышырга

җибәрәләр. Студентлар анда колхозчыларга булышып кына калмыйча, кичләрен авыл клубларында концертлар куялар, халыкара хәл турында лекцияләр укыйлар.

Фарсель Зыятдиновның ул чорда группадашларының Питрәч районының Надеждино авылында бер ай дәвамында ничек бәрәңге алулары турында язып та чыкканы бар. Таңнан алып караңгыга кадәр, бәрәңге күренмәс була башлаганчы, алар басуда була. Уникешәр сәгать эшлиләр. Колхозчылар болай эшләсә, бәлки, студентларның кирәге дә булмас иде. Тик алай түгел икән шул. Бигрәк тә урыс авылында артыгын кыймылдарга яратмыйлар. Хәер, алар өчен моның кирәге дә юк. Ничә еллар бушка диярлек эшләп файдасын күрмәгәч, алар инде үз хуҗалыкларын кайгыртырга күнеккәннәр...

Биредә эш тәмамлангач, күрше авылга да булышырга туры килә студентларга. Колхоз рәисе үзе килеп үтенеп сорый. Эш беткәч, студентларга берәр капчык бәрәңге бирәләр, бераз акча да тия. Аларга шунысы да ярап куя.

Рүзәлләр группасы студентлары университет күләмендә дә алдынгылар исәбендә була. Алар төрле күрсәткечләр буенча призлы урыннар алалар, бүләкләр яулыйлар. Шуның нәтиҗәсе буларак, Ленинградка экскурсиягә баралар, Идел буендагы лагерьда ял итәләр.

Уку йортының даны беренче чиратта укытучыларының дәрәҗәсе белән билгеләнә. Ул яктан ике гасырлык Казан университетының даны бөтен дөньяга мәгълүм. Аның тарихында бөек Н.И. Лобачевский кебек йөзләрчә галимнәрнең исемнәре алтын хәрефләр белән язылган.

Рүзәлләргә дә күренекле галимнәр, күркәм шәхесләр белем бирә. Татарлардан беренче философ-профессор Мансур Абдрахманов лекцияләрен тыңлау бәхетенә ирешә Рүзәл. Мансур Ибраһимович фронттан күкрәгенә орден-медальләр тагып кайта, бер аягы протез булса да, лекцияләрне баскан көйгә укый. Соңрак ул университетның проректоры да була.

Ул чорда татар әдәбияты кафедрасын әдәбият тарихы белгече, язучы, сугыш ветераны Хатыйп Усманов җитәкли. Шушы ук кафедрада бик принципиаль галим, сугышта бер аягын калдырып кайткан Ибраһим Нуруллин эшли. Ул «Күренекле кешеләр» сериясеннән Габдулла Тукай, Фатыйх Әмирхан турында һәркемнең өстәл китабы булырлык әсәрләр язып бастырган. Татар әдәбияты кафедрасы профессоры Нил Юзиев та — үтә зыялы кеше. Борынгы татар әдәбиятын күренекле мәгърифәтче, зур белгеч Якуб Агишев укыта.

Татар теле укытучыларыннан зур галим, профессор Мирфатыйх Зәкиев була. Соңыннан ул Казан педагогика институтын, Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтын җитәкли.

«Введение в языкознание», «Общее языкознание» курсларын шулай ук фронт-

та булып, немец әсирләре белән эш иткәндә тәрҗемәче вазифаларын башкарган, заманында Ленинградта дөньякүләм галимнәрдән белем алган профессор Әнвәр Ахунҗанов укыта. Дәресләрендә ул, студентларны бераз ял иттереп алу өчен, башыннан үткән кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар турында сөйли торган була.

Морфология буенча лекцияләрне академик, Ленинград университетының атаклы галимнәре шәкерте Диләрә Тумашева укый. Ул университетның тарих-филология факультеты деканы вазифасын башкара, татар теле кафедрасы мөдире булып та эшли.

Рус әдәбияты профессоры Йолдыз Нигъмәтуллинаны Рүзәл Юсупов әдәбият белгечләренең иң зур белемлеләреннән берсе дип саный. Фән теле белән әйткәндә, киң эрудицияле галимә. Биографиясе дә күркәм: ул — күренекле әдәбиятчы, тарихи шәхес Галимҗан Нигъмәти кызы. Башка фәннәрдән дә бик күркәм, зур белемле, оригиналь шәхесләр укыта Рүзәлне. Ул аларны бүген дә җылы хисләр белән искә ала.

Ул чорда В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының ректоры дөньякүләм күренекле галим, физик Михаил Тихонович Нужин була. Студентларның, аны үз итеп: «Нам нужен и Нужин, и хороший ужин», — дип такмаклап йөрүләре хәтеремдә калган. Беренче карашка кырыс күренсә дә, гаҗәеп мәрхәмәтле, ярдәмчел кеше иде ул. Университетта уку чорында, группа старостасы буларак, миңа теге яки бу мәсьәлә буенча ректорга еш мөрәҗәгать итәргә туры килде. Берсенә стипендия кирәк, икенчесенә — тулай торакта урын, өченчесенә — матди ярдәм... Михаил Тихонович, барлык эшләрен читкә куеп, һәрвакыт игътибар белән тыңлый, мөмкин кадәр ярдәм күрсәтергә тырыша иде. Без ректорга һәрвакыт рәхмәтле булдык.

Студент еллары — һәркемнең тормышында якты истәлекле чор. Алар гомер буе күңелләрдә матур хатирәләр буларак саклана. Студент тормышы, җәмәгать эше яшьләрне күп нәрсәгә өйрәтә, сәяси яктан чыныктыра.

*«Без университетның фән, мәгърифәт, мәдәният казанында кайнадык, тарихи шәхесләрнең акыллы сүзләрен тыңлап, тиешле белемнәр алып, гыйбрәтле тормышларыннан үрнәк алып, үзебезнең рухи дөньябызны баеттык, алдынгы идеяләр белән коралландык,* — дип яза Рүзәл Юсупов. — *Казан дәүләт университеты тиешле белгечлек буенча белем дә бирә, теләгән һәм сәләте булган кешеләргә фән белән шөгыльләнү өчен юл да ача, иҗатка тартымлы егет-кызларга бу өлкәдә көчләрен сынап карау өчен мөмкинлекләр дә булдыра. Университет минем тормышымда якты сәхифәләргә бай, нәтиҗәле үсеш, алдагы сынауларга әзерлек чоры булды».*

Рүзәл Юсупов үзенең группадашлары белән горурлана, аларның уңышларына шатлана. Аларның барысы да соңыннан республикабызга тугрылыклы хезмәт итә

торган, җәмгыятькә файдалы, күренекле шәхесләр булдылар. Сүз уңаеннан кайберләрен билгеләп үтик.

Равил Фәйзуллин — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күп еллар дәвамында «Казан утлары» журналы мөхәррире булып эшли, 1990—1995 елларда Татарстанның Югары Советы депутаты, Татарстан Фәннәр академиясенең почётлы члены.

Шамил Маннапов — күренекле шагыйрь, журналист. Аның «Солдатта булган диләр» кебек шигырьләре халыкның яраткан җырларына әверелде.

Фарсель Зыятдинов — икътисад фәннәре докторы, профессор, язучы, журналист, күп китаплар авторы.



*Рүзәл — Ленин стипендиаты*

Филология фәннәре докторлары Фирдәвес Гарипова, Флёра Баязитова, Әнвәр Шәрипов (шулай ук язучы да). Группаның старостасы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтының баш фәнни хезмәткәре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге премиясе лауреаты, татар халык әкиятләрен җыеп, эшкәртеп, китаплар бастырып чыгарган Ленар Җамалетдинов; элеккеге партия өлкә комитетының бүлек мөдире урынбасары, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтының директор урынбасары Шәрифҗан Асылгәрәев; группаның комсоргы, күп еллар республиканың китап палатасы директоры, соңыннан Казан педагогика университетында эшләгән Роза Ханнанова һ.б.

Группаның берничә егетенә, шул исәптән Рүзәл Юсуповка да, индивидуаль план буенча укырга рөхсәт бирелә. Алар, биш еллык уку планын дүрт елда үтәп, бишенче курс өчен зачёт-имтиханнарны алдан биреп куеп, укуны иртәрәк тәмамлыйлар һәм эшкә урнашалар. Рүзәл, кафедра мөдире Мирфатыйх Зәкиев тәкъдиме белән, тәрҗемә теориясе һәм практикасы белгечлеге планы буенча укып, тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган диплом яклый. Университеттан филолог-тәрҗемәче дигән квалификация алып чыга. Ул Казан дәүләт университетын кызыл диплом белән тәмамлый.



*Рүзәлләр группасы студентлары:*
*уңнан сулга — Рүзәл Юсупов, Шамил Маннапов, Ким Садыков, Фарсель Зыятдинов, Ленар Җамалетдинов. Казан, 1962 ел*



*Студентлар колхозга булыша (Саба районы, июль, 1962 ел)*




*КДУ студентлары язучылар белән. Рүзәл — арткы рәттә сулдан икенче*





*Студентларның үзешчән сәнгате (уңнан — Рүзәл Юсупов, Әнвәр Шәрипов)*



*Рүзәлләр группасы (15 елдан соң)*



*Университеттагы сабакташы Фарсель Зыятдинов белән*



*Группа Рүзәл Юсупов юбилеенда*

## ЭФИР ЖУРНАЛИСТИКАСЫН ҮЗЛӘШТЕРҮ

Рүзәлне, сынау шарты белән, тәрҗемәче итеп радиога эшкә алалар.

Тәҗрибәсез килеш радиода тәрҗемәче булып эшләү өчен зур тәвәккәллек кирәк. Бу аның тормышында чираттагы сынау була.

Тәрҗемә — катлаулы, авыр эш. Ул һөнәри осталык та, зур белем дә таләп итә.

Моңарчы радиода күп еллар тәрҗемәче булып Абдулла абый Төхфәтуллин эшләгән. Ул, әлбәттә, «ас», чын татарча әйткәндә, «ата» тәрҗемәче. Сәламәтлеге какшау аркасында пенсиягә китәргә мәҗбүр булган. Рүзәлне шуның урынына тәкъдим итәләр.

Рүзәл, университетта укыганда, күп булмаса да, язып тәрҗемә итү тәҗрибәсе алган була. Дипломында да «филолог-тәрҗемәче» дигән язу бар. Ләкин язып тәрҗемә итү бер авыр булса, телдән тәрҗемә итеп машинкага бастыру ике-өч тапкыр авыррак. Рүзәлнең мондый тәҗрибәсе бөтенләй булмый әле, әлбәттә.

Радиода, һәркемгә мәгълүм, соңгы хәбәрләр тапшыру практикасы бар. Ул чагында ашыгыч хәбәрләрне Мәскәүдән телетайп аппараты белән ала торган булалар. Алалар да, шунда ук русчадан татарчага тәрҗемә итеп, эфирга тараталар (чыгаралар). Язып, иркенләп уйлап тәрҗемә итәргә вакыт юк. Тәрҗемәче телетайптан текстны алып карап танышып чыга да татарчага әйләндерү өчен, машбюрога кереп, машинисткага әйтеп торып бастыра. Бастырган текстны редактор тиз генә укып, кирәк тапса, төзәтеп чыга да кул куеп, эфирга җибәрү өчен, дикторга бирә.

Абдулла абый эшне, әлбәттә, тиз тота торган булган. Телетайптан алуга, хәбәрләр текстының татарчасын машинистка Суфия ханымга әйтеп торып бастырган.

*«Болай эшләү минем өчен зур проблема, ягъни бик авыр булды,* — дип искә ала Рүзәл ул вакытларны. — *Шулай да тырыштым-тырмаштым. Телетайптан алган текстны мин, ыңгыраша-ыңгыраша булса да дигәндәй, Суфия апага әйтеп торып тәрҗемә итә башладым. Әлбәттә, Абдулла абый кебек тиз булмый, ялгышлар да китә иде. Шунсыз мөмкин дә түгел. Кайбер җөмләләрне, сүзләрне, бер әйткәч, ялгышканлыгымны аңлап, төзәтеп, кабат әйтәм. Суфия апа — искиткеч машинистка, минем авыздан чыгуга, басып та куя. Мин, төзәтеп, кабат бастырудан бик уңайсызланам, гафу үтенәм. Шөкер, Суфия апа акыллы хатын булып чыкты: минем хәлне аңлый, «ярый-ярый, зыян юк, энем» дигән булып, үзгәртеп, яңадан баса. Бик күркәм кеше иде, күңелемдә аның турында яхшы хисләр саклана. Аның осталыгы шул дәрәҗәдә ки: хәтта ул, тәрәзәдән ишегалдындагы күренешләрне күзәтеп, автомат рәвештә баса ала иде.*

*Мин, җәфалана-җәфалана, бер ай үтүгә, машинисткага әйтеп торып, соңгы хәбәрләрне ярыйсы гына тәрҗемә итә башладым. Моннан тыш, минем вазифала-*

*рыма төрле темаларга караган башка текстларны да тәрҗемә итү кирә. Аларын инде җайлап, уйлап, язып эшлим. Кешеләр эштән китеп беткәч тә, радиода озак утырырга туры килә торган иде.*

*Университеттагы дүртенче һәм бишенче курсларның уку планын бер елда үтәп килгәнлектән һәм бу яңа авыр эшне башкарганлыктан булса кирәк, минем организмым зур киеренкелеккә бераз бирешеп алды. Берничә мәртәбә, кич өйгә кайтырга чыккач, борынымнан шыбырдап кан китте. Бер тапкыр, канны үзем туктата алмагач, радио каршындагы поликлиникага кереп, врачлардан ярдәм сорарга туры килде.*

*Шуның өстенә, күзләрем сызлый башлады. Сәбәбе: артык зур киеренкелектән күз басымы күтәрелгән. Кайбер чаралар күрергә туры килде. Шөкер, әкренләп узды тагын».*

Шулай итеп, Рүзәлнең радиода эшли башлавына карата «кан төкерсәң дә сынатма» дигән халык мәкален туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәсендә дә кулланырлык була. Саф һавада мөмкин кадәр күбрәк булу, җәяү йөрү зарурлыгы турында җитди уйлана башлый Рүзәл. Тора-бара йоклар алдыннан җәяү йөреп кайту аның гадәтенә әверелә. Бүгенге көнгә кадәр ул бу гадәтенә тугры булып кала.

Тәрҗемәче һөнәрен ярыйсы гына үзләштереп, радиода берничә ай эшләгәч, радио-телевидение комитеты рәисе Ф.Г. Надыйров Рүзәл Юсуповны телевидениегә редактор итеп күчерергә була. Ул вакытта Казан телевидениесе тапшыруларына игътибар да, таләп тә бик югары иде. Партия өлкә комитетының матбугат үзәге тапшыруларны даими рәвештә карап барды, анализлады, берәр нәрсә ошамаса, утлы табага бастырасыларын белеп торасың.

Рүзәл Юсуповны телевидениенең пропаганда редакциясенә татар тапшырулары өчен җаваплы редактор итеп билгеләделәр. Ул чагында редакцияләрдә, шул исәптән пропаганда редакциясендә дә, кагыйдә буларак, икешәр редактор иде. Берсе — татар, икенчесе рус тапшырулары өчен җавап бирә. Рус телендәге тапшыруларны Людмила Михайловна Пивоварова әзерләде. Бер үк вакытта ул тулаем пропаганда редакциясе эшенә җавап бирүче өлкән редактор да иде. Людмила Михайловна Казан телевидениесенең иң тәҗрибәле хезмәткәрләреннән саналды. Монда эшкә керешкәнче, ул Урта Азиядә педагогика институтында эшләп кайткан, диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты исемен алган. Редакциянең режиссёры телевидение ачылганнан бирле биредә эшләүче, инде шактый тәҗрибә туплап өлгергән Калерия Ивановна Косарева, режиссёр ассистенты композитор Александр Ключарёвның килене Нина Ключарёва иде. Нина Алексевнаның ире Эмиль Ключарёв исә телевидениенең музыкаль тапшырулар редакциясендә режиссёр булып эшләде.

Пропаганда редакциясе әзерли торган тапшыруларның тематикасы бик киң иде: иҗтимагый-сәяси, тормыш, партия, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәсенә караган тапшырулар, хокук саклау органнарының эше, истәлекле даталар, тагын башка темаларга багышланганнары. Кыскасы, эшләргә мәйдан зур иде.

Рүзәл эшли башлаган чорда, үткән гасырның алтмышынчы елларында, телестудия инде билгеле дәрәҗәдә формалашып өлгергән, аның структурасы эшләнгән, белгечләр тупланган, техник җиһазлар да алынган була. Шулай да биш-алты елда гына телевидение кебек катлаулы системаның эшен тулы күләмдә җайга салу мөмкин түгел. Махсус белемле кадрларның булмавы үзен нык сиздерә әле. Җитәкчеләр — партия өлкә комитетыннан, мәдәният министрлыгыннан, журналистлар — радиодан, газета-журналлардан, режиссёрлар театрлардан алына. Ул чорда республикада гына түгел, ил күләмендә дә телевидение өчен кадрлар әзерли торган уку йортлары бөтенләй булмый. Аларны эш, практика, тормыш үзе өйрәтә. Әмма һәр хезмәткәргә куелган таләпләр зур була.

Бүлек редакторы Рүзәл Юсуповның вазифасына редакция эшенең планын төзү, авторлар табу, алар белән бергә тапшыруларны оештыру, аларның текстларын әзерләп режиссёрга бирү, аларны күрсәтерлек хәлгә җиткереп (кинога, фотога төшереп һ.б.), режиссёр белән бергә тапшыруларның сыйфаты өчен эфирга чыгарганчы җавап бирү керә иде. Телевидение тапшырулары коллектив хезмәт нәтиҗәсендә барлыкка килә. Анда, иҗат төркеменнән тыш, күпсанлы техник хезмәткәрләр дә катнаша. Ул чорда Казан телевидениесендә эшләүче иҗади хезмәткәрләр саны 75 булса, техниклар 200 гә якын иде.

*«Телевидениедәге эштән уңдым мин. Анда эшләү минем өчен бик нәтиҗәле, кызыклы булды,* — дип искә ала Рүзәл телевидениедә эшләгән чорын. — *Башта бераз кыенрак булса да, мин бу эшне тиз үзләштердем һәм коллективка җиңел кушылдым, коллектив үзе дә мине әйбәт кабул итте кебек. Мин анда тормышның төрле өлкәләреннән бай мәгълүматлар алдым, күп нәрсәләргә өйрәндем һәм зур белемле, киң карашлы, күркәм шәхесләр белән таныштым, рухи яктан нык баедым. Анда эшләү дәверендә, кинооператор, фоторепортёрлар белән йөреп, тапшыру өчен кино-фотоматериаллар әзерләп, күп җирләрдә — предприятиеләрдә, колхоз-совхозларда, оешмаларда, культура учреждениеләрендә, уку йортларында булырга туры килде. Кайбер тапшыруларны эфирда үзем алып бара идем. Әһәмиятле, кызыклы дип саналганнарын, мәкалә, репортаж итеп язып, газеталарда бастырып килдем».*

Мин Рүзәлнең телевидениедә эшләү елларын яхшы хәтерлим. Ул телевидениегә килгәндә, мин анда идем инде. Республика газетасы «Социалистик Татарстан»да (бүгенге «Ватаным Татарстан») бераз тәҗрибә туплагач, партия өлкә коми-

теты мине телевидениегә информация тапшырулары җитәкчесе итеп җибәргән иде. Хәтерлим: Рүзәл телевидение эшенең серләренә тиз төшенде. Эшкә керешүенә күп тә үтмәде, ул әзерләгән тапшыруларга уңай бәя бирә башладылар.

Ул чорда Казан телевидениесе коллективы бик дус, тырыш иде. Техниканың шактый примитив булуына карамастан, тамашачы кызыксынып карый торган, югары сыйфатлы тапшырулар әзерләнде. Үзең белгәнне күршеңә өйрәтү, ярдәм кулы сузу һәркемнең намус эшенә әйләнде. Кадрларның һөнәри үсешенә атна саен уздырыла торган летучкалар да уңай тәэсир итте. Летучкаларда бер редактор һәм бер режиссёр график буенча атна дәвамындагы тапшыруларга анализ ясый, аларның уңай якларын һәм кимчелекләрен күрсәтә иде. Теләгән һәркем чыгыш ясап, үз фикерен әйтә. Баш редактор белән баш режиссёр да бәясен бирә. Летучканы телестудия директоры Хәйдәр Сөләйманович Шакирҗанов үзе алып бара һәм йомгаклау сүзен дә ул әйтә иде.

Х.С.Шакирҗанов телевидениегә килгәнче партия өлкә комитетында лектор булып эшләгән, Бөек Ватан сугышы ветераны, тормышның ачысын-төчесен күп татыган, бик әдәпле, мәсьәләне төптән уйлап хәл итә торган кеше иде. Ул үзенә авырлык килгән очракларда да объективлыктан, гаделлектән тайпылмады. Тәнкыйтьләргә туры килгәндә дә, ул кешене кимсетмәде, фикерен җайлап кына җиткерә белде. Шунысы үкенечле, пенсия яшенә җитүгә, Хәйдәр Сөләймановичны эшеннән җибәрделәр. Кемгәдер урыны кирәк булган, күрәсең. Бу хәлне телевидение авыр кичерде. Физик яктан нык кеше булса да, Хәйдәр абый еш авырый башлады, урын өстенә ятты һәм, үзе кебек үк акыллы хатыны Фәүзия ханымны, ике улын һәм оныкларын, бөтен телевидение коллективын ятим калдырып, бакый дөньяга китеп барды.

Рүзәл Юсупов тәҗрибәле, иҗади коллегаларыннан күп нәрсәгә өйрәнде, эфир журналистикасын үзләштерде. Хәлбуки, Казан телевидениесендә аңа үрнәк алырлык сәләтле шәхесләр шактый иде. Иҗтимагый-сәяси тапшыруларның баш редакциясен Итфал Ихсанов җитәкләде. Пропаганда редакциясе дә шушы баш редакция составында иде. Рүзәл әзерләгән тапшыруларның текстларын да ул тикшереп, редакцияләп, раслап җибәрә. Телевидение редакторлары һәм башка хезмәткәрләр аннан күп нәрсәгә — дөрес сөйләргә, әдәплелеккә, тыйнаклыкка, эзлекле фикер йөртергә, тапшыруларның композициясен оста төзергә өйрәнделәр. Итфал Исхакович — телевидениегә радиодан беренчеләрдән булып күчеп килгән редактор. Ленинградта ике еллык югары партия мәктәбендә укып кайткан. Буш вакытларында китап укырга ярата иде. Бик әзерлекле кешеләр белән дә теләсә нинди темага тиң булып әңгәмә ясарга, фикер алышырга сәләтле иде ул. Соңрак И.Ихсанов телевидениенең киноредакциясен оештырып, аның баш редакторы булып эшләде.

Казан телевидениесендәге әдәби-музыкаль тапшыруларның баш редакциясен ул чорда соңрак тәнкыйтьче булган, язучы, Муса Җәлилнең тормыш юлын, иҗатын җентекләп өйрәнгән Рафаэль Мостафин җитәкләде. Татар телен дә, рус телен дә яхшы белгән Рафаэль Әхмәтович ул вакытта тыелган яки онытылган бик күп шәхесләрнең исемнәрен халыкка кайтаруга күп көч куйды, бөтен гомерен шуңа багышлады, дисәк тә ялгыш булмастыр. Мин аның белән гомеренең соңгы көннәренә кадәр аралашып яшәдем.


Рүзәл Юсупов эшләгән алтмышынчы елларда телевидениедә баш режиссёр Гали Кәримович Хөсәенов иде. Телевидениегә Г.Камал исемендәге татар театрыннан килгән, һәрнәрсәне йөрәге аша үткәрә, тиз кабынып китүчән, кырыс кеше. Катлаулы тапшырулар әзерлеге барышын ул, гадәттә, үзе кызыксынып, тикшереп тора иде. Тапшыруны әзерләүче иҗат төркеменә киңәшләрен җиткереп торды. Спектакльләрне эфирга чыгарганда, пультка үзе дә килеп утыра иде. Авыр, фаҗигале язмышлы кешеләр турында тапшыру барганда елап җибәргән чакларын да хәтерлим мин аның. Гали Хөсәенов, телевидениедән киткәч, Әлмәт театрының баш режиссёры булды һәм анда эшләгәндә Габдулла Тукай премиясе алуга иреште.

Мәскәү кинематография институтын тәмамлап кайткан, кино, театр сәнгатен бөтен нечкәлекләре белән белгән режиссёр Эдмас Үтәгәнов та бу чорда иҗади активлыгы белән аерылып торды. Бик катлаулы тапшыруларны да җиренә җиткереп әзерли иде ул. Туры сүзле кеше: уйлаганын сәгате-минуты белән ярып сала, дипломатия саклап тормый. Аның бу сыйфаты җитәкчеләргә ошап бетми иде, әлбәттә. Шуңа күрә мактаулы исемнәр дә, зур бүләкләр дә бирмәделәр Эдмаска. Әмма ул моңа лаек иде.

Радио-телевидение комитеты — үзенә бер, телевидение тапшыруларын техник яктан тәэмин итә торган телеүзәк (телецентр) махсус икенче оешма иде. Аның директоры Георгий Бернардович Бобек бер үк вакытта комитет рәисе Ф.Г.Надыйровның урынбасары да булып саналды. Георгий Бернардович бик тыйнак кеше, оста җитәкче, талантлы инженер буларак хәтеремдә калган. Милләте буенча ул Идел буе немецы иде. Сталин әмере белән аның бөтен туганнарын, дус-ишләрен союз буенча таратып бетергәннәр. Ул ничектер Казанга килеп төпләнеп калган. Кайбер спорт сөючеләрнең исендәдер әле: аның улы Герман Бобек озак еллар Казанның «Рубин» футбол командасы капкачысы булды. Георгий Бернардович, улым яратмый, дип, азапланып булса да, тәмәке тартуны ташладым, дип сөйләгән иде.


Мин дә, Рүзәл дә эшләгән ул еллардагы телевидение дикторлары Айрат Арсланов, Әминә Сафиуллина, Иркә Сакаева, Абдулла Дубиннар бик оста эфир белгечләре иде. Эфирда үз-үзләрен тотышлары, оста, матур сөйләүләре, телне камил белүләре, гади генә, ләкин зәвыклы киенүләре белән алар тамашачыны сокланды-





*Р.Юсупов — радио тәрҗемәчесе. 1965 ел*

*Р.Юсупов — телевидение редакторы. 1967 ел*



*Телестудиядә эш вакытында. Казан, 1967 ел*

ралар иде. Бүгенге дикторлар алардан үрнәк алса, һич кенә дә начар булмас иде. Мин хәзер кайбер тапшыруларны алып баручыларның телне начар белүләренә, эфирга ярымшәрә чыгуларына оялып утырам.

Людмила Пивоварова Казан дәүләт университетына укытырга киткәч, Рүзәл редакциядә икенче Людмила белән эшли башлый. Монысы Людмила Ракиповна Мосягина була. Телне яхшы белә, әйбәт яза иде ул. Хискә бирелүчән, нечкә күңелле ханым буларак исендә калдыра Мосягинаны Рүзәл. Людмила Ракиповна берничә тапкыр телевидениенең партоешма секретаре булып сайланды. Соңыннан ул берничә ел КПССның Ленин райкомында идеология секретаре булып эшләде.

Казан телевидениесендә Туфан Миңнуллин, Рөстәм Кутуй, Роберт Миңнуллин, Әнәс Хәсәнов кебек исемнәре бөтен республикага яхшы таныш шәхесләр дә эшләде. Алар — республика телевидениесенең уңышларына зур өлеш керткән кешеләр. Танылган кино режиссёры Станислав Говорухин, үзәк телевидениенең беренче программасында озак еллар «Время» тапшыруларын алып барган Галина Зименкова шулай ук беренче чыныгуларын Казан телевидениесендә алалар.

Телевидение тарихының күп өлеше минем күз алдында үтте, дисәм, ялгыш булмастыр. Мин анда 26 ел чамасы эшләдем. Башта өлкән редактор, аннары егерме елга якын баш мөхәррир булдым. Берничә тапкыр партком секретаре итеп сайландым. Шуңа күрә бөтен коллектив белән кулга-кул тотынып эшләргә туры килде. Минем якташым, дустым Рүзәл Юсуповка телевидениедә күп эшләргә насыйп булмады. Шулай да зур канәгатьләнү белән искә ала ул гомеренең бу чорын. *«Казан телевидениесе миңа кызыклы, күркәм кешеләр белән якыннан аралашып, иҗади мохит шаукымын тоеп эшләргә мөмкинлек бирде»*, — дип яза ул үзенең истәлекләрендә.

Чыннан да бу чорда телевидениедә үткәрелгән һәр чара хезмәткәрләрнең тәҗрибәсен арттыру, аларның үсешенә ярдәм күрсәтү максатыннан оештырылды. Партия, комсомол, профсоюз җыелышларында теге яки бу бүлекнең эше анализланды, аерым хезмәткәрләрнең иҗат портретлары тикшерелде. Мондый гамәлләр һәркемне үз эше турында уйландыра, һәр адымына таләпчәнрәк карарга этәрә иде. Төрле тармакларда эшләүче хезмәт алдынгылары, җитәкчеләр, күренекле язучылар, артистлар, композиторлар, партия-совет эшлеклеләре белән очрашулар да даими үткәрелеп килде. Аларда эфир тапшыруларының сыйфаты, уңышлы һәм кимчелекле яклары турында сүз бара иде.

## ХУШ, ТЕЛЕВИДЕНИЕ, ИСӘНМЕ, ИНСТИТУТ...

1967 елның җәендә, телевидениедә әйбәт кенә эшләп йөргәндә, Казан педагогика институты ректоры Мирфатыйх Зәкиев Рүзәл Юсуповны үзе җитәкчелегендә аспирантурада укырга чакыра. Хәер, диплом алганда ук андый тәкъдим ясаган була ул аңа. Ләкин, бераз эшләп, матди хәлне яхшыртырга кирәк, дип, Рүзәл әдәпле генә баш тарта. Ярар, бер-ике елдан килерсең, дип, Мирфатыйх Зәкиевич шәкертен хезмәт юлына озатып кала. Билгеле, җитәкчесенең мондый ышаныч күрсәтүенә ныклы нигез дә була. Аның диплом эше фәнни яктан бик яхшы килеп чыга. Яклау вакытында оппонент, күренекле галим Фуат Ганиев күләме (200 битлек) һәм сыйфаты белән башкаларныкыннан шактый нык аерылып торган хезмәтне: «Бу инде диссертациягә тиң», — дип бәяли. Шуның өстенә, Рүзәл, уку дәвамында барлык имтиханнарны да «бишле»гә тапшырып, университеттан кызыл диплом алып чыга.

Телевидениедә эшләгәндә ул Казан педагогика институты аспирантлары белән бергә философия һәм немец теле дәресләренә йөри һәм ул фәннәрдән «кандидатлык минимумы» дигән имтиханнар тапшыра. Шулай итеп, аспирантурада уку чорында башкарылырга тиешле эшнең шактый өлешен алдан ук эшләп куя ул.

Телевидение белән саубуллашу моңсу була. Рүзәлнең эштән китү турында гариза белән керүен радио һәм телевидение комитеты рәисе Фаик Надыйров ошатып бетерми, бераз үпкә дә белдерә. Гомумән, Фаик Газизович кадрлар белән эшләүгә бик сак килә иде. Кешене эшкә алганда җентекләп тикшерү, сынау вакыты билгеләү, ә әйбәт эшләүчеләрне җибәрмәскә тырышу аның эш стиленә әверелде. Әгәр кайсыдыр хезмәткәр эшен тиешенчә башкара алмаса, аннан котылырга кирәк булса, бу вазифага конкурс игълан ителде (ул чорда андый система бар иде). Моңарчы телевидениедә эшләгән хезмәткәр конкурста җиңә алса гына вазифасында кала иде. Әмма андый очраклар телевидение һәм радио тарихында бик аз булды. Әгәр синең урыныңа конкурс игълан итсәләр, конкурс тәмамлануын көтмичә китеп баруың хәерлерәк.

Шулай бервакыт үзем дә Ф.Г.Надыйровка эштән җибәрүен сорап гариза белән кергән идем. Мин ул вакытта телевидениенең иҗтимагый-сәяси тапшырулар баш мөхәррире, бер үк вакытта җәмәгать башлангычы тәртибендә партком секретаре вазифасын да башкара идем. Партком секретареның эше тавык та чүпләп бетерерлек түгел. Район комитеты да, шәһәр комитеты да, өлкә комитеты да һәр адымыңны тикшереп тора. Әмма хезмәт өчен бер тиен дә акча түләмиләр. Рәхмәт әйтәсе урынга һәрвакыт әрләп торалар. Гариза бирү өчен җитди сәбәп тә булды. Менә нәрсәдән гыйбарәт иде ул. Телевидениенең яшьләр өчен тапшырулар редакциясендә режиссёр ассистенты булып яшь кенә егет Равил Гайнетдинов эшли иде. Тыйнак

кына егет, вазифаларын тырышып башкара. Шуны истә тотып, комсомоллар аны телестудиянең комсомол комитеты бюросы әгъзасы итеп сайладылар. Ләкин көннәрдән бер көнне Равилебез эштән китеп барды.

Мин үзем моңа әллә ни әһәмият бирмәдем. Яхшырак эш тапкандыр, дип уйладым. Егет әле яшь, бәлки, югары, һич булмаса урта махсус белем алырга телидер, дип исәпләдем. Режиссёр ассистентларының хезмәт хакы да кечкенә. Ашарларына да җитәр-җитмәс кенә. Равил Гайнетдинов эштән китеп, берничә көн узуга, зур тавыш купты. Равил телевидениедән генә түгел, Казаннан ук китеп барган икән. Бохара мәдрәсәсенә укырга кергән. Аның әтисе, бабасы, бөтен нәселләре дини кешеләр булганлыгын мин шул вакытта гына белдем.

Мине партия өлкә комитетының идеология секретаре Мөҗәһит Вәлиев чакырып алды да утлы табага бастырды, «республикада тәрбия эшен таркатучы, муллалар әзерләүче зат» дип атады. «Мы тебя самым строгим образом накажем», — дип озатты. Секретарь сүзендә торды, икенче көнне үк парткомның коллективта идеология эшен ничек оештыруын тикшерергә өлкә комитеты инструкторы Минвагыйз Зәйнетдинов җитәкчелегендәге комиссия килде. Максат куйгач була бит: комиссия «партком бернәрсә дә эшләми» дигән нәтиҗәгә ясады. Миңа, секретарь буларак, «строгий выговор» бирелде. Шушы ук комиссия соңрак парткомның комсомол комитетына җитәкчелеген, аннары коллективта атеистик тәрбиянең торышын тикшерде. Әлбәттә инде, комиссиянең бәяләмәсе нигезендә, миңа тиешле партия җәзасы бирелде.

Гаепсездән гаепләүләре минем гайрәтне чигерде, эштән күңел кайтты. Берничә выговорлы баш мөхәррир партком секретаре булырга тиеш түгелдер, дигән нәтиҗәгә килдем. Җитмәсә, берничә ай гына элек безгә тәҗрибә уртаклашырга килгән Якутия радио-телевидениесе комитеты рәисе урынбасары мине үзләренә эшкә чакырып киткән иде. «Берничә елга булса да безгә кил, кадрларны өйрәтеп китәрсең. Хезмәт хакың Казандагыдан ике ярым тапкыр артык булыр. Килүгә фатир бирербез. Казанга отпускка үз машинаңда кайтырсың», — дигән сүзләре турында уйлана башладым. Һәм, ниһаять, гариза язып, комитет рәисе Фаик Газизович янына кердем.

Ф.Г.Надыйров күзлеген салып өстәлгә куйды да бүлмә буйлап йөрергә тотынды. Аннары минем каршыга килеп утырып, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Тәрбияле кадрларның болай да аз икәнлеген син үзең дә яхшы беләсең бит. Бераз ял итеп ал, отпускка чыгып кер, тынычлан. Бик үк күп булмаса да, финанс ярдәме күрсәтү мөмкинлеген дә табарбыз.

Аннары комитет рәисе кабат күзлеген киде. Минем гаризаны кулына алды да почмагына «Отказать» дип язып куйды. Бераздан ул тагын сөйли башлады:

— Мин синең бернинди гаебең булмавын яхшы беләм. Бу хакта Вәлиевкә дә аңлатырга тырыштым. Равил Гайнетдиновны мәдрәсәгә укырга без җибәрмәдек бит. Ул бездән рөхсәт сорап тормады. Дини белем алырга теләге бар икән, алсын. Бәлки, киләчәктә туган авылына кайтып, мулла булыр. Шәле — республиканың иң зур авылларыннан берсе бит. Тырышса, авылында хөрмәтле кеше булыр.

Фаик Газизович хаклы булып чыкты. Равил Гайнетдинов Шәле мулласы булу белән генә чикләнмәде, бөтен Россия күләмендәге мөфтигә әйләнде. Хәзер ул — ислам дөньясында иң күренекле шәхесләрнең берсе. Равил Гайнетдинне телевизордан күргән саен, «строгий выговор»ларымны искә төшереп елмаеп куям. Дин дәүләттән аерылган дип исәпләнсә дә, дингә караш бөтенләй башка шул бүген. Кемнедер мәдрәсәгә укырга җибәргән өчен җәза бирмиләр, рәхмәт йөзеннән бары дога гына кылалар...

Рүзәлнең телевидениедән китүен өнәп бетермәсә дә, Фаик Газизович аны тоткарламады, гаризасына кул куйды. Теләге, мөмкинлеге барында укысын, дип уйлагандыр, күрәсең. Һәркемгә булдыра алган кадәр ярдәм кулы суза торган кеше иде шул ул. Урыны җәннәттә булсын! Шулай итеп, телевидение редакторы Рүзәл Юсупов 1967 елның октябреннән Казан дәүләт педагогика институты аспирантына әйләнде.

Шактый гына тормыш тәҗрибәсе туплап өлгергән була Р.Юсупов. Ул һәр адымын мөмкин кадәр ныклап уйлап башкарырга тырыша. Бөек галим Мичурин да: «Табигатьтән рәхимлекләр көтеп торып булмый, аларны яулап алу — безнең бурыч», — дигән бит. Тырышлык куймасаң, бернәрсәгә дә ирешеп булмый. Ныклы белем алуны максат итеп куйган Рүзәлгә, билгеле инде, яшәү шартларын үзенә кайгыртырга туры килә.

Юсуповларның барысы да олы абыйлары Равил шәһәр читендә салып чыккан таш йортта яшиләр. Әти-әниләре дә, авылдагы йорт-җирләрен, сыер-сарыкларын сатып, шунда килеп төпләнә. Алар белән бергә кече малайлары Мөнир дә Казанга килеп укый башлый. Наил, Рүзәл, Әнәс, армиядә хезмәт итеп, бер-бер артлы шушында кайталар. Равил Саимә исемле бер чибәр кызга өйләнеп тә җибәрә. Тиздән аларның малайлары дөньяга аваз сала...

Шулкадәр халык бер йортта бергә озак яши алмый, әлбәттә. Димәк, ничек кенә булса да, тагын бер куыш әмәлләргә кирәк. Һәм шулай эшлиләр дә. Равил үзе эшли торган авиация заводы җитәкчеләреннән җир кишәрлеге сорап ала. Юсуповлар, җиң сызганып, шунда Наил белән Рүзәлгә йорт салырга керешәләр. Башта ук аны, ике гаиләгә булыр дип, уртадан калын стена белән бүлеп эшләүне планлаштыралар. Төзелештә күпчелек эшләрне Юсуповлар үзләре башкара. Эш җиңел булмый, билгеле. Материал табу авыр була ул чакта. Финанс мөмкинлекләре дә чикле.

Йортның нигезе өчен ташны Семиозёрка авылы яныннан Равилнең үз машинасында ташыйлар. Йортның фундаментын да үзләре сала, кирпеч стеналарын да үзләре өя, түбәсен дә үзләре яба егетләр.

Университетта укыганда берничә җәйге каникулны, шулай ук шактый ял көннәрен йорт төзелешендә үткәрергә туры килә Рүзәлгә. Ленин стипендиясенең дә бер өлеше шушы төзелешкә кереп китә. Авыл малае барысына да түзә. Әти-әниләренең әллә ни ярдәм итә алмавын, финанс запаслары булмавын яхшы аңлый ул.

Юсуповлар гаиләсендә һәр вакыйганы бергәләп билгеләп үтү традициягә кергән була. Рүзәл университетны тәмамлап диплом алгач та, гаилә мәҗлесе үткәрелә. Рүзәлгә дә, әти-әнисе адресына да күп кенә җылы сүзләр әйтелә. Лотфикамал апаның хәтта күзләре дә яшьләнә. Аның малайларының һәркайсы, әниләренең гаилә өчен үзен аямавын күреп, хатын-кызга ихтирамлы булып үсте. Лотфикамал апа һәр киленен ипи-тоз белән каршы алды, үгет-нәсыйхәтен бирә барды. Аннары киленнәренең кайберләре белән берничә ел бергә яшәргә туры килде кайнанага. Алла рәхмәтедер инде, малайларына уңган хатыннар туры килде, әниләрен дә үз иттеләр, тату яшәделәр.

Малайларының бишесе дә акыллы, эшчән булса да, гомере буена бер кыз табып үстерә алмавына уфтанып куя кайчакта Лотфикамал апа. Ир бала кыз бала кебек киңәшкә ярамый шул. Ходай, аның ялваруларын ишетептер инде, яхшы киленнәр бирә. Тагын өч малаен өйләндерәсе бар. Аларына да әйбәт хатыннар туры килсен иде, дип тели ана.

Тормышның үз кануннары бар. Һич тә көтелмәгән вакыйгалар, очрашулар да булып ала. Көннәрдән бер көнне Рүзәл Олы Мәңгәр авылына әтисенең бертуганының кызы Рәйсә апаларына кунакка кайта. Олы Мәңгәр — данлыклы, зур авыл. Кышкардан ерак түгел. Рәйсә апасы мәктәптә татар теле укыта, кирәк чакта киңәшләрен дә бирә. Татар теленә мәхәббәт, бәлки, Рәйсә апасыннан да бераз күчкәндер Рүзәлгә.

Кунак егетне кичләрен өйдә утыртып булмый бит инде. Рүзәл клубка чыгып китә. Анда егетләр һәм кызлар күп була. Сөйләшергә, әңгәмә корырга ярата торган Рүзәл яшьләр белән тиз аралаша. Пөхтә генә киенгән, җитди кыяфәтле бер чибәр кызга игътибар итә ул. Егетләрдән сораштырып белә: шушы авылныкы, Казанда авиация институтында укый икән. Ул чорда авиация институты керү өчен дә, уку өчен дә иң авыр институтлардан санала. Димәк, кыз тырыш, уңган булырга тиеш, дип саный егет.

Рүзәл кызны танцыга чакыра. Бии-бии танышып та китәләр. Кыз Дилара исемле икән. Рүзәл аны өенә кадәр озатып куя. Бу кичнең күңелле һәм мәгънәле дә, өметле дә үтүен икесе дә тоя алар.

Казанга кайткач, яшьләр очраша башлый. Кыска гына вакыт эчендә бер-берсенә нык ияләшеп тә китәләр. Очрашуларда мәхәббәт уты кабына. Һәм көннәрнең берендә Диларага тәкъдим ясый егет. Бу вакытка шактый зур тормыш мәктәбен узып өлгергән Рүзәлнең яше дә бара. Егерме сигез тулып килә.

Өйләнешү — җитди, җаваплы гамәл. Рүзәл, Диларaның авылына кайтып, әти-әниләренең ризалыгын сорый. Булачак кияү белән әби-бабайлар якыннан таныша, аңлаша. Казанда Юсуповлар: Габдуллаҗан абый белән Лотфикамал апа, Равил, Наил, Әнәс һәм Мөнир дә Рүзәлнең өйләнүен хуп күрәләр, Диларaны ошаталар. Лотфикамал апа, башка киленнәре кебек, Диларaны: «Төшкән җиреңдә таш бул», — дип каршы ала, бал-май каптыра. Уртанчы улының да башлы-күзле булуына нык куана ана. Аның инде ике генә киленне каршы аласы кала. Әнәс белән Мөнирне дә өйләндерсә, өстеннән бурычы тулаем төшәчәк бит. Хәер, алары да бу изге эшне озак көттерми...

Туй күңелле үтә. Бу көнне Юсуповлар гына түгел, барлык дуслары, якыннары да бәйрәм итә. Диларaның да туган-тумачасы, дуслары, сабакташлары килә. Северный бистәсе өстенә җыр тарала: «Кил син, кил син безнең урамнарга...» Северный бистәсендәге Рүзәл яшәгән йортка аның белән бергә гомер кичерергә, гомер буе яратышып яшәргә дип килә Дилара. Рүзәлгә юлдаш та, теләктәш тә, терәк тә булырга дип килә.

*«Кыйммәтле, шаккатыргыч туйлар ясап йөрерлек түгел иде безнең хәлләр ул чакта (матди якны әйтүем),* — дип яза соңрак Рүзәл. — *Бары да гади генә, тыйнаклык белән генә. Әмма бәхет байлыкта, купшылык-зиннәтлелектә түгел. Кулыбыздан килгәнчә туй иттек. Мин инде күптән, әти-әнине борчымыйча, үзем тапканга яшәргә күнеккән идем. Ленин стипендиясе алганлыктан, кием-салымны да үз акчама ала идем, шуның өстенә, дүртенче курстан ук эшләп, әти-әниләр, туганнар ярдәме белән, торырга урын да әзерләп куйган идем. Туй чыгымнарын да үзем күтәрдем. Күңелле, истәлекле үтте туй. Северный бистәсендә моңарчы бергә яшәгән Равил абыйның өендә үткәрдек аны».*

Туйда Рүзәл белән бер группада укып чыккан егет-кызларның да күпчелеге катнаша. Группадашы Ленар Җамалетдинов белән бергә радионың музыкаль тапшырулар редакциясендә эшләгән Рафаэль Ильясов һәм баянчы Рамил Курамшин (хәзер Татарстанның халык артистлары) туйның бизәге була.

Аспирантурага укырга кергән елны өйләнә Рүзәл. Аннан соң инде күп сулар аккан. Аларның тормышларында вакыйгалар да күп булган, шатлыклар да, кайгылар да әйләнеп узмаган аларны. Дөнья шулай яратылган инде ул: күп кешеләрнең тормышы җиңел генә бармый. Юсуповлар гаиләсендә дә авырлыклар аз булмый. Өйләнешеп яши башлауның беренче еллары яшь гаилә өчен чын мәгънәсендә

сынау чоры була. Акча җитмәү, яшәү шартларының кырыс булуы үзен нык сиздерә. Аспирант стипендиясе зур булмый, Дилараның хезмәт хакы да зурдан кубарлык түгел. Бер елдан уллары Фәнис туа.

Дөрес, Рүзәл, гаиләнең матди хәлен җиңеләйтү өчен, кулыннан килгәнчә тырыша: тәрҗемә итә, нәшрият заказы буенча рецензияләр яза, тагын башка төрле вак-төяк эшләр башкара. Барыбер мохтаҗлыктан арынып булмый, акча җитми, еш кына күршеләрдән бурычка алып торырга туры килә. Диссертация язу да җиңел түгел, күп вакытны ала.

Яше тулганчы ук, улларын яслегә бирәләр. Дилара эшли башларга мәҗбүр була. Якын-тирәдә балалар комбинаты булмаганлыктан, Фәнисне еракка — Челюскин урамына йөртергә туры килә. Посёлокка автобуслар сирәк йөри, кайберләре туктап тормыйча узып кына китә. Диларага эшкә өлгерергә кирәк, Рүзәлгә исә берничә транспорт белән институтка барып җитәсе бар. Анда төрле чаралар еш булып тора, аларда катнашырга кирәк. Диссертация белән дә утырмый булмый. Тема моңарчы өйрәнелмәгән, катлаулы: «Русчадан татарчага тәрҗемә итүнең лексика мәсьәләләре». Димәк, ике телне дә камил белү зарур, күп материал кирәк.

Тырыша Рүзәл: кандидатлык диссертациясен билгеләнгән вакытыннан бер елга алданрак язып бетерә. Уңышлы гына яклый да. Диссертация яклагач, Казан педагогика институты ректоры Рүзәл Юсуповны татар теле кафедрасының өлкән укытучысы итеп билгели. Шулай итеп, яшь галимнең югары уку йортында эшләү чоры башлана. Бу 1970 елның язы була.

# ФӘН ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ ДӨНЬЯСЫНА НЫКЛЫ АДЫМНАР

## ФӘНҺӘМ МӘГЪРИФӘТ ДӨНЬЯСЫНА НЫКЛЫ АДЫМНАР

Укытучы булып эшли башлавына күп тә үтми, Рүзәл Юсуповны институтның тарих-филология факультетының партия оешмасы секретаре итеп сайлап куялар. Бу эш — җәмәгать башлангычы тәртибендә, ягъни бернинди түләүсез. Шул ук вакытта төп эшең булган укытуга да зыян килмәскә тиеш.

Партия оешмасы секретарьлыгы өчен хезмәт хакы түләнмәсә дә, эше муеннан була. Акча алып эшләүчеләрнекеннән һич кенә дә ким түгел. Чөнки факультет бик зур, үзе бер кечерәк югары уку йорты кадәр. Ул чакта партиянең абруе көчле иде, шунлыктан партия оешмасы секретарена куелган таләпләр дә югары була. Укыту вазифаларыннан кала, факультеттагы барлык эшләр партоешмага, аның секретарена йөкләнә. Студентларны тәрбияләүнең киңкырлы эш икәнлегенә университетта укыганда ук нык төшенгән була инде Р.Юсупов.

Ышаныч казанып өлгергәч, аңа бик кирәкле кеше итеп карый башлыйлар. Ректор Мирфатыйх Зәкиев җаваплы участокларны күбрәк Р.Юсуповка тапшырырга тырыша. Ник дисәң, ул — ышанычлы кеше, бервакытта да башлаган эшен җиренә җиткермичә туктамый. М.Зәкиев шәкертенең мондый сыйфатларын ул факультетның комсомол секретаре булганда, диплом язганда да күреп өлгергән була.

Рүзәл Юсуповка җиңел генә, җаен белеп кенә яшәргә дә була, әлбәттә. Тик ул алай булдыра алмый, ни дисәң дә «оеткысы» башка. Әтисе Габдуллаҗан абый да, әнисе Лотфикамал апа да җиңел кәсеп эзләп йөрүчеләрне яратмадылар, улларына хезмәтне җигелеп башкару, һәр эшне җиренә җиткереп үтәү гадәте иңдерделәр. Шуңа күрә әти-әниләре биргән тәрбия балаларына гомерлек юлдаш булып килә. Бары тик үз көчләре, үз тырышлыклары белән яулап ала алар биеклекләрне.

Авыл мәктәбендә, Казан кооперация техникумында укыганда, Курган далаларында һәм Памир тауларында салынган оеткы — туган телне, аның үзенчәлекләрен, зурлыгын, бөеклеген ачыклау теләге тынгылык бирми Рүзәлгә. Үзенең бөтен барлыгы белән омтыла ул бу максатка. Туган телнең бөтен нечкәлекләрен, матурлыгын, башка телләргә тәрҗемә итү үзенчәлекләрен өйрәнү теләге белән яна ул. Туган халкына ихтирамын, аны яратуын шул газиз туган телен җентекләп өйрәнүе белән белдерергә тырыша Кышкар егете.

Дәресләре булса-булмаса да, һәр көнне иртәдән кичкә кадәр институтта булырга туры килә. Северный бистәсеннән шәһәр үзәгенә йөрү уңайсыз. Берничә транспортта барасы. Кышкы салкын көннәрдә автобусларны яртышар сәгать, хәтта артыграк та көтәргә туры килә. Кайчак, түземлегең беткәч, җәяү китәсең. Җитмәсә, Рүзәлнең кулында һәрвакыт зур портфель була. Анда, китап-дәфтәрләрдән тыш,

азык-төлек тә салынган була. Ник дигәндә, ризыкка кытлык чор. Северный бистәсе кибетләрендә балык консервлары белән уксус шешәләреннән башка әйбер сирәк күренә. Шуңа күрә кичләрен өйгә азык-төлек әйберсеннән нәрсә дә булса табып алып кайтырга тырышасың.

Гаиләдә хатын-кызга тагын да авыррак. Йорттагы мәшәкатьләрнең күбесе Дилара өстенә төшә. Уллары Фәнискә биш яшь тулгач, Юсуповларның кызлары Диләфрүз дөньяга аваз сала. Аны да 11 айдан балалар бакчасына урнаштыралар. Чөнки Диларaның эшкә чыгасы бар. Җитмәсә, әле ул читтән торып институтта да укып йөри. Адәм баласы, бигрәк тә крестьян баласы, авырлыкларга түзә инде ул!

Дөрес, бераз соңрак, Рүзәл кандидатлык диссертациясен яклап, доцент булгач, гаиләнең матди хәле җиңеләя төшә. Дилара да яңа эшкә күчә: «Татхимфармпрепараты» берләшмәсендә профсоюз комитеты рәисе булып эшли башлый. Әмма мәшәкатьләр әллә ни кимеми.

Университетта укыганда «тәрҗемә җене» кагылганнан, ягъни тәрҗемә эшенең теориясен, кагыйдәләрен өйрәнә башлаганнан бирле, Рүзәл үзе дә азмы-күпме тәрҗемә эше белән шөгыльләнә. Юкарак фәнни-техник китаплар, сәяси эчтәлекле басмалар һәм берникадәр В.И.Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. «В.И.Ленин, Фридрих Энгельс и Карл Маркс об искусстве», «В.И.Ленин о религии» дигән китапларны, В.И.Ленин әсәрләренең тулы басмасының соңгы ике томын тәрҗемә итү бик авыр була. Алар нәшриятта басылып чыга. Кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң, Татарстан китап нәшриятында Р.Юсуповның бер-бер артлы «Тәрҗемә теориясенә кереш», «Тәрҗемә мәсьәләләре», «Тәрҗемә һәм тел культурасы» исемле һәм татар теле гыйлемендә мөһим урын тоткан башка хезмәтләре дөнья күрә.

*«Бу эшләрнең миңа файдасы икеләтә булды,* — ди Рүзәл. — *Беренчедән, шактый гына гонорар алдым, икенчедән, үземнең алдагы фәнни эшем өчен материаллар тупладым. Аннан килеп, миңа Татарстан китап нәшриятында тәрҗемә китапларының кульъязмаларына рецензияләр язу эшен тапшыралар иде. Моның да файдасы тиде. Минем бу эшләр турында сөйләвемнең хикмәте — аларның минем докторлык диссертациясенең темасын билгеләү өчен этәргеч булуында».*

Тәрҗемә белән даими шөгыльләнү яңа фикерләр уята һәм кайбер фәнни серләрне ачыклый төшәргә мөмкинлек бирә. Татар һәм рус телләре күренешләренең һәркайсының үзенә генә хас специфик үзенчәлекләре булу белән бергә, икесе өчен дә гомуми сыйфатларның да булуы күренә. Төрле телләрдәге бу гомумилек һәм үзенчәлек философиядәге «гомуми һәм специфик нәрсәләрнең диалектик бердәмлеге» дигән закончалыкка нигезләнә. Бу юнәлешләрне бөтен нечкәлекләре белән җентекләп өйрәнергә кирәк, дигән карарга килә Рүзәл. Берникадәр уйланып йөр-

гәч, татар һәм рус телләрендәге гомуми һәм үзенчәлекле чараларны ныклап анализлап, фәнни яктан нигезләп, зур гыйльми хезмәт рәвешендә язып чыгарга ниятли ул. Шулай итеп булачак докторлык диссертациясенең темасы ачыклана: «Общее и специфическое в лексико-семантической и фразеологической системе русского и татарского языков».

Тема сайлау, диссертациянең исемен билгеләү — зур, катлаулы эшнең беренче адымы гына. Язарга керешкәнче, бик күп теоретик материал белән танышып чыгарга, фактик материал җыярга, фикерләрне системага салып, план төзергә, башка төрле гамәлләр кылырга кирәк. Р.Юсуповның докторлык диссертациянең темасы ике тел нисбәтен өйрәнү белән бәйле булганлыктан, мәсьәлә тагын да катлаулана төшә. Тема киң, күп материал тупларга кирәк, ике телнең дә үзенчәлекләрен яхшы белү зарур.

Рус һәм татар телләрендәге гомуми һәм специфик лексик-фразеологик чараларның бу ике телдә кулланылу үзенчәлекләрен ачыклый галим. Моның өчен телләрне чагыштыру алымнарын кулланып эш итә. Гомуми сыйфатлар, образларның асылы ике телдә бер төрлерәк, әйтелешләре, формалары гына башкачарак. Әмма аерым бер телнең үзенә генә хас үзенчәлекле яклары да аз түгел. Әйтик, татарлар «бите алма кебек», «шомырт кебек күзләре» дип сөйлиләр. Болай сөйләү татар теленә генә хас. Руслар кешенең битенә карата һич тә «как яблоко» дигән чагыштыру кулланмый. Галимнәр, татар телендәге кайбер төшенчәләрне русчага төгәл мәгънәсендә бөтенләй тәрҗемә итеп булмый, диләр. Күренекле рәссам Бакый ага Урманче, «сагыш» сүзен русчага тәрҗемә итеп булмый, дип саный иде. «Наз», «моң» төшенчәләренең дә тулы мәгънәләрен рус телендә бирү авыр. Шуларның барысын да истә тотып, мәсьәләне тагын да тирәнрәк анализлау кирәклеген аңлаган хәлдә, доцент Р.Юсупов эзләнүләрен тагын да җәелдерә бара. Һәм, ниһаять, төрле телләрдә аралашуның гомуми лексик фондның киңәюенә китерүен бөтен тулылыгы белән раслый.

Галимнең «Рус һәм татар телләренең лексик-фразеологик чаралары» дигән монографиясен белгечләр, тел гыйлеменең яңа бер өлкәсе булган контрастив лингвистикага караган ачыш, дип бәялиләр. Биредә, беренче тапкыр буларак, рус һәм татар телләрен янәшә куеп өйрәнүгә кагылышлы күпкырлы анализ ясала. Сүз уңаеннан шунысын да искәртеп үтү урынлы: моңарчы тәрҗемә теориясенә кагылышлы фәнни хезмәтләр бөтенләй булмый диярлек.

Ниһаять, эш ахырына якынлаша. Үткән гасырның сиксәненче еллары ахырында Рүзәл Юсуповның докторлык диссертациясе яклауга әзер була инде. Әмма катлаулы, күпкырлы һәм гаять зур практик әһәмияткә ия булган әлеге хезмәтнең мөһимлеген аңлаучылар ул вакытта, мөгаен, әллә ни күп булмагандыр. Чөнки та-

тар телендә сөйләшүчеләр кими барган, күпчелек тармакларда туган телебез кулланыштан төшеп калган чор иде бу. Шулай да тагын 10—15 елдан икетеллелек мәсьәләсенең яңадан калкып чыгу мөмкинлеген, Татарстанда татар теленең рус теле белән беррәттән дәүләт теле дип игълан ителәчәген, күрәсең, Рүзәл алдан тоя белгән, сизенгән. Шул ягы белән дә зур әһәмияткә ия бу хезмәт.

Әмма ул чорда бу хезмәткә тиешле бәя бирүчене табу җиңел булмый. Диссертациянең язылып бетүен белгән галимнәр дә тыныч кына йөри бирә, аны яклау өчен ярдәм күрсәтергә алынмый. Рүзәлнең темасы — рус-татар телләрен чагыштырып өйрәнү буенча докторлык диссертациясен яклата торган совет илдә бөтенләй булмый. Хәер, Мәскәүдә ниндидер специфик тема буенча язылган хезмәтне яклату өчен вакытлы совет җыярга мөмкин. Ә кем йөри аның артыннан?! Факультет деканы Михеева болай да Рүзәлне бик өнәп бетерми. Чөнки Р.Юсупов еш кына, партоешма секретаре буларак, җыелышларда аның җитәкчелек эшендәге кайбер кимчелекләрне күрсәтә, аларны бетерү кирәклеген әйтә. Бу усал холыклы ханым — элекке партком секретаре — тәнкыйтьне тыңларга күнекмәгән. Җае чыккан саен «әҗерен кайтару» ягын карый. Ректор М.Зәкиевнең дә үз мәшәкатьләре җитәрлек. Аннары Рүзәлнең доцент булып эшләп йөрүе, институттагы күп төрле җаваплы эшләрне карусыз алып баруы аның өчен кулайрак та әле. М. Зәкиев бу тема буенча докторлык диссертациясе яклап булуына ышанып та бетми. Илдә бу өлкәдә белгечләрнең, танылган докторларның бик аз булуын, махсус советның юклыгын яхшы белә ректор.

Шулай итеп, тарихи әһәмияткә ия фәнни хезмәт киштәдә тузан җыеп ята бирә. Нәрсә эшләргә? Эшне кайдан башларга? Белешә торгач, Р.Юсупов моның бер юлын ачыклый. СССР Министрлар Советы карамагындагы югары аттестация комиссиясе (ВАК) рөхсәте белән, берәр гыйльми учреждениенең рус теленнән диссертация яклату советына өстәмә дүрт-биш галим — төрки телләр белгечләрен кертеп, бер тапкыр гына махсус яклату оештырырга мөмкин. Әмма бу — бик катлаулы, авыр гамәл. Моны Казанда башкарып булмый. Димәк, Мәскәүгә барып, берәр әмәлен эзләп карарга кирәк. Шундый фикергә килеп, Мәскәүгә юл тота галим. Анда берничә советка мөрәҗәгать итеп карый. Алынасылары килми, чөнки алар өчен бу өстәмә мәшәкать кенә бит. Матди яктан ныклап кызыксындырганда, бәлки, эшкә тотынырлар да иде. Ләкин моның өчен акча каян аласың?!

СССР Фәннәр академиясенең Тел гыйлеме институтындагы төрки һәм монгол телләре бүлеге мөдире, СССР Фәннәр академиясе академигы, дөньякүләм зур абруйлы галим Әдһәм Рәхимович Тенишев янына барырга, дигән уйга килә Рүзәл. Кандидатлык диссертациясе яклаганда, Әдһәм Рәхимович Рүзәлнең оппоненты була. Шунда танышып калган булалар алар.

Бу вакыйгадан соң инде күп еллар үтсә дә, Рүзәл Әдһәм Рәхимовичны һаман да олы рәхмәт хисләре белән искә ала. Бу изге затка гомере буе рәхмәт укый: *«Әдһәм Рәхимович сүземне кире какмады, шул чакта да, соңыннан да миңа нык ярдәм итте. Ул булмаса, мин диссертацияне, бәлки, тиз генә яклый да алмаган булыр идем әле»*, — ди ул.

Бераз уйланганнан соң, Ә.Р.Тенишев, Р.Юсуповның диссертациясен яклауга кабул итүен үтенеп, СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институты директоры академик Федот Петрович Филинга мөрәҗәгать итә. Телефоннан сөйләшкәннән соң, алар директорның эш бүлмәсенә Рүзәл белән бергә гариза язып керәләр. Мәһабәт гәүдәле, калын тавышлы Федот Петрович кунакларны бик итагатьле кабул итә, ашыкмыйча, иркенләп сөйләшә һәм диссертацияне яклауга кабул итәргә рөхсәт бирә. Билгеле инде, Р.Юсупов бик шатлана, әмма бераз шүрли дә. СССР Фәннәр академиясенең Рус телен фәнни тикшерү институтында докторлык диссертациясе яклау — мәртәбәле дә, җаваплы да. Анда дөньяга мәгълүм рус галимнәре эшли. Татар авылында туып-үскән, татар мәктәбендә, аннары университетның татар бүлегендә укыган кешегә шулар каршында гаять зур имтихан тотарга туры килә бит.

Яклауга рөхсәт алу эшнең башы гына була әле. Хәзер инде диссертация яклауда катнашырга риза булырлык һәм оппонентлар булып чыгыш ясарлык рус һәм төрки телләр галимнәрен табарга, аннары ВАКның аларны совет составына кертүе турында приказ чыгаруын көтәргә кирәк була. Шуннан соң оппонентларның, диссертацияне укып чыгып, бәяләмә язып бирүләрен көтәсе була.

Вакытлы советның составын билгеләүгә дә Әдһәм Тенишев күп көч куя. Советка, аның инициативасы белән, рус һәм төрки телләрне чагыштырып өйрәнү буенча танылган галимнәр Ә.Тенишев, Ә.Юлдашев, С.Мусаев, В.Иванов кертелә. Оппонентлар итеп академиклар Н.Шанский, Ә.Тенишев, профессорлар Л.Скворцов, Л.Новиков билгеләнә. Совет әгъзаларының Рүзәлгә җылы мөнәсәбәте сизелә. Ихтимал, монда Әдһәм Рәхимовичка ихтирам белән карауларының да тәэсире булгандыр.

Бәла аяк астыннан чыга, диләр бит. Яклау көне якынлашканда, көтмәгәндә, институт директоры Ф.П.Филин вафат була. Яңа директор билгеләп куйганчы, яклау кичектерелеп тора. Ярты елга якын көтәргә туры килә. Ниһаять, ыгы-зыгылар артта кала. Яклау көне килеп җитә. Әмма оппонентларның берсе академик Н.Шанскийның әле һаман да бәяләмә язарга вакыты табылмый. Бу хакта борчылып, советның гыйльми секретаре В.Белоусов Рүзәлгә хәбәр итә. Ярдәм сорап, тагын Әдһәм Рәхимовичка мөрәҗәгать итәргә туры килә. Ниһаять, Рүзәл иртәгә яклау буласы көннең кичендә генә Н.М.Шанскийдан бәяләмәне алып кайта. Аның искәрмәләренә җавапны Рүзәл төнлә яза. Ул язып бетерүгә, Дилара аны машинкада басып бирә.

Оппонентларның бәяләмәләрендә бу хезмәтнең татар һәм рус телләре өчен генә түгел, барлык төрки телләр өчен дә әһәмияткә ия булуы күрсәтелгән була. Бу

фикер куандыра диссертантны. Билгеле, оппонентлар кайбер тәкъдимнәрен дә, киңәшләрен дә бирәләр. Киләчәктә, һичшиксез, алар диссертант тарафыннан аның алдагы хезмәтләрендә искә алыначак.

Төн йокысыз диярлек үтсә дә, Рүзәл белән Дилара иртәгәсен, соңармыйча, башкаланың Волхонка урамында урнашкан Рус теле институтына килеп җитәләр. Диссертация яклау процедурасы башлана. Залда — дөньякүләм танылган галимнәр, рус һәм төрки телләрнең төп белгечләре. Салмак кына, әмма ышанычлы тавыш белән сөйли Р.Юсупов. Торган саен галимнәрнең игътибарын үзенә ныграк җәлеп итә бара.

Ул минутларда ничек борчылганын, дулкынланганын диссертант үзе генә белә. Шулай булмый соң! Ничә ел җәфаланып язган хезмәтнең язмышы, дөресрәге, ул хезмәтнең иясе язмышы хәл ителә бит. Тарихта беренче тапкыр татар егете иң дәрәҗәле галимнәр алдында ике телне чагыштырып, ул телләрнең нисбәтен, үзенчәлекләрен ачып бирә, аларның закончалыкларын күрсәтә. Оппонентлар фәнни хезмәтне уңай бәяли. «Филология фәннәре докторы» дигән гыйльми дәрәҗә бирергәме, юкмы, дигән карар совет әгъзаларының яшерен тавыш бирү юлы белән хәл ителә. Совет әгъзалары докторантны яклап тавыш бирә. Шулай итеп, Кышкар Габдуллаҗаны малае Рүзәл Юсупов өчен гаять мөһим, чын мәгънәсендә тарихи вакыйга уңай хәл ителә: совет аңа, докторлык гыйльми дәрәҗәсе бирергә, дигән карар кабул итә. Бу Рүзәл Юсупов тормышындагы иң әһәмиятле, иң шатлыклы вакыйга, зур җиңү, чираттагы авыр сынауны уңышлы узу була.

Карар игълан ителгәч, тәбрикләүләр башлана. Әдһәм Тенишев Рүзәлне кочаклап ук ала. Аның күзләрендә яшь бөртекләре күренә: шулкадәр борчылган да, шатланган да була ул аның өчен. Бер татар егетенең олы юлга чыгуын һәм монда үзенең дә лаеклы өлеше булуын тоеп шулай куана бу дөнья күләмендәге зур галим.

Бу урында диссертантның үзенә дә сүз биреп китү мәгъкуль булыр:

*«Инде бу хәлиткеч шатлыклы вакыйганы сурәтләгәндә, диссертацияләрне (кандидатлыкны да, докторлыкны да) язганда иң зур ярдәм күрсәткән кешенең исемен атамасам, бу гаделсезлек булыр иде,* — ди Р.Юсупов. — *Ул — хатыным Дилара. Ул диссертацияләрнең икесен дә (ә бу — берничә йөз бит) комиссион кибеттән арзанга гына сатып алган иске «Москва» машинкасында басып чыкты. Аны әле бер тапкыр гына басып калып булмый: төзәтеп, кабат-кабат басарга туры килә. Күп кенә мәкаләләрне дә, монографияне дә ул басты. Ул эшләрне, ул вакытларны аңа зур рәхмәт хисләре белән искә алам.*

*Тагын шуны да әйтергә бурычлымын: әлбәттә, беренче чиратта изге кеше Әдһәм Рәхимовичка рәхмәт укыйм. Мәрхүм булды инде ул, урыны җәннәттә булсын. Калган оппонентларыма да, институт директоры академик Федот Петрович Филинга, институт директоры урынбасары профессор Валерий Васильевич*

*Ивановка да, советның гыйльми секретаре В.Белоусовка да ярдәмнәре өчен еш кына эчемнән рәхмәтләр укыйм.*

*Гомумән, СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институты коллективы миндә уңай тәэсир калдырды. Яклауга әзерлек барышында, яклау процессында һәм соңыннан да институт хезмәткәрләренең һәркайсы миңа теләктәшлек белдереп, күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итеп торды.*

*Докторлык диссертациясе язу, «фәннәр докторы» дигән гыйльми дәрәҗә алу, аннары тиздән «профессор» исеме бирелү минем эшемдә һәм гомумән тормышымда җитди борылышларга нигез булды».*

Берничә көннән «Татарстан» поезды әле яңа гына «пешеп чыккан» докторны туган ягына алып кайтып китә. Хуш, Мәскәү! Хушыгыз, игелекле затлар… Тенишев һәм Филиннар, Юлдашев һәм Мусаевлар, Шанский һәм Ивановлар, Скворцов һәм Новиковлар… Рәхмәт сезгә, татар халкының гади бер улының тыйнак кына хезмәтен олуг бәяләвегез, аңа ярдәм кулы сузуыгыз өчен…

Юл буе шуларны күңеле аша кичереп кайта Рүзәл. Һәр мизгел бер-бер артлы күз алдыннан үтә. Мәсьәлә инде хәл ителгән булса да, күзенә барыбер йокы керми. Мөгаен, монысы инде куанычтан, дулкынланудандыр...

* * *

Казан үзенең галим улын тыйнак кына каршылый. Шул ук йортлар, урамнар, шул ук хезмәттәшләр... Берәүләр Рүзәлне докторлык дәрәҗәсе алуы белән чын күңелдән кайнар котлый, уңышлар, сәламәтлек тели. Кайберәүләр исә яшь докторны көндәш буларак кабул итә. Рүзәл Юсуповның факультет деканы белән мөнәсәбәтләрен моңарчы да дустанә дип әйтеп булмый иде. Партия оешмасы секретаре буларак факультет җитәкчелегенә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләре ошамый иде деканга.

«Профессор» исеме алганнан соң, деканның Рүзәлгә карашы тагын да кискенләшә, юк-бар сәбәпләр табып туктаусыз бәйләнә башлый ул. Үзенә җитди көндәш дип санаган булса кирәк Юсуповны. Шулай бер көнне Рүзәлне хәтта дәрес биргәндә дә деканатка чакырып алалар. Бернинди дә ашыгыч хәл итәргә кирәкле нәрсә юк икән бит, югыйсә.

— Сезгә беркетелгән группа студентлары ни өчен тулай торакта яшәми? Пропискага кергәннәр, ләкин яшәмиләр. Ни өчен шөгыльләнмисез бу мәсьәлә белән? — ди декан, тавышын күтәрә төшеп.

— Әллә янгын чыкканмы дип торам. Моны әйтү өчен дәрестән чакырырга кирәк идеме? Ничек инде шуны да аңламаска? — ди Р.Юсупов, елмая төшеп.

Бу вакыйгадан соң декан башкачарак үч алу ягын карый. Эзләгән кешегә җае чыга бит аның. Сентябрь аенда «яна» торган юллама туры килгәч, Рүзәл Һиндстан-

га турист булып китеп бара. Бу хакта деканга әйтә, ул риза була. Җәйге отпуск вакытында алган больничный исәбенә булыр, административ отпуск рәсмиләштерүнең кирәге юк, диләр кадрлар бүлегендә.

Әмма Һиндстаннан кайтуына, «рөхсәтсез киткән өчен» дип, приказ белән Р.Юсуповка шелтә белдереп куйганнар. Кайтуын көтеп тә тормаганнар. Декан киткәнче үзе белән булган сөйләшүне инкарь итә. Шелтәнең хаксыз бирелгәнлеген аңлатып, ректорга язу кертә Р.Юсупов. Әмма ул нәтиҗә бирми. Ачыктан-ачык әйтмәсә дә, олы яшьтәге деканның факультетта яшь профессор булуын өнәмәве күренеп тора. Ихтимал, кафедра мөдиренә дә үзе белән янәшәдә Мәскәүдәге Рус теле институтында докторлык диссертациясе яклап кайткан профессор булуы ошап бетмәгәндер: бер казанга ике тәкә башы сыймый, диләр бит. Максат куелган икән, аңлатма гына коткармый. Шелтә барыбер үз көчендә кала.

Бу хәлне Рүзәл авыр кичерә. Ректор янына сөйләшергә керә.

— Нигә шулкадәр мыскыл итәсез? Нигә шелтә бирергә кирәк иде? Минем гаебем юк бит. Күпме көч куеп, барлык буш вакытымны җәмәгать эшенә бирүемне күреп торасыз бит, — ди ул.

— Миңа бу очракта сезне якларга ярамый иде. Якласам, шәкертенә тел-теш тидерми, дип әйтәчәкләр иде, — ди ректор.

— Аңлашыла, — ди Рүзәл. Мондый очракта бүтән сөйләшеп торуның мәгънәсе юклыгын аңлый.

Хәл катлаулана. Биредә мин кайберәүләргә комачаулык тудырам булса кирәк, дип уйлый Юсупов. Һәм, үзем укып чыккан Казан дәүләт университетына күчәргә кирәк, дигән фикергә килә. Университетта аны белгән кешеләр күп.

Университет ректоры А.И. Коновалов Рүзәл Юсуповның теләгенә каршы килми. Аның өчен махсус рәвештә татар мәктәпләрендә рус теле укыту кафедрасы ачарга, Рүзәлне шуның мөдире итеп куярга була.

Чыбыксыз телефон тиз эшли: Рүзәлнең университетка күчәргә ниятләве турындагы хәбәр педагогика институты ректоры Мирфатыйх Зәкиевкә килеп ирешә. Ул уйга кала. Яхшы әзерлекле, эшчән яшь ир кешене башка җиргә җибәрәсе килми аның. Һәм Рүзәлне үзенә чакырып ала. Башта аның китәргә җыенуының сәбәпләрен ачыклый.

— Мин монда үземнең кирәк түгеллегемне аңладым, — ди галим.

— Син монда да бик кирәк. Без сине декан итеп куярга уйлыйбыз, үзең эшли торган факультет деканы итеп, — ди ректор.

— Рәхмәт. Мин тәкъдимегезне кабул итә алмыйм, — дип чыгып китә Рүзәл.

Берничә көннән шушы ук мәсьәлә буенча ректор аны кабат үзенә чакыра. Озак сөйләшәләр һәм, ниһаять, килешәләр. Рүзәл Юсупов үз өстенә авыр йөк алуын яхшы аңлый. Чөнки декан вазифасы кешеләр белән эшли белүне, тырышлык таләп

итә. Факультет зур, катлаулы, күп төрле белгечләр әзерләнә. Эш муеннан. Шулай да бик үк хафаланырлык сәбәп тә юк. Дүрт ел партия оешмасы секретаре, декан урынбасары булып эшләп бай тәҗрибә туплады бит инде ул. Деканлык эше аңа таныш. Факультетны яхшы белә, коллектив белән мөнәсәбәте начар түгел.

Кыска вакыт эчендә үзенә тапшырылган вазифаның бөтен нечкәлекләренә төшенә Рүзәл Юсупов. Яңа себерке яңача себерә, ди халык. Хак сүз. Тик Р.Юсупов үзен күрсәтер, танытыр өчен түгел, ә булсынга, яхшы әзерлекле, чын педагоглар әзерләп чыгару өчен тырыша. Уку-укыту методикасы камилләштерелә, яңа уку алымнары кертелә, заманча сулыш, демократия рухы белән сугарылган кулланмалар чыгаруга игътибар бирелә, һәм факультетта башка уңай үзгәрешләр башлана.

Ләкин аңа декан булып озак эшләргә туры килми. Уйламаганда, көтмәгәндә язмыш мәсьәләне үзенчә хәл итеп куя.

## ҖИТӘКЧЕЛЕК ЭШЕНДӘ КӨЧ СЫНАУ

Көтмәгәндә генә Казан педагогика институты ректоры Мирфатыйх Зәкиевне Тел, әдәбият, тарих институтының директоры итеп билгеләп куялар.

Педагогика уку йортына яңа җитәкче кирәк була. Партия өлкә комитетының җаваплы кешеләре ректорлыкка кандидатура эзләү белән шөгыльләнәләр. Бу мәсьәләдә Мирфатыйх Зәкиевичнең дә фикерен сорыйлар. Ул үз урынына пединститутның фәнни эшләр буенча проректоры Фәрит Ситдыйковны тәкъдим итә. Бу уку йортында күптәннән эшли, коллективны яхшы белә, дип

Шулай да мәсьәлә тиз генә хәл ителми. Әллә өстәгеләрнең үз мәшәкатьләре күп була, әллә инде кемгәдер кандидатура ошап бетми: институт ректорсыз яши бирә. Көннәрнең берендә Рүзәл Юсуповны партия өлкә комитетына чакырып алалар. Институт хәлләре турында сораштыралар. Әңгәмә барышында Рүзәлдән: «Сез ректор итеп кемнәрне тәкъдим итәр идегез?» — дип сорыйлар. Ул берничә кешене атый, аларның эшенә кыскача гына бәя бирә.

...Берничә көннән Рүзәлне өлкә комитетына тагын чакырып алалар. Әңгәмә ахырында: «Ректорлыкка сине тәкъдим итсәк, нәрсә әйтерсең?» — диләр. Рүзәл Юсупов ректорлыкның гаять катлаулы һәм җаваплы эш икәнен белә. «Мин әле мондый зур эшкә әзер түгел», — дип җавап бирә ул. «Уйлап кара әле», — дип кайтарып җибәрәләр аны.

*«Мин җитәкчеләр, гадирәк итеп әйткәндә, «начальниклар» бик җитди, кырыс, кискен тавышлы, команда гына биреп эшләргә күнеккән кешеләр була, югыйсә, хезмәткәрләре аны тыңламый, санга сукмый дигән фикер хөкем сөргәнлеген белә*

*идем. Төгәлрәк итеп әйткәндә, бу — совет системасындагы җитәкчеләрнең (зурысының да, кечкенәсенең дә) стереотибы иде. Ә мин үземне салмак табигатьле, тыныч холыклы, тавыш күтәреп сөйләшергә яратмый торган, оялчан, демократ кеше дип беләм. Андый кеше җитәкче (бу очракта меңнәрчә кешедән торган зур коллектив җитәкчесе) була алырмы, дигән шигем бар иде. Әмма мин ул елларда туристлык путёвкалары белән чит илләргә йөргәндә күрә идем: андагы җитәкчеләр үз кул астындагы кешеләр белән тупас мөгамәлә итми, тавыш күтәрми һәм, гомумән, башка илләрдә, бигрәк тә Көнбатыш Европа илләрендә, зур эш өчен җаваплы кеше — гади кешедән, бай ярлыдан аерылып та тормый. Миңа җитәкчеләрнең һәркем белән әдәпле, сабыр, тыныч тавыш белән сөйләшүләре ошый»*, — дип сөйли Рүзәл Юсупов.

Өченче тапкыр Рүзәлне партия өлкә комитеты секретаре Рәис Кыямович Беляев чакырып ала. Ул, аның белән берникадәр сөйләшкәннән соң, турыдан-туры сорау бирә:

— Я, ничек, хәл иттеңме ректорлык мәсьәләсен?

— Булдыра алырмынмы икән, Рәис Кыямович, бик зур эш бит, — ди Р.Юсупов.

— Син булдырырсың, Рүзәл. Әйдә, эшлә, институтны тагын да алга җибәр. Мин сиңа ышанам, — ди секретарь.

— Рәхмәт, Рәис Кыямович! Ышанычыгызны аклау өчен, үземне аямыйча тырышырмын, — дип җавап бирә Рүзәл.

Рүзәл Юсупов үзен сынап карарга, чын цивилизацияле илләрдәгечә, кешеләр белән әдәпле итеп, демократик стильдә эшләп карарга була. Коллективның ышанычын акларлык итеп, бөтен көчен куеп эшләргә ниятли.

Аннары Рәис Кыямович Рүзәлне партия өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйлевич Усмановка тәкъдим итә. Әңгәмә озак бармый. «Беренче» берничә сорау бирү белән чикләнә. Кандидатурага риза булган, күрәсең. Иртәгәсен үк Рүзәл Юсупов Г.И.Усманов кул куйган юллама һәм Р.К.Беляев исеменнән язылган характеристика белән Мәскәүгә, РСФСР Мәгариф министрлыгына юл тота.

Мәскәүдә булачак ректорга, РСФСР Мәгариф министры белән очрашканчы, өч-дүрт көн дәвамында күп кенә инстанцияләрне йөреп чыгарга туры килә. Башта министрлыкның бүлек мөдирләре белән таныша. Аннары СССРның Махсус урта һәм югары белем министрлыгында, СССР Мәгариф министрлыгында була. Министр урынбасарлары, министрлар тарафыннан кабул ителә. СССРның Махсус урта һәм югары белем министрлыгы коллегиясе утырышында аның белән әңгәмә коралар. Ниһаять, аны РСФСР Министрлар Советында Россия хөкүмәтенең бүлек мөдире, заманында Татарстан партия өлкә комитетының идеология бүлеге мөдире булып эшләгән Андриянов кабул итә. Якташлар булгач, озаклап сөйләшеп утыралар

алар. Аннары КПСС Үзәк комитетының Россия бүлегендә була Рүзәл. Монда аны ниндидер сектор мөдире кабул итә. Шуннан соң гына Рүзәл Юсупов РСФСР Мәгариф министры янына керә. Бераз сөйләшеп утырганнан соң, Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповны Казан педагогика институтының ректоры итеп билгеләү турында министрның приказы чыга.

Мәскәүдән приказ алып кайткач, Рәис Беляев яңа ректорны институт коллективына тәкъдим итә, аңа уңышлар тели. Аннары Р.А. Юсуповны ректор креслосына утырта. Кыяр-кыймас кына, ниндидер ярамаган эш эшләгән кебек кенә, уңайсызланып килеп утыра ул. Бу минутларда алда торган зур җаваплылык, билгесезлек борчый аны. Бу 1986 елның июль ае була.

Элекке ректор М.Зәкиев озак еллар җитәкчелек итү чорында институт өчен шактый күп файдалы эшләр башкара, ул эшләгән елларда уку йорты чираттагы баскычка күтәрелә. Ләкин заман үзгәрә, яңа таләпләр куя. Институтны тагын да алгарак җибәрү, укыту-тәрбия системасының сыйфатын күтәрү, матди базаны ныгыту һәм башка мөһим эшләр тора алда.

*«Мин эшемне, кайбер башка җитәкчеләр кебек, институттагы төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләрне алмаштырудан башламадым. Тәҗрибәле кадрларның оештыру осталыгын, уңай эш алымнарын акыл белән файдаланырга тырыштым, үзем дә өйрәндем. Минем төп принцибым — югары нәтиҗәле эш таләп итүне кешеләргә яхшы мөнәсәбәт, кайгыртучанлык белән бертигез тоту. Җитәкче өчен иң әһәмиятле сыйфат — кешелекле булу, масаймау, беркемнең дә кешелек намусына кагылмау, беркемгә дә кимсетеп карамау. Һәркем үзенә күрә бер шәхес. Һәркемнең үз горурлыгы бар, беркемнең дә бүтәннәрне кимсетергә хакы юк. Үземнең иң әһәмиятле бурычларымның берсе итеп коллективта үзара аңлашу, татулык мөнәсәбәтләре булдыруны һәм саклауны санадым»*, — ди Рүзәл Юсупов

Гомумән, укытучының кешеләргә игелек иңдерүче мәрхәмәтле зат булырга тиешлеген аңлап эш итә Р.Юсупов. Яхшы укытучыдан башка яхшы инженер да, табиб та, җитәкче дә була алмый. Җәмгыятьнең киләчәге мәгариф системасына, укытуның, тәрбиянең торышына турыдан-туры бәйле. Дөрес, тормыштагы социаль-сәяси үзгәрешләр, базар шартларына күчү укытучы статусына да тискәре йогынты ясады. Әмма укытучының начар эшләргә хакы юк. Педагогика уку йортында, гомумән, начар кешеләр эшләргә тиеш түгел. Югары сыйфатлы укытучылар, тәрбиячеләр әзерләү — беренче бурыч, изге максат.

Рүзәл Юсуповның ректорлык чоры (1986—2002 еллар) Казан педагогика институты өчен чын мәгънәсендә реформа еллары булды. Сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да үсеш бөтен өлкәләрдә барды. Ул, рейтингы буенча, йөз педагогика югары уку йортының беренче унлыгына кереп, Россиянең һәм Татарстанның әйдәп баручы вузларының берсенә әверелде.

Бу чорда факультетлар һәм кафедраларның саны икеләтә артты: 6 факультет иде — 12 булды, 30 кафедра 60 ка җитте, студентлар һәм укытучылар контингенты да күпкә артты, яңа белгечлекләр кертелде. Казан дәүләт педагогика университетының Яр Чаллы филиалы оештырылды, бу уку йорты тарихында беренче мәртәбә вузның чит ил вузлары белән элемтәләре булдырылды, һәм алар елдан-ел киңәйде, ныгыды; докторлык диссертацияләре яклау советлары ачылды, укыту өчен материаль база ныгыды, хезмәткәрләрнең һәм укытучыларның тормыш хәле яхшыра төште. Бу елларда вузның фәнни потенциалы да нык артты: 1986 елда фән докторлары һәм профессорлар саны 16 булса, 2002 елда алар 60 ка җитте. Фән кандидатлары һәм доцентларның, мактаулы исемнәргә лаеклы укытучыларның, фәннәр академияләре әгъзалары, Сорос профессорлары һәм доцентларының саны күбәйде.

Республиканы зур белемле, тәрбия эшенә тагын да әзерлеклерәк, киң кырлы укытучы-тәрбиячеләр белән тәэмин итү бурычы педагогика уку йортларыннан яңа белгечлекләр һәм дисциплиналар кертүне, уку планнарын, программаларын камилләштерүне һәм үзгәртүне, булачак белгечләрнең белемнәре сыйфатын күтәрүне таләп итә иде. Ректорга төп бурычны гамәлгә ашыру эшенә җиң сызганып керешергә, коллективны шушы бурычны үтәүгә тупларга, һәр эшкә төшенеп, кирәк чакта һәркемгә ярдәм итәргә, кешеләргә дә, үзенә дә таләпләрне арттыра барырга туры килде.

Уку планнарына бу һәм башка культурология дисциплиналары кертелү булачак укытучыларга эстетик тәрбия бирү һәм аларны гомумән профессиональ яктан әзерләү бурычын уңышлы хәл итү мөмкинлеге бирде. Казан педагогика университетының педагогика һәм башлангыч белем бирү методикасы, педагогика һәм мәктәпкәчә белем бирү, психология, педагогик юнәлешле юриспруденция белгечләре әзерли башлавы да төптән уйланып һәм тормыш практикасын исәпкә алып кылган гамәл булды. Ул белгечлекләр республикада тиз арада популярлык казанды, һәм Казан педагогика университетына, бу белгечлекләрне үзләштерү өчен, елдан-ел күбрәк егет-кызлар килә иде.

Рүзәл Юсупов ректор булып эшли башлаганга кадәр Казан педагогика институтында традицион рәвештә өч төп Көнбатыш Европа илләре теле — инглиз, немец, француз телләре белгечләре әзерләнеп килде. Соңгы елларда, илебезнең Көнчыгыш дәүләтләре белән бәйләнеше киңәя баруын исәпкә алып, университетта, инглиз теле белән бергә, берәр Көнчыгыш халыклары телен — гарәп, төрек, фарсы, һинд, кытай, япон телен дә белә торган белгечләр әзерли башладылар. Хәзер Көнчыгыш илләрендә монда укып чыккан белгечләрнең эшләве — гадәти күренеш.

Рүзәл Юсупов, ректор булып эшли башлавының беренче көннәреннән үк, кафедраларның, хуҗалык бүлекләренең эшләрен якыннан белеп торуны җитәкчелек итүнең әһәмиятле алымы итеп кабул итә. Урыннарда күп булырга, укытучылар,

студентлар, хезмәткәр-эшчеләр белән мөмкин кадәр күбрәк очрашырга тырыша. Факультет җыелышларында, гыйльми советлар, кайчакта кафедралар утырышларында, студентлар җыелышларында теләп катнаша, кешеләр белән турыдан-туры сөйләшергә ярата. Ел саен факультет студентлары белән очрашып, ачыктан-ачык сөйләшүне практикага кертә. Урыннардагы хәлне белеп тору аның уңышлы эшләвенә нык ярдәм итә.

Студентларның тулай торакларында һәр бүлмәгә, кухня-юыну бүлмәләренә, кирәк дип тапканда һәр туалетка кереп йөреп, яшьләрнең яшәү шартларын якыннан белешеп тора. Бу кызык өчен түгел, бәлки андагы тәртипсезлекләрне, җитешсезлекләрне бетерү өчен эшләнә. Студентларның тулай торакта үз-үзләрен тотышларын һәрвакыт күз уңында тоталар, студентларның үзидарә системасын камилләштерә, активистларны стимуллаштыра баралар. Кыскасы, студентларның — булачак укытучыларның — яшәүләре тәртипле, үзләре әдәпле, культуралы булсын өчен, төрле чаралар күрелә. Шуңа күрә дә Казан педагогика университетының тулай торагы башка вузларныкы арасында күп еллар үрнәк булып, конкурсларда призлы урыннар алып килә. Ректор имтихан сессияләре вакытында, факультетларда барган төрле экзаменнарга кереп, җавап бирүчеләрне тыңлаштыргалап чыга торган була. Бу аңа студентлар белеменең сыйфаты хакында кыйммәтле информация бирә.

Җитәкче кешегә коллектив алдында күп тапкырлар чыгыш ясарга туры килә. Рүзәл Юсупов баштан ук үзенең урынбасарлары әзерләп биргән текст буенча сөйләүне түгел (әзерләргә кушмый да торган була), бәлки докладларны үзе әзерләп, үзе язып сөйләүне принцип итеп куя.

Һәр елны традицион рәвештә 31 август яки 1 сентябрь көнне, бөтен укытучыларны җыеп, актлар залында гыйльми советның киңәйтелгән утырышын үткәрәләр. Ректор узган уку елындагы укыту, тәрбия, фән һәм хуҗалык эшләренә анализ ясап, уңышларны да, җитешсезлекләрне дә күрсәтеп, эшне яхшыртуга юнәлтелгән тәкъдимнәр ясап доклад сөйли. Аның күп еллар чираттагы ялы бары ике атна кына була (өч-дүрт ел, гомумән, отпуск ала алмый). Шул вакытта берәр җиргә ял итәргә китсә, чемодан тутырып кирәкле информация текстларын алып барып, отчёт докладын язып кайта торган була.

Шундый кырыс режимда эшли ректор. Ул моны дөрес режим, дөрес эш стиледер дип әйтми, әмма ул инде җайлап кына, иркенләп, үзенә кыенлык китермичә генә эшли алмый. Максаты — бөтен көчен биреп вузның дәрәҗәсен күтәрү, эшне яхшы итеп, мөмкин булса, хәтта бик яхшы итеп эшләү була. *«Бу максатка ни дәрәҗәдә ирешкәнмендер, монысын халык беләдер,* — ди Рүзәл. — *Әмма үкенечтә калмады: кулымнан килгәннең барысын да эшләдем, үземне аямадым».*

Ректорның, аның коллегаларының тырышлыгы бушка китми. Казан педагогика институтының күп меңле коллективы киеренке хезмәте нәтиҗәсе буларак,

1994 елда уку йорты яңа статус ала — педагогика университетына әверелә. Уку йортының статусын күтәргәнче, Мәскәүдән зур комиссия килеп, институт эшен һәрьяклап җентекләп тикшерә. Россия Мәгариф министрлыгының җаваплы хезмәткәрләре, Россия вузларыннан тәҗрибәле педагоглар, галимнәр була анда. Миңа, журналист буларак, бу вакыйгаларны матбугатта яктырту бурычы куелган иде. Шунлыктан институттагы Мәскәү комиссиясе кешеләре белән аралашып торырга туры килде. Аерым алганда комиссия җитәкчесе, Россия Мәгариф министрлыгының бүлек мөдире Б.Чащихин һәм комиссия әгъзасы, Карелия дәүләт педагогика институты ректоры А.Бритвихин белән әңгәмә кордым. Аларның һәрберсе институтта укыту-тәрбия эшенең торышын югары бәяләде.

Казан дәүләт педагогика университеты чын мәгънәсендә авыл белән шәһәрне бергә тоташтыра. Университет коридорларында йөргәндә, тыйнак, беркадәр тартыныбрак сөйләшүче һәм гадирәк киенгән авыл яшьләре белән янәшәдә шактый шомара төшкән, билгеле дәрәҗәдә мәдәниятне, сәнгатьне үзләштерергә өлгергән шәһәр егетләре һәм кызларын да очратасың. 4—5 ел бергә уку дәверендә алар бер-берсенә нык йогынты ясыйлар, үз-үзләрен тотышлары гына түгел, дөньяга карашлары һәм холыклары да сизелерлек үзгәрә. Уку елы башында уллары һәм кызлары белән ата-аналар да шактый күп килә бирегә. Аларны аңлап була, билгеле. Һәркем үз баласын зыялы итеп тәрбияләргә, аңа югары белем бирергә тырыша. Мин үзем балаларны кечкенәдән үк мөстәкыйльлеккә өйрәтүне хуплыйм. Әгәр кеше үз көче белән уңышларга ирешсә, аның нәтиҗәсе югарырак була. Андыйлар башкаларга салынмый, авырлыкларны үзләре җиңеп чыгарга тырыша.

Чын, гадел җитәкче өчен кешеләр белән сөйләшә, аларны тыңлый белү, һәркемне лаеклы шәхес итеп тану — иң әһәмиятле сыйфатлар. Ректор Рүзәл Юсупов университет хезмәткәрләрен һәм студентларын шәхси мәсьәләләр буенча кабул иткәндә, мин әнә шулар турыда уйланып утырдым.

Җитәкчегә бер күренеп чыгу яисә зарлану, кемнедер гаепләү өчен кермиләр ректор янына. Һәрберсенең нindидер гозере була. Барысы да җитәкчедән ярдәм көтә. Хезмәткәрләрнең күпчелегенең үтенече акча белән бәйле. Берсе — өстәмә эш башкаруын, икенчесе стажының зур булуын дәлил итеп, хезмәт хакын арттыруны үтенә. Ректор, әлбәттә, боларның барысын да белә. Көченнән килсә, хезмәт хакларын икеләтә арттырыр иде. Шулай да игътибар белән тыңлый, бухгалтериягә, проректорларга, башка җитәкчеләргә шалтыратып ала, мәсьәләне уңай хәл итәргә тырыша һәм хәл итә дә.

Университетның финанс мөмкинлекләре чикле булса да, ректор кайберәүләрнең хезмәт хакын күтәрү әмәлен таба, ә кайберләренә матди ярдәм күрсәтә. Мәсьәләне шундук хәл итү мөмкинлеге булмаса, ректор әңгәмәдәшенә хәлне тәфсилләп аңлата, аның өметен өзми. Шуңа гаҗәпләнеп утырдым: нигәдер берәү дә

үпкәләми, гозерен игътибар белән тыңлап, уңай хәл итәргә тырышуы өчен җитәкчегә рәхмәт әйтеп чыгып китә. Ректор исә кафедралардагы, факультетлардагы эшнең торышы, хезмәттәшләренең хәле, гаиләләре, бала-чагалары белән кызыксынып ала. Зур семьяның абруйлы башлыгы кебек тоела ул миңа андый минутларда.

— Рүзәл Абдуллаҗанович, Сез тыңлый беләсез, тагын килергә булдым әле, — дип башлады сүзен өлкән яшьтәге бер ханым. — Теге дәреслекне һаман да чыгарып булмый бит. Югыйсә, министрлык та хуплаган иде инде. Нәшрият каршы. Һаман да Казан дәүләт университеты профессорыннан шүрлиләр. Университет исә үзенең бер профессорын автордаш итеп кертергә тели. Мин андый юлга баса алмыйм. Намусым кушмый. Шулай да үзем исән вакытта бу дәреслекне чыгарасы иде бит.

Ректор кулъязманы кафедра утырышында тикшерергә киңәш итте. Белгечләр танышып, уртак фикергә килсеннәр, аннан соң әмәлен табарбыз, диде.

Урта яшьләрдәге бер ассистент ханым, бүлмәгә керүгә үк, күз яшьләрен тыя алмады. Бер бик якын кешесе каты авырып киткән икән. Рак булмагае, дип шикләнә. Табиблар консультациягә башка шәһәргә җибәрергә киңәш иткәннәр. Ләкин берсе дә юллама бирергә җыенмый.

Мондый үтенечне хәл итү ректор вазифасына керми дә кебек. Шулай да хезмәттәше аның янына килгән бит, өметләнеп килгән.

Рүзәл Юсупов Татарстан Югары Советының сәламәтлек саклау даими комиссиясе рәисе В.М.Зариповка шалтыратты. Берничә сүз белән мәсьәләне аңлатты. Ул исә кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәклеген төшендерде. Үзенең хәзер үк аңа шалтыратып куячагын белдерде. Ассистент, шактый тынычланып, рәхмәтләр әйтеп, ректор бүлмәсеннән чыгып китте. Ректор аны ишеккә кадәр озатып куйды.

Ректор урынына утырырга да өлгермәде, бүлмәгә әле мыеклары да чыкмаган ике егет керде. Алар зур җитезлек белән ректорның эш өстәленә бер уч кәгазь китереп салдылар. Күренеп тора: студентлар. Төркиягә стажировкага китәргә йөриләр икән. Инде чит телләр факультеты деканатында мәсьәлә хәл ителгән. Бары тик ректор рөхсәте генә кирәк. Мондый изге эшкә каршы килеп буламы соң! Барсыннар, укысыннар, кеше булсыннар. Республикага чит илләрдәге мәгариф системасын яхшы белгән белгечләр бик кирәк.

Гомумән, чит ил вузлары белән студентлар алмашу Рүзәлнең ректорлык чорында матур традициягә әйләнеп киткән. Кытайдан, Мисырдан, Төркиядән, Германиядән һәм башка илләрдән шактый күп студентлар белем алды. Укытучылар алмашу, тәҗрибә уртаклашу да гадәти күренешкә әверелгән.

Университетның чит ил уку йортлары, фәнни оешмалары һәм мәдәният учреждениеләре белән хезмәттәшлегенең активлыгы уку йортының рейтингын билгеләгәндә әһәмиятле урын ала. Шуны истә тотып, халыкара бүлек оештырыла, күп

кенә илләрнең университетлары белән нәтиҗәле элемтәләр урнаштырыла. Казан дәүләт педагогика университетының әзерлек бүлегендә Европа, Азия, Африканың төрле илләреннән килгән егетләр һәм кызлар рус телен өйрәнә. Чит ил кешеләре Казан педагогика университетында төрле белгечлекләр буенча аспирантура уза, кайберләре КДПУ советларында диссертация яклый. Мәсәлән, Кытайдан килеп педуниверситетта кытай телен укытучы Хе Хуа рус-кытай телләрен чагыштырып диссертация яклый.

2001 елда, Татарстан Президенты аппаратының тышкы элемтәләр департаменты тәкъдиме белән, Казан дәүләт педагогика университеты базасында Идел буе Иран үзәге оештырыла. Бу үзәкнең максаты Россия белән Иран арасындагы хезмәттәшлекне җәелдерүгә ярдәм итү була.

...Ректорның кабул итү көнендә бүлмәсенә тагын бер-бер артлы дүрт студент керде. Дөрес, аларны «студент» дип атау бик үк дөрес булмас. Барысы да университет программасын тулысынча үтәгәннәр, хәзер укучыларга үзләре белем бирәләр. Әмма аларның барысы да университеттан дипломсыз чыгып киткән булганнар. Дәүләт имтиханнарын тапшыра алмаганнар. Хәзер кабат имтихан тотарга рөхсәт сорыйлар.

Ректор тиз генә кул куярга ашыкмады. Кайда, ничек эшләүләре, нинди кыенлыкларга очраулары белән кызыксынды. Дәүләт имтиханында «яну» сәбәпләрен ачыклады. Аннары гына ризалыгын бирде.

Дүрт кешенең бер үк мәсьәлә буенча ректорга керүе мине уйланырга мәҗбүр итте. Университеттан дипломсыз чыгып китүчеләр шактый күпме әллә? Ни өчен студент, 4—5 ел укыганнан соң, дәүләт комиссиясе алдында җавап тота алмый? Моңа кем гаепле? Кафедраларның, деканатларның эшчәнлеге белән танышканда, мин шул сорауларга җавап эзләдем. Һәм таптым да кебек. Биредә белемне гадел бәяли башлаганнар. Әзерлегең нинди — шундый бәя аласың. Тартып-сузып маташмыйлар. Канәгатьләнмәслек җавапны канәгатьләнерлек дип бәяләмиләр. Күрә торып брак чыгарырга ярамый бит. Надан укытучының җәмгыять өчен файдасына караганда зарары күбрәк. Чөнки ул киләчәктә мәктәптән үзе кебек үк наданнарны күпләп чыгарачак. Андыйлар дипломның әһәмиятен югалта, уку йортының абруен төшерә.

Әлбәттә, еллар буе уку йорты организмын какшатып, инде тамыр җәеп өлгергән чирне бер селтәнүдә генә дәвалап бетереп булмый. Анализ күрсәткәнчә, чит телләр, музыка-педагогика һәм кайбер башка факультетларны тәмамлаучыларның белем дәрәҗәләре бик югары. Ул факультетларда укучыларның 70—80 проценты фәннәрне «бик яхшы» билгеләренә үзләштерә. Әмма кайбер белгечлекләр буенча «3»легә укучылар саны 60—70 процентка җитә. Ә «3»ле — «2»ленең күршесе,

якын дусты. Рус-татар бүлегендә читтән торып укучыларның 75 проценты, ягъни дүрттән өч өлеше, рус әдәбиятыннан дәүләт имтиханын «3»легә тапшырган. Җитди уйлану өчен җирлек бар монда.

Билгеле, йомшак студентларны һәм ялкауларны дәүләт имтиханына кадәр сөйрәп йөртмәскә, алардан түбән курсларда ук арынырга кирәк. Гыйльми советның киңәйтелгән утырышында ректор шундый таләп куйды, киләчәктә студентларның белем дәрәҗәсенә контрольне тагын да арттыру зарурлыгын белдерде. Дөрес, ул чорда уку йортына иң лаеклыларны, укытучы булырга хыялланучыларны гына кабул итү мөмкинлеге дә бар иде. Бер урынга өчәр гариза бирелде. Имтиханнар башланганчы яки тапшырылгач, абитуриентлар белән әңгәмә үткәрелде. Аларның укытучы булу өчен кирәкле сыйфатлары ачыкланды. Хәзер мондый тәртип юк инде. Урта мәктәпне тәмамлаучылар документларын берничә уку йортына тапшыралар да, кая кабул итсәләр, шунда укый башлыйлар. Аларның нинди белгечлек турында хыялалнуын һәм сәләтләре кайсы белгечлеккә күбрәк туры килүен беркем дә ачыклап тормый.

Рүзәл Юсупов ректор булып эшләгән чорда, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып та конкурстан үтә алмаучыларны договор нигезендә укырга алалар иде. Әлбәттә, андыйларга укыган өчен бераз түләргә туры килә. Түләү күләме зур түгел иде: башка вузлардагыга караганда иң азы. Шулай да дифференциаль түләү системасын кертә ректор. Гадәттә, бөтен Россия уку йортларындагы гомуми тәртип нигезендә, кабул итү имтиханнары нәтиҗәләре буенча бюджет исәбенә укырга керә алмаучыларның барысы да, университет белән килешү төзеп, укыган өчен тигез күләмдә түли. Бу системаның гаделсезлеге бар. Конкурс аша укырга керү өчен бер балл җитмәсә дә, өч-дүрт балл җитмәсә дә, бер үк күләмдә түләтелә. Укый башлагач, договор буенча кергәннәр еш кына бюджет исәбенә кабул ителгәннәрдән яхшырак укыйлар. Бу имтихан-сессия нәтиҗәләрендә яхшы күренә.

Шуның өстенә, договор буенча укучыларга стипендия дә бирелергә тиеш түгел, матди ярдәм күрсәтергә дә рөхсәт ителми. Тулай торакта яшәгән өчен түләү дә бюджетта укучыларныкына караганда берничә тапкыр артыграк булырга тиеш.

*«Мин, бу гаделсезлек белән килешергә теләмичә, договор буенча укучылардан дифференциаль тәртиптә түләтү системасы керттем. Кабул итү имтиханнарында конкурстан узу өчен бер балл гына җитми калган студентлар беренче курста укыганда, мәсәлән, елына өч мең сум гына түлиләр, ике балл җитмәгәннәр — дүрт мең сум, өч балл җитмәгәннәр биш мең сум түлиләр. Кыскасы, җитмәгән һәр балл өчен берәр мең сум арта бара,* — ди Р.Юсупов. — *Икенче курстан алып, укып бетергәнче, түләүнең күләме җәйге сессия имтиханнарында алган балларга карап билгеләнә. Имтиханнарның уртача баллы биш булса, студент*

*киләсе уку елында ике мең сум гына түли. Уртача билгесе (баллы) дүрт ярым булса, ике мең ярым сум түли. Һәм шул тәртиптә һәр ярты балл өчен яртышар мең сум арта бара. Бу тәртип тырышып укуны стимуллаштыра. Югыйсә, «өчкә көчкә» укып йөргәне дә, «бишле»гә укыганы да бертигез түли иде. Яхшы укыганнарга карата зур гаделсезлек бу».*

Казан педуниверситетында договор буенча укучыларга хәтта берничә ел стипендия дә түләп киләләр, бик мохтаҗларга матди ярдәм дә күрсәтелә, тулай торакта яшәгән өчен барысына да бертигез (стипендия суммасының 5%ы күләмендә генә) түләтелә. Соңыннан ректор Р.Юсуповка бу «юмартлыклары» кыйммәткә төшә. Дифференциаль система булдыруны финанс-ревизия комиссиясе закон бозу буларак кабул итә. Моның өчен ректорга рәхмәт белдереп, бу тәҗрибәне башка уку йортларына да таратырга кирәк булгандыр да бит. Берәү дә системага каршы бара алмый шул.

Ректор Р.Юсупов, договор белән кереп, яхшы укучы, матди хәлләре бик авыр кайбер студентларны, документаль рәвештә тикшереп, уку өчен түләүдән азат итү тәртибе кертә. Бу — аның кеше хәлен аңлый, ярдәм итә белүен күрсәтә торган сыйфатының чагылышы. Бер мисал.

Җәмиләнең әнисе — Бөгелмә кызы — Алжир гарәбенә кияүгә чыгып, аннан ике бала белән аерылып, туган җиренә кайтып яши башлый, кондитер булып эшли. Җәмилә Алжирда гарәп теле өстенә француз телен дә үзләштерә. Бөгелмәгә кайткач, берничә класс рус мәктәбендә укып, бу телне дә өйрәнә. Татар телен дә белә. 11 нче классны тәмамлагач, Казан педуниверситетының инглиз теле бүлегенә договор буенча укырга керә. Укуы яхшы. Энесе техникумда укый. Чит илдә икенче семьясы белән яшәгән әтисеннән бернинди дә ярдәм юк. Аз гына хезмәт хакы алып эшләгән бер анага ике баланы укыту, шуның өстенә, берсенең укуы өчен түләп тору мөмкин түгел, әлбәттә. Гарәпчә, французча, русча, татарча белгән, инглизчә өйрәнеп килгән кызның Татарстан өчен ни дәрәҗәдә кирәкле белгеч булачагына төшенергә мөмкин һәм кирәк тә. Рүзәл Абдуллаҗанович аны уку өчен түләүдән азат итә. Җәмилә, ректорга мең рәхмәтләр укый-укый, университетны уңышлы тәмамлый, республика мәгарифенә турылыклы хезмәт итә.

Рүзәл Юсуповның ректорлык чорында университетның шәһәр буйлап сибелгән 8 уку бинасы бар иде. 26,4 мең квадрат метр мәйдан биләүче бу биналар төрле вакытларда төрле максатлар белән төзелгән булган. Университетта көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрендә 10 мең чамасы студент белем ала, меңгә якын профессор һәм укытучы аларга лекцияләр укый, семинарлар һәм практик дәресләр үткәрә. Болардан тыш, шәһәрнең төрле урыннарында тулай тораклар, «Яльчик» спорт-ял базасы, Победилово авылы янында агробиостанциясе бар. Мондый зур

хуҗалыкны тәртиптә тоту җиңел эш түгел. Теоретик багажың булу, үз эшеңне, коллективны яхшы белү генә җитми, акыл һәм бай тормыш тәҗрибәсе дә кирәк. Акыл зирәклеге гомер буе чарлана, ә тормыш тәҗрибәсе мыскаллап җыела. Рүзәл Юсупов бу сыйфатларга ия, ул — түбәннән күтәрелгән, катлаулы тормыш юлы узган җитәкче.

Яңа ректор эшкә керешкәндә, биналарның күбесенә ремонт ясарга кирәк була. Институтның төп бинасы фасадының аскы өлешендә метрдан артык киңлектәге полоса корым кебек кап-кара ямьсез буяу белән капланган. Вестибюль стенасының аскы өлеше дә киң полоса итеп карага буяп куелган. Ректор кабинетының стеналары ниндидер ямьсез тупас материал белән капланган, түшәмендә рельс шпаллары асылынып тора.

Сул болак урамында тарих-филология факультеты урнашкан бинаның эченә керерлек түгел. Аудитория түшәмнәреннән штукатуркалар кубып төшкән, стеналары кап-кара, дымланып утырудан гөмбәләп беткән. «Яльчик» спорт-ял базасында күп өйләр ташландык хәлдә, яшәрлек түгел, аларга берничә дистә ел ремонт булмаган. Кыскасы, институтның матди базасын ныгыту белән җитди шөгыльләнергә кирәк була. Эшкә керешәләр. Күпсанлы биналарны төзек хәлдә тоту өчен, даими эшләүче берничә бригададан торган төзүче-ремонтчылар фирмасы төзелә.

Бу чаралар тиздән уңай нәтиҗәләрен күрсәтә. Ремонт күрмәгән биналар, аудиторияләр, бүлмәләр калмый. Ике-өч, күп дигәндә, дүрт-биш ел саен һәр аудиториядә, лаборатория, кабинет, коридор, вестибюль, холларда да, матурлык таләпләрен исәпкә алып, ремонт ясала. Биш уку бинасы фасадларын шундый итеп буяталар ки, алар шәһәрдәге иң матур биналар исәбенә керә. Шәһәр мэры Камил Исхаков моның өчен ректорга рәхмәт әйтә.

Илдә 90 нчы еллардан башланган кризис үзен нык сиздерә. Казан педуниверситеты да финанс кытлыгы кичерә. Биш-алты ел дәвамында Мәскәү акчаны бары хезмәт хакы һәм стипендия түләргә генә бирә. Башка максатлар өчен миллионнарча сумны уку йорты җитәкчелегенең үзенә табарга туры килә.

*«Мин — табигатем белән хуҗалык кешесе. Үзем җаваплы вузның төзеклеге өчен, гаиләм өчен эшләгәнгә караганда да күбрәк көч салдым, дисәм, ялгыш булмастыр. Мин үземә принцип итеп алдым: уку-укыту, эшләү урыннары төзек, чиста, пөхтә, матур, кыш көне җылы булырга тиеш. Бу принципның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлегенә коллегаларымны да инандырдым кебек»,* — ди Рүзәл Юсупов.

Кризис елларында уку йортын техник чаралар, әдәбият белән тәэмин итү кыен була. Шулай да бу өлкәдә дә шактый эш эшләнә. Физика факультеты барлык кирәкле укыту-фән җиһазлары белән тәэмин ителә, математика факультеты да игътибардан читтә калмый. Химия кафедрасы өчен заманча лабораторияләр булдырыла. Күп

кенә приборлар, укыту өчен техник чаралар, җиһазлар, башка кафедралар өчен дә уку кирәк-яраклары сатып алына. Һәр кафедра компьютерлар һәм ксерокслар белән тәэмин ителә. Институт Интернет челтәренә тоташтырыла.

Ректорат, деканатлар, кафедралар, 90 нчы еллардагы демократлашу идеясе белән артык мавыкмыйча, студентларны тәрбияләү эшенең заман тарафыннан сыналган формаларыннан ваз кичмәделәр, бу эшнең уйланылган, нык системасын бозмадылар. Киресенчә, университет җитәкчелеге тәрбия эшен тагын да яхшырту, камилләштерү юлына басты. КДПУ студентларын тәрбияләү эше максатчан, комплекслы итеп башкарылды. Шуның нәтиҗәсе буларак, педагог студентлар башка уку йортлары студентларыннан тыйнаграк, әдәплерәк булулары белән аерылып тордылар. Ректоратның тәрбия эшендә җитди чаралар күрүе нәтиҗәсендә, университет студентларының мораль-этик сыйфатлары яхшы якка нык үзгәрде. Ул чорда наркомания күренешләре бөтенләй булмады, яшәү кагыйдәләрен тупас бозулар да юк иде диярлек. Таләпләрне арттыргач, студентларның өстәлләргә, башка җиһазларга рәсемнәр ясау, җиһазларны пычрату очраклары бетте. Вакыт-вакыт лабораторияләрне, аудиторияләрне йөреп, карап чыгуны ректор үзенең гадәти вазифасына әверелдерде.

Шулай да ректор студентларны тәрбияләү эшендә һәр яктан да идеаль тәртипкә ирешелде дип санамый, эшләнеп бетмәгән, эчне пошыра торган нәрсәләр дә калды әле, ди. Мәсәлән, студентларны тәмәке тарту гадәтеннән тулысынча арындырып булмады. Кайбер кызларның — булачак аналарның — качып-посып тәмәке тартып йөрүе бигрәк тә кәефне җибәрә.

90 нчы еллар азагын һәм 2000 еллар башын Казан педагогика университеты тормышында үзенә күрә культура революциясе чоры дип атарга мөмкин. Бу елларда студентларга эстетик тәрбия бирү нык җәелде. Сәнгать белән шөгыльләнү студентларның ихтыяҗына һәм рухи азыгына әверелде. Ректор инициативасы белән, барлык белгечләрнең уку планнарына яшь буынны тәрбияләү өчен аеруча кирәкле курслар — музыка тәрбиясе нигезләре, сөйләм культурасы, сөйләм техникасы, риторика, хореография кертелде һәм тиешле кафедралар ачылды. Университет педагогика һәм психология, педагогик юнәлешле юриспруденция белгечләре әзерли башлады.

Эстетик тәрбияне көчәйтү максатында, барлык студентлар өчен дә, министрлыкның уку планнарында булмаган «Эстетика һәм культура нигезләре» дигән фән укытыла башлый. Аның бурычы — булачак укытучыларның культура дәрәҗәләрен күтәрү, аларда матурлыкны аңлау сәләте тәрбияләү һәм үз-үзләрен әдәпле тоту кагыйдәләренә өйрәтү. Татар филологиясе факультеты бинасында студентлар театры оештырыла. Аның режиссёры итеп Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты Марсель Җаббаров билгеләнә.

Булачак педагоглар үзләре дә җырлый-бии белергә, кирәк булганда моңа башкаларны да өйрәтә алырга, шулай ук музыка грамотасыннан хәбәрдар булырга, берәр төрле музыка коралында да уйный белергә тиеш, дигән принципны истә тотып, барлык студентларга да «Музыка тәрбиясе нигезләре», «Хореография» курслары кертелә. Дипломлы белгеч киләчәктә кайда гына эшләсә дә, бу чараларның һәрберсе бик кирәк була. Укытучыларга үзешчән сәнгать коллективлары оештырырга, концертлар, спектакльләр куярга, лекцияләр укырга да туры килә бит.

Әлбәттә, барысы да ал да гөл булмый. Кимчелекләр чыга тора. Берара физик культура факультеты студентларының үз-үзләрен тотышлары турында ректоратка күңелсез хәбәрләр килә. Кемнедер сугышып имгәткәннәр, студент егетләрдән кемнәрдер кызларга бәйләнгән... Мондый хәлләрне ректор педагогик уку йорты өчен хурлык дип бәяли, җитди чаралар күрә башлый. Бөтен коллективны җыеп, кискен сөйләшү оештыра. *«Спортта ирешкән уңышларыгыз да җәзадан коткармаячак. Сез — беренче чиратта педагогик уку йорты студентлары»*, — ди ректор. Аннары факультет деканына мөрәҗәгать итә: — *Ринат Абзалович, мин сезне тырыш, уңган егет дип беләм. Фәндәге һәм башка өлкәләрдәге уңышларыгызны да күреп торам һәм тиешле бәя бирәм. Ләкин барыбер тиз арада факультетта тәртип урнаштырып, тәрбия эшен яхшыртмасагыз, тиздән үткәреләчәк декан сайлавында ректорат һәм партком кандидатурагызны тәкъдим итәр дип уйламагыз».*

Күрелгән чаралар тиешле нәтиҗә бирә: факультетта хәлләр уңай якка үзгәрә, студентларның үз-үзләрен тотышындагы ямьсез күренешләр бетерелә. Студентларны тәрбияләү эшенә зур үзгәрешләр кертелә.

Университет коллективы «педагогика университеты укытучыларының җитди бурычы — ныклы белем бирү белән бергә тәрбияле студентлар әзерләү» дигән девиз белән яши башлый. Тулай торакта тәрбия эше белән шөгыльләнү өчен махсус декан урынбасары билгеләп кую системасы кертелә һәм башка төрле чаралар күрелә.

*«Ректор булып эшли башлавымның беренче көннәреннән үк, кафедраларның, хуҗалык бүлекләренең эшләрен якыннан белеп торуны үземнең җитәкчелектә әһәмиятле алым буларак кабул иттем. Урыннарда күп булырга, укытучылар, студентлар, хезмәткәр-эшчеләр белән мөмкин кадәр күбрәк очрашырга тырыша идем. Факультет җыелышларында, гыйльми советларның, кайчакта кафедраларның утырышларында, студентлар җыелышларында өлгерә алганча күбрәк катнашуны, кешеләр белән турыдан-туры сөйләшүне максатым итеп куйдым. Системалы рәвештә студентлар белән очрашып, ачыктан-ачык сөйләшүне практикага керттем. Урыннардагы хәлне белеп тору уңышлы эшләвемә нык ярдәм итте*, — дип яза Рүзәл Юсупов.

## КӨНЛӘШҮ — ЯМАН ЧИР

Тотынган эшен җиренә җиткереп үтәү — Рүзәл Юсуповның кечкенәдән үк күнеккән гадәте. Ректорлык эшен дә ул үзен аямыйча, сыйфатлы итеп башкарырга тырыша. Ләкин кайберәүләргә башкаларның уңышларын күр алмау, алай гына да түгел, хезмәттәшләре эшеннән гаеп эзләү хас. Педагогика университетында да андый бер профессор була. Казан университетында ул минем белән бер чорда бер факультетта укыды. Группадашларының сөйләвенә караганда, бу егет имтиханнарны яхшы тапшырып килгән. Шулай да мин аның җәмәгать эшендә катнашуын хәтерләмим. Керәшен авылында туып үскән бер гади егет иде ул. «Татарстан яшьләре» газетасы өчен мәкаләләр язып йөрде. Күрәсең, газеталарга язышып йөрүе ярдәм иткәндер: тарих бүлеген тәмамласа да, аны эшкә, әдәби хезмәткәр итеп, радиога алдылар. Әмма ул анда төпләнеп кала алмады, бераздан эштән китеп барды. Һәм, Тобольски пединститутына барып, Россиянең булачак мәгариф министры җитәкчелегендә аспирантурага керде, Ленин методологиясе буенча диссертациясен яклады.

Яшь, милли кадр булуын исәпкә алыптыр инде, Владимир Ивановны партия өлкә комитетының фән бүлеге мөдире итеп билгеләделәр. Аннары ул берникадәр вакыт республиканың мәгариф министры булып торды. Әйтергә кирәк, анда әллә ни эш майтара алмады. Владимир Васильевич министрлыктан китеп, педагогика институтында укыта башлый. Сөйләүләренә караганда, В.Иванов, М.Зәкиев киткәч, ректор итеп Ф.Ситдыйковны куярлар, дип ышанып йөргән, ә бушап калган фәнни эшләр буенча проректор урынына үзе утырырга хыялланган. Мондый вариант барып чыкмагач, яңа ректор өстеннән шикаятьләр язарга керешкән. Ничек кенә булса да, аны эшеннән алдыртырга уйлаган.

Партия өлкә комитетында һәм министр булып эшләп алганлыктан, элемтәләре зур була профессор Ивановның. Шуның өстенә, ул әшәке алымнар белән оста эш итә, бернинди юньсезлек эшләүдән дә чирканып тормый. Күзгә карап ялганлый, яла яга. Шикаятьләрне Мәскәүгә Россиянең Мәгариф министрлыгына, КПСС Үзәк комитетына, аның контроль комиссиясенә һәм башка оешмаларга яудыра. Партиянең хакимияттә нык утырган чоры була әле. Аноним шикаятьләр дә җентекләп тикшерелә.

Яшәү шартлары уңайлы булмаганлыктан, Рүзәл Юсупов, ректор булып билгеләнгәнче үк, фатир чиратына басып куйган була. Шәһәр читендә абыйсы белән яшәгән кечерәк кенә йортта җылы су да, телефон да булмый, туалет урамда. Эшкә берничә транспорт белән йөрергә туры килә. Ректор булып бер ел эшләгәч, Р.Юсупов, Мәскәүдәге Россия Мәгариф министрлыгыннан сорап, үзенә квартир алу өчен, Казанның башкарма комитеты исеменә акча күчертә. Ректор бу мәсьәлә белән пар-

тия өлкә комитеты секретаре янына кергәч, ул, М.Зәкиев шушы көнгә кадәр сиңа фатир бирмәгән идемени әле, дип гаҗәпләнә. Гаризасына «фатир белән тәэмин итәргә» дигән виза салып чыгара. Гариза кирәкле барлык документлар белән бергә Казан шәһәр Советы башкарма комитетының торак-коммуналь бүлегенә тапшырыла. Тиздән Рүзәл Юсуповның дүрт кешелек гаиләсенә кечкенә метражлы (48 квадрат метрлы) квартир бирелә.

Әмма ректор гаиләсенең кешечә яши башлавы теге профессорга тынгылык бирми. Ул КПСС Үзәк комитетының контроль комиссиясенә шикаять юллый. Имеш, ректор, йорты була торып, фатир алган. Шикаять, тикшерү өчен, КПСС Бауман райкомы парткомиссиясенә җибәрелә. Ректор шикаятьне үзе күп еллар эшләгән тарих-филология факультетының ачык партия җыелышында бөтен коллектив катнашында тикшерергә тәкъдим итә. Халык күп җыела. Барлык укытучылар килә. Җыелышны алып баручы партоешма секретаре мәсьәләнең асылын аңлата, шикаятьнең эчтәлеге белән таныштыра. Барлык чыгыш ясаучылар нәфрәтләнеп сөйлиләр, шикаятьчене сүгәләр, ә ул залда тыныч кына утыра бирә. Җыелыш ректорны тулысынча аклап чыга. Әмма парткомиссия рәисе генә тынычланмый. «Мин аңа барыбер җәза бирдертәчәкмен», — дип кайтып китә.

Җыелышта катнашкан журналист Марсель Зарипов «Советская Россия» газетасында тәнкыйть мәкаләсе урнаштыра. Институт галимнәренең сөйләвенә караганда, мондый адым алдан ук җентекләп уйланылган була. М.Зариповның дачасы М.Зәкиев тарафыннан ректорлыкка тәкъдим ителгән Ф.Ситдыйков хатынының этисе — республика газетасы редакторыныкы белән янәшә була. Күршеләр дус булалар, буш вакытларын бергәләп күңелле итеп үткәрәләр. Республика газетасы редакторы партия өлкә комитеты бюросы әгъзасы була. Ә бу — ул чакта бик зур дәрәҗә була.

Тиздән ректорның фатир алуына кагылышлы шикаять партиянең Бауман райкомы бюросы утырышында тикшерелә. Бернинди гаебе булмаса да, каты шелтә (строгий выговор) белдерелә. Ни хәл итәсең, замана — көчленеке. Билгеле, Р.Юсупов райком бюросы биргән шелтә белән килешми.

— Уйламыйча, тикшермичә фикер йөртү — аяныч хәл. Бу, иртәме-соңмы, бюрократлашкан партия җитәкчеләренең үзләрен дә авыр хәлгә куярга мөмкин, — ди ректор.

— Нәрсә сез, Рүзәл Абдуллаҗанович, бюро әгъзаларын гаепләргә уйлыйсызмы? — диләр аңа.

— Үзегезне түгел, гамәлегезне. Югыйсә, карар чыгарганчы, барысын да җентекләп өйрәнергә, тикшерергә була иде. Моңарчы мин яшәгән йорт әллә кайда түгел, Северный бистәсендә генә. Үз күзләрегез белән күрсәгез, анда яшәүчеләр

белән сөйләшсәгез, документларга күз төшерсәгез, мондый күңелсез нәтиҗәгә килмәс идегез, — ди ул.

Педагогика уку йорты әзерләп чыгара торган белгечләр сыйфатлы булсын өчен, институтка мәктәптә яхшы укып чыккан яшьләр килүе әһәмиятле. Мәктәптә «өч»кә укып йөрүчеләрдән яхшы укытучы чыгуы шикле. Шуңа күрә ректорат төрле юллар белән әйбәт укучы абитуриентлар тупларга тырыша.

Шундый изге максат белән район үзәкләрендә ректоратның күчмә утырышлары үткәрелә. Бу юлы шундый чара Алексеевск районында уздырыла. Проректорлар, деканнар, кафедра мөдирләре район укытучылары белән очраша. Эшлекле, файдалы сөйләшү була, яшьләрне укырга җибәрүнең конкрет планы төзелә. Галимнәр, мәктәпләрдә булып, укытучыларның эш тәҗрибәсе белән танышалар. Кышкы көн кыска, шул арада караңгы да төшә, кунып кайтырга туры килә.

Андагы ашханәдә өч тапкыр туклану һәм район кунакханәсендә кунып чыгу өчен, читтән торып укыту проректоры В.Закиров сөйләшүе буенча, профсоюз өлкә комитеты каршындагы махсус фонд Алексеевск районына акча күчерә.

Шуннан соң күп тә үтми, РСФСР Мәгариф министрлыгына, КПСС Үзәк комитетына ректорны пычрату өчен язылган күләмле шикаять китә. Имеш, институт кешеләре Алексеевск балаларына тиешле продуктлар белән тукланганнар. Моның ялган икәнлеген раслау авыр булмый. Акча күчерү турында мәгълүматлар бухгалтериядә саклана.

Шул ук Алексеевск районында булуга кагылышлы икенче шикаятьтә ректорның ришвәт буларак балык продуктлары алып китүе тасвирлана. Чыннан да кунакларның һәркайсына күчтәнәч итеп берәр балык биреп җибәрәләр. Институт укытучылары арасындагы В.Иванов, мин балык ашамыйм дип, аннан баш тарта. Шикаять килеп төшкәч кенә, эшнең нәрсәдә икәнлеге ачыклана. Шикаять хатында шундый эчтәлекле хәбәр дә була: янәсе, ректор эшли башлагач та, үз мәнфәгатьләрен кайгырта башлаган, ректоратка керә торган идәнгә мәрмәр плитә җәйдергән. «Мәрмәр» дигәннәре чынлыкта мәрмәр ватыклары икән. Коридордан ректор бүлмәсенә керә торган ашъяулык кадәр генә урынга җәелгән линолиум ертылып беткәч, аның урынына цемент измәсенә бутап мәрмәр кыйпылчыклары җәйдергәннәр. Ректорат каршындагы фән бүлегенә керә торган урынга да шундый ук измә җәелгән. Коридор ремонтлауның ни зыяны бар, югыйсә.

Шулай яшертен рәвештә этлек эшләве бер-ике елга сузыла профессорның. Ниһаять, Ходайның бу кабахәтлекне туктатырга дигән сәгате суга. В.Иванов институтның офсет лабораториясендә машинистка булып эшләүче хатынга бастырып йөри икән шикаятьләрен. Ул ханым, төп эшенә өстәмә түләү белән, аның хуҗалык договоры эшләре дип аталган язу-сызу кәгазьләрен машинкада бастыра торган бул-

ган. Машинистка белән бергә эшләүче икенче бер ханым профессорның пычрак гамәлләрен фаш итәргә тели. Һәр биткә яңа копировка кәгазьләре куялар. Ә аннан бөтен текстны тулысынча укып була икән. Һәм В.Ивановның чираттагы шикаяте шулай фаш ителә. Шикаятьтә берничә күренекле галимнең имзасы торуын да күрә ректор.

Эшне нәрсәдән башларга соң? Үзеннән-үзе аңлашыла, беренче чиратта шикаять язучының кем икәнен коллективка җиткерергә, ул язганнарның ялган һәм яла ягу икәнлеген коллектив алдында фаш итәргә кирәк. Эшне имзалар куелган шикаятьтән башлау зарур. Имза авторларының һәркайсы белән аерым-аерым сөйләшеп чыгасы, фикерләрен белешәсе булыр. Ректор иң элек күп еллар кафедра мөдире булып эшләгән профессор белән сөйләшә. Башта эштәге кыенлыклар, хәл итәсе мәсьәләләр белән кызыксына. Аның ректорга мөнәсәбәтендә бернинди начарлык сизелми. Белем бирү системасында ректор курсын яклавы турында да әйтә ул хәтта.

Бераздан ректор теге шикаятьне кафедра мөдире алдына куя. Ул, шикаять ахырында үз имзасын күргәч, кычкырып ук җибәрә:

— Кирәк бит, ә? Нинди кабахәтлек! Ничек ояты юк бу хайванның? Мин бу шикаятьне беренче тапкыр күрәм. Андый шикаятькә кул куйганым юк минем.

— Имза сезнекеме соң?

— Минеке.

— Ничек була соң инде алайса? Үзегез шикаятьне күрмәгән дә, ә имза сезнеке?

Кафедра мөдире үзенең имзасын җентекләп карарга керешә. Аннары әйтеп куя:

— Минем имзаны кайдан да булса кисеп алганнар да шикаять астына ябыштырганнар, аннан ксерокопиясен төшергәннәр. Монда минем бер катнашым да, гаебем дә юк. Мондый түбәнчелеккә бара алмыйм мин. Ректор буларак мин сездән бик канәгать. Институтта тәртип урнаштырырга сездә энергия җитәр дип уйлыйм. Кирәк дип тапсагыз, миңа таяна аласыз.

Алар шулай аңлашып, тыныч кына аерылышалар. Аннары ректор башка имза авторлары белән сөйләшеп чыга. Аларның да һәркайсы шикаятьне күргәннәре дә булмавын әйтәләр.

— Бу бит — шантаж, намуслы кешеләрне пычрату. Кичекмәстән бөтен коллектив алдында фаш итәргә кирәк моны, — ди һәркайсы.

Ул чордагы тәртипләр буенча, әхлаксызлык гамәле кылган партия әгъзасын башта факультетның партия бюросында, аннары партия җыелышында тикшерергә кирәк була. Җыелыш карары институтның партия комитетында, район һәм шәһәр комитетларында расланырга тиеш.

Шулай да профессор Ивановны утырыш-җыелышларга китереп булмый. Ул, авырыйм дип, качып кала. Институт җитәкчелегенә, хастаханәгә барып, баш табиб белән сөйләшергә туры килә. Ниһаять, пациент хастаханәгә кереп ятудан туктый. Шулай да ул партбюро утырышларыннан берничә тапкыр чыгып кача. Ниһаять, партком секретаре һәм кадрлар бүлеге бу профессорның партия җыелышына килүенә ирешәләр. Көн тәртибендә — аның партия әгъзасы мораленә каршы килә торган гамәлләрен тикшерү.

Җыелыш биш сәгать бара. Коммунистлар, В.В.Ивановны партиядән чыгарырга, дигән карар кабул итә. Хезмәттәшләренең исемен хурлаган, аларга яла яккан өчен. Карар тиздән парткомда һәм партия райкомында раслана. Ләкин шәһәр комитетында профессорның әхлакый гаебе фаш ителсә дә, ул катгый шелтә (строгий выговор) белән партия сафында калдырыла. Күрәсең, моңа аның элек партия өлкә комитетында бүлек мөдире булып эшләве, андагы дус-ишләре ярдәм иткәндер.

Партия сафларында калгач, В.Иванов үзен тагын да иркенрәк тота башлый. Мәскәүгә шикаятьләр китә тора. Төп максат: Р.Юсуповны, уңышлы эшләргә сәләтсез, дип күрсәтеп, эшеннән җибәртү. Профессорны хезмәт коллективы җыелышына да чакырып карыйлар, ләкин ул килми. Берничә көн эштә бөтенләй күренми.

— Менә инде ничә көн эшкә йөрмисез, үз теләгегез белән гариза языгыз да тыныч кына китеп барыгыз, — ди кадрлар бүлеге мөдире Фираз Харисов.

Юк, алай да эшләргә теләми В.Иванов, эшкә дә йөрми. Эшкә чыкмавын сәбәп итеп, кадрлар бүлеге КЗОТ буенча приказ әзерләргә мәҗбүр була. Приказ белән өч көн эчендә таныштырырга, кул куйдырып алырга кирәк. Ф.Харисов аның өенә китә.

— Бөтен җирем авырта, институтка бармыйм, — ди бу.

— Бармасагыз бармассыз. Менә шушы кәгазь белән генә танышып чыгыгыз.

В.Иванов кычкыра ук башлый:

— Болай булса, мин Мәскәүгә барам!

— Барырсыз, тик кул гына куеп бирегез. Приказ белән танышуыгыз турында, — ди Фираз Харисов.

Профессор артык уйлап тормыйча кул куя. Шундук, ялгышуын сизеп алып, тагын кычкыра башлый:

— Әле Мәскәү бар! Мәскәү якагыздан тотса, берни эшли алмассыз!

— Анысы сезнең эш, барыгыз, — ди Ф.Харисов, кул куйдыруына шатланып.

Икенче көнне В.Иванов иртән үк кадрлар бүлегенә килеп җитә.

— Сез мине приказга көчләп кул куйдырдыгыз. Мин эштән китәргә җыенмыйм, — ди ул.

— Приказ чыкты инде. Хәзер сез биредә эшләмисез, — ди Харисов тыныч кына.

— Барлык эшләмәгән көннәр өчен түләячәксез! — дип, ишекне каты ябып чыгып китә профессор.

Шуннан тагын шикаятьләр башлана. Партия өлкә комитетына язып аргач, Мәскәүгә язарга тотына. Низагка РСФСР Мәгариф министрлыгы нокта куярга тиеш була. Ләкин эш катлаулы булып чыга. Кадрлар бүлеге начальнигы каты тора. «Абруйлы егет бит ул. Аны һәркайда беләләр. Партия өлкә комитетының фән бүлеге белән җитәкчелек иткән. Элекке өлкә партия комитеты секретаре Фикърәт Табеев та аны яхшы белә. В.Ивановны эштән куарга кирәкми», — ди начальник.

Министр урынбасары Дмитрий Забродинның кабул итү вакытын туры китереп, Ф.Харисов аның кабинетына керә. Бераз сөйләшкәннән соң, министр урынбасары кадрлар бүлеге кнопкасына баса:

— Валентина Сергеевна, без бит бу хакта инде сөйләшкән идек, — ди ул.

Трубкада бүлек начальнигының өзек-өзек тавышы ишетелә:

— В.Ивановны эштән җибәреп дөрес эшләмәгәннәр. Бу хакта безне өйрәтүнең кирәге юк.

Трубканы куйгач, Дмитрий Михайлович Фираз Харисовка карап тора да:

— Хәзер үк юрист янына керегез. Ул сезне кабул итәр, мин җибәрде диярсез. Нәтиҗәсе турында миңа хәбәр итәрсез.

Юрист кырыс кеше булып чыга, артык бер сүз дә әйтми.

— Мин Харисов булам...

— Беләм.

Аннары Харисов нәрсәдер аңлатмакчы була, юрист аны шунда ук бүлдерә:

— Сөйләп торасы юк, миңа барысы да аңлашыла. Тик менә бу җөмләне болайрак язсагыз, яхшырак булыр. — Аннары папканы Ф.Харисовка суза: — Булган. Башка берни дә кирәкми.

— Бу хакта мин Забродинга җиткерә аламмы?

— Теләсә кемгә җиткерә аласыз. Сез мәсьәләне дөрес хәл иткәнсез.

Фираз Харисов министр урынбасары янына йөгерә.

— Дмитрий Михайлович, булды! — ди ул, куанычын яшерә алмыйча.

— Күрәм, — ди Забродин, — сез хаклы булып чыктыгыз. Юрист алдында дөрес эшләгәнегезне дәлилли алгансыз. Сау булыгыз!

Сөенеченнән ишектән ничек чыгып киткәнен дә тоймый Фираз Фахразович. Аннан вокзалга ашыга. Кичке «Татарстан» поездына өлгерергә кирәк була.

# КЕШЕЛӘРГӘ ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘҮДӘН КУРКЫРГА КИРӘКМИ

Бездә хөкем сөргән кырыс чынбарлык шартларында бюджет өлкәсе хезмәткәрләре, бигрәк тә укытучылар, көч-хәл белән очны-очка ялгап яшәгәндә, вузда эшләүчеләрне, аеруча аз хезмәт хакы ала торган авыр хәллеләрне, шулай ук кыен шартларда яшәгән студентларны социаль яклау мөмкинлекләрен табуның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеге һәркемгә аңлашыладыр.

Ректор Рүзәл Юсупов кечкенәдән үк авыр шартларда үскәнлектән һәм пединститутның гади укытучысы булып эшләгәндә дә җиңел яшәмәгәнлектән, анда һәрвакыт матди кыенлыкта яшәгән кешеләрнең хәлен аңлау, аларга булышу теләге була. Шунлыктан ул елларда университетта эшләүчеләрдән һәм укытучылардан авыр хәллеләргә хәтта үзенә куркыныч янаганда да ярдәм итәргә тырыша.

Шундый күпсанлы чараларның берсе — договор белән укучылар (кабул итү имтиханнарында җитәрлек күләмдә балл җыя алмаганнар) өчен дифференциаль тәртиптә түләү системасы кертү булды. Бу турыда әйтелде инде.

Педуниверситетта хезмәт хаклары аз булган йөзләрчә укытучыларга һәм хезмәткәр-эшчеләргә системалы рәвештә материаль ярдәм күрсәтелеп килә.

Эшләүчеләрнең күбесенә бюджеттан тыш керем һәм бюджет акчасы исәбенә берәр тапкыр өстәмә түләү бирелә. Мәсәлән, 2002 елда гына да бюджет акчасы исәбенә биш миллионнан артык сумлык (ул чактагы акча белән) бер тапкыр түләү була. Шул ук елны студентларга, стипендияләренә өстәп, бер ярым миллион сум акча бирелә. Шулай ук аларга өстәмә дүрт стипендия түләнә.

Ректорат бигрәк тә аз хезмәт хакы алып эшләүчеләргә — гыйльми дәрәҗәсез укытучыларга, лаборантларга, хуҗалык эшчеләренә карата кайгыртучанлык күрсәтеп килә. Аларның төп хезмәт хакларына өстәп түләү гадәткә кертелгән була.

Университет хезмәткәрләренә социаль ярдәм тагын шунда күренә: хезмәт хаклары кечкенә күләмле укытучыларга, хуҗалык эшчеләренә, лаборантларга һәм башка төр хезмәткәрләргә аз гына (символик рәвештә генә) түләү белән вузның «служебный» дип атала торган квартираларында һәм тулай торакларында яшәргә мөмкинлек бирелә. Андыйларның саны университетта шактый була.

Узган гасырның 90 нчы еллары башында Казан педагогика университетында шактый күп кешене квартиралар белән тәэмин итү мөмкинлеге табыла. Торакны гадел юл белән, бары тик профсоюз оешмасы оештырган чират тәртибендә генә бирү гадәткә кертелә. Гади эшчеләр дә уңайлы квартираларга ия була. Гомере буена начар торакта яшәгән җыештыручы Сания ханым, өч бүлмәле яңа квартира алгач, шатлыгыннан ни эшләргә белмичә, бу хәлгә ышанмыйча йөри. Күп еллар

дәвамында, ректорны очратканда, шатлыгыннан елый-елый рәхмәтләр укый торган була.

Илдә бушлай торак белән тәэмин итү системасы бетерелгәч, университет 50ләп кешегә өлешчә түләү тәртибе белән квартиралар бирү җаен таба.

Җитәкченең эше, яхшы нәтиҗәләргә ирешим дисәң, шома гына бармый, әлбәттә.

Казан педагогика вузында кайбер кешеләр, бигрәк тә хуҗалык өлкәсендәгеләр, үзләре дигәнчә генә, иркен эш итәргә күнеккән булганнар. Шундыйларның берсе — хуҗалык эшләре җитәкчесе. Аның башбаштаклык күрсәтү, тәртип бозу күренешләре ачыклана. Катгый чаралар күреп, хуҗалык өлкәсендә җитәкчелекне алмаштырырга туры килә. Эш рәтләнә һәм соңыннан күп кенә игелекле гамәлләр кылына, университетның хуҗалыгы яхшыра.

Тарих факультетында да проблемалар җыелган булып чыга. Бер бара ректор анда, ике бара, кимчелекләр турында кисәтә. Декан тәртип урнаштыра алмый. Аның урынына икенче кешене куярга туры килә. Эшләр җайлана.

Рүзәл Юсупов соңыннан шуны аңлый. Аның даими рәвештә орынып диярлек эшли торган коллегаларының — проректорларның кайберләре, беркем белән дә сүзгә килмичә, бернәрсә дә таләп итмичә, җайлап, бөтен кешегә дә яхшатлы булып кына йөрергә күнеккәннәр икән. *«Мин артык демократ булып чыкканмын, ахрысы, яхшы сүз белән генә эш итәргә тырышканмын,* — дип искә ала бу хәлләрне Р.Юсупов. — *Кайберәүләр мондый стильне аңламый икән. Урынбасарларның җиңел генә, һәркемгә дә яхшатлы булып, таләп итмичә генә эшләргә өйрәнгәннәрен вакытында алмаштырырга кирәк булган, күрәсең. Соңрак миңа ялагайланып йөргән коллегаларымның кайберләре минем үземә этлек эшләделәр: яла ягу юлына бастылар. Җитәкче булу гади генә эш түгел: үзең белән һәрдаим янәшә эшләгән, сиңа һәрвакыт «җәме — җә» дип торган кешеләрне яхшы белергә һәм алар белән сак булырга кирәк икән.*

*Турысын әйтә торган кешеләрдән, сиңа ошамаган сүз әйтсәләр дә, куркырга, аларны читкә этәрергә кирәкми. Бер мисал. Бер елны студентларның язгы фестивалендә физика факультеты йомшаграк чыгыш ясады. Мин, студентларның фестивальдә ясаган чыгышларына йомгак ясаганда, киләсе елда физикларга ныграк тырышырга кирәк булачак, дигән фикер әйттем. Физика факультеты деканына бу сүз авыр тоелган, күрәсең: минем сүземә каршы тупасрак итеп җавап бирде. Мин аның кискен реакциясенә зур игътибар итмәдем: яшь кешеләрдә була ул шулай кайчак кискенрәк, уйлап бетермичәрәк эш итү.*

*Әмма ул декан уңган егет иде: факультет алга барды. Һәм мин тиздән аңа зуррак эш — укыту буенча проректор булырга тәкъдим иттем. Егет гаҗәплән-*

*де. Ул мине теге инцидент өчен ачу саклар дип уйлаган булса кирәк. Андый нәрсә минем уемда да юк иде. Бик тырыш, акыллы проректор булды, берничә ел үзара әйбәт мөнәсәбәттә, аңлашып эшләдек».*

Рүзәл Юсуповның ректор булып эшләү дәверендә уңышлары, игелекле гамәлләре, әйбәт башлангыч һәм яңалыклары күп була. Аларны сөйләп бетерү мөмкин дә һәм кирәк тә түгелдер. Без бу язмабызда аларның кайберләрен кыскача гына сурәтләп киттек.

Коллективның уңышларында җитәкченең роле: эшне уйлап оештыруда, хезмәткәрләрне алда торган әһәмиятле бурычларны үтәүгә туплый белүдә һәм иң мөһиме — тырышып эшләгән, намуслы кешене күрә, аның күңелен күтәрә, аңа кулыңнан килгәнчә ярдәм итә алуда һәм һәркемгә лаеклы кеше итеп карый белүдә.

Вуз коллективының уңышлы эшләвенең нигезе — сәламәт, саф микроклимат булуда. Бу исә коллектив хезмәткәрләре белән — җитәкчеләр, укытучылар белән студентлар арасындагы югары әхлаклы, цивилизацияле, кешелекле мөнәсәбәтләрдән барлыкка килә. Рүзәл Абдуллаҗанович җитәкчелек эшенә керешкәч тә моңа төшенеп, институтның (университетның) барлык бүлекләрендә дә яхшы микроклимат булдыру һәм аны саклауны иң беренче бурычы итеп куя. Моңа ирешү җиңел булмый.

*«Мин бер төп принципка таянып эш иттем: әңгәмәдәшеңне игътибар белән тыңлап, аның проблемасын аңларга һәм аны, үзеңә кыенлык килгәндә дә, уңай хәл итәргә тырышырга кирәк,* — дип сөйли Рүзәл Юсупов. — *Җитәкче кеше өчен тагын бер мөһим шарт: мәсьәләләрне хәл иткәндә, үз кул астыңда эшләүчеләргә басым ясау, мәҗбүр итү, авторитаризм ысулы кулланмаска, бәлки аңлату, инандыру методын иң беренче итеп санарга. Минемчә, җитәкче әңгәмәдәшенең фикерен дөресрәк дип тапса, ул үз фикеренә каршы килгән очракта да аның белән килешсә, моның эшкә бернинди дә зыяны тими һәм моннан җитәкченең абруе да кимеми, бәлки арта гына төшә. Кеше фикеренә колак сала белү — җитәкче өчен бик әһәмиятле сыйфат, әмма хәзерге заманда, минемчә, безнең җитәкчеләргә әлеге сыйфат җитеп бетми, һәм моның җәмгыять өчен зыяны зур, кайчакта исә бик зур була».*

Гадәттә, оешмаларда, дәүләт учреждениеләрендә системалы рәвештә финанс ревизияләре булып тора. Казан педагогика университетында Рүзәл Юсупов ректор булып эшләгән чорда андый ревизияләр дүрт-биш елга бер үткәрелә. Мәскәүдән, Россия Мәгариф министрлыгыннан була алар. Тикшерәләр, вак-төяк җитешсезлекләр табалар, эшне яхшырту, камилләштерү турында тәкъдимнәр ясыйлар, алар исәпкә алына, төзәтелә. Бу — табигый күренеш.

Әмма ике меңенче гасыр азагыннан педуниверситетка, аның ректорына югарыдан, кайбер җитәкчеләр тарафыннан караш үзгәрә башлый.

Россия Финанс министрлыгының Татарстан буенча контроль-ревизия идарәсеннән бер елны ревизия килә, икенче елны да килә, өченче елны тагын килә! Аңлашыла: бу юньлегә түгел. Димәк, ректорны эшеннән алу планы корылган. Димәк, ул кемнәргәдер ошамый башлаган яки кемгәдер урын кирәк булган.

Эш буенча бәйләнер җир юк: университет һәр яктан да алдынгы урында бара. Ул елларда Казан педагогика университетының абруе нык күтәрелгән иде. Әмма хәзерге заманда тырышып эшләп кенә ярап булмый икән җитәкчеләргә.

Ярамавының сәбәбен, дөресрәге, сәбәпләрен Рүзәл болай аңлата.

Беренчедән, Югары Совет депутаты булганда, ул җитәкчеләр тәкъдим иткән карар проектларын берсүзсез яклап тавыш биреп утырмаган: үз фикерен — ул кемнәргәдер ошамаса да — ачыктан-ачык әйтә, кирәк булганда, кемнәрнедер тәнкыйть тә итә торган булган. Шуңа күрә дә, парламентның икенче чакырылышына сайлауда үз фикерләрен кыю әйтә торган беркемне дә, шул исәптән Рүзәл Юсуповны да уздырмыйлар. Бездә сайлауларның гадел үткәрелмәгәнлеге һәркемгә мәгълүм.

Икенче сәбәп шуннан гыйбарәт. Татарстанның Югары Советында «республикада татар милли университеты ачарга» дигән карар кабул ителгән иде (әйбәт карар, әлбәттә), әмма бу карар гамәлгә ашырылмады. Димәк, шулай итеп, бу мәсьәләдә парламент карары үтәлми булып чыга, ә ул һичшиксез үтәлергә тиеш. Республика җитәкчелеге, бу мәсьәләне хәл итү өчен, Казан дәүләт педагогика университетын үзгәртеп, шуннан татар милли университеты төзергә тәкъдим итә. Рүзәл Юсупов, бу уку йортының ректоры буларак, болай ди: *«Мин, әлбәттә, татарларның милли университеты булуга каршы түгел, киресенчә, мондый карарны бик хуплыйм. Ләкин 130 еллык тарихлы, зур һәм күренекле Казан педагогика университетын татар милли уку йорты итеп үзгәртү реаль эш түгел. Чөнки, беренчедән, абруйлы педагогика югары уку йорты үз урынында кирәк, икенчедән, бу университет Россия Федерациясе карамагында, һәм министрлык мондый үзгәртүгә һич кенә дә юл куймаячак. Татар милли университетын Татарстан бик яхшы итеп үзе төзергә, үзе финанслап торырга һәм үз карамагында тотарга тиеш. Ул чакта Татарстанның мондый мөмкинлеге бар иде, ләкин аны кулдан ычкындырдылар». Минем мондый җавабым, проблемага мондый карашым кайбер власть ияләренә ошамады, әлбәттә. Мәсьәлә, уйлаганча, җиңел генә хәл ителмәде һәм гомумән хәл ителмәде. Республика башлыгы моңа ректор Юсупов гаепле дип ышандырырга тырышты. Безнең җитәкчеләр үз сүзләрен җөпләп, хуплап торуга гына күнеккән шул.*

*Казан педагогика университетындагы бер-бер артлы ревизияләрнең максаты баштан ук аңлашылды: ничек кенә булса да гаеп табу. Гайрәт чигергеч күренеш*

*булды ул ревизияләр. Бигрәк тә соңгысы. Бер дә урынсыз бәйләнүләр, акны кара дип язып куюлар... Комиссия членнары безнең аңлатканны тыңламыйлар, актны үзләре теләгәнчә язалар.*

*Ревизия тәмамлангач, акт белән риза булмавыбызны язып, аның астына үзебезнең бик җентекле җавабыбызны теркәп, гаепләүләрнең дөрес түгеллеген фактлар белән расладык.*

*Әмма безнең ул аңлатма язуыбызны укып торучы булмады. Маховик әйләндереп җибәрелгән: аны без туктатырлык түгел иде инде».*

Җитди булмаган финанс, хуҗалык ялгышларын һәр зур һәм хәтта кечкенә оешмада да табарга була. Казан педуниверситетында дәүләтнең әйберсен, акчасын үзләштерү булмый. Турыдан-туры ректор күрсәтмәсе белән эшләнгән финанс режимын бозулар да күренми.

Ләкин барыбер ревизия актын Мәскәүгә министрлыкка җибәрәләр. Татарстан җитәкчелеге андагы тиешле кешеләргә үз фикерен җиткергән: Юсупов ректорлыкта калмаска тиеш.

Министрлыкның кадрлар идарәсе начальнигы Р.Юсуповка үз теләге белән ректорлыктан китәргә тәкъдим итә. Рүзәл Абдуллаҗанович, финанс ялгышларында үзенең шәхси гаебе юклыгын әйтеп, сайлау срогым буенча бер ел эшлисем калды, шул вакыт җиткәч китәрмен, ди.

Р.Юсуповның ризалыгы булмагач, министрлык буенча приказ чыгаралар. Анда ректорга хөкем шундый: «Бер тапкыр тупас ялгыш җибәргән («одноразовое грубое нарушение») өчен эштән алырга».

Рүзәл Юсупов ачы язмышына риза булырга үзен әзерли башлаган була инде: хурланырлык нәрсә юк, җинаять эшләмәгән. Әмма, уйламаганда, бер зур белемле, тәҗрибәле таныш юрист белән очрашып сөйләшкәч, ул, бу хәлгә кагылышлы документлар белән танышып, сине эштән чыгарырлык сәбәп юк, үзеңнең хаклыгыңны суд белән раслый аласың, дип, Мәскәү судына бирергә киңәш итә. Рүзәл, аның киңәшен тотып, Мәскәүдәге Россиянең Мәгариф финистрлыгы урнашкан район судына мөрәҗәгать итә.

Судья, тиешле документлар белән танышып, Рүзәл Юсупов эшенең асылына төшенгәч, судның карарын игълан итә: «Р.А. Юсуповны хәзер үк ректорлык эшенә кайтарырга (торгызырга)».

Рүзәл Абдуллаҗанович, ректор булып тагын бер елга якын эшләп, үз теләге белән китә.

Шушы чорда ул дуслар булып, үзенә тәлинкә тотып йөргәннәр арасында вак җанлы, икейөзле кешеләр барлыгын белә.

Моның белән дөнья бетми: Рүзәл Юсупов Казан педагогика университетында кафедра мөдире булып эшләп кала. Кешеләр аңа хөрмәт белән караудан туктамый.


Әмма Рүзәл Абдуллаҗановичның күңелендә калын юшкын утырып кала. Хаксызга рәнҗетелүне, яла ягуларны, матбугатта үзе турында ялган нәрсәләр басып чыгаруларны кичерүе бик авыр була, әлбәттә. Моның сәламәтлеккә зыяны да тими калмый, билгеле.

Соңрак куанычлы хәлләр дә була. Шундыйларның берсе: 2007 елда Рүзәл Юсуповны Татарстан Фәннәр академиясенең академигы һәм вице-президенты итеп сайлап куялар. Ул һәр елны икешәр-өчәр китап, дистәләгән мәкаләләр язып бастырып тора. Башка файдалы гамәлләре дә була, әлбәттә.






*Ректор кабинетында*



*Профессор Р.А.Юсупов студентларга лекция сөйли*



*Рүзәл Юсупов үзе эшләгән татар теле факультеты укытучылары белән*



*Доцент Р.Юсупов — студентлар группасы җитәкчесе*



*Педуниверситет җитәкчеләре ял базасы «Яльчик»тагы төзелеш белән танышырга килгән*



*«Университет» статусы мәсьәләсен хәл итү комиссиясе членнары белән*




*КДПУда фәнни конференция бара*



*Академик Р.А.Юсупов җитәкчелегендә советта диссертация яклау*
*(оппонент академик Ә.Р.Тенишев сөйли)*




*Казан педуниверситеты үз канаты астына алган «Татар-төрек лицее»нда*



*Казан педагогика университетының юбилее кичәсендә*




*КДПУга спорттагы казанышлары өчен приз тапшыру*





*Казан педуниверситеты колоннасы 1нче Май демонстрациясендә*



*Татарстан вузлары ректорларының республика җитәкчеләре белән очрашуы*

# ТЕЛ ГАЛИМЕ — ПУБЛИЦИСТ

## ТЕЛ ГАЛИМЕ — ПУБЛИЦИСТ

Рүзәл Юсуповка телефоннан шалтыратып хәлен белешкәндә, нәрсә белән шөгыльләнүе турында сорасаң, ул, гадәттә, бертөрле җавап бирә: «Менә язып утырам әле». Аннары нәрсә язуы турында сөйләп китә.

Чыннан да Р.Юсупов күп яза. Китаплар яза, газета-журналларга мәкаләләр яза, радио-телевидениегә чыгышларын әзерли. Шушы көннәрдә мин аның яңа гына чыккан «Матбугат һәм эфир теле» дигән китабын укып утырганда, андагы кушымтада академик Р.А.Юсуповның басылып чыккан хезмәтләре исемлегенә игътибар иттем: 60 тан артык монография, дәреслек һәм уку ярдәмлеге, 500 чамасы фәнни һәм публицистик мәкалә. Мондый иҗат нәтиҗәләренә, мөгаен, гомере буе бары язу-сызу белән генә шөгыльләнгән профессиональ язучыларның да бик азы гына иядер. Белүемчә, галимнәрнең дә, гадәттә, монографияләре берничә генә була. Ә Р.Юсуповның монографияләре — 22!

*«Университетта укыганда миңа, халыкча әйтсәк, «тәрҗемә җене» кагылганнан бирле, ягъни тәрҗемә эшенең кагыйдәләрен, теориясен өйрәнә башлаганнан бирле, азмы-күпме тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнергә туры килде,* — дип яза Рүзәл Юсупов. — *Кечерәк фәнни-техник китаплар, политик эчтәлекле басмалар һәм берникадәр В.И.Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә иттем. Араларында бик авырлары да булды. Мәсәлән, «В.И.Ленин, Фридрих Энгельс и Карл Маркс об искусстве», «В.И.Ленин о религии» дигән китапларны тәрҗемә итеп чыгуга ничек түземлегем җиткәндер, хәзер үзем дә гаҗәпләнеп куям. В.И.Ленин әсәрләренең тулы басмасының соңгы ике томын тәрҗемә итү дә бик авыр эш булды. Яшь чакта көч тә, дәрт тә күбрәк була шул. Бу китаплар нәшриятта басылып чыкты».*

Күрәсең, язмышы шундыйдыр, Рүзәл Юсуповка тормышында, туган теле белән беррәттән, рус телен дә күп кулланырга, даими рәвештә ике телдә дә чыгышлар ясарга туры килә. Бу аның тормышының, эшчәнлегенең үзенчәлекләренә карый. *«Автобиографиямдә бер символик деталь бар: бала чагымда, саф татар авылында яшәп, татар мәктәбендә укып йөргәндә, рус телендә язылган кечерәк кенә балалар китабын укып чыкканнан соң, кинәт кенә кайдандыр бер теләк туып, шул китапны тәрҗемә итәргә маташкан идем. Бу — бик кызык хәл. Әйтерсең ниндидер бер тылсымлы көч миңа киләчәктәге тәрҗемә итү һәм телләрне чагыштырып өйрәнү өлкәсендәге эшемә әзерләнә торырга кирәклеген кисәтеп куйган. Гыйльми тикшеренү юлына аяк басканнан бирле, миңа төрле төзелешле рус һәм татар телләренең үзара нисбәте, бәйләнеше, бер-берсенә йогынтысы мәсьәләләрен өйрәнү белән шөгыльләнергә туры килде»,* — ди Рүзәл Юсупов.

Галимне татар теленең язмышы, сафлыгы, дөреслеге мәсьәләләре һәрвакыт аның игътибар үзәгендә булып, борчып тора. Һәм бу аның фәнни-публицистик хезмәтләрендә дә ачык чагылыш таба. «Тәрҗемә һәм тел культурасы», «Укучыларда сөйләм культурасын тәрбияләү», «Икетеллелек һәм сөйләм культурасы», «Җылы сүз җан эретә», «Икесен дә яхшы бел» дигән һәм башка китапларында ул татар теленең әдәби нормаларын саклауны яклый. Татарстан китап нәшриятында академикның татар теле гыйлемендә мөһим урын тоткан фәнни хезмәтләре бер-бер артлы дөнья күрә. «Тәрҗемә теориясенә кереш», «Тәрҗемә мәсьәләләре», «Инсафлының теле саф», «Әдәп башы — тел» дигән китапларын укучылар җылы кабул иттеләр.

«Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның хезмәтләре нәкъ шушы көн кадагына суга торган темага язылган. Хезмәтләрнең актуальлеге соңгы елларда артканнан арта бара, чөнки Татарстан Республикасының яңа Конституциясе, «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» законы, Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы кабул ителү телләрне типологик аспектта өйрәнүне көнүзәк мәсьәлә итеп куйды, — дип яза «Бәрәкәтле иҗат» дип исемләнгән мәкаләсендә Рүзәлнең сабакташы, филология фәннәре докторы Фирдәвес Гарипова. — Татар теленең статусын дәүләт дәрәҗәсенә күтәрү Татарстанда икетеллелекне тормышка ашыру бурычын куя, һәм шул нигездә тел белеме галимнәре тарафыннан төзелешләре ягыннан төрле булган татар һәм рус телләренең үзара бәйләнеш закончалыкларын өйрәнү көн тәртибенә килеп баса».

Р.Юсуповның глобаль концептуаль проблемаларны күтәреп, аларны зур эрудицияле, төпле һәм нигезле итеп, күп фактик материалларга нигезләнеп чишкән иң әһәмиятле хезмәтләреннән берсе — «Татар һәм рус телләрендәге лексик-фразеологик чаралар» (Казан, 1980) дигән зур күләмле китабы. Анда автор татар һәм рус телләре лексикасындагы гомумилекләрнең алынмалар белән генә чикләнмәвен күрсәтеп, бу өлкәдә күп мәсьәләләрне яңача хәл итә. Шул уңайдан бер телдәге теге яки бу форманы механик рәвештә икенчесенә күчергәндә килеп чыккан ялгышларга тукталa, татар һәм рус телләрендәге фразеологик берәмлекләрнең охшаш һәм аермалы якларын да барлап чыга.

Җир йөзендә алты меңнән артык тел булуы мәгълүм. Алар чыгышлары, төзелешләре, вазифалары белән төрлесе төрле дәрәҗәдә кулланылышта йөри. Бу уңайдан тарихка күз салу кызыклы. Борынгы Рим империясе чәчәк аткан чорда латин теле империянең халыкара аралашу теле булып торган, ә Урта гасырларда исә гарәп халифәте көчле дәвердә — гарәп теле, күпмедер дәрәҗәдә фарсы теле, Болгар дәүләте чәчәк атканда яисә Алтын Урда вакытында борынгы татар-бол-

гар, татар-кыпчак телләре халыкара тел вазифасын үтәгән. Һәм, ниһаять, совет империясендә бу вазифаны рус теле үтәде. Хәзерге көндә дөньякүләм дәрәҗәдә халыкара тел булып инглиз теле гамәлдә йөри. Шунлыктан күпчелек фәнни, публицистик, техник, нәфис һәм башка әдәбият инглиз теленнән тәрҗемә ителә. Шуңа күрә тәрҗемәнең теоретик һәм гамәли кануннарын, закончалыкларын белү бүгенге көндә зур әһәмияткә ия.

Бу җәһәттән академик Р.Юсуповның «Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре» дигән китабы бүгенге көнгә аваздаш, заман таләпләренә җавап бирә. «Бу фәнни-популяр хезмәттә тәрҗемәнең назари һәм гамәли мәсьәләләре төрле телләрдән тәрҗемә кылу, сөйләм культурасын төрле этрафлардан торып бәян итү җирлегендә яктыртыла. Әлеге хезмәт журналистлар, укытучылар, студентлар, филолог галимнәр, икетеллелек шартларында, глобальләшү, интеграцияләнү чорында ана телебез хакында уйланган, аның киләчәк язмышы өчен борчылган киң җәмәгатьчелек өчен бик тә кирәкле, әһәмиятле кулланма, өстәл китабы булачак», — дип язды «Татарга да тылмач кирәк» дигән мәкаләсендә филология фәннәре докторы Мәлик Хәйруллин («Мәдәни җомга», 13 май, 2011 ел).

Без, Россия дәүләтендә яшәүче татарлар, кечкенәдән үк, үзебезнең туган телебез белән беррәттән, рус теленнән дә файдаланырга дучар ителгән. Күпчелекне рус халкы тәшкил иткән күпмилләтле илдә, рус телен белми торып, уңышлы яшәү бик кыенга туры килә, дөресрәге, мөмкин дә түгелдер. Шушы халәттә татар кешесенә туган телендә теге яки бу фикерне, мәгълүматны бәян иткәндә, тиешле төшенчәне белдергәндә, күп очракта рус теленнән тәрҗемәгә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Чөнки һәртөрле информация, фән-техника, сәясәт, мәдәният өлкәсендәге яңалыклар безнең илдә, кагыйдә буларак, рус телендә ирештерелә, һәм руслардан башка халыклар, шул исәптән татарлар да, кирәкле мәгълүматны рус теленнән тәрҗемә итеп ала.

Димәк, безнең телебез хәзерге шартларда даими рәвештә рус теле белән элемтәдә тора, һәм татар теле иясенә рус телен дә белеп, ул телдә дә эш итәргә, шуның өстенә, бу ике телне берсеннән икенчесенә тәрҗемә итеп тә кулланырга туры килә.

*«Тәрҗемә итүнең зур практикага нигезләнгән мәгълүм принциплары, алымнары һәм ысуллары, теориясе, фәне бар. Аларны белми торып, югары сыйфатлы тәрҗемәгә ирешү мөмкин түгел. Һәвәскәр башкарган тәрҗемә оригиналның мәгънәсен дә бозарга, тәрҗемә теленең дөреслегенә, табигыйлегенә зыян да китерергә мөмкин,* — дип яза Рүзәл Юсупов «Ялгыш тәрҗемә итү — туган телне бозу» дигән мәкаләсендә («Мәдәни җомга», 30 май, 2014 ел). — *Тәрҗемә эшенә куела торган төп ике таләп — оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен мөмкин булганча*

*төгәл, тулы итеп бирү һәм тәрҗемә теленең дөреслеген саклау. Бу таләпләрнең икесен дә үтәү җиңел эш түгел, ләкин бик тырышканда мөмкин. Русчадан татарчага тәрҗемәләрдә барыннан да бигрәк туган телебез бозыла. Хәер, оригиналның мәгънәсенә зыян китерү хәлләре дә сирәк түгел».*

Безнең тел соңгы елларда бигрәк тә рус теленнән ялгыш тәрҗемә итү аркасында бозыла. Тәрҗемәче оригинал сүзенә тәңгәллекне сүз сөрешеннән (тексттан) аңлашылган мәгънәгә карап билгеләми, бәлки андый тәңгәллек итеп күпчелек очракта кулланыла торган, гадәттә, ике тел сүзлекләрендә теркәлгән һәм башына беренче килгән сүзне куллана. Мәсәлән, ул, рус телендәге «глубокая радость» әйтелмәсен татарчага, «глубокий»ның сүзлектә теркәлгән төп мәгънәсенә туры килә торган «тирән» сүзеннән файдаланып, «тирән шатлык» дип тәрҗемә итә. Һәм бу тәгъбир татар теле өчен табигый килеп чыкмый. Оригинал мәгънәсен дөрес белдерү өчен, «глубокий» сүзенең бу әйтелмәдәге мәгънәсен төгәл бирерлек тәңгәллек эзләп табарга кирәк. Андый тәңгәллек булып «зур» сүзе хезмәт итә: зур шатлык. «Глубокий» сүзен ялгыш тәрҗемә итү нәтиҗәсендә төзелгән ясалма әйтелмәләр генә дә дистәләп санала: «тирән рәхмәт» (чын татарча — зур рәхмәт), «тирән мәхәббәт» (олы мәхәббәт, нык (көчле) ярату), «тирән ихтирам» (зур ихтирам), «тирән кайгы» (зур кайгы, кара кайгы), «тирән кызыксыну» (нык кызыксыну), «тирән белем» (ныклы, төпле, яхшы белем һәм башкалар).

Тел гыйлемендә Р.Юсуповны даими борчый һәм каләмен хәрәкәткә китерә торган тагын бер өлкә бар, ул да булса — сөйләм культурасы. Үзара әңгәмәләрдә булсын, конференция-утырышларда булсын, ул һәрвакыт булачак укытучыларның сөйләм культурасы дәрәҗәсен камилләштерү мәсьәләләрен күтәрә, шушы юнәлештә гамәли чаралар күрә. Ул әлеге курсны, бик мавыгып, яратып, шәкертләренә укытты, аларның да шундый ук гамь белән яшәвен теләде. Галим буларак, ул уннарча еллар инде сөйләм культурасын үстерүгә багышланган хезмәтләр яза. «Укучыларыбызда сөйләм культурасы тәрбияләү», «Инсафлының теле саф», «Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре», «Тәрҗемә мәсьәләләре» кебек китаплары — укытучыларның һәм студентларның төп таянган хезмәтләре. Болар өстенә Р.Юсупов — татар теле буенча мәктәпләр өчен берничә дәреслек, программа төзегән кеше. Иң әһәмиятлесе шунда: боларның һәммәсенә ихтыяҗ бар. Аларны укытучылар, журналистлар, тел культурасы мәсьәләләре белән бәйләнешле башка һөнәр ияләре дә куллана.

*«Тел — ул кешеләр иҗат иткән иң бөек казанышларның берсе. Телдән башка чын нәтиҗәсендә кешелек җәмгыяте барлыкка килә, хәзерге дәрәҗәсенә ирешә дә алмаган булыр иде. Тел — кешеләрнең үзара аралашуының, бер-берсенә мәгълүмат тапшыруының төп коралы. Ләкин телнең вазифалары моның белән генә чикләнми,*

*һәр халыкның туган телендә аның үзенә генә хас табигате, үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре чагылыш таба, рухи байлыклары — мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты, тарихы саклана һәм үстерелә. Күп галимнәр хаклы рәвештә халыкның теле белән рухи халәтендә генеалогик һәм тарихи бәйләнеш бар дип һәм һәр халыкның теле — бөтен дөнья җәмгыятенең уникаль (бердәнбер) хәзинәсе дип саныйлар. Бу мәсьәләдә бөек рус педагогы К.Ушинскийның гыйбрәтле сүзләре аеруча игътибарга лаек: «Халыкның теле — аның рухи тормышындагы иң күркәм, беркайчан да сулмый, мәңге яшәреп торган гөлчәчәге. Телдә бөтен халык һәм аның бөтен Ватаны рухландырыла...» Менә шуңа күрә колонизаторларның барысы да беренче чиратта үзләренә буйсындырылган халыкларның телләренә каршы көрәшкән, шул ук вакытта җирле халыклар туган телләрен, традицияләрен һәм милли бәйсезлекләрен төрле чаралар белән саклап калырга тырышкан»,* — дип яза Р.Юсупов.

Бүгенге көндә Россиянең күп кенә җитәкчеләре башында «Бер тел, бер дин, бер халык — русиялеләр» дигән империячел идея хөкем сөрә. Соңгы елларда Россия хакимияте милләтләрнең туган телләрен куллануга, өйрәнүгә һәм саклауга булган халыкара хокукларын санга сукмый. Россия Конституциясе таләпләре белән исәпләшми торган берничә закон кабул ителде. Милли мәктәпләрдә бердәм дәүләт имтиханнарын рус телендә бирү, мәктәпләрдә милли телләр һәм әдәбиятлар укытуны мәктәп программаларыннан чыгару, милли тел дәреслекләрен Россия Мәгариф министрлыгы рөхсәте белән генә бастыру турындагы законнар — шундыйлардан.

Руслардан башка халыкларның яшәешенә һәм үсешенә каршы юнәлтелгән сәясәтнең тискәре нәтиҗәләре безнең республикада да үзен нык сиздерә. Мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын өйрәнү белән кызыксыну кими, һәм укучыларның бу фәннәрдән белемнәре түбәнәя. Шәһәрләрдәге татар мәктәпләрендә укучылар саны азая. Татар теленең кулланылу мәйданы да тарая, сыйфаты да түбәнәя бара. Татарстан шәһәрләрендә яшәүче татар яшьләренең 60 проценттан күбрәге туган телләрен начар белә яки бөтенләй белми.

Академик Рүзәл Юсупов көн кадагындагы актуаль мәсьәләләр буенча даими рәвештә мәкаләләр язып бастыра. «Звезда Поволжья» газетасында басылган «О нашей Казани», «Татарская республика или губерния?», «Цена праздника» (Республика көне уңаеннан), «О Конституции», «Родной язык и татарские школы», «Концепция» дигән һәм башка кайбер публицистик мәкаләләре укучыларны нык уйландыра һәм дулкынландыра. Аның «Без һәр сүзебез өчен җаваплы» («Ватаным Татарстан», апрель, 2014), «Ни өчен артка чигенәбез?» («Ватаным Татарстан», 11 август, 2015), «Дәресләрдә тәрбия мәсьәләләре» («Мәгариф», 2005, №6) һәм күп кенә башка мәкаләләре укучыларда әһәмиятле фикерләр уята.

Казан (Идел буе) федераль университеты оештырылу уңаеннан да Р.Юсупов үзенең карашын белдерде, бу хакта берничә мәкалә язып бастырды. Аларның кайберләре, Россия хөкүмәтенең рәсми карары чыгуга ук, республика газеталарында басылды. Ул вакытта әле федераль университет составына кайсы уку йортларының кушылачагы турында рәсми документ юк иде. Халык арасында бары тик имеш-мимешләр генә йөрде. Шулай да «130 елдан артык тарихы булган Казан педагогика университеты мөстәкыйль югары уку йорты булудан туктаячак» дигән яңалык халыкта, бигрәк тә Татарстан мәктәпләрен һәм республикадан читтәге мәктәпләрне татар теле, әдәбияты укытучылары белән тәэмин итү өчен җаваплы хезмәткәрләрдә һәм, гомумән, туган телне саклау, үстерүне кайгырта торган кешеләрдә шикшөбһәләр, борчулы уйлар туага сәбәп булды.

*«Мин үзем бу яңалыкны уңайга юрарга тырышам»,* — дип язды Рүзәл Юсупов. Аның күзаллавынча, федераль университет составында гуманитар институт булырга тиеш иде. Бу институтта татар, рус, инглиз телләрен (ихтыяҗ булганда кайбер башка телләрне дә) яхшы белгән, әдәбияттан, тарих, философия, мәдәнияттән җитәрлек белемнәре булган һәм, әлбәттә, югары кешелеклелек, әдәп нормаларын үзләштергән, хәзерге заман шартларында төрле өлкәләрдә уңышлы эшләрлек һәм иҗат итәрлек югары сыйфатлы белгечләр әзерләнергә тиеш иде.

Казан (Идел буе) федераль университеты республиканың берничә уку йортын үз эченә алды, чиксез зурайды. Әмма бу уку йортының эше бүген бик күпләрдә канәгатьсезлек тудыра. *«Минем күп кешеләрнекенә туры килә торган фикеремчә, Казан педуниверситетын бетерү игелекле мәгариф эшенә зур зыян салды. Бу — гафу ителмәслек гамәл кылулары өчен җаваплы кешеләр яхшы белем һәм тәрбия бирү җәмгыятьнең уңышлы алга баруының беренче шарты, прогрессның нигезе икәнлеген һәм югары профессональ дәрәҗәдәге укытучылар Казан педагогика университеты кебек абруйлы мөстәкыйль уку йортында гына әзерләнгәнлеген уйламаганнар, күрәсең. Монда шуны искәртү урынлы: Россия Федерациясенең барлык республикаларында һәм өлкәләрендә, барлык зур һәм уртакул шәһәрләрендә, шул исәптән Мәскәүдә дә, әлбәттә, педагогика югары уку йортлары уңышлы эшләп килә, һәм беркемнең дә башына аларның берсен юкка чыгарырга кирәк дигән уй килми,* — дип язды Р.Юсупов. — *Казан педагогика университетын бетерү аркасында бигрәк тә татар теле һәм әдәбияты белгечләрен әзерләү эшенә зур зыян килде. Бу белгечлекләр буенча укытучылар саны берничә тапкыр киметелде, һәм укытуның сыйфаты түбәнәйде. Соңгы вакытларда югары белемле татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләүнең торышы хакында борчылып сөйләүчеләрнең арта баруы очраклы хәл түгел. Әмма иртәме-соңмы аек акыл җиңеп чыгар, һәм республиканың тиешле*

*җитәкчеләре, әгәр дә алар татарларның туган телләренә, димәк, бай мәдәниятле татар халкының үзенең дә язмышына битараф булмасалар, педагогик белем бирү проблемасы турында җитдирәк уйланырлар, якын арада Казан педагогика университетының шанлы традицияләрен һәм игелекле гамәлләрен торгызу мөмкинлекләрен табарлар».*

2017 ел башында академик Рүзәл Юсуповның тагын бер китабы дөнья күрде. «Мәгърифәт, милләт, мәмләкәт» дип исемләнгән бу китапта халкыбызның рухи тормышындагы бик әһәмиятле тәрбия, аң-белем, милли горурлык мәсьәләләре, туган телебез, мәдәниятебез, күркәм гореф-гадәтләребезне саклау һәм республикабызның дәүләт төзелеше проблемалары бәян ителә.

Китаның «Кереш» дигән бүлегендә әйтелгәнчә, хәзерге чорда татар халкының иң әһәмиятле изге бурычы — үзен милләт буларак саклау һәм дәрәҗәсен күтәрү. Югыйсә соңгы вакытларда аның яшәешенә һәм алга баруына торган саен ныграк куркыныч яный. Бигрәк тә милләтнең төп билгесен тәшкил иткән туган теленә зур зыян килә, аны өйрәнү, дөрес куллану өчен шартлар кыенлаша. Татарларның бай мәдәниятен саклап калу, үстерү өчен мөмкинлекләр дә җитәрлек түгел.

Татарларның югары мәдәниятле, алдынгы милләт булып яшәве перспективасы, язманың исеменнән күренгәнчә, хәлиткеч өч төшенчәгә — мәгърифәт, милләт, мәмләкәт (дәүләт) төшенчәләренә бәйләп бәян ителә. Китапта «милли аңны үстерү, милли горурлык хисләре тәрбияләү, татар милләтен күтәрү, алга җибәрү идеясе илдә яшәүче күп төрле башка халыкларның интернациональ дуслыгына һәм бердәмлегенә, дәүләт күләмендәге патриотизм рухына һич кенә дә каршы килергә тиеш түгел» дигән фикер үткәрелә.

Китап өч бүлектән тора. Беренче бүлекне автор «Мәгърифәт нуры ныграк яктыртсын» дип исемләгән. Мәгърифәт — «аң-белем», «мәдәният» мәгънәләрен белдерә торган сүз. Димәк, ул кеше тормышының матди ягы кебек үк әһәмиятле рухи эчтәлеген тәшкил итә. *«Россиядә кыргый капиталистик мөнәсәбәтләр хөкем сөргән, кешеләрнең тормышында базар, товар, акча хәлиткеч нәрсәгә әверелә барган хәзерге заманда, мәгърифәтчелек идеясе белән коралланып, кешеләрнең җанын савыктыру, рухи тормышларын югары дәрәҗәле, мәгърифәтле итеп кору зарурлыгы бик актуаль була бара,* — дип яза автор. — *Хәзер илебез икътисади һәм рухи кризис кичерә. Һәркемгә мәгълүм: хакимият ияләре узган гасырның 90 нчы елларыннан бирле, дәүләтне үзгәртеп корабыз дип, илне шактый нык бөлгенлеккә төшерделәр, халыкның матди хәлен авырайттылар, шуның өстенә, кешеләрнең рухи тормышында да тискәре күренешләр арта, әхлак дәрәҗәсе түбәнәя».*

Ил язмышына битараф булмаган, аек акыллы күренекле шәхесләр дәүләтебезнең авыр хәлдә булуына борчылалар, тормышны яхшырту юлларын табарга тыры-

шалар һәм бу уңайдан дәүләт җитәкчеләренә мәгълүмат чаралары аша үзләренең эшлекле тәкъдимнәрен ирештерәләр. Рүзәл Юсупов та — нәкъ менә шундыйларның берсе.

Автор билгеләп үткәнчә, тәрбия — кешелек җәмгыятенең тоткасы. Кеше туганнан алып гомеренең азагына кадәр төрле дәрәҗәдә, төрле рәвештә тәрбия ала. Тәрбия төрле халыкларда төрлечәрәк, ягъни үзенчәлеклерәк гамәлгә ашырыла. Әмма аның төп билгеләре, нигездә, гомуми: кешеләргә бала чактан башлап тиешле аң-белем бирү, төрле һөнәрләр өйрәтү, бөтен кешелек җәмгыятенә хас әхлак сыйфатларын, коллективта яшәү кагыйдәләрен сеңдерү. Аларның барысы да югары үсешкә ия булган цивилизацияле халыкларда төп бер максатка ирешүне — җәмгыять әгъзаларын культуралы, әдәпле затлар итеп тәрбияләүне күздә тота.

Дәүләт, тәрбия белән шөгыльләнүне иң әһәмиятле, иң ашыгыч бурыч итеп санап, бу эшне бөтен ил күләмендә югары баскычка күтәрү максатын күздә тоткан комплекслы программа буенча гамәлгә ашырырга тиеш, дип саный Р.Юсупов. Бу программаның тәрбия эшенең бөтен дөньяда тупланган тәҗрибәсен исәпкә алуы шарт. Монда шунысы әһәмиятле: программа киң колачлы булсын, ягъни ул һәртөрле аудиторияне — кечкенә балалардан алып олыларга кадәр халык катламнарын күздә тотып эшләнергә тиеш. Шул ук вакытта анда төрле халыкларның бу өлкәдәге милли үзенчәлекләре дә чагылыш тапсын.

Программада тәрбиянең төрле төрләре, аерым алганда әхлак, хезмәт тәрбиясе, эстетик, патриотик, дини, экологик, физик тәрбия урын алырга тиеш. Рүзәл Юсуповның әлеге хезмәтендә тәрбия төрләренең һәрберсенең төп юнәлешләре бәян ителә.

Китапның икенче бүлеге мәгариф өлкәсендәге проблемаларга багышлана. Монда профессорның, шушы темага багышлап, татар һәм рус телләрендә язылган әһәмиятле мәкаләләре туплап бирелгән. Автор билгеләп үткәнчә, бюрократизм, формализм, кәгазь волокитасы, узган гасырның 90 нчы елларыннан алып, җитештерү кимүгә параллель рәвештә арта бара. Соңгы вакытларда төп көчне эшнең сыйфатын яхшыртуга, нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтәсе урында, структур үзгәрешләр кертү, форма яңарту белән мавыгу гадәткә керде. Бу бөтен илгә, шул исәптән безнең республикага да, халык хуҗалыгының барлык өлкәләренә дә хас.

*«Моннан берничә ел элек, безнең югары хакимият әмере белән, Казан дәүләт педагогика университетына республика карамагындагы ике югары уку йортын: — Татар гуманитар институты белән Татарстан — Америка региональ институтын кушып, бер вуз — Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты оештырдылар. Бу гамәлнең укытучы-педагоглар әзерләүнең*

*сыйфатын күтәрү өчен бернинди дә файдасы тимәде, зыяны исә шактый зур булды. Бу чара югарыдагы берничә җитәкченең мәнфәгатьләре өчен генә күрелде»,* — дип яза автор.

Мондый гамәлләрен җитәкчеләр «бу вуз Татар милли университеты урынына булачак» дип аңлатырга тырыштылар. Чөнки Татарстан Югары Советының «республикада татар милли университеты төзергә» дигән карары бар иде. Әмма бу карар тормышка ашмады. Берләштереп ясалган вуз барыбер Россия карамагындагы педагогика уку йорты булып калды. Тиздән Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының үзен дә бетерделәр: аны Казан (Идел буе) федераль университетына куштылар.

*«Бездә күп кенә җитди, зур мәсьәләләрне халык белән, эшне яхшы аңлаган белгечләр белән киңәшләшмичә, административ тәртиптә хәл итү аркасында зыянлы эшләр башкарылуга гыйбрәтле мисал бу,* — ди Р.Юсупов. — *Педагогика кадрларын әзерләүнең сыйфаты да түбәнәйде. Университетта, аерым алганда филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында, белгечләр әзерләү эшендә беренче планда югары белем дәрәҗәсенә, яхшы сыйфатка ирешү түгел, формаль күрсәткечләргә ия булып, вузга күбрәк акча эшләтү бурычы тора. Хәзер монда булачак белгечләргә төпле белем бирү, студентларны яхшы педагоглар итеп әзерләп чыгару укытучы-галимнәр алдына төп максат итеп куелмый».*

Автор бәян иткәнчә, «реформалар ясыйбыз» дигән булып, күп дистә еллар сыналган, нәтиҗәле эшләп килгән мәгариф системасын боздылар, аның нигезен какшаттылар. Мәктәп тәмамлап чыккан яшьләрнең, хәтта студентларның, югары белемле белгечләрнең туган телне бозып, стиль, орфография, пунктуация хаталары белән сөйләү һәм язу очраклары табигый күренешкә әверелеп бара. Яшьләрнең һәм урта буын кешеләренең сөйләмнәрендә дә тел ялгышлары күп.

Безнең уку йортларында чит телләрне өйрәтү түбән дәрәҗәдә. Европада, Азия, Африка илләрендә урта белем алучы яшьләр мәктәптә укыганда ук инглиз телендә иркен сөйләшәләр. Ә бездә юк, чөнки тел укыту методикасы дөрес түгел. Ул күбрәк кагыйдәләр, билгеләмәләр ятлауга, теория өйрәтүгә корылган. Минемчә, тел өйрәтүнең максаты укучыны иркен аралашырга, дөрес сөйләргә, язарга өйрәтү булырга тиеш. Республикабыздагы рус мәктәпләрендә укучыларның, шул исәптән татар балаларының да, унбер ел буена татар телен өйрәнеп тә, татарча әйбәт сөйләшергә, язарга өйрәнмәүләре һич кенә дә нормаль хәл түгел. Бездә теорияне өйрәнү еш кына үзмаксатка әверелеп кала.

Мәктәптә сыйфатлы белем алу репетиторлык системасы аша түләүлегә кайтып кала. Бу исә күпчелек ата-аналарның хәленнән килми. Ни өчен балаларның ба-

рысын да түләүсез, бертигез тырышып, сыйфатлы итеп укытмыйлар, ярым-йорты белем белән генә калдыралар, дигән урынлы сорау туа.

*«Вуз укытучылары да элекке кебек, нәтиҗә булсын дип, күңел биреп хезмәт итмиләр. Чөнки эшкә күңелләре үсми. Аларга лаеклы хезмәт хакы түләмиләр. Укытучы-галимнәрнең полицейскийдан ким алып эшләвен ничек аңлап була? Россиядә заманча ныклы белем, яхшы тәрбия бирү өчен, укытучыларның хезмәт хакын, хокук саклау органнары хезмәткәрләренеке кебек, ике-өч мәртәбә арттырырга, тормыш шартларын яхшыртырга, шул ук вакытта эшнең сыйфаты өчен таләпләрне нык күтәрергә кирәк. Шушы шарт үтәлгәндә генә, безнең ил алдынгылар сафына басар, дип өмет итәргә мөмкин»,* — ди Рүзәл Юсупов.

Соңгы елларда дәүләт җитәкчеләре керткән яңалыклар күп очракта уңай нәтиҗә бирми. Чөнки, беренчедән, бик әһәмиятле, хәлиткеч карарларны, мәсьәләнең төрле якларын төптән уйламыйча, бер-ике генә кеше хәл итеп куя. Икенчедән, бездә ил язмышына кагылышлы бик җитди карарларны бөтен халык белән киңәшләшеп, референдум үткәрү юлы белән кабул итү тәртибе юк.

Эшнең сыйфатын яхшырту турында җитди уйланасы урында, мәгарифкә, чит илләрдән алып, бездә уңай нәтиҗә бирми торган яңалыклар кертү белән мавыгалар. Бердәм дәүләт имтиханнары, тестлар үткәрү, югары уку йортларында ике баскычлы итеп белем бирү кебек алымнар үзләрен акламады.

Элек һәр югары уку йорты укытучылары, абитуриентларны студент итеп үзләре тикшереп алганда, аларның сыйфаты өчен җаваплы иде. Хәзер исә кайдандыр, ни рәвешледер алып килгән билгеләренә карап кабул итәләр. Мәсьәләләрне һәрьяклап уйламыйча хәл итү, илне идарә итүдә кирәгеннән артык үзәкләштерү системасы тормышның төрле өлкәләрендә чагылыш таба, һәм бу хәл еш кына тискәре нәтиҗәләргә китерә.

*«Татарлар өчен хәзерге заманда иң әһәмиятле, иң зур максат ул — үз милләтебезне, халкыбызны, телебез һәм мәдәниятебезне, матур гореф-гадәтләребезне саклап калу. Бу изге максатка ирешә алынырмы, юкмы — кистереп әйтү кыен, чөнки хәзерге рус дәүләтенең вазгыяте шулай дәвам итә барса, милләтләрнең, шул исәптән татарларның да, милләт буларак саклану һәм прогресска ирешү мөмкинлекләре көннән-көн кими барачак. Әлегә узган гасырның туксанынчы елларында Дәүләт суверенлыгы декларациясе, яңа Конституция кабул итеп, суверенлык турында референдум үткәреп ирешкән нәтиҗәләребез юкка чыгып килә»,* — дип яза академик.

Р.Юсуповның «Мәгърифәт, милләт, мәмләкәт» дигән китабының «Татарстан Республикасы» дип исемләнгән өченче бүлегенә авторның сәяси чыгышлары һәм республика тормышына кагылышлы кайбер рәсми документлар туплап бирелгән.

Биредә 1990 елның 30 августында депутат Рүзәл Юсуповның Югары Совет сессиясендә ясаган чыгышы, суверенлык декларациясе тексты, Татарстан Конституциясе, Республика көне, Татарстан Республика партиясе эшчәнлегенә багышланган һәм башка материаллар урын алган.

Р.Юсупов тарафыннан төзелгән «Теория и практика перевода» программасын СССР Мәгариф министрлыгы илебезнең барлык педагогика уку йортларында кулланма буларак файдаланырга тәкъдим итте, һәм бу программа Мәскәү һәм Ленинградтагы үзәк нәшриятларда басылып чыкты.

Сөйләм культурасы, тәрҗемә теориясе һәм чагыштырма тел гыйлеме өлкәсендә эшләүче белгеч буларак, Р.Юсупов һәрвакытта да татар теленең әдәби нормаларын саклау һәм үстерү позицияләрен яклап килә, аның сафлыгы һәм культурасы традицияләре сагында тора. Бу мәсьәләләргә багышланган хезмәтләрнең зур теоретик һәм практик әһәмияте бар.

«Татар-рус телләренең бәйләнеше: теориясе һәм практикасы» дигән фәнни хезмәте өчен, академик Р.А.Юсуповка 1988 елны фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе бирелде.

Аспирантура, докторантура һәм «Тарихи, типологик һәм чагыштырма тел гыйлеме» дигән тема буенча докторлык диссертацияләре советы, татар теле кафедрасы җитәкчесе, күп еллар Россиядәге иң зур педагогик вузлардан берсенең ректоры буларак, Р.Юсуповка тел гыйлемен оештыруда, фәнни-педагогик кадрлар әзерләүдә һәм үстерүдә актив катнашырга туры килә.

Аның җитәкчелегендә 30 кандидатлык һәм 5 докторлык диссертациясе әзерләнде һәм якланды. Хәзерге вакытта Рүзәл Юсуповның укучылары Татарстанның һәм Россиянең гыйльми учреждениеләрендә һәм югары уку йортларында уңышлы хезмәт итәләр.

Р.А.Юсуповка республика, Россия һәм халыкара фәнни конференцияләрдә катнашып чыгышлар ясарга туры килде.

Фәнни багланышлар урнаштыру, гыйльми-педагогик эш буенча тәҗрибә алмашу максатында, ул Америкада, Англия, Германия, Франция, Австралия, Кытай, Төркия, Кипрда һәм башка илләрдә командировкаларда булды.

Рүзәл Юсупов яшь галимнәргә, диссертация яклаучыларга фәнни һәм материаль ярдәм күрсәтүне, аларның Россиядәге халыкара фәнни конференцияләрдә, симпозиумнарда, гыйльми семинарларда катнашуларына, чит илләргә командировкага баруларына ярдәм итүне үзенең бурычы итеп санады.






*Халыкара тюркология конференциясендә*

*Татарстан Фәннәр академиясе членнары*
*(беренче рәттә уңнан беренче — академик Р.А.Юсупов)*





*Татарстан Фәннәр академиясенең гуманитар бүлеге членнары*



*Татарстан Фәннәр академиясе аппараты хезмәткәрләре (беренче рәттә сулдан бишенче — Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Р.А.Юсупов)*



*Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Хәрби академия президенты, армия генералы М.А.Гәрәев белән*

# ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЭШЛӘР



*Татарстан президенты М.Ш.Шәймиев җитимагый хәрәкәт лидерлары белән очраша (сулдан икенче — Татарстанның Республика партиясе председателе Р.А.Юсупов*





*Рүзәл Юсупов — Казан шәһәр советы депутаты*

*Казан шәһәр советының мәгариф комиссиясе председателе Р.А.Юсупов комиссия члены генерал Фомин белән*

## ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЭШЛӘР

*«Миңа, язмыш кушуы буенча, үземнең көчемне һәм сәләтемне шактый актив рәвештә өч төп өлкәдә гамәлгә ашырырга туры килде,* — дип яза Рүзәл Юсупов. — *Бу, беренчедән, җитәкчелек белән үрелеп барган укытучылык шөгыле, икенчедән, шулай ук укыту-тәрбиягә якын торган фән өлкәсе һәм, өченчедән, иҗтимагый-сәяси эшләр. Мин узган тормыш юлыма анализ ясаганда, үземнең күп гамәлләремне, кичерешләремне зиһенемдә яңартканда, энергиямне, белемемне һәм тәҗрибәмне бу өлкәләрнең кайсысында күбрәк кулланганлыгымны, минем өчен аларның кайсысы аеруча әһәмиятле, нәтиҗәле икәнлеген билгеләү җиңел булмый».*

Уйлансаң, чыннан да шактый кызык хәл килеп чыга. Укытучылык һәм җитәкчелек эшен башкарган өчен хезмәт хакы түләнә. Гыйльми эш шулай ук югары мәктәп укытучысының вазифасына керә. Ә менә иҗтимагый, җәмәгать эше — башкачарак нәрсә. Ул — энтузиастлар, фидакарьләр шөгыльләнә торган гамәл. Мондый хезмәт күңел кушуы, җан таләбе буенча, хезмәт хакы алмыйча башкарыла.

Рүзәл Юсупов җәмәгатьчелек эшеннән яшьтән үк һәм гомере буе бәхетем булды дип саный. Ул үз гомерендә күп энергиясен һәм көчен, намусы кушканча, нәкъ менә шундый эшкә багышлый. Армиядә хезмәт иткәндә үк иҗтимагый тормышта актив катнаша: үзе хезмәт иткән заставаның комсоргы, стена газетасы редакторы була. Күрәсең, иҗтимагый активлыгын исәпкә алыптыр, Рүзәлне армиядә үк КПСС сафларына кабул итәләр.

Казан дәүләт университетында укый башлагач та ул иҗтимагый тормышның казанында кайный. Инде шактый мөстәкыйль тормыш юлы узган, сынаулар кичкән егетне беренче курста ук тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретаре урынбасары итеп сайлыйлар. Ә икенче курстан инде Рүзәл комсомолның факультет бюросы секретаре вазифасын башкарырга керешә.

Ул чорда В.И.Ульянов-Ленин исемен йөрткән Казан дәүләт университетында комсомол аеруча зур көчкә ия иде. ВЛКСМ әгъзалары республика иҗтимагый тормышының алгы сафында бардылар, күп кенә файдалы эшләр башкардылар. Истәлекле даталарны билгеләп үтү, төрле сәяси кампанияләрдә, Ленин өмәләрендә катнашу, балалар йортларына шефлык ярдәме күрсәтү, урып-җыю эшләрендә катнашу, Органик синтез берләшмәсе корпусларын торгызуда ярдәм итү һәм күп кенә башка гамәлләр кылу алар өлешенә туры килде.

*«Безнең группа бигрәк тә актив булды. Шундый егет-кызлар җыелган иде: барысы да сайлап алган кебек бик тә тырыш, инициативалы. Җәй һәм көз көннәрендә күп тапкырлар республика колхоз-совхозларына барып, авыл халкына ярдәм итүебез турында аеруча матур истәлекләр саклана. Без анда җиң сызганып эшләп кенә калмый идек, кичләрен клубта халыкка бушлай концертлар куйдык,*

*концерт алдыннан халыкара хәл турында лекцияләр укыдык. Бу эш миңа йөкләнә иде. Группа старостасы Ленар Җамалетдинов — концертны алып баручы, интермедияләр остасы. Лениза Галиева җырлый, бии. Равил Фәйзуллин, Фарсель Зыятдинов, Шамил Маннапов үзләре язган шигырьләрен укыйлар. Һәркем үз һөнәрен күрсәтә. Мин дә читтә калмадым. Гармун уйнау һәм бию минем вазифага керде. Кыскасы, безнең группа сәләтле, ялкынлы йөрәкле егетләр һәм кызлардан тора иде»,* — дип яза Р.Юсупов.

Студент елларында комсомол эшләрендә актив катнашуы, һәр чараны намус белән, җиң сызганып башкаруы, соңыннан аның Казан дәүләт педагогика институтында (университетында) мөһим эшләр башкаруы өчен әзерлек чоры, нигез булып торды, дияргә мөмкин. Монда да иҗтимагый эшләргә күмелә ул. Эшли башлавының беренче елларында ук аны партия бюросы әгъзасы итеп сайлыйлар. Аннары дүрт ел дәвамында (хәтта докторлык диссертациясе яклаган елны да) тарих-филология факультетының партия оешмасын җитәкләргә туры килә. Бу чорда ул чын мәгънәсендә үзенең оештыру сәләтен чарлый. Бераз соңрак, меңнәрчә кешелек зур коллективны җитәкләгәндә, теге яки бу чараны ничек үткәрергә, дип баш ватарга туры килми инде. Һәр гамәлне башкару өчен җәмәгатьчелек эшләрендә алган тәҗрибәсе ярдәм итә. Күп профильле зур факультетның партия оешмасы секретаре булу, җәмәгать эше саналса да, күләме, мәшәкатьләре белән түләүле, штаттагы эштән һич кенә дә калышмый. Ул көчне, энергияне фәнни эшкә сарыф ителгәннән дә күбрәк ала. Чөнки коллективтагы бөтен тәрбия, иҗтимагый-сәяси эш партия оешмасына, беренче чиратта аның секретарена йөкләнә.

Иҗтимагый-сәяси эшләрен башкарып өлгерү өчен, Р.Юсуповка, бер көнне дә калдырмыйча, иртәдән кичкә чаклы факультетта булырга туры килә. Һәр көнне аның килүен тавык та чүпләп бетерә алмаслык дистәләрчә эш көтеп тора. Өлгер генә! Шуның өсенә, студентларга дәресләр бирергә, фән белән шөгыльләнергә дә вакыт табарга кирәк бит әле. Гадәттә төшке ашны да сәгать өч-дүртләрдә генә ашарга туры килә Рүзәлгә. Чөнки укытучылар факультетта чакта, күрәсе кешеләрне күреп, мәсьәләләрне хәл итеп калырга кирәк бит.

Ректор булып эшли башлагач, Р.Юсуповны Казан шәһәр советы депутаты итеп сайлыйлар. Монда да ул җаваплы вазифа башкара: мәгариф комиссиясе рәисе була. Шәһәр зур, мәктәпләр, балалар бакчалары, урта һәм югары һөнәри белем уку йортлары күп, аларның эше белән танышып торырга, депутат вазифалары кушканча, эшнең торышы өчен җавап та бирергә туры килә. Ике ел дәвамында (бер чакырылыш чоры) Р.Юсупов, гадәтенчә, депутатлык һәм комиссия рәисе вазифаларын җиренә җиткереп башкарып килә. Комиссия рәисе урынбасары, талантлы педагог Л.П.Кочневаны бүген дә зур хөрмәт белән искә ала ул. Алар бик тату һәм ярдәмлә-

шеп эшлиләр. Соңрак Любовь Петровна район мәгариф бүлеге мөдире итеп билгеләнә, аннары Казан шәһәрендәге бик алдынгы җиденче гимназиянең директоры була, кандидатлык диссертациясе яклый. Бүген аның мәгариф тармагындагы яңа эш алымнары бөтен Россиягә мәгълүм.

*«Без, мәгариф комиссиясе әгъзалары, Казан шәһәренең мәктәпләре, балалар бакчалары һәм башка төрле мәгърифәт учакларының эшен яхшырту буенча шактый күп игелекле эшләр башкардык»,* — ди Рүзәл. Казан шәһәр советында тупланган тәҗрибә киләчәктә аңа Татарстан Югары Советы депутаты вазифаларын башкарганда ярдәм итә.

## СУВЕРЕНЛЫККА ИРЕШҮ — ИЗГЕ ГАМӘЛ

Узган гасырның 80 нче еллары азагы Советлар Союзы халыкларының уянуы, милли үзаңы үсү чоры булды. Илдә тормышның социаль шартларын нигездән яхшырту, республикаларның сәяси статусын үзгәртү, демократияне үстерү өчен, халык хәрәкәте куәтле дулкын булып күтәрелде. Татарстанда ул союздаш республика статусына ирешү таләбендә чагылыш тапты. Хокук ягыннан союздаш республикалар белән тигезләшү бурычы куелды. Татарстан союз килешүенә шул рәвешле кул куярга җыенды, әмма вакыйгаларның алга таба бик тиз үсеш алуы союздаш республикаларның да статусларыннан канәгать булмауларын күрсәтте. Нәтиҗәдә республикаларның суверенлык идеясе хөкем сөрә башлады.

«Суверенлык» төшенчәсе — читтән тыкшынуга юл куймыйча, дәүләтнең эчке эшләрендә һәм тышкы мөнәсәбәтләрендә бәйсезлеге һәм мөстәкыйльлеге, дип аңлатыла.

СССР төбәкләрендә күп кенә социаль-икътисади проблемалар хәл ителмәде, милләтара проблемалар да кискенләшә төште. Халыкларның үзбилгеләнүгә һәм үзидарәгә, тормышның социаль шартларын яхшыртуга, милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау, үстерүгә булган законлы омтылышларын чагылдырып, республика җәмәгатьчелеге күп тапкырлар Татарстанның статусын үзгәртү таләбен куйды, чөнки ул аның алга таба социаль-сәяси һәм икътисади үсеше таләпләренә җавап бирмәде. Халыкның зур күпчелеге хезмәт коллективлары җыелышларында, демонстрацияләрдә һәм митингларда, барлык дәрәҗәдәге вәкаләтле хакимият органнарына сайлау кампанияләре вакытында, массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстанның статусын үзгәртүне таләп итте. Бу таләпне гамәлгә ашыру өчен, бөтен халык тарафыннан демократик юл белән сайланган парламент кирәк иде.

*«Татарстанның 1990—1995 еллардагы Югары Советы республикабыз тормышында чын цивилизацияле илләрдәге кебек сайланган һәм демократик принцип-*

*лар белән эш иткән бердәнбер парламент булды. Шатланып һәм горурланып әйтә алам: мин депутатлыкка җиде кандидат арасыннан альтернатив нигездә сайландым, һәм без гомумән алганда демократик шартларда эшләдек. Истәлекле 1990—1995 еллардагы Югары Совет Татарстанда һәм бөтен Россиядә мөһим мәсьәләләрнең демократик юл белән хәл ителүенең матур үрнәген тәшкил итә»,* — дип яза Рүзәл Юсупов.

1990 елның 12 июнендә Россия Федерациясенең Югары Советы Россиянең дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итә. Бу акт төбәкләрне дә шушы юлга этәрә. Россия Декларациясендә үзе өчен гаять зур хокуклар һәм вәкаләтләр күздә тотылып, аның составындагы республикаларга аларның сәяси статусын күтәрү хакында бернинди сүз булмый. Шунлыктан республикалар үзләренең хокуклары һәм иреге өчен көрәш башлап җибәрәләр. Бу көрәшнең алгы сафына Татарстан чыга. Тарихның көн тәртибенә Татарстан Республикасында дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итү мәсьәләсе куела.

Югары Совет президиумы Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең проекты буенча карар кабул итә, һәм бу проектны әзерләү буенча эш төркеме оештырыла. Әлеге төркем составына парламентның милли мәсьәләләр һәм мәдәният комиссиясе рәисе буларак Р.Юсупов та кертелә. Рүзәл Абдуллаҗанович җитәкчелегендәге комиссия әгъзаларына, барлык тәҗрибәләрен һәм белемнәрен кулланып, нык тырышырга туры килә.

Тарих битләрен актарып утырганда, ирекле, мөстәкыйль һәм хөр яшәеш кешелек дөньясында борынгы заманнардан бирле иң югары кыйммәтләрдән саналып килүен тоясың. Бик күпләр шундый тормыш турында хыялланып яшәгән, һәрдаим шуңа омтылган. Аңа ирешү өчен күпме кан-яшь түгелгән, хәтта иң асыл затларга гомерләрен бирергә туры килгән. Әмма шунысы гаҗәп: бу кыйммәтнең әле һаман да дөньякүләм дәрәҗәдә тантана итә алганы юк.

Кеше дөньяга тыныч, мул тормышта, хөр яшәү өчен килә. Бу — аның Ходай тарафыннан бирелгән хокукы. Ләкин бүген без хокук көче түгел, ә көчленең хокукы өстенлек иткән заманда яшибез. Шунлыктан хәзер бары тик ныклы әзерлеге булган, көчле һәм горур халыклар гына мөстәкыйльлеккә ирешә. Ә әзерлеге аз булганнар һәм юашлар, үзләренә бәхет елмайган очракта да, аны саклап кала алмыйлар.

Татар халкы 1552 елда югалткан дәүләт төзелешен торгызу өчен күп көч куйды. Моның өчен халкыбызга сикәлтәле бик озын юл үтәргә туры килде. Билгеле булганча, Татарстан АССР 1920 елда төзелде. Беренче карашка, чоры өчен бу алга таба үсешкә ныклы адым булып күренсә дә, төптәнрәк уйлаганда, ул милләтнең, шушы төбәктә яшәүче халыкның хокукларын чикләүгә, үсешенә билгеле дәрәҗәдә комачаулык тудыруга китерде. Чөнки Совет хөкүмәте җитәкчелеге республикалар-

ны сортларга аерды. Республика халкының канәгатьсезлеге өчен нигез салынды. Инфраструктура үстерелмәде, юллар юк, республика үзе газны күпләп чыгарса да, фәкать шәһәрләр генә газ белән тәэмин ителде. Торак нык тузды, яңасы бөтенләй төзелмәде диярлек. Кибет киштәләре буш иде. Чөнки республикада җитештерелгән азык-төлек күпләп Мәскәүгә озатылып барды. Шунлыктан туклану продуктларын Мәскәүдән ташырга туры килде.

СССРның 1936 елгы Конституциясе кабул ителер алдыннан, Татарстан хөкүмәте республиканың хокукларын арттыру, аларны союздаш республикаларныкы белән тигезләүне сорап, Үзәк Комитетка мөрәҗәгать итә. Әмма уңай нәтиҗәгә ирешелми. Сталин үзенең СССР Конституциясе турындагы йомгаклау чыгышында союздаш республика статусын таләп иткән Татарстан һәм Башкортстанга карата: «Им союзности не видать как своих ушей», — дип җавап бирә. Стенограммада «залда көлешәләр» дип язылган.

1977 елда кабул ителгән Брежнев Конституциясе дә республикаларның статусын үзгәрешсез калдыра. Ә гамәлдә хәтта союздаш республикаларның хокуклары да кысылганнан-кысыла бара. Ә бит Мирсәет Солтангалиев 1924 елда ук республикаларны гади административ берәмлекләр белән тигезләү сәясәте СССРның таркалуына китерәчәген фаразлап язып чыга. Әмма моңа колак салучы булмый. Республикаларның хокуклары кысылганнан-кысыла бара. Һәм нәтиҗәдә күренекле шәхесебезнең фаразлары дөрес булып чыкты.

1990 елның 27 августында Татарстан АССРның уникенче чакырылыш Югары Советының икенче сессиясе ачылды. Аның көн тәртибенә тарихи мәсьәлә — дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация проектын тикшерү кертелгән иде. Язмышыбызны хәл итә торган бик җаваплы сессия булды ул. Моны республика җитәкчеләре дә, депутатлар да, барлык татарстанлылар да яхшы аңлады. Сессиядә берничә көн дәвамында кискен фикер алышулар, көчле бәхәсләр барды. Билгеле, беренче чиратта моңа депутатлар составының чуар булуы сәбәпче иде. Депутатларның бер өлеше Татарстанның тулы бәйсезлеген кичекмәстән игълан итү ягында булса, икенчеләре исә Декларация кабул итүне бөтенләй теләмәде, максатларына ирешү өчен төрле киртәләр корырга тырышты, ярым-йорты карар кабул итәргә омтылды. Депутатларның бер өлеше, төрле сәбәпләр табып, Декларация кабул итү мәсьәләсен кичектереп торырга тәкъдим итте. Урып-җыю эшләренең авылда иң кызган чоры, ә без монда, җыелышып, көннәр буе сүз куертып утырабыз, диючеләр дә булды.

Ул көннәрдә Казанда гына түгел, республика районнарында, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә хәл нык кискенләште. Югары Советка «Суверенлык турындагы Декларацияне һичшиксез кабул итәргә!» дигән телеграммалар яуды. Ирек мәй-

данында халык диңгезе чайкалды. Мөстәкыйльлек таләп итүчеләр, кырыклап автобуска төялеп, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Азнакай, Алабуга шәһәрләреннән һәм башка төбәкләрдән килделәр.

Депутат В.Курылев мәйданнан халык таралганчы сессия эшен туктатып торырга тәкъдим кертте. Янәсе, Ирек мәйданында митинг үткәрүче халык, шаулашып, депутатлар эшенә комачаулык тудыра. Тагын берничә депутат та аның фикерен куәтләде. Сессия залында хәл шактый кискенләште. Шулвакыт депутат Рүзәл Юсупов сүз алды:

— Минемчә, митинг безнең эшкә комачаулык ясамый. Андагы халык бөтен җәмәгатьчелекне, республиканың барлык халкын борчыган төп мәсьәлә буенча үзенең теләктәшлеген күрсәтә, бердәмлеген белдерә, — диде ул.

Аннары Р.Юсупов Югары Совет исеменә килгән 600дән артык телеграмманың эчтәлеге белән депутатларны таныштыруны таләп итә. Телеграммаларда «Суверенлык мәсьәләсен уңай хәл итәргә!» дигән таләпләр язылганын белә ул. Рүзәлнең бу таләбен А.Васильев һәм тагын берничә депутат яклап чыга. Шуннан соң Югары Совет рәисе Минтимер Шәймиев секретариатка телеграммаларның эчтәлеген игълан итәргә күрсәтмә бирә. Тиздән аның әмере үтәлә дә.

Декларациянең берничә варианты бар иде. Аларны, берләштереп, сессия каравына чыгару бурычы куелды. Декларацияне әзерләгәндә, мөстәкыйль дәүләт оештыру, Россия белән аерым бер төрле мөнәсәбәтләрдә булу, яңа барлыкка килергә тиешле Союз договорына мөстәкыйль кул кую бурычы торды. Бу Татарстанның махсус позициясе иде.

Сессиядә мәсьәләне карау М.Шәймиев чыгышы белән башланды. Менә ул чыгыштан кайбер өзекләр:

«Югары Советның бу сессиясендә карала торган Татарстан Республикасының дәүләт суверенлыгын игълан итү мәсьәләсе безнең барлык күпмилләтле халкыбыз өчен бик тә зур әһәмияткә ия. Әлеге мәсьәләнең хәл ителүенә Татарстанның бүгенге көне генә түгел, иртәгәсе көне дә, аның гражданнарының — татар һәм русның да, чуваш һәм украин, мари һәм мордва, белорус һәм еврейның да — республикабызда яшәүче барлык милләт вәкилләренең дә язмышы нык бәйләнгән. Үзгәртеп коруда туган яңарыш процессы милли үзаң тергезелүнең, милли хәрәкәтләрнең зур үсеш алуының куәтле факторына әверелде.

Татарстан АССР бүген икътисади, рухи потенциалы, хуҗалыгы комплексына керткән өлеше буенча кайбер союздаш республикалардан калышмый. Татарстанда СССРда җитештерелә торган бутил каучугының дүрттән өче, кино-фотоматериалларның яртысы, полиэтиленның чиреге, автомобиль шиннарының 15 проценты эшләп чыгарыла. Илдәге халык хуҗалыгы йөкләренең зур өлешен КамАЗлар

ташый. Республика куәтле авыл хуҗалыгы потенциалына ия, илне шактый күп нефть һәм катлаулы машина төзелеше продукциясе белән тәэмин итә. Татарстан АССРның 1989 елда ирешкән милли табышы (кереме) 9,3 миллиард сумнан артыграк».

«Республикаларны союздаш һәм автономиялеләргә бүлеп йөртү автономияле республикалардагы иҗади союзларның социаль базасы үсешенә тискәре йогынты ясый. Республикабыз халкы, реаль мөмкинлекләргә нигезләнеп, хаклы рәвештә Татарстанның дәүләт статусында шундый үзгәрешләр булуын, аның суверен дәүләтләрнең яңартылган союзында шундый урын бирелүен таләп итә: ул җайга салына торган базар икътисадында, бер яктан, яхшы яшәргә һәм республиканың матди һәм рухи мөмкинлекләрен үстерергә, икенче яктан, бу союзны, аның социаль һәм икътисади нигезен ныгытырга мөмкинлек бирер иде. Мәгълүмат чараларында, иҗтимагый-сәяси оешмаларда, шәһәр һәм район сессияләрендә, күп кенә предприятие һәм оешмаларның коллективларында тикшерү, фикер алышу барышында республика статусы мәсьәләсендә депутатларда һәм халыкта ике төрле караш барлыкка килде. Беренчесе — «республикабыз без күреп, белеп гадәтләнгән союздаш республикалар кебек булсын» дигән караш. Икенче караш тарафдарлары Татарстанны Россия Федерациясе составында һичшиксез суверен республика итеп күрергә телиләр. Бу ике төрле карашны халыкның күпчелегендә яклау тапкан суверенлык идеясе берләштерә».

«Декларация проектының төп идеяләре — Татарстанның дәүләт суверенлыгын игълан итү һәм аны, күпмилләтле халык ихтыярынча, Татарстан Совет Социалистик Республикасына әверелдерү, Татарстан Республикасының суверенлыгы — килешү нигезендә ирекле рәвештә Россия Федерациясенә һәм ССР Союзына биргән хокукларыннан тыш, эчке һәм тышкы тормыш мәсьәләләрен хәл итүдә дәүләт хакимиятенең өстенлеге, мөстәкыйльлеге. Декларация Татарстан ССРның Конституциясен төзүдә, республика законнарын үстерүдә, Союз һәм РСФСР белән федератив килешүләрне әзерләүдә катнашу өчен нигез хезмәтен үти».

М.Шәймиев чыгышыннан соң сүз Рүзәл Юсуповка бирелә:

*— Татарстан Республикасының дәүләт суверенлыгын игълан итү ул — объектив зарурлык, хокукый дәүләт төзү, татар халкын милләт буларак тергезү һәм үстерү юлында иң мөһим этап. Безнең республикада гына түгел, бәлки аннан читтә яшәүче миллионлаган татарлар да бүген үзләренең лаеклы халык икәнлекләрен раслауга, чын бәйсезлек алуга, чын тигезлеккә һәм прогресска ирешүгә булган хыялларын тарихи әһәмияткә ия шушы документны кабул итү белән бәйли. Хәзер акыллы һәм намуслы кешеләрнең берсе генә дә әлегә кадәр хөкем сөргән унитар,*

*тоталитар һәм иерархик дәүләт системасының татарларның чын тигез хокуклыгын, мәдәниятләрен һәм телләрен үстерү өчен барлык кирәкле шартларны булдыра алмавын күрми кала алмый,* — ди ул.

Депутат республиканың бүгенге тормыш хәленә кагылышлы кайбер мисаллар китерә. Татарстанның башкаласында, башка шәһәрләрендә, район үзәкләрендә татар мәктәпләре калмаган, республиканың үз фәннәр академиясе, нәфис фильмнар студиясе юк. Дәреслекләр, методик әдәбият, уку-укыту әсбаплары җитми, татар телендә газета-журналлар аз чыга. Төп халыкның туган теленең кулланыш өлкәсе елдан-ел тарая бара.

Р.Юсупов карашынча, суверенлык игълан итү республикада социаль, икътисади тормышны яхшырту өчен зур мәйдан ачачак. Республика җирләрен, табигый ресурсларын, бөтен техник-икътисади мөмкинлеген, территориясендәге предприятие, учреждение, оешмаларын үз милке дип игълан итеп, халык үз икътисадын үзе кору, җитештерүдән табыш алу һәм үз байлыкларыннан теләгәнчә файдалану мөмкинлеген алачак.

Шуны да искә төшерергә кирәк: Татарстан предприятиеләренең 98 проценты Союз һәм Федерация карамагында иде. Алар үз табышларыннан җирле бюджетка бик аз өлеш чыгарды. Ә Татарстан икеләтә салым түли. Менә шуңа күрә республиканың йөзләрчә мең кешеләре әлегә кадәр иске, ярым җимерек йортларда яши, мәктәпләр, балалар бакчалары, яслеләр җитми.

Халыкара хокук документларында язылганча, һәр милләтнең үзбилгеләнүгә, дәүләт суверенлыгына ия булуга хокукы бар. Димәк, татар халкының бәйсезлек алу, тигез хокуклы булу теләгенә ниндидер комачаулык ясау һәм каршылык күрсәтү халыкара хокукны бозу, илдә хокукый дәүләт төзүне тоткарлау һәм татар халкына карата гаделсезлек кылу дип каралачак.

Рүзәл Юсупов чыгышын шундый сүзләр белән тәмамлады: *«Мин, беренче чиратта республикабыздагы төрле милләт вәкилләре арасында яхшы күршелек, дуслык мөнәсәбәтләрен булдыру һәм ныгыту өчен җаваплы депутат буларак, ТАССР парламентындагы коллегаларыма шундый өндәмә белән мөрәҗәгать итүне бурычым дип саныйм: Декларация язмышын хәл иткәндә мәсьәләнең бөтен якларын да исәпкә алып, җитди уйлап, күп миллионлы татар халкының язмышы өчен зур җаваплылык хисе тоеп, тавышыбызны Татарстан халкының чын суверенлыгы өчен бирик».*

Депутатлар Рүзәл Юсупов чыгышын хуплап кул чаптылар. Фикер алышуда күп депутатлар катнашырга теләк белдерде. Мәсьәлә үтә әһәмиятле булганлыктан, теләгән кешеләрнең барысына да сүз бирергә килешенде. Трибунага бер-бер артлы М.Мөлеков, Д.Сиражиев, В.Косулин, Р.Хафизов һәм башка депутатлар күтәрелде.

Татарстан иҗтимагый үзәге рәисе, татар халкының ирекле яшәве өчен ялкынлы көрәшче Марат Мөлековның чыгышы зур кызыксыну белән тыңланды.

— Без һәр көнне республикабызның суверенлыгын яклап язылган күп телеграммалар, хатлар алабыз. Без Татарстанны суверен дәүләт һәм халыкара хокук субъекты дип игълан итәргә тәкъдим итәбез. Бу — безнең Декларация проектының төп моменты. Төрле имеш-мимешләр таратучылар бар. Янәсе, татар иҗтимагый үзәге республикабызда яшәүче русларны безнең республикадан күчерергә тели икән, дип сөйлиләр. Бу — ялган һәм яла, иптәшләр. Татар иҗтимагый үзәгенең бер генә документында да тапмассыз сез моны. Һичшиксез, яңа суверен Татарстан дәүләте Россия Федерациясе белән иң тыгыз бәйләнештә, дустанә мөнәсәбәттә булачак.

Марат Мөлековның, гражданлык килешүенә ирешеп, «30 нчы августны суверен Татарстан көне булырлык итеп тавыш бирик!» дигән өндәмәсе бик урынлы һәм вакытлы булды.

Фәүзия ханым Бәйрәмова гадәттәгечә бик хисле итеп, тәэсирле чыгыш ясады: «Бу җирләр, телебез, динебез безгә — татарларга — күп мең еллар элек Аллаһ тарафыннан бирелгән. Без аларны беркемнән дә яулап алмадык һәм яулап алырга җыенмыйбыз да. Без бары тик үзебезнең хокукларыбыз, милләтебезне саклап калу өчен көрәшәбез!» — диде ул.

Республика өчен суверенлыкның мөһимлеге хакында Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе генераль директоры депутат Г.Сәхапов конкрет фактлар китереп, ышандырырлык итеп сөйләде. Ул республикабызның икътисади хокуксызлыгын күрсәтә торган гыйбрәтле саннар китерде. Аның сүзләренә караганда, республикада җитештерелгән сәнәгать продукциясенең 80 проценты Союз, 18 проценты Россия карамагындагы предприятиеләргә туры килә, калганы гына республикабызга карый. Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе елына 1 миллиард 300 миллион сумлык продукция чыгара. Предприятиенең еллык табышы 340 миллион сумлык. Продукциянең 220 миллионлыгы Химия промышленносте министрлыгына һәм бары биш проценты гына Татарстан Республикасының юл төзелешенә бирелә. Түбән Кама шәһәр советына бары ике миллион эләгә. Г.Сәхапов әйтүенчә, экспортка сату югарыдан төшерелгән лицензия буенча башкарыла, һәм керемнең бөтенесе диярлек Мәскәүдә кала.

«Бер нәрсә бик ачык мәгълүм: моннан ары болай яшәү мөмкин түгел, һәм безгә артка чигенергә дә юл юк. Бүген Татарстан Республикасының, аның халыкларының язмышы хәл ителә. Тарих һәм үзгәртеп кору безгә искиткеч яхшы мөмкинлек бирде. Әгәр аны кулдан ычкындырсак, безне гафу итмәсләр», — диде ул.

Суверенлык мәсьәләләре буенча фикер алышу барышында Татарстан хөкүмә-

тенең икътисади программасы турында махсус доклад та тыңланды. Аны Министрлар Советы рәисе урынбасары Ф. Хәмидуллин ясады. «Татарстан Республикасы җан башына сәнәгать продукциясенең күләме буенча автономияле республикалар арасында беренче урында тора һәм Россиянең уртача күрсәткечләреннән күпкә югарырак саннарга ия. Республикабызда җан башына авыл хуҗалыгы продукциясенең күрсәткечләре дә Россия буенча уртача күрсәткечтән югарырак. Шул ук вакытта, — диде Ф.Хәмидуллин, — Татарстан Россиянең башка төбәкләреннән социаль өлкәдә шактый арттарак бара. Мәсәлән, хастаханәдә урыннар белән тәэмин итү буенча ул бары тик 61 нче урында, торак белән тәэмин ителү буенча 37 нче урында. Суверенлык шартларында хөкүмәт сәясәтенең асылы күпмилләтле халыкның республиканың сәяси мөмкинлегеннән тулысынча файдалануыннан гыйбарәт булачак».

Суверенлык идеясен, бигрәк тә аның икътисадка караган өлешен яклап, СССР Югары Советы депутаты Ю.Красильников чыгыш ясады. Депутатларга аның бигрәк тә: «Татарстан бүген сәнәгать потенциалы милкенең ничә процентына ия? Бер ярым процентына! Бер генә колониянең дә беркайчан да үзенең милкендә шулкадәр кечкенә капиталы булмаган... Мин Татарстанга, аны халыкара хокук субъекты итеп танып, тулы суверенлык бирү ягында», — дигән сүзләре нык тәэсир итте.

Фикер алышу тәмамланганнан соң, сессия утырышын алып баручы Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, Декларация текстын ахырынача әзерләп бетерү өчен килештерү комиссиясе төзелде. Аның составына депутат Рүзәл Юсупов та кертелде.

Комиссия озак эшләде. Кайбер пунктлар буенча төрле фикерләр булды. Шулай да уңышлы эшләү һәм үзара килешүгә ирешә алу нәтиҗәсендә комиссия, бердәм фикергә килеп, сессиягә Декларациянең соңгы текстын тәкъдим итә алды.

Ниһаять, тарихи мизгел килеп җитте. Декларация тексты тавышка куелды. Сессия утырышында катнашкан 242 депутатның 241е проектны яклап тавыш бирде. Бары бер генә депутат битараф иде. Журналист халкы кызыксынучан бит. Алар «битараф»ның кем булуы белән кызыксындылар. Ул Казан шәһәрендәге бер зур предприятиенең партком секретаре иде. Журналистлар күпме генә төпченсәләр дә, бу депутат битараф калуының сәбәпләрен аңлата алмады.

Парламент депутатларының һәм республика халкы язмышына битараф булмаган бик күп башка кешеләрнең киеренке көрәше нәтиҗәсендә туган бу мөһим документ шундый сүзләр белән башлана:

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Югары Советы,

— республиканың күпмилләтле халкы язмышы өчен тарихи җаваплылыкны аңлап;

— Россия Федерациясендә һәм Совет Социалистик Республикалар Союзында яшәүче барлык халыкларның суверен хокукларына ихтирам белдереп;

— автономияле республика статусы аның күпмилләтле халкының киләчәктә сәяси, икътисади, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килмәвен күрсәтеп үтеп;

— татар милләтенең, республикада яшәүче бөтен халыкның үзбилгеләнүгә булган аерылгысыз хокукын тормышка ашырып;

— демократик хокукый дәүләт төзергә омтылып,

1. Татарстанның дәүләт суверенлыгын игълан итә һәм аны Татарстан Совет Социалистик Республикасы — Татарстан Республикасы итеп үзгәртә.

2. Татарстан ССР территориясендәге җир һәм җир асты байлыклары, табигать байлыклары һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора.

3. Татарстан ССР үз территориясендә яшәүче барлык гражданнарга, нинди милләттән булуларына, социаль чыгышлары, диннәре, сәяси карашлары нинди булуга һәм башка аерымлыкларга карамастан, кешенең тигез хокукларын һәм ирекләрен гарантияли. Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең дәүләт телләре сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә...»

Депутатлар парламент бинасыннан чыкканда, төн уртасы җитеп килә иде инде. Шулай да Ирек мәйданы халык белән тулы. Депутатларны тәбриклиләр, кулларын кысалар, рәхмәтләр әйтәләр. М.Шәймиев мәйданда күренүгә, бер төркем егетләр аны күккә чөяргә тәкъдим итә. Мәйдан гөрли. Кемнәрдер күмәкләшеп бии, икенчеләре җырлый. Күп меңнәрчә татарларның һәм республикада яшәүче башка милләт кешеләренең чиксез зур шатлыгы иде бу. Һәркемнең куанычын кем белән булса да уртаклашасы, бөтен мәйданны тутырып: «Хуш киләсең, ирекле Татарстан! Без моны бик озак көттек!» — дип кычкырасы килә.

Ниһаять, күп буын әби-бабаларыбызның гасырлар буена хыялланып килгән өметләренең аклануына юл ачылды. Планетаның бер почмагында хөкем сөргән халкыбызның гавәм күләмендә тигезлек, дуслык һәм һәркемгә бәхет, хөррият теләгән хыялының тормышка ашуы өчен мөмкинлекләр барлыкка килде.

Шулай да депутатлар арасында рус һәм татар телләренең икесен дә дәүләт теле дип кабул итүне хупламаучылар, хәтта аны хата дип бәяләүчеләр дә бар иде.

*«Татарстанның дәүләт теле, мәгълүм булганча, татар теле булырга тиеш иде. Кайсы гына дәүләтне алып карасак та, ул дәүләтнең исемен чагылдыручы халыкның теле дәүләт теле дип кабул ителә. Икетеллелеккә аның кимчелекләрен белә торып барырга туры килде безгә. Шунсыз Декларацияне кабул итеп булмый иде. Ә бүген исә республикабызда татар һәм рус телләренең дәүләт теле сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы гарантияләнә»,* — дип аңлатма бирде Рүзәл Юсупов.

— Тик менә рус теле дә дәүләт теле булганда телләрнең тигез кулланылышы гына икеле, — дип әңгәмәгә кушылды Марат Мөлеков. — Ни өчен дисәк, татар телендә сөйләшүче аз. Дәүләт аппаратында да, министрлыкларда да, учреждениеләрдә дә татарча сөйләшүче юк дәрәҗәдә. Анда эшләүче татарлар үз телләрен белми. Ике тел дә тигез хокуклы булгач, алар татар телен өйрәнмәячәк тә. Ләкин бүгеннән үк без бар системаны татар теленә күчерә алмыйбыз. Моның өчен вакыт кирәк. Әйтик ун ел, унбиш. Ә менә беренче сыйныфтан ук татар телен укытуны кертсәк, алга таба да шулай дәвам итсә, алар 10—15 елдан белгеч булып җитешәчәк. Ул чагында инде татар телен белүне таләп итәргә дә, икетеллелекне кабат карап, татар телен — дәүләт теле, ә рус телен аралашу теле дип игълан итәргә дә мөмкин булачак.

Ни дисәң дә, тирән катламнардан килгән чал тарихыбыз бар безнең. Татар дәүләте, озакка булса да, тик вакытлыча гына тынып торган булган. Менә бүген татар халкы үз дәүләтенә җан өрде, ул уянды, шәт терелер, аякка басар. Әнә шулай эзлебез без тарихта, абруйлы Идел-йортта. Ә бу йортта көрәш тукталмаган һәм тукталмас та.

Мин ул вакытта «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә эшли идем. Газетаның чыга гына башлаган чоры. Шәһәр хакимияте башлыгы Камил Исхаков тырышлыгы белән дөнья күргән, башкалабызның беренче милли газетасының төп юнәлеше шулай ук республикабызның суверенлыгын, татар халкының бәйсезлеген яклау иде. Сессия барган көннәрне телефоннар көне буе тынып тормады. Сораулар бер үк иде. «Ничек анда? Игълан иттеләрме инде?» Парламенттан бу сорауга җавап алынгач кына, газетаның иртән дөнья күрәчәк саны типографиягә тапшырылды.

Декларациядә Татарстанның СССР составында булуы күрсәтелмәде. Чөнки Татарстанның СССР яки Россия составына керүен раслаучы бер генә документ та юк. Академик Индус Таһиров та төрле чыгышларында бу хакта искәртергә ярата. Декларация кабул иткәндә килешү комиссиясендә республика суверенлыгын бик үк өнәп бетермәгән депутатлар группасы «Народовластие» Декларациядә Татарстанның Россия составында булуы күрсәтелмәүгә каршы чыккан иде. Алар бу хакта күп тапкырлар сүз кузгатып килделәр.

Татарстанның дәүләтле булуы өчен көрәштә XX гасырдагы өч чорны билгеләп үтү урынлы булыр. «Без бишенче елны уяндык таң белән», — дип язды Г.Тукай. Татар берничә ел эчендә матди һәм рухи яктан күтәрелә, байый. Шулай да бу озакка бармый, тагын сүрелү башлана. Икенче чор Татарстанга автономияле республика статусы бирү белән тәмамлана. Өченче дулкын, үткән гасырның 80нче еллары урталарында башланып, 2000 елларга кадәр дәвам итте. Әгәр ул чорда халык күтәрелмәгән булса, без, мөгаен, мондый Декларацияне кабул итә алмаган булыр идек.

Кызганыч, үткән гасыр ахырында Татарстан суверенлыгы өчен җиң сызганып, армый-талмый көрәшүчеләрнең кайберләре бүген безнең арада юк инде. Әмма аларның хезмәте халык хәтерендә. Марат Мөлеков, Дамир Сираҗиев, Мөдәррис Шәйхиев кебек асыл егетләребезнең игелекле эшләрен онытырга безнең хакыбыз юк.

Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә реакция салкынча булды. Үзәк телевидение дикторы, Декларация кабул ителү турындагы информацияне укыганда: «Һәр урамның да үзен суверен дип игълан итүе бар», — дип ычкындырды. Күрәсең, эчке тойгылары тышка бәреп чыкты. Алга таба үзәкнең баш калкыткан империячел тәкәбберлегенең төбәкләрдә — беренче чиратта донор милли республикаларда көч туплаган мөстәкыйльлек тойгысы бәрелешенең төрле формалары белән характерланган вакыйгаларда сәяси үзәкләштерү һәм иң катлаулы хәлләрдә дә килешергә омтылыш зур роль уйнады.



*Парламентның милли мәсьәләләр һәм мәдәният комиссиясе председателе Р.А.Юсупов комиссия členнары Җ.Ш.Шәйхиев (сулда) һәм Р.Ш.Хафизов белән*



*Депутат Рүзәл Юсупов парламент президиумы утырышында*



*Бер төркем парламент депутатлары язучылар белән*
*Туфан Миңнуллинның туган җирендә — Кама Тамагы районында*

## РЕФЕРЕНДУМ — ХАЛЫК ФИКЕРЕ

Декларация никадәр генә мөһим булмасын, ул закон да, норматив хокукый акт та түгел, бәлки бары тик теләкне, максатны чагылдыра торган документ кына. Аның төп нигезләмәләрен закон кысаларына салырга кирәк була. Аларны законнарга әйләндерә башлагач, кайберләре үзгәрә төште. Хәер, бу табигый хәл иде. Җитмәсә, федераль үзәк субъектларның шактый вәкаләтләрен үзенә алды, ә кайберләре уртак вәкаләтләргә әйләнде.

Республиканың дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация федераль үзәк тарафыннан аңлау тапмады. Шуңа күрә бу чорда Россия белән сөйләшүләрне дәвам иттерү безнең өчен стратегик яктан мөһим иде. Бу сөйләшүләрдә безнең суверенлык Россия ягыннан шулай бәяләнде: «…суверенлык — сезнең партноменклатураның табышы, шул рәвешле ул үзен саклап калырга тели, ә халык сезнең белән бер якта түгел. Үзегезнең позицияне референдумда раслагыз».

Референдумны без уйлап чыгармадык, ул Россия ягының таләбе иде. Республикадагы рус халкының һәм татарларның бер өлешенең суверенлыкка каршы чыгуына өметләнделәр. Мәскәү Татарстанны плакатлар, лозунглар белән тутырды, басым ясау өчен генераль прокуратура хезмәткәрләрен җибәрде.

Югары Совет 1992 елның февралендә күпмилләтле Татарстан халкының ихтыярын ачыклау өчен референдум уздыру хакында карар кабул итте. Республика үзенең әлеге гамәле белән баштан ук бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүнең цивилизацияле юлын сайлады. Референдумны әзерләү һәм үткәрү бик катлаулы иҗтимагый-сәяси шартларда барды. Татарстан халкының ирекле, демократик рәвештә ихтыярын белдерүгә хокукын саклау өчен чын көрәш башланып китте. Россия җитәкчелеге референдумда суверенлык өчен җавапның уңай булуыннан курка башлады. Шунлыктан Россия Президенты Борис Ельцинның мөрәҗәгате дә булды. Мәсьәлә Россиянең Конституция һәм Югары судларында, Югары Советында да каралды. Ләкин монда Россия хакимиятенең ни өчен һәм нинди нигездә республика гражданнарын үз фикерләрен әйтү хокукыннан мәхрүм итәргә маташуларын аңлавы кыен иде.

Шушындый гадәти булмаган шартларда республикада халыкка референдумның изге максатын аңлату буенча зур эшләр башкарылды, мәгълүмат чараларында күпсанлы чыгышлар ясалды. Югары Совет депутаты буларак, Р.Юсуповка да халыкны, алда торган референдумда актив катнашып, Татарстанның демократик, ирекле яшәве, аның суверенлыгы өчен тавыш бирергә өндәп, радио-телевидениедә, матбугатта күп тапкырлар чыгыш ясарга туры килде.

Рүзәл Юсупов университетта бер группада укыган теләктәшләре, галимнәр Ф.Зыятдинов, Ш.Асылгәрәев белән берлектә, берничә газетада мөрәҗәгать урнаштырды. Анда шундый юллар бар:

— Иң мөһиме — безгә референдумның уңай нәтиҗәләренә республикабыз халыклары арасындагы гасырлардан килә торган дуслыкны бозмыйча, милләтләр арасында кискен каршылык тудырмыйча ирешү. Татулык нигездә ирешелгән мөстәкыйльлек бар халыклар өчен дә кадерле һәм отышлы булачак. Референдум уңай хәл ителсә, татар халкы бүген урыс, чуваш, мари, удмурт, башкорт, яһүд халыкларына рәхмәтле булыр, моңа җавап йөзеннән киләчәктә бу милләтләрнең татар халкына хөрмәте артыр, чөнки игелек беркайчан да җирдә ятмый. Икенчедән, республикабыздагы барлык милләтләр дә мөстәкыйльлек шартларында мул, тулы тормышта яшәячәкләр. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Киләчәктә дус һәм тату яшәргә омтылган, барлык байлыктан бергәләп, акыллы файдаланырга, һәр милләтнең өлгергән проблемаларын уңышлы хәл итәргә теләгән һәм республикабызның башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен ирекле килешүләр нигезендә коруын кулай күргән һәркем, Татарстан Республикасы бәйсезлеген яклап, «әйе» дип тавыш бирер дип ышанасы килә.

Татарстан җитәкчелеге, референдумда катнашучыларның ким дигәндә 50 проценты суверенлыкны яклап тавыш бирер, дигән фикердә торды. Халык арасында булып, яхшылап аңлатканда, бәлки, 60 процент та җыеп булыр, дигән өмет тә бар иде.

Бу вакытта Россия Президентының милли сәясәт буенча киңәшчесе мәгълүм демократ Галина Старовойтова иде. Ул ханым Татарстан референдумына каршы чыкмады. Чөнки бу — демократиянең аякка басуына каршы килү булыр иде. Шул ук вакытта ул үзенең чыгышларында мондый фикерне әйтә башлады: әгәр дә референдум була икән, анда чыгарылган мәсьәләне референдумда катнашучыларның өчтән ике өлеше хупларга тиеш. Билгеле, ул чагында бу кадәр тавыш җыеп булмый иде. Ләкин һәр республиканың үз законнары бар бит. Татарстан үз законына таянып эш итте.

Референдумга чыгарылган сорау шундый иде: «Сез Татарстан Республикасының, суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты буларак, Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы шартнамәләр нигезендә коруына ризамы?» Мәскәүнең Татарстанга басымы шушы формулировкага да бәйле иде. Бигрәк тә андагы «халыкара хокук субъекты» дигән сүзләргә.

Референдум көне якынлашкан саен, басым да көчәя барды. Татарстан Югары Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга Россия парламентында да җавап тотарга туры килде. Кызганыч, республиканы шулай гаепләгәндә, Россия Югары Советына Татарстаннан сайланган депутатларның берсе дә аны яклап чыкмады. Алай гына да түгел, федералист карашлы депутатларыбыз республикага пычрак та атты әле.

Бу катлаулы чор турында күренекле сәясәтче, тарихчы Рафаэль Хәкимовның бер язмасында шундый юллар бар: «Чечнядагы сугыш башта Татарстанда буласы

иде ул. Безнең өчен әзерләнгән сценарий буенча башлап җибәрделәр инде аны. Референдум алдыннан Мәскәүдә куркынычсызлык советы утырышы үткәрелә. Анда Шахрай белән Станкевич Татарстанга гаскәр кертергә тәкъдим итә. Скоков каршы була. Без Татарстанда үз тикшеренүләребезне үткәрдек, Шәймиевнең сәясәтен анда татары да, урысы да хуплый, ди ул. Бу хакта миңа Скоков үзе сөйләде.

Референдумга чит илләрдән күзәтүчеләр килү бик шәп булды. Арада АКШ конгрессменнары да бар иде. Аннары Швеция, Бөекбритания илчелекләреннән дипломатлар килде — сәяси яктан бик мөһим нәрсә ул... Дөресен генә әйткәндә, Россиядә татар да күп инде. Алар да күтәрелергә мөмкин бит. Әнә күпме кеше телеграмма җибәрде, Татарстанга тимәгез, дип. Татар бит таралган-чәчелгән. Низаг-фәлән чыкса, локальләштерү читен булачак иде».

21 март көнне иртәнге сәгать җиделәр тирәсендә республикадагы барлык 2611 сайлау участогы да ачылды. Тавыш бирү башланды. Үзәк комиссия, шәһәр, район, участок комиссияләре әгъзалары ныклык күрсәтте. Иң мөһиме, халык куркып калмады, бердәм рәвештә референдумда катнашып, үз сүзен әйтте, бәйсезлеген һәм халыкара хокукларга ия дәүләт икәнлеген яклап тавыш бирде. Монда шунысы игътибарга лаек: референдумдагы сорауга уңай җавап биргән кешеләр татарлардан да, руслардан да бер чама булган. Шулай итеп, бөтен халык күләмендә тавыш бирү суверен дәүләт барлыкка килү фактын юридик яктан раслады. Моның нигезе исә республиканың дәүләт суверенлыгы турындагы Декларациягә салынган иде.

22 март көнне иртән мин, парламент хәбәрчесе буларак, Югары Совет бинасына юл тоттым. Максатым референдум нәтиҗәсен ачыклау иде. Ишектән керүгә, мине депутат Дамир Сираҗиев кочаклап алды. Ул бөтен бинага яңгыратып: «Әгъзам, победа! Без җиңдек!» — дип кычкырды. Көн башланып кына килүгә карамастан, парламент бинасында халык күп иде. Кызып-кызып сөйләшәләр, бер-берсен котлыйлар. Һәркемнең шатлыгы йөзенә чыккан. Әлеге вакыйгадан соң күп еллар үтсә дә, бу күренеш һаман да әле минем күз алдымда тора.

## КОНСТИТУЦИЯ — ХОКУКЫЙ ДӘҮЛӘТНЕҢ НИГЕЗЕ

Суверенлык Декларациясе, бөтен халык тавыш бирү юлы белән билгеләнгән статус яңа Конституция проектына нигез итеп алынды, халыкара стандартларга җавап бирә торган Конституция эшләргә тырышылды. Анда халыкара хокук нормалары республика законнарыннан өстен итеп куелды. Конституция проектын әзерләгәндә шәхес хокукын яклауга нык игътибар бирелде. Чөнки дәүләтнең куәте территориясенең зурлыгы яки халыкның саны белән түгел, ә гражданның реаль статусы, дәүләт хезмәтенә аның хокукы, демократик институтларның ныклыгы,

җәмгыятьнең икътисади, социаль, мәдәни үсеш дәрәҗәсе белән бәяләнә. Конституция — дәүләт тормышының төп мәсьәләләрен билгеләүче иң югары юридик көчкә ия закон гына түгел, бәлки демократик үзгәрешләрнең нигезе дә. Республиканың дәүләт-хокук статусындагы үзгәрешләрне төп законга беркетү дә бик мөһим иде.

Дөньяда Конституциянең идеаль модельләре юк, диләр. Һәр дәүләт үзенең традицияләренә, сәяси, икътисади хәленә таянып эш итә. Татарстан Конституциясе дә республикада яшәүче халык массалары мәнфәгатьләрен чагылдыруны максат итеп куйды. Конституция проекты Президент Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге махсус комиссия тарафыннан әзерләнде. Аның эшендә Югары Совет президиумы әгъзалары, халык депутатлары, күренекле галимнәр катнашты. Проектны чит ил экспертлары анализлады, ул халык депутатларының район һәм шәһәр советлары сессияләрендә, хезмәт коллективларында, матбугатта тикшерелде. Фикер алышу барышында барлыгы 5350 тәкъдим, төзәтмә кертелде.

*«Төп Закон проекты текстын язуда миңа, Конституция комиссиясе члены буларак, актив катнашырга туры килде. Бу бик әһәмиятле документ проекты, Югары Совет сессиясендә карауга тәкъдим ителгәнче, күп тапкырлар тикшерелде, үзгәрешләр кертелде,* — дип яза Рүзәл Юсупов. — *Мин актив депутат булдым. Ихтимал, хәтта артык актив та булганмындыр. Чын суверенлыкка ирешү идеясенә ышанып һәм моның тормышка ашырылуын теләп, мин үземнең чыгышларымда дәүләт суверенлыгы турындагы Декларациянең хәлиткеч пунктларын һәм Конституциянең аеруча мөһим статьяларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән мәсьәләләрне шактый кискен куя һәм башкарма хакимиятнең Декларация идеяләрен тормышка ашыру буенча җитдирәк гамәлләр кылуын таләп итә идем».*

Хәтерлим әле, Югары Совет сессиясендә Конституциянең иң мөһим статьяларын тикшергәндә, көймә еш кына комга терәлгәләп алды. «Народовластие» һәм «Татарстан» төркемнәренә берләшкән депутатлар бер үк мәсьәләгә капма-каршы караштa тора иде. Андый очракларда килештерү комиссияләре төзелде. Ул комиссияләрнең әгъзалары кайчакта берничәшәр сәгать бәхәсләшә иде. Конституция проекты тикшерелгән көннәрдә Ирек мәйданында күпсанлы плакатлар күтәреп килгән халык диңгезе чайкалды. Милли азатлык хәрәкәте оешмалары көне буе митинглар үткәрде, Конституцияне тизрәк кабул итүне, суверенлыкны ныгытуны таләп итте.

Хокук саклау органнары хезмәткәрләре дә йоклап ятмады. Яхшы коралланган омончылар, милиционерлар ул көннәрдә парламент бинасы тирәсенә чамадан тыш күп тупланды. Югары Совет бинасына үткәнче, документларны кат-кат тикшерделәр. Ул тарихи көннәрдә эчке эшләр хезмәткәрләре өчен Ирек мәйданы, аның белән тоташкан урыннар төп эш урыны булды, дисәм, ялгыш булмастыр. Парламент бинасы каршында өсте брезент белән ябылган дистәләрчә машиналар кизү

торды. Алардагы кулларына автоматлар тоткан ОМОНчылар, ерткыч бүреләрне хәтерләткән этләр әле дә күз алдында.

Милләтче депутатларның оппонентлары, «Народовластие» депутатлары төркеме лидеры Иван Грачёв Ирек мәйданындагы митингны туктатуны, мәйданны халыктан бушатуны таләп итте. Янәсе, урамдагы халык депутатларга эшләргә комачаулык тудыра.

Сессия эшендә тәнәфес игълан ителде. Шулай да милиция хезмәткәрләре Ирек мәйданын халыктан бушата алмады. Берәү дә мәйданнан китмәде. Шуннан соң бер төркем депутатлар урамга чыгып, халыкны Конституция кабул итүнең ничек барышы белән таныштырды, мөмкин булганның барысын да эшләргә вәгъдә бирде. Хәзергә халыкның Ирек мәйданыннан китеп торуын сорадылар. Бу сүзләр дә нигездә мәйданны үз кулларында тотучы, Чаллыдан килгән «Азатлык» яшьләр оешмасы егетләренә тәэсир итмәде булса кирәк.

— Безгә Марат абый чыгып әйтсен, — диде егетләрнең берсе. — Ул әйтмичә, без урыныбыздан кузгалмаячакбыз.

Чыннан да, халык алдында чыгыш ясаучы депутатлар арасында нигәдер ул вакытта Марат Мөлеков күренмәде. Югыйсә, сессиядә нинди мәсьәләләр каралуы, нинди карарлар кабул ителүе хакында төшке ял вакытында һәм кичләрен халыкка җиткереп баруны ул үзенең намус эше дип саный иде.

Ул көнне Маратны тиз эзләп таптылар. Зур-зур атлап кайдандыр килеп чыкты да, нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй, ашыкмыйча гына күзлек пыялаларын сөртеп алды. Аннары калын тавышы белән мәйданга мөрәҗәгать итте:

— Иптәшләр, хәл бик җитди. Без тырышырбыз. Хәзергә сез Опера һәм балет театры янына китеп торыгыз. Кирәк булсагыз, бик тиз хәбәр итәрбез.

Берничә минуттан мәйдан бушап калды. Сессия дәвам итте.

1992 елның 6 ноябре республика тарихы елъязмасына мәңгегә кереп калды. Бу көнне Татарстан Республикасының Конституциясе кабул ителде. Конституция кабул итү һәр дәүләт язмышы өчен зур әһәмияткә ия. Конституция — бер үк вакытта Төп закон да һәм билгеле бер тарихи этапта җәмгыять тормышының көзгесе дә.

*«1992 елның 6 ноябрендә кабул ителгән Конституция төпле белемнәре булган, әзерлекле, тәҗрибәле кешеләр тарафыннан уйлап эшләнелгән, дәүләт суверенлыгын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән җитди документ иде. Суверенлык идеясе аның башында — беренче маддәсендә ачык белдерелгән: «Татарстан Республикасы — бөтен күпмилләтле халкының теләкләрен һәм ихтыяҗларын чагылдыручы суверен, демократик дәүләт». Конституция үз халкының ихтыяҗларын тулысы белән үз законы буенча канәгатьләндерүне күздә тотып эшләнгән иде. Мәсәлән, 20 нче статьяда әйтелгәнчә, гражданнарның хокуклары, иреге һәм вазифалары*

*республиканың үз Конституциясе тарафыннан карала һәм шуның җирлегендә гамәлгә ашырыла. Конституция нык уйлап язылган һәм барыбызны да шатландырган иде,* — ди Рүзәл Юсупов.

Бу документта: «Конституция Татарстан Республикасының дәүләт статусы турында халыкның тавыш бирүе (референдум) нәтиҗәләре нигезендә игълан ителә», — диелә. 59 нчы маддәдә әгәр алар республиканың халыкара йөкләмәләренә каршы килмәсә, Татарстан законнарының бөтен республика территориясендә өстенлеккә ия булуы күрсәтелә. Конституциянең «Экономик система» бүлегендә суверен дәүләтнең хәлиткеч принцибы билгеләнә: «Җир, аның байлыклары, урманнар һәм башка төрле табигый ресурслар, хайваннар һәм үсемлек дөньясы, дәүләт банкларының активлары, Татарстан халыкларының мәдәни, тарихи хәзинәләре һәм республиканың хуҗалык мөстәкыйльлеген, матди һәм рухи культурасының саклануын тәшкил иткән башка төрле милек гомумхалыкныкы булып санала».

Конституция кабул ителү дәүләтебезне кире кайтару юнәлешендә гаҗәеп зур вакыйга булды. Хәтта депутатлар да бер-берсен котладылар. Сессия утырышы тәмамлануга, ул вакыйганың истәлеге итеп, депутатларга сәгатьләр тапшырылды. Югары Совет ашханәсендә аш мәҗлесе үткәрелде. «Народовластие» депутат төркеме лидерлары гына тантаналарда катнашмады. Сессия утырышы бетәр-бетмәс, алар кайтып китте. Күрәсең, Конституция кабул ителүгә ризасызлыкларын шул рәвешле белдерделәр. Ничек кенә булмасын, яңа Конституциядә Татарстанның хокуклары киңәя төште, яңа статусы законлаштырылды.

Татарстан Конституциясе икътисади системага принципиаль карашларга нигез салды. Социаль базар хуҗалыгы принцибын игълан итү республикада социаль-икътисади реформаларны тизләтү өчен зур әһәмияткә ия булды. 1992 елгы Конституция хакимиятнең үз органнарын, яңа демократик һәм базар икътисады институтларын төзүгә мөмкинлек бирде. Президентлык, даими эшләүче профессиональ парламент, җирле үзидарә, Конституция суды кебек дәүләти-гавами институтларны конституциячел-хокукый беркетү сәяси һәм социаль-икътисади мөнәсәбәтләрне яңа баскычка күтәрде.

Россиядә законнар системасының төзек булмавы сәбәпле, төбәкләр законнарының федераль законнарга туры килмәве проблемага әверелде. Нәтиҗәдә Татарстан Дәүләт Советының берничә чакырылышы 1990—1995 елларда кабул ителгән законнарны федераль законнарга туры китерү белән шөгыльләнде. Бу уңайдан Р.Юсупов хаклы рәвештә: *«Әгәр, Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе законнары белән бертөрле булырга тиеш, дигән принцип белән эш итсәң, республика законнарының кирәге каламы соң? Алай булгач, Дәүләт Советының үзенең дә кирәге каламы икән, дигән хаклы сорау туа»*, — дип язды.

Конституция — Татарстан халкы яшәешенең асылын тәшкил итүче Төп Закон. Безнең өчен моннан да зуррак закон юк. Башка күп дистәләрчә, йөзләрчә законнар — моның белән чагыштырганда икенчел дәрәҗәдәгеләр, шул Төп Законны гамәлгә ашыруга хезмәт итә торганнар. Шуңа күрә дә дөньяның цивилизацияле дәүләтләрендә Конституция бик сирәк очракта: дистәләрчә, йөзләрчә елларга бер тапкыр гына үзгәртелә. Моның ачык мисалы — Америка Кушма Штатлары.

Безнең Татарстан Конституциясенә исә һәр ел саен, хәтта елга берничәшәр мәртәбә үзгәреш кертелеп торды.

*«Мин, хәзерге Дәүләт Советының Төп Закон кабул ителүнең 20 еллыгын билгеләп үтәргә җыенганын белгәч, дөресрәге, бу дата уңаеннан үткәреләчәк конференциягә чакыру алгач, Конституция текстының 1993 елда басылып чыкканын һәм соңгы тапкыр чыгарылганын алып, аларны чагыштырып карагач, иңеп киттем,* — ди Р.Юсупов. — *Болар — икесе ике Конституция, дисәң, бу чынбарлыкка күбрәк туры килер. Соңгысын чын-чынлап Татарстан Конституциясе дип әйтү кыен, аны Россия — Татарстан Конституциясе дип атарга туры килә. Чөнки ул без теге вакытта һәр пункт, һәр җөмлә һәм сүзне көрәшеп кабул иткән Төп Закон түгел инде. Татарстан Конституциясенең соңгы вариантында республикабызның суверенлыгын тәшкил иткән статьяларның күбесе алып ташланган, нык үзгәртелгән».*

Татарстан Конституциясе беренче кабул ителгәннән соң 16 тапкыр үзгәртелгән. **16 тапкыр**! Төп Законның титул битенә: «Татарстан Республикасының Конституциясе 1992 елның 30 ноябрендәге Татарстан законы нигезендә (1994 елның 29 ноябрендәге; 1995 елның 30 марты, 8 декабрендәге; 1996 елның 27 ноябрендәге; 1999 елның 26 мае, 31 июлендәге; 2000 елның 3 марты, 31 мае, 19 декабрендәге; 2001 елның 28 июнендәге; 2002 елның 19 апрелендәге; 2003 елның 15 сентябрендәге; 2004 елның 12 мартындагы; 2005 елның 14 мартындагы; 2010 елның 30 мартындагы һәм 22 ноябрендәге үзгәртүләр белән) гамәлгә кертелде», — дип язылган. Бу кадәр үзгәрткәч, аның нәрсәсе калсын соң?! Конституциянең баштагы вариантындагы беренче маддәсендә, ачык һәм аңлаешлы итеп, «Татарстан Республикасы — суверен демократик дәүләт» дип язылган иде. Ә 2012 елда басылып чыккан соңгы вариантының беренче маддәсе менә мондый рәвешкә килгән: «Татарстан Республикасы — Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының «Идарә итү предметларын чикләү һәм Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары арасындагы вәкаләтләрне үзара бүлешү» турындагы килешүе нигезендә Россия Федерациясе белән берләштерелгән һәм Россия Федерациясе субъектын тәшкил итә торган демократик хокукый дәүләт. Татарстан Республикасының суверенлыгы, Россия Федерациясенең идарә итү чикләреннән һәм

Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының бергә идарә итү предметлары буенча Россия Федерациясенең вәкаләтләреннән тыш бөтен дәүләт (закон чыгару, башкару һәм суд) хакимиятенә ия булуында чагылыш таба һәм Татарстан Республикасыннан аерылгысыз сыйфатын тәшкил итә».

*«Әлеге башваткыч текстны аңлаган кеше монда инде «суверенлык» төшенчәсенең бик аз гына чалымлануын сизәр»,* — ди Рүзәл Юсупов. Академик дәрәҗәсендәге зур тел галименә дә аңлау авыр булган Конституция текстына гади халык ничек төшенер, аннан ничек файдаланыр икән? Бу сорауга Төп Законны шундый хәлгә китергән депутатлар җавап бирсә генә инде.

Кат-кат үзгәртелгәннән соң, Татарстан Конституциясенең эчтәлеге Россия Конституциясе маддәләре өстенлегенә нигезләнеп калган. Бу хәл яңартылган Конституциянең иң әһәмиятле маддәләрендә ачыктан-ачык күренеп тора.

Р.Юсупов хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, Татарстан Конституциясенең соңгы тапкыр төзәтелгәнен укыган саен кәеф кырыла бара, чөнки һәр пунктында, һәр маддәсендә Татарстанның роле, дәрәҗәсе кечерәйтелгән. Анда республиканың үзенә генә хас, аның үз халкының ихтыяҗларын күздә тоткан маддәләр калмаган диярлек.

Билгеле, Татарстан парламенты депутатларын республикабызның Төп Законын үзгәртергә Россия хакимият органнары, беренче чиратта Конституция суды мәҗбүр иткән. Шулай да депутатларыбыз Татарстан Конституциясен Россиянеке белән тәңгәлләштергәндә чик-чаманы бөтенләй онытып җибәргәннәр. 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителгән Конституциянең беренче пунктында болай диелгән иде бит югыйсә: «Бу Конституция Татарстан Республикасының дәүләт статусы турында халыкның тавыш бирүе (референдум) нәтиҗәләре буенча кабул ителде һәм игълан ителә».

Референдумда Татарстанда яшәүче татарлар да, урыслар да, башка милләт кешеләре дә республиканың дәүләт суверенлыгын яклап тавыш бирделәр. Мәгълүм булганча, референдум нәтиҗәләре исә иң зур хокукка ия. Аның нәтиҗәсен беркем дә, хәтта Президент та, парламент та үз карары белән юкка чыгара алмый. Татарстан халкы беренче чиратта үзенең референдумы нәтиҗәләре буенча кабул ителгән Төп Законы буенча яшәргә тиеш.

— *Бүген федераль хакимияттә республикабызның суверенлыгын искә төшереп торган Татарстан Республикасы һәм Татарстан Президенты статусларын юкка чыгарырга кызыгып йөрүчеләрнең барлыгы билгеле. Шунлыктан безнең республика халкына, хакимият ияләренә Татарстанның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация, суверенлык турындагы референдум нәтиҗәләрен һәм суверенлык рухы белән сугарылган 1992 елгы Татарстан Конституциясен янә искә төшерергә һәм бу чиксез кыйммәтле документларны кабат гамәлгә ашыру*

*белән шөгыльләнергә дә туры килмәгәе әле,* — дип яза Р.Юсупов. — *Соңгы елларда Декларациядә һәм Конституциядә беркетелгән позицияләрдән җитди читенүләр булып тора. Мондый күренешләрнең объектив һәм субъектив сәбәпләре дә бар. Әмма мин бер нәрсәгә инанам: Декларациянең әһәмиятле пунктларының үтәлмәве өчен җаваплылык барыннан да бигрәк Дәүләт Советына төшә. Чөнки парламент ул — коллектив рәвештә законнар чыгару органы һәм аның вазифаларына кабул ителгән законнарның үтәлешен контрольдә тоту да керә.*

Күп кенә сәясәтчеләр һәм хокук галимнәре дә бүген Россия Конституциясенең камил булмавын таныйлар. Әмма ул һаман да тәртипкә китерелми, гадәттә республикалар конституцияләрен үзгәртү генә таләп ителә. Югыйсә, карашлар төрлелеген бер-берeңә якын килү белән генә җиңәргә мөмкин бит. Барлык конституцияләрнең тәңгәллеге һич тә мәҗбүри түгел. Шунысы да бар, Татарстан Конституциясе федератив мөнәсәбәтләрне үстерүнең яңа формуласын ныгытты, ул тормышыбызның аерылгысыз өлеше булып әверелде. Хәзер инде хуҗалык һәм җәмгыять эшен муафыйк алып баруны шулардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Ничек кенә булмасын, республика Конституциясе беренче чиратта халкыбыз мәнфәгатьләрен яклауга, халыкның тормыш хәлен яхшыртуга хезмәт итәргә тиеш. Җир шарындагы һәр милләт шикелле, татар халкы да үзенең дөнья цивилизациясендәге лаеклы урынын билгеләргә, бай тарихы, мәдәнияте, иҗтимагый акылы, камил теле белән горурланырга, аларны үстерергә, киләчәккә илтергә хаклы.

## ТЕЛЛӘР ТУРЫНДА ЗАКОН КАБУЛ ИТҮ

Татарстанның 1990—1995 елларда эшлисе парламентына альтернатив нигездә депутатлар сайлау демократиягә билгеле дәрәҗәдә юл ачылу булды. Яңа сайланган депутатлар җиң сызганып эшкә керештеләр. Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителде, Татарстанның Президенты сайланды, республиканың дәүләти-хокукый статусын күтәрү турында референдум үткәрелде, республиканың яңа Конституциясе кабул ителде, Россия — Татарстан Шартнамәсенә кул куелды. Болар ул чорда республиканың сәяси процессының алга барышында мөһим этаплар иде.

Татарстан Конституциясе нигезендә үзебезнең хокук системасын формалаштыру процессы яңа импульс алды. Дәүләт төзелеше өлкәсендә Югары арбитраж суды турында, Конституцион суд турында, дәүләт хезмәте турында, бюджет төзелеше һәм бдюжет процессы турында һәм күп кенә башка әһәмиятле законнар кабул ителде. Алар республиканың дәүләт төзелешен камилләштерүгә, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуга юнәлдерелгән иде.

Татарстан парламенты республикада үзгәртеп коруларны, җир реформасы үткәрүне, милекне хосусыйлаштыруны күздә тоткан, шулай ук базар шартларына кергәндә республика халкын социаль яклауга, җинаятьчелеккә каршы көрәшне көчәйтүгә юнәлтелгән һәм башка төрле прогрессив законнар кабул итте.

Бу законнарны әзерләүдә һәм кабул итүдә, даими комиссия рәисе һәм Югары Совет президиумы әгъзасы буларак, Рүзәл Юсупов та актив катнашты. Ә менә «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы законны әзерләүгә иң күп көч сарыф иткән кеше депутат Р.Юсупов булды, дип әйтергә тулы нигез бар. *«Парламентның «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон кабул итүе республикабызның рухи тормышында әһәмиятле вакыйга булды. Минем «милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссия рәисе» дигән статусым, Казан педагогика университеты ректоры һәм татар теле гыйлеме кафедрасы мөдире булып эшләвем, шулай ук филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә һәм профессор исеменә ия булуым табигый рәвештә миңа бу гаять әһәмиятле документны әзерләүдә һәм кабул итүдә актив катнашу бурычын йөкли иде,* — дип язды соңрак Р.Юсупов. — *Без, академик Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиев, профессор Фоат Әшрәпович Ганиев һәм башка кайбер белгечләр белән бергә, суверенлык турындагы Декларацияне кабул иткәнче үк, телләр турындагы законның проектын төзергә керешкән идек. Дәүләт суверенитетын игълан иткәннән соң һәм Татарстан Республикасының яңа Конституциясен кабул иткәч, телләр турыдагы законны кабул итү кичектергесез хәлителергә тиешле эшкә әверелде».*

Югары Советта «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон проектын әзерләү буенча махсус комиссия төзелде. Аның составында Рүзәл Юсупов та бар иде. Закон проектын парламентның барлык даими комиссияләрендә тикшереп фикер алышуны оештыру һәм, ул комиссияләрдә яраклы дип табылганнан соң, аны сессиягә тәкъдим итү Рүзәл Абдуллаҗановичка тапшырылды. Билгеле, бу закон проектын парламент сессиясендә карау өчен әзерләү җиңел эш булып чыкмады. Аны кабул иткәнче, Рүзәл Юсуповка, филологик һәм педагогик белемнәреннән файдаланып, шактый нык тырышырга туры килә.

*«Телләр турындагы закон проектын әзерләгәндә һәм сессиядә караганда иң четерекле нәрсә дәүләт телен билгеләү булды. Кайбер депутатлар дәүләт теле итеп бер генә телне — татар телен генә билгеләү ягында тордылар. Мәсьәләнең болай куелышы, табигый рәвештә, рус телендә сөйләшүче депутатларның җитди каршылыгына очрады. Күпсанлы рус халкы яшәгән республикада бер татар телен генә дәүләт теле дип игълан итү өметле һәм хаклы гамәл түгел иде,* — ди Р.Юсупов. — *Миңа татар телен генә яклаучы коллегаларымны мәсьәләне болай*

*хәл итәргә омтылышның реаль түгеллегенә инандырырга һәм «татар телен дә, рус телен дә дәүләт телләре итеп билгеләргә» дигән формулировка белән килешергә кирәк, дип өндәргә туры килде. Ахыргы исәптә акыл өстен чыкты. Депутатларның күпчелеге татар һәм рус телләрен дәүләт телләре дип игълан итүгә риза булдылар. Закон проектын әзерләү һәм сессиядә карау барышында кайбер башка мәсьәләләр буенча да төрле фикерләр белдерелде».*

Телләр турындагы закон проектын сессиядә караганда, бу мәсьәлә буенча доклад ясау Рүзәл Юсуповка тапшырылган иде. Аның докладыннан соң, гадәттәгечә, проект буенча актив һәм кызыксынулы фикер алышу булды. Һәм «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон депутатларның иң зур күпчелегенең уңай тавыш бирүе нәтиҗәсендә кабул ителде. Бу татар халкы һәм республикадан читтә яшәгән күпсанлы татарлар өчен шатлыклы вакыйга булды.

Россия төбәкләренә сибелеп яшәгән татарлар республика йөзендә телне саклау һәм мәдәниятне үстерү өчен таяныч барлыкка килүен тойдылар. Татар халкы тарихында беренче мәртәбә бөтендөнья татарларының конгрессы уздырылды. Анда милли үсешнең иң мөһим проблемалары тикшерелде. Республика татар телендә укытучылар өчен фәнни-методик үзәккә әверелде. Бүген Татарстан Россия Федерациясендәге татар мәктәпләрендә ана теле һәм әдәбияты укытучыларының квалификациясен күтәрү, аларны дәреслекләр белән тәэмин итү, татар теле буенча ел саен уздырыла торган төбәкара олимпиадалар, балаларның җәйге ялын оештыру, Россия төбәкләрендә татарча белем бирүне алга җибәрү проблемаларын хәл итүдә булышу һәм башка төрле игелекле гамәлләр кылырга тырыша.

Татар теле юридик яктан гына түгел, чынлыкта да дәүләт теле булып китә. Аның гомуми белем бирә торган мәктәпләрдә укыту предметлары исәбенә кертелүе принципиаль мөһим. «Мәгариф турында» һәм «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» республика законнары нигезендә татар һәм рус телләре, дәүләт телләре буларак, мәгариф учреждениеләрендә тигез күләмдә өйрәнелә. Югары уку йортларында да татар телендә укыту даирәсе акрынлап киңәя бара.

Шулай да «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы законны гамәлгә ашыру буенча проблемалар аз түгел әле. Татарстан хөкүмәте законда күздә тотылган татар телен өйрәнү, үстерү, саклау бурычларын үтәү белән җитәрлек шөгыльләнмәде. Андагы бик әһәмиятле мәсьәләләргә формаль караш хөкем сөрде. Законнарның үтәлешен контрольдә тотып, аларның гамәлгә ашырылуын хөкүмәттән таләп итәргә тиешле парламент бу үтә мөһим бурычны игътибарыннан читтә калдырды. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы законның әһәмиятле статьялары бүгенгә кадәр тиешенчә үтәлми.

*«Татар теле укытучылары, нигездә, искергән методика — кагыйдәләр, билгеләмәләр ятлату, күнегүләр эшләтү методикасы буенча эш итәләр, җанлы, матур телдә йөгерек итеп сөйләргә өйрәтү, ягъни коммуникатив алым белән эшләү җитми,* — дип яза Р.Юсупов. — *Мәктәпне тәмамлап чыккан укучылар сөйләгәндә, язганда орфоэпик, грамматик, стилистик хаталар җибәрәләр, туган телнең нормаларын бозалар, бай сүзлек запасыннан тулы файдалана белмиләр. Татар теле укытучыларының балаларга туган тел укытудагы «гөнаһлары» мәктәпне тәмамлап чыккан яшьләрнең практик эшләрендә, бигрәк тә матбугат органнарында, радио-телевидениедә эшләүчеләрнең язу, сөйләү практикасында тел ялгышларын күп җибәрүләрендә күренә».*

Һәр халык өчен үзенең туган теле — иң кадерле, иң әһәмиятле нәрсә. Безнең өчен ул — татар теле. Туган тел — ана сөте белән бирелгән газиз тел. Туган тел — атаң-анаң, туган җирең, авылың, шәһәрең, республикаң кебек изге төшенчә. Димәк, аны өйрәнү, яхшы белү, дөрес куллану, бозмыйча саклау — һәр кешенең бурычы.

* * *

*«Мин актив депутат булдым. Ихтимал, хәтта артык актив та булганмындыр әле. Чын суверенлыкка ирешү идеясенә ышанып һәм моның тормышка ашырылуын теләп, мин үземнең чыгышларымда дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең хәлиткеч пунктларын һәм Конституциянең аеруча әһәмиятле статьяларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән мәсьәләләрне шактый кискен кую һәм башкарма хакимияттән Декларация идеяләрен тормышка ашыру буенча җитдирәк гамәлләр кылуын таләп итеп килдем»,* — дип язды Рүзәл Юсупов.

Рүзәл Юсуповның 1990—1995 елларда Югары Совет депутаты булып эшләвен аның сугышчан характеры формалашу чоры дияргә мөмкин. Шул чакта ул хәлиткеч мәсьәләләргә карата үз фикерен булдырырга һәм аны кыю рәвештә ачыктан-ачык белдерергә өйрәнә. Югары Совет сессияләрендә, парламентның президиумы һәм аның комиссияләре утырышларында аңа төрле мәсьәләләр буенча күп тапкырлар киеренке бәхәсләрдә катнашырга, кыю рәвештә үз фикерен әйтергә һәм нәтиҗәдә парламент җитәкчесенең, ә соңрак республика башлыгының канәгатьсезлегенә дучар булырга туры килә. Ләкин ул чакта аның халык тормышын яхшыртуның хәлиткеч мәсьәләләренә карашын беркем дә үзгәртә, дөрес юлдан тайпылдыра алмады.

Ул чорны искә алып, Р.Юсупов болай дип яза: *«Республикабыз парламенты сессияләренең стенограммаларында минем Татарстан язмышы өчен бик әһәмиятле мәсьәләләр буенча ясалган чыгышларымның текстлары сакланадыр. Ул чыгышларымда мин авылларда фермер хуҗалыкларын оештыру һәм җәелдерү өчен шартлар булдырырга кирәк, балалар һәм яшьләрне тәрбияләүгә дәүләт тара-*

*фыннан күбрәк акча бүлеп бирелергә тиеш, җинаятьчелекнең, эчүчелекнең арта баруын, радио-телевидениедә, кинода һәм матбугатта порнографияне пропагандалауны туктату өчен дәүләтнең хокук саклау органнары нәтиҗәлерәк эшләргә тиеш, дип сөйләдем».*

Республика суверенлыгы турындагы Декларацияне, Татарстан Республикасы халыклары дәүләт телләре турындагы законны һәм хөкүмәт карарын, шулай ук башка әһәмиятле закон һәм карарларны тормышка ашыруга ярдәм итү теләге Р.Юсуповны, җәмәгать эшлеклесе, зур югары уку йорты ректоры һәм галим буларак, мәгълүмат чараларында — матбугатта, радио һәм телевидениедә актив рәвештә чыгышлар ясарга этәрә. Ул әһәмиятле мәсьәләләр буенча күп тапкырлар татар һәм рус телләрендә газета-журналларда, радио-телевидениедә чыгышлар ясады. Бу чыгышлар җәмәгатьчелектә кызыксыну уята иде, һәм аны кабат-кабат чакырып тордылар.

*«Үземнең көчемнән, узган тормыш юлым һәм парламенттагы эшем тәҗрибәсеннән, шулай ук белемнәремнән файдалану нияте белән, мин чираттагы чакырылыш парламентына сайланырга ризалыгымны бирдем,* — ди Р.Юсупов. — *Теоретик яктан караганда, минем сайлану мөмкинлекләрем җитәрлек: мине ул чагында элекке чакырылыш парламентында актив депутат буларак та, мин җитәкчелек иткән чорда зур уңышларга ирешкән югары уку йорты ректоры буларак та республикада яхшы беләләр иде. Шуның өстенә, мин эшләгән уку йортының күп меңләгән укытучылары һәм студентлары сайлау алды компаниясендә үзләренең җитәкчеләрен сайлату өчен күп көч куйдылар».*

Әмма Рүзәл Юсуповның һәм аның коллегаларының өметләре акланмый. Рүзәл Абдуллаҗанович һәм парламентта кыю, принципиаль чыгышлар ясаган башка депутатларның берсен дә киләсе чакылырыш советына үткәрмиләр. Чөнки сайлау гадел итеп уздырылмый. *«Безнең илдә — Россиядә дә, Татарстанда да — әлегә гадел сайлауларның булганы юк. XII чакырылыш Югары Советын моннан бердәнбер чыгарма итеп карарга мөмкин. Мин үзем катнашкан ике сайлау компаниясендә парламентка сайлау законының һәм кагыйдәләренең тупас бозылуы хәлләренә шаһит булдым, андый тәртипсезлекләр, закон бозулар аркасында үзем дә җитди зыян күрдем,* — ди Р.Юсупов. — *Соңрак мин шуны аңладым: хакимият ияләренә үз фикерләрен һәм идеяләрен ачыктан-ачык һәм кыю рәвештә әйтә торган кешеләр кирәк түгел икән: ул идея һәм фикерләрне гамәлгә ашыру кайбер кешеләр өчен артык эш, мәшәкатьләр китереп чыгара бит».*

Бездәге сайлау системасының гадел түгеллеген күрсәтә торган бер гыйбрәтле мисал да китереп узыйк. 1990—1995 еллардагы иң актив, нәтиҗәле эшләгән, чын-чынлап милләт язмышы, дәүләтчелегебезне торгызу өчен җиң сызганып ты-

рышкан Рүзәл Юсупов, Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова, Дамир Сираҗиев, Мөдәррис Шәйхиев кебек актив депутатларның берсе дә Татарстанның алдагы чакырылыш Дәүләт Советына сайлана алмады. Чөнки югарыдан шулай оештырылган иде. Дәшми торган, кушканны үтәүче уңайлы депутатлар эшенең тискәре нәтиҗәсе күз алдында. Хәзер парламент сессияләрендә XII чакырылыш депутатлары эшләгәндәге кебек прогресска ирешүгә юнәлтелгән җанлы, кыю фикер алышулар, бәхәсләр юк. Бер көндә бәхәссез-нисез дистәләгән мәсьәләләр хәл итеп куела.

*«Бик тә гаҗәп хәл: соңгы ун-унбиш елда Дәүләт Советы депутатлары Мәскәү күрсәтмәсе буенча 1990—1995 еллардагы Югары Совет кабул иткән законнарны Россия Федерациясе законнарына туры китерерлек итеп үзгәртү белән шөгыльләнәләр. Татарстан законнары Россиянеке белән бертөрле булырга тиеш, дигән принципка таянып эш итсәң, республика законнарының кирәге каламы соң?! Алай булгач, Дәүләт Советының үзенең дә кирәге бармы икән, дигән хаклы сорау туа»,* — дип язды Рүзәл Юсупов.

## ХАЛЫКЧАН ПАРТИЯ ТӨЗҮ

Өлкән буын вәкилләре яхшы хәтерлидер: коммунистлар партиясе, һичшиксез, куәтле идеология коралы хезмәтен күп вакытлар уңышлы үтәп килде. Әмма мәгълүм булганча, 80 нче еллар азагында ул банкротлыкка чыкты, һәм аның идеаллары якты киләчәккә өнди алмас булды. Дөресрәге, гаеп партиянең идеалларында түгел, бәлки ул идеалларны бозган кешеләрдә, партия җитәкчеләрендә иде.

Коммунистлар партиясенең бозык репутацияле җитәкчеләре хәзерге дәүләтнең идарә органнарында эшләргә тиеш тә түгелләр иде. Бөтен дөньяда шулай, тик нигәдер безнең Россиядә генә алай түгел.

*«Мин коммунистлар партиясенә шактый хезмәт итеп өлгердем. Ул партиягә, армиядә хезмәт иткәндә, егерме яшемдә үк кереп, аның актив члены булдым. Мин 90нчы еллар башында коммунистлар партиясеннән, аның банкротлыкка чыкканын белгәч, үз теләгем белән киттем. Ләкин, кайберәүләр кебек, партияне каргап, сүгеп йөрмим. Минем өчен шул нәрсә бик сәер: партиянең элекке актив членнарының, бигрәк тә җитәкчеләренең күбесе хәзер шул партиянең яманатын сатып йөриләр. Аның җитешсез яклары бар, ләкин андагы бар нәрсә дә начар түгел иде бит. Хәзергегә караганда ул чорда тәртип ныграк, халык тәрбиялерәк, яшәү максатчан, гаделлек зуррак иде. Әмма ул чакта ректорның партиядән китүе сенсация һәм шактый хәтәр күренеш иде. Ярый әле миңа зур зыян тимәде»,* — ди Р.Юсупов.

Коммунистлар партиясе таркалгач, төрле партияләр баш калкыта башлады. Шундыйларның берсе «Иттифак» куйган төп максат — бәйсез Татарстан төзү — бик катлаулы бурыч иде. Тик моңа ирешү юлларының анык түгеллеге, каршылыклы булуы ачыкланды. Шуңа күрә аларны күпчелек халык якламады. Күпчелек халыкны үз артыннан ияртә алырлык партия кирәклеге ачыкланды. Ул, республика халкы ихтыяҗларын исәпкә алып, әмма каршылыклар тудырмыйча, тыныч юл белән, демократик Татарстан Республикасының прогресска ирешүенә, халыкның бәхетле яшәвенә ярдәм итәргә бурычлы партия булырга тиеш иде.

Профессор Рүзәл Юсупов бу хакта фикердәшләре, дуслары белән киңәште, фикер туплады. Яңа партиянең программасын, уставын төзү бурычы куелды. Аны Республика партиясе дип атау мәслихәт булыр дигән фикергә киленде. Әмма партия төзү теләген бик тиз генә гамәлгә ашыру мөмкин булмады. Ректорлык хезмәте, депутатлык мәшәкатьләре яңа партия төзүне кичектерә барырга мәҗбүр итте. Шулай да Р.Юсупов бу зур эшкә әзерләнүен туктатмады. Ул бу максатта матбугат, радио, телевидениенең мөмкинлекләреннән тулы файдаланырга тырышты. Бу эштә аңа, университет тәмамлагач, берничә ел телестудиядә редактор булып эшләве, ул елларда туплаган тәҗрибә дә ярдәм итте.

Рүзәл Юсупов чыгышларын күбрәк рус телендә ясарга тырышты. Кайберәүләр моңа сәерсенеп караса да, аңа профессорның үз карашы бар иде. Беренчедән, татарча укый, сөйләшә белүчеләрнең күпчелеге болай да аның белән фикердәш, Татарстанның суверенлыгын, бәйсезлеген яклый. Рус телендә сөйләшүчеләрнең исә мөстәкыйльлек идеясенә мөнәсәбәтләре башкачарак. Бигрәк тә менә шулар белән эшләргә кирәк. Әлегә аларның бер өлеше республикабызга исем биргән җирле халыкның рухи омтылышларын, теләкләрен аңлап җиткерми. Аларга шулай ук татарларда милли үзаңның үсүе, һаман киңрәк колач ала баруы да аңлашылмый. Аларга шуны төшендерергә кирәк. Депутат-профессор үз эшен әнә шуңа юнәлтте.

*«Республиканың киләчәге — аның бәхетле булуы — барыннан да бигрәк безнең ни дәрәҗәдә ирекле булуыбызга бәйле»,* — дип язды Рүзәл Юсупов 1992 елның гыйнварында басылган «Тормыш күрсәткәнчә» дигән мәкаләсендә. Анда ул хәлнең чынлыкта ничек булуын, каршылыкларны, аларны хәл итү юлларын күрсәтте, әлегәчә мөстәкыйльлекнең асылын аңлап җиткермәгән кешеләргә хәлнең чынын аңлатып бирергә тырышты.

Ни генә булмасын, борынгыдан ук үз дәүләте булган татар халкы тулысынча үзбилгеләнү, үз язмышын ирекле рәвештә үзе хәл итү хокукына ия. Әлеге хокукын тормышка ашыруга ирешәчәк тә ул. Бу эштә аңа Татарстанда яшәүче башка халыклар — руслар, чувашлар, марилар, яһүдләр теләктәш булсалар, бурыч җиңелрәк хәл ителәчәк.

1992 елның 9 гыйнварында оештыру комитеты, Татарстанның Республика партиясен төзү буенча җыелыш үткәрергә, дигән карарга килде. Бу тарихи җыелыш Казанның Актёрлар йортында 25 гыйнварда иртәнге сәгать унда башланды. Анда партиянең программа һәм устав проектларын әзерләүгә күп көч куйган юрист Гаял Мортазин рәислек итте. Җыелышка Казаннан һәм берничә районнан шактый гына кешеләр килгән иде. Көн тәртибенә Татарстанның Республика партиясен оештыру, партиянең программа һәм устав проектларын, җитәкче органнарын сайлау мәсьәләләре кертелде.

Бу оештыру җыелышында докладларны Рүзәл Юсупов белән Гаял Мортазин ясады. Докладлар буенча фикер алышуда Ф.Шәйдуллин, Ә.Мәхмүтов, А.Фокин, Б.Касыймов, Г.Газиев, К.Латыйпов һәм башка кайбер кешеләр чыгыш ясады. Аннары Татарстанның Республика партиясен төзү турында карар кабул ителде, партиянең программасы һәм уставы расланды. Партиянең даими комитеты составына И.Абдуллин, Ш.Асылгәрәев, М.Егоров, Ф.Зарипов, Л.Кариева, Б.Касыймов, К.Латыйпов, Ә.Мәхмүтов, М.Мөлеков, Г.Мортазин, Н.Мышев, О.Никитина, И.Парамонова, Р.Халитов, К.Шәйхетдинов, Р.Шәфиков, Р.Юсупов кертелде. Рүзәл Юсупов партиянең рәисе итеп сайланды. Секретарьлар итеп Ф.Зарипов, Л.Кариева, К.Латыйпов, И.Парамонова, Р.Халитов, К.Шәйхетдинов, Р.Шәфиков, ревизия комиссиясе рәисе итеп И.Галимов сайланды.

*«Оештыру җыелышында партиянең рәисе итеп сайлап куюлары, һичшиксез, минем тормышымда зур вакыйга, рухи борылыш булды,* — дип яза Р.Юсупов. — *Миңа бу партиянең программасын, уставын төзү һәм партияне Юстиция министрлыгында теркәү эшләре белән күп шөгыльләнергә туры килде. Министрлыкта теркәлү өчен, партиянең башлангыч оешмалары республика районнарының ким дигәндә яртысында булырга тиеш. Бу безнең өчен бик катлаулы эш булды. Хакимият органнары, партияне теркәтмәс өчен, төрле юллар белән комачауларга тырышты. Ләкин без үзебезнең максатка ирештек. Татарстанның Юстиция министрлыгында партияне теркәттек. Бу эштә безнең коллегабыз профессор Фираз Фахразович Харисовның роле зур булды. Тиздән без партиябезнең басма органы «Татарстан Республикасы» газетасын оештырдык. Аны да Юстиция министрлыгында теркәттек. Бу газета татар һәм рус телләрендә чыгып килде. Татарстанның Республика партиясе изге максатларга ирешүне күздә тотып эш итә торган центристик партия иде».*

Суверенлык җилләре исә башлауга, Татарстанда берничә партия һәм күп кенә оешмалар барлыкка килде. Әлбәттә, бу — табигый хәл. Моны сәяси тормышыбыздагы җитди прогрессив үзгәрешләр белән аңлатырга кирәк. Республиканың мөстәкыйльлек юлына аяк басуы, аны гамәлгә ашыру барышы төрле фикерләр,

төрле карашлар тудырды. Шуның нәтиҗәсе буларак оешкан «Иттифак» бердәмлек партиясе, Россия Демократлар партиясенең Казан бүлеге, болардан тыш «Азатлык», «Суверенитет» оешмалары, Татар иҗтимагый үзәге, гәрчә аларның программалары бер-берсеннән шактый аерылып торса да, һәрберсе үзен халыкка хезмәт итә торган партия яисә оешма дип игълан итте.

Коммунистлар партиясенең инде халыкка хезмәт итә алмавы ачыклангач, яңа оешкан партияләргә дә халык шикләнебрәк карады, зур ышаныч күрсәтмәде. Шуңа күрә Татарстанның Республика партиясе халыкка хезмәт итү максатын куйды. Әлеге партия, Татарстан халкы ихтыяҗларын исәпкә алып, каршылыклар тудырмыйча, дәүләтчелегебезне тулысынча формалаштыруга ярдәм итү өчен эш башлады.

Партияне оештыручылар җыелышында кабул ителгән декларациядә шундый юллар бар: «Татарстан Республика партиясенең максаты — хезмәт ияләренең киң катлауларын чын демократик, хокукый һәм чәчәк атучы җәмгыять төзүгә һәм аны үстерүгә туплау. Бу партия, милләтләренә, социаль чыгышларына, нинди дин тотуларына бәйсез рәвештә, барлык гражданнарның мәнфәгатьләрен яклаячак!

Татарстан — безнең уртак йортыбыз. Анда бар кеше дә бәхетле яшәсен өчен тынычлык, халыклар арасында татулык һәм үзара аңлашу кирәк. Татарстанның Республика партиясе Татарстан халыклары республикабызда тотрыклылык, иминлек урнаштыру өчен гакыл һәм җаваплылык хисе белән эш итәрләр, каршы торуларга юл куймыйча, республика алдында торган гаять катлаулы проблемаларны уңышлы хәл итү өчен бөтен тырышлыкны куярлар дигән ышанычны белдерә».

*«Билгеле булганча, цивилизацияле, культуралы партиянең максаты — беренче чиратта халыкка хезмәт итү. Безнең партиянең дә бурычы — халыкның тормыш дәрәҗәсен кайгырту. Бу — купшы сүзләр булып кына калмасын дип тырышабыз. Хәзер күп төрле оешмалар, партияләр бар. Карап торуга, аларның һәркайсының нияте изге шикелле. Ләкин еш кына куелган бурычлар үтәлми кала. Мин, шушы партияне оештыручыларның берсе һәм җитәкчесе буларак, бу мәсьәләгә бик җитди карыйм. Безнең партия киләчәккә өмет уятырга тиеш. Халык ышанычын яулый алганда гына уңышка ирешәчәкбез. Моның өчен, үзегез беләсез, эшләп күрсәтергә кирәк. Шуны истә тотып, партия Татарстанны хокуклы, демократияле дәүләт итүне үзенең иң беренче бурычы итеп куя. Чөнки бу — безнең йөз еллар дәвамында хыялланып яшәгән уебыз. Аннан килеп, бурыч: сәяси, икътисади мөстәкыйльлеккә ирешү. Кыскача әйткәндә, партия халыкның матди тормышын яхшырту, аңа хокуклар бирү, суверен дәүләт төзүдә ярдәм итү юнәлешендә эшләячәк»,* — диде Р.Юсупов, партиянең максатларын ачыклап, газета хәбәрчесенә.

Татарстанның Республика партиясе суверен Татарстанның алга баруында уңай

роль уйнады. Ул үзенең членнарын, алар аша республиканың башка кешеләрен дә Татарстан халыкларының демократик казанышларын саклауга һәм ныгытуга туплау, кайберәүләрнең суверенлык идеясеннән баш тартырга омтылуларын фаш итү белән шөгыльләнде. Профессор Р.Юсупов җитәкләгән партия республикада референдум үткәрү һәм анда күпчелек халыкның «әйе» дип җавап бирүенә ирешү өчен көрәшкә күтәрелде. Үз тирәсенә Марат Мөлеков, Фираз Харисов, Рәшит Вагыйзов, Гаял Мортазин, Кави Латыйпов, Тәлгать Шиһабиев, Николай Мышев кебек милләтпәрвәрләрне туплаган бу партия чыныгуны әнә шул көннәрдә алды. Аның вәкилләрен һәркайда — завод һәм фабрикаларда, колхоз һәм совхозларда, студентлар арасында төрле очрашу һәм митингларда күрергә була иде.

Референдум уңаеннан партиянең сәяси советы 1992 елның мартында республиканың күпчелек газеталарында халыкка мөрәҗәгать бастырды:

«Әгәр дә сез республикабыз халкының тулы һәм мул тормышта яшәвен, татар һәм русларның, мари һәм чувашларның, башкорт һәм мордваларның, яһүд һәм украиннарның, гомумән, Татарстанда яшәүче барлык милләт вәкилләренең иңгә-иң торып, тату һәм дус гомер кичерүен, олы дуслыкның дәвам итүен телисез икән, 21 мартта үтәчәк референдумга битараф калмассыз дип ышанабыз. Иң мөһиме — референдумның уңай нәтиҗәләренә республикабыз халыклары арасындагы гасырлардан килә торган дуслыкны бозмыйча, милләтләр арасында кискен каршылык тудырмыйча ирешү. Татарстан Республикасы, күпчелек халыкның теләген исәпкә алып, үзенең бәйсезлеген республикабызда яшәгән барлык милләт вәкилләре ризалыгы белән ныгытып куярга тели. Һәр милләтнең өлгергән проблемаларын уңышлы хәл итүне һәм республикабызның башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен ирекле килешүләр нигезендә коруны кулай күргән һәркем, Татарстан бәйсезлеген яклап, «әйе» дип тавыш бирер, дип ышанасы килә».

Референдум алдыннан партия әгъзалары, үз позицияләрен белдереп, радио һәм телевидениедән чыгышлар ясадылар, «түгәрәк өстәл»ләрдә катнаштылар. Профессор Р.Юсупов җитәкләгән партия үз әгъзаларын сайлау участокларына күзәтүчеләр итеп билгеләде. Ул чактагы дәрт, күтәренкелек чынлап та сокланырлык иде. Татар иҗтимагый үзәге активистлары ярдәме белән БДБ илләреннән, Россия төбәкләреннән, Татарстаннан меңгә якын күзәтүче тупланды. Казандагы һәр сайлау участокларына икешәр-өчәр күзәтүче туры килә иде.

Татарстанның Республика партиясе халыкның тормыш дәрәҗәсе начарая баруга, әхлак нормаларының какшый баруына зур борчылу белдереп килде. Партия шулай ук Америка Кушма Штатларының Иракны варварларча бомбага тотуына каршы чыкты, Чечен республикасына карата җинаятьчел гамәлләр кылуы өчен Россия хөкүмәтен тәнкыйтьләде.

Татарстан Республика партиясенең матбугатта басылган «Конституцияне бозуларга юл куймаска!» дигән белдерүе аеруча игътибарга лаек. Анда республика җитәкчелегенең суверенлык турындагы Декларацияне һәм республиканың Төп законы — Конституцияне гамәлгә ашыру белән акрын шөгыльләнүенә борчылу белдерелә, республиканың бәйсезлегенә һәм алга баруына юнәлдерелгән позицияләрдән чигенү булырга тиеш түгеллеге әйтелә.

Партия белдерүеннән берничә өзек китереп үтик:

«Конституциянең беренче статьясында «Татарстан — суверен дәүләт» диелгән. Ә суверенлык ул — мөстәкыйльлек һәм бәйсезлек дигән сүз. Конституцияне бозарга беркемнең дә хакы юк.

Татарстан җитәкчеләренең, бигрәк тә Президентның, шулай ук парламентның, хөкүмәтнең иң әһәмиятле, изге бурычы — үз Конституциябезне тайпылышсыз гамәлгә ашыруга ирешү.

Һичшиксез, Россия белән сөйләшүләр алып барырга, килешүләр төзергә, хезмәттәшлек итәргә һәм дус яшәргә кирәк. Бу — бәхәссез. Ләкин дус, тату яшәү, хезмәттәшлек итү үзеңнең бәйсезлегеңне, мөстәкыйльлегеңне югалту хисабына булырга тиеш түгел. Россия белән Татарстан арасында төзелгән һәм, ихтимал, тө-



*Татарстанның Республикасы партиясе активы утыры*

зeлəчəк килешүлəр тигезлеккə, гаделлеккə корылмаса, Татарстан халкын элеккечə үк бəйлелектə тотуга исəплəнгəн булса, андый килешүлəр чын килешү була алмый, һəм алар халыкларның дуслыгына, татулыгына китермəячəк. Чын дуслык, туганлык бары тик тигез хокуклылар арасында гына булырга мөмкин».

Рүзəл Юсупов Татарстан Республика партиясе рəисе булып 1992—1995 елларда хезмəт куя. Аннары партия дилбегəсен «Шəһри Казан» газетасы мөхəррире Хəлим Гайнуллинга тапшыра. Бераздан Матбугат министры урынбасары итеп билгелəнгəнлектəн, Х.Гайнуллин да бу җəмəгать эшеннəн азат ителде. Һəм ул чагында инде премьер-министр эшеннəн бушаган Мөхəммəт Галлəмович Сабиров Татарстанның Республика партиясен җитəклəргə ризалык бирə. Бу вазифа аңа тапшырыла.

* * *

*«Миңа ректорлар корпусында да шактый күп җəмəгать эшлəре башкарырга насыйп булды,* — дип яза Рүзəл Юсупов. — *«Татарстан Республикасы ха-*



*Татарстанның Республика партиясе председателе Р.А.Юсупов политсовет утырышында партиянең чираттагы бурычларын бəян итə*

*лыклары телләре турында» закон кабул ителгәннән соң, студентларга кайбер фәннәрне татар телендә укыту ихтыяҗы барлыкка килде. Шуны исәпкә алып, Татарстан югары уку йортларының ректорлары советы карамагында татарча укыту һәм татар теленә өйрәнү мәсьәләләре буенча махсус гыйльми-методик совет төзелде. Аның рәисе итеп мине билгеләделәр.*

*90 нчы елларда бу совет татар теленең югары уку йортларындагы статусын күтәрүдә әһәмиятле роль уйнады. Татар теленә өйрәтү һәм татарча укыту өчен уку-укыту әдәбияты сыйфатында югары уку йортлары укытучылары язган дәреслекләргә, уку ярдәмлекләренә, сүзлекләргә, аларны басарга тапшырганчы, шушы советта гыйльми-методик экспертиза уздырыла иде. Гыйльми-методик совет ярдәмендә югары уку йортларында аерым фәннәрне татарча укыту мәсьәләләре буенча фәнни-практик конференцияләр уздырылды. Аларда көн кадагындагы иң мөһим проблемалар тикшерелде. Совет болардан тыш та уку йортларында студентларга татар телен өйрәтү белән бәйләнешле шактый гына бүтән төрле вазифалар да башкарды.*



*Телевидениедә тапшыру вакыты (алып баручы – Э.Хамматова)*

*«Йөкне тарткан атка төйиләр» дигән кебек, җәмәгать эшләрен дә бер үк кешегә күпләп өяләр. Алда билгеләп үткәннәрдән тыш, тагын татар һәм рус телләре белгече, галим һәм педагогика уку йорты җитәкчесе сыйфатында, берничә ел Министрлар Кабинеты карамагындагы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы законны гамәлгә ашыру комитеты эшендә катнашырга туры килде. Бөтендөнья татарлары конгрессының башкарма комитеты члены буларак, мин аның эшенә дә күпмедер өлешемне керттем.*

*Мине, матбугат битләрендә актив чыгыш ясавымны исәпкә алып, «Мәгариф», «Татарстан», «Шәһри Казан», «Мәгърифәт», «Заман», «Фән һәм тел», «Милли мәдәният» газета һәм журналларының редколлегияләре составына керттеләр».*

Ниһаять, Рүзәл Юсуповның тагын бер иҗтимагый эше: 1992 елда Казан педагогика университеты җитәкчелеге инициативасы белән «Татарстан — гарәп илләре» дуслык җәмгыяте оештырылды. Ректор Р.Юсупов аның председателе иде. *«Җәмгыять Татарстан белән гарәп илләре арасында дуслык урнаштыруга һәм ныгытуга хезмәт итеп килде, шактый гына игелекле эшләр башкарылды. Күп башлангычларның инициаторы һәм авторы гарәп теле һәм мәдәниятенең яхшы белгече, бик әйбәт оештыручы Александр Савельевич Михеев иде. Бик үкенечле хәл: ул фани дөньядан иртә китеп барды. Мин аны якты хисләр белән искә алам»,* — дип бәя бирә үзенең кайбер иҗтимагый эшләренә һәм фикердәшләренә Рүзәл Юсупов.

# ЧИТ ҖИРЛӘРНЕ КҮРЕП ГЫЙБРӘТ АЛ

# ЧИТ ҖИРЛӘРНЕ КҮРЕП ГЫЙБРӘТ АЛ

Һәр зыялы кешенең дөньяга карашы киң, эрудициясе бай булырга тиеш. Моның өчен илебезнең төрле почмакларында яшәүче халыкларның, шулай ук чит илләрдә яшәүчеләрнең тормыш-көнкүрешен мөмкин кадәр якыннанрак белеп тору зарур. Югары уку йорты укытучылары өчен бу бигрәк тә мөһим. *«Мин, диссертация яклап, матди яктан бераз гына аякка басып торырлык хәлгә килгәч, вакыт-вакыт чит илләргә чыгып йөри башладым. Һәм тиздән шуны аңладым: минем бу карарым бик дөрес һәм вакытлы булган икән. Берничә илдә булып кайтуга ук, минем күп нәрсәләргә карашым үзгәрде, фикерләрем баеды, күңел офыкларым киңәйде. Минем чит илләргә сәфәр кылуларым җитмешенче еллардан башланды. Элек ике-өч елга бер тапкыр туристлык путёвкасы белән йөрдем. Аннары эш буенча бара башладым, соңгы елларда яңадан, турист булып, шактый еш йөрим»,* — ди Рүзәл Юсупов.

Академик Рүзәл Юсупов — дөньяны айкаган галим. Ул чит илләргә сәяхәтләрен Мисыр, Алжир һәм Төркиядән башлый. Чехословакия, Болгария, Германия, Италия, Франция, Испания, Португалия, Англия, Голландия, Швейцария, Греция, Кипр кебек Европа илләрен йөреп чыга. Көнчыгыш илләреннән Һиндстанда, Малайзиядә, Индонезиядә, Сингапурда, Гарәп Әмирлекләрендә, Иранда, Япониядә, Кытайда, Вьетнамда, шулай ук Америка Кушма Штатларында, Доминикан республикасында, Мексикада, Австралиядә була.

Әлбәттә, дөньяның барлык илләрен йөреп чыгу үзмаксат түгел. Моның өчен акчаң да, вакытың да җитми. Беренчедән, аеруча үзенчәлекле, экзотикалы Һиндстан, Малайзия, Австралия, Доминикан республикасы, Мексика кебек илләрдә, икенчедән, цивилизация нык алга киткән, халыкның тормыш дәрәҗәсе югары булган Япония, Америка Кушма Штатлары, Германия кебек илләрдә, Скандинавия дәүләтләрендә булырга тырышырга кирәк дип саный Рүзәл Юсупов.

Минем бер дус редакторым Франциядән сәяхәттән кайткач, Парижның культура ядкарьләрен, аның искиткеч архитектура корылмаларын бер тапкыр да барып күрмәгән кеше үзен зыялы кеше дип саный алмый, дигән иде. Бу, бәлки, бераз арттырып җибәрүдер. Ләкин болай дип әйтүдә чынбарлык чагыла.

Академик Рүзәл Юсупов, чит илләрдә булуы турында истәлекләр язып, кайберләрен «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан» һәм башка кайбер газеталарда бастырып барды. Аларда халыкка бик аз мәгълүм яки бөтенләй таныш булмаган фактларга да тап буласың.

Берничә язмасында немец халкының тырышлыгына, пөхтәлегенә соклана галим. Чыннан да немецлар Икенче Бөтендөнья сугышында җимерелеп беткән

Германияне, Берлин, Дрезден, Лейпциг кебек хәрабәгә калган тарихи шәһәрләрен 15—20 елда аякка бастырганнар, таланган завод-фабрикаларын тиз арада торгызып эшләтә башлаганнар, халык хуҗалыгының бөтен тармакларын, тормышларын җайга салганнар. Инде 70нче еллар башында ук Германия шәһәрләренең урамнары төзек, чиста, һәркайда тәртип, кибетләрендә азык-төлек тулып ята, һич кенә дә Россиянекеләр белән чагыштырырлык түгел иде. Моның сәбәбе немец халкының югары культурага ия булуында дип саный Р.Юсупов.

Рүзәл Юсуповның, Германиягә барып, ун көн дәвамында ул чакта Мюнхен шәһәрендә урнашкан «Азатлык» радиостанциясендә эшләп кайтуы турында язганы бар. Аны бирегә радиостанциянең Урта Азия, Кавказ халыклары телләрендәге тапшыруларның баш редакторы булып эшләүче Чарльз Карлсон чакырып ала. Профессор Ч.Карлсон моңарчы Казан дәүләт педагогика университеты укытучыларының, шул исәптән ректор Р.Юсуповның дустына әверелгән була. Ул Казанга берничә тапкыр килеп, милләте белән америкалы буларак, студентларга инглиз теленең катлаулы үзенчәлекләрен үзләштерергә ярдәм итә, укытучыларга консультацияләр бирә.

Профессор Чарльз Карлсон үзенең шәхси кунагы Рүзәл Юсуповка «Азатлык» радиостанциясенә кереп йөрү өчен пропуск әзерләп куя. Казан кунагы ул радиодагы татар-башкорт телендәге тапшырулар редакциясе өчен татарларның, аларның телләренең тарихы, Татарстандагы иҗтимагый-сәяси хәл, үзгәртеп коруларның барышы турында берничә тапшыру әзерли. Редакция үтенече буенча Кырым татарларының (аларның лидерлары Мостафа Җәлил катнашуында), шулай ук Себер татарларының (профессор Алишева белән) тормышларына, эшләренә багышлап оештырылган турыдан-туры эфир тапшыруларында катнаша.

Үзләрендә кунакта Казан дәүләт педагогика университеты ректоры, Татарстан парламенты депутаты, Татарстанның Республика партиясе рәисе булуын белеп алгач, Р.Юсуповка рус, казах, украин, үзбәк телләрендәге тапшырулар редакцияләреннән дә мөрәҗәгать итәләр, интервьюлар алалар. Андагы журналистлар белән якыннан аралашу Рүзәл Абдуллаҗанович өчен кызыклы да, файдалы да була.

Бөтен төрки дөньяга яхшы таныш, фаҗигале язмышлы милләттәшләребез кайда гына яшәми безнең! Мюнхен шәһәрендә булганда шундыйларның берсе Гариф Солтан белән очраша Рүзәл Юсупов.

Гариф Солтан — Башкортстанда туып үскән милләттәшебез. Бөек Ватан сугышы алдыннан ул педагогика институтының чит телләр факультетында немец телен өйрәнә. Әмма укуын тәмамламаган килеш фронтка җибәрелә. Гариф Солтан миллионнарча совет солдатларының язмышына дучар була: әсирлеккә төшә. Немец

телен шактый камил белгәнлектән, аны тәрҗемәче итеп эшләтәләр. Ул әсирлектә вакытта шагыйрь Муса Җәлилне һәм аның иптәшләрен дә күреп йөргән, ләкин алар белән «Идел — Урал» легионында булмаган. Сугыш беткәч, Америка Кушма Штатларына китеп, анда университет тәмамлаган, төрле җаваплы эшләр башкарган, соңыннан Германиягә килеп, Мюнхенда «Азатлык» радиостанциясендә эшли башлаган.

Сугышта әсирлеккә төшкән һәркемгә кара тамга тагылып килде. Сәбәпләрен тикшереп-нитеп тормыйча, туган илләренә кайтуга, һәркайсын 25 елга төрмәгә утырта тордылар. Моны яхшы белгәнлектән, шактый кешеләр, туган якларын бик сагынсалар да, чит илләрдә калдылар. Гариф Солтан — зур эрудицияле, күп телләр белгән, үз милләтенең патриоты буларак, гомере буе татар халкының тигез хокуклы, бәхетле тормышы өчен көрәшеп, абруйлы халыкара оешмаларда, мәгълүмат чараларында татарларны яклап чыгышлар ясаган, китаплар язган олуг шәхес, бөтен гомерен үз халкының мәнфәгатьләрен ялауга багышлаган милләттәшебез.

Рүзәл Юсупов Гариф Солтан белән «Азатлык» радиосында эшләүче Фәридә ханым фатирында очраша. Ул аның хәтерендә бик зыялы, тәрбияле кеше буларак калган. *«Төрле темаларга сөйләшеп утырдык. Татарстан белән бик кызыксынды, туган ягын сагынуын, Казанга кайтып килергә теләге зур булуын әйтте. Ләкин Россия хакимияте ияләренең аны ачык күңел белән кабул итүләренә шиге бар иде булса кирәк»,* — ди Рүзәл.

Гариф Солтан вафат инде. Бөтен гомерен татар халкының матур киләчәге өчен үзен аямыйча көрәшеп тә, туган якларын кайтып күрә алмыйча, якты дөньядан китеп барган бу олуг шәхес. Исеме тарихта сакланырга лаеклы шәхес ул. Бәлки, аның турында якын киләчәктә китаплар язылыр, нәфис фильмнар төшерелер, спектакльләр куелыр. Милләттәшләребез бу изге эшләрне, һичшиксез, башкарырга тиеш.

Англиядә, аның башкаласы Лондонда булуы турында да кызыклы истәлекләре бар Р.Юсуповның. *«Лондонда, утрауда урнашкан дәүләтнең башкаласы буларак, җирләре зур булмаса да, уннарча бик иркен ял парклары бар. Шәһәрдә гомумән яшеллек күп. Лондон өстеннән самолётта узганда, шәһәр зур урман эчендә урнашкан кебек. Парклары — чыннан да халыкның ял итү урыны: кешеләр чирәм өстенә иркенләп утырып, ятып ял итәләр. Ләкин үзләреннән соң бер бөртек тә чүп калдырмыйлар. Парклар да, скверлар да, урамнар да чип-чиста. Һәркайда газон, чәчәк. Өйләрнең тәрәзә төпләрендә урам ягыннан чүлмәкле гөлләр асылынып тора. Гөл, чәчәк һәркайда: өйгә кергәндә, подъездда да, хәтта бензин салу станцияләрендә дә. Хәер, бу — Көнбатыш илләре өчен хас, гомуми күренеш. Мин*

*булган илләрнең барысында да — Германиядә, Испаниядә, Франциядә, Голландиядә һәм башка илләрдә дә — шулай гөл-чәчәк эчендә яшәргә тырышалар».*

Р.Юсупов Лондонга Казан педагогика университетының гарәп теле укытучысы Александр Михеев, инглиз теле укытучысы Наилә Бикбулатова белән бергә бара. Казан кунакларын Лондонда татар халкының күренекле улы, талантлы шагыйрь, зур белемле милләттәшебез Равил Бохараев каршы ала. Равил Бохараев күпчелек вакытын алар белән бергә үткәрә, төрле оештыру мәсьәләрен хәл итүдә ярдәм итә, шәһәрнең тарихи урыннарын күрсәтеп йөри.

Равил Бохараев Лондондагы Би-би-си радиосында Рүзәл Юсуповтан интервью алуны оештыра. Бөтен дөнья өчен эшли торган бу искиткеч зур радиостанция эфирга дистәләрчә телләрдә, шул исәптән рус телендә дә, тапшырулар бирә икән. Р. Бохараев әлеге радио белән озак еллар дәвамында хезмәттәшлек иткән. Эфирга Россия, Татарстан турында күп материаллар әзерләп биргән. Р.Юсупов Лондонда хезмәт өчен түләүнең бик югары булуына гаҗәпләнеп кайткан. Радиодан биш минутлык интервью өчен, безнең акчага күчереп исәпләгәндә, аның бер айлык ректорлык хезмәт хакы күләмендә гонорар түләгәннәр. Татарстан радио-телевидение каналларының күпчелеге исә авторларына гонорар түләп мәшәкатьләнмиләр.

Р.Бохараев турында сүз чыккач, шунысын да искәртеп үтү урынлы булыр: таныш-белешләремнең һәркайсы, Англиягә барып кайтса, Бохараевның ярдәме хакында сөйләми калмый иде. Милләттәшләренә, кешеләргә булышлык күрсәтү өчен яратылган зат, дип бәялиләр иде аны. Академик Әбрар абый Кәримуллинның шундый бер хәл турында сөйләгәне исемдә. Ул Лондонга килеп төшә. Алдан килешү буенча аэропортта аны Р.Бохараев каршы ала. Машинага утырып аэропорттан шәһәргә кузгалгач кына, Әбрар абый юлга дип әзерләп куйган акчасын өендә калдыруын сизеп ала. Бу хакта ул бик уңайсызланып кына Равилгә җиткерә. «Акча була да, бетә дә. Баш исән булсын», — ди Р.Бохараев тыныч кына. Аерылышканда Ә.Кәримуллин чыгымнар турында сүз кузгаткач, Равил кул гына селти: «Безнең сөйләшеп өлгерергә кирәкле мөһимрәк мәсьәләләребез дә житәрлек бит», — ди. Бик үкенечле, күркәм милләттәшебез Равил Бохараев арабыздан иртә китеп барды...

Лондонның яшеллеккә төренгән бер бик матур районында 1924 елда салынган Әхмәди мәчете эшли. Мәчетнең ишегалдындагы һәм тирә-юнендәге икешәр-өчәр катлы биналарда Бөтендөнья «Әхмәди» ислам җәмгыятенең офисы һәм торак йортлары урнашкан. *«Безгә, Равил Бохараев ярдәмендә, Әхмәди тарафдарлары белән якыннан танышып, аларның тормышы, тарихлары һәм яшәү рәвеше хакында шактый күп нәрсәләр белергә насыйп булды. Әхмәдичеләр җәмгыяте — Римдагы Ватикан кебегрәк оешма. Аларның үзләренең куәтле теле-радиостанцияләре*

*эшли, күпсанлы дини һәм дөньяви китаплар бастыралар. Бу җәмгыятьнең үз газета-журналлары да чыга.*

*Әхмәдичеләр ниндидер дини экстремистлар түгел (бездә хәзер рәсми карашка туры килми торган һәр фикер иясен шундый исем белән атау гадәткә керде). Алар — гадәти ислам тарафдарлары. Тик алар бозылмаган, чын исламны яклыйлар, дин кабыгына төренеп, асылда Коръәннең катгый кануннарына туры килми торган гамәлләр кылып йөргән кешеләрне тәнкыйтьлиләр. Алар, мәсәлән, кайбер мөселманнарның зур байлыклар туплавын, гаять зур зиннәтле сарайлар төзү белән мавыгуын хупламыйлар, Коръәнгә каршы килә торган, димәк, әхлаксызлыкка китерә торган гамәлләр кылган кешеләрне өнәмиләр», —* дип яза Р.Юсупов.

Әхмәдичеләр җәмгыяте 12 миллионнан артык кешене берләштерә. Аның дөньяның 127 илендә оешмалары бар. Әхмәдичеләр идеяләрен яклаучылар саны елдан-ел арта бара. Мөгаен, моның төп сәбәбен әлеге җәмгыятьнең кешелекле, гадел булуындадыр дип исәпләргә кирәк. «Әхмәди»нең бөтен тәгълиматы, яшәеше, аның тарафдарларының кылган гамәлләре игелеклелек белән сугарылган. Җәмгыять составындагы бер генә кешенең дә башкаларга зыян салырга бернинди хокукы юк. Салмыйлар да.

Дөньяның төрле төбәкләрендә кан коюлы сугышлар өзлексез дәвам итә. Меңнәрчә кешеләр җәфа чигә, вафат була. Әхмәди җәмгыяте башлыгы Хозур хәзрәт Мирза Таһир Әхмәт Лондондагы штабында Рүзәл Юсупов һәм Казаннан килгән иптәшләре белән әңгәмәсендә кан коюлы сугышлар турында бик борчылып сөйли. Мең бәла белән ут астыннан чыккан илле Босния мөселманын үзләренә сыендырганнар. Шул ук вакытта Хозур сугыш нәтиҗәсендә ятим калган Босния балаларын, нинди милләттән булуларына карамастан, үзләренә тәрбиягә алган.

*«Хозур безнең белән өч тапкыр очрашып әңгәмә корды. Әңгәмә радио һәм телевидение эфирында тапшырылып барды. Шулай итеп, ул безгә, Татарстан вәкилләренә, зур хөрмәт күрсәтте, —* ди Рүзәл. *— Хозур — ул шундый шәхес: аның белән очрашу өчен Лондонга дөньяның төрле почмакларыннан киләләр, аның янына зур дәрәҗәле кешеләр — күренекле дәүләт эшлеклеләре, хәтта кайбер дәүләтләрнең президентлары, корольләре, премьер-министрлары килә. Гади дин әһелләре, аны күрү өчен, берничәшәр көн көтеп торалар икән. Хозур — мәһабәт, күркәм, зур белемле кеше. Ул берничә чит тел белә, буш вакытларында поэзия белән шөгыльләнә, күп укый».*

Хозур Әхмәт Казаннан килгән кунаклар белән ашыкмыйча, вакытын кызганмыйча, иркенләп сөйләшеп утыра. Әңгәмәләр төрле темаларга, шул исәптән диннең торышы, мөселманнарның тормыш-көнкүреше, Россиядә соңгы вакытларда

барган сәяси вакыйгалар хакында була. Әңгәмәләрдән Хозурның Россиядәге хәлләрне белүе ачыклана. Ул ислам дине кануннарын бездәге кайбер дин әһелләре кебек формаль гына сакламый, бәлки дингә чын күңеленнән ышана һәм башкалардан да шуны таләп итә.

Хозур соңгы елларда Татарстанда мәчетләрнең күп төзелүеннән дә хәбәрдар икән. Дингә игътибар артуны яхшы күренеш дип саный ул, әлбәттә. Әмма мәчетләргә халыкның бик аз йөрүеннән канәгать түгеллеген әйтә. «Мәчет булмаска да мөмкин, мәчеттән башка урында да намаз укырга була. Иң әһәмиятлесе: кешеләр инансыннар, ислам кануннарын сакласыннар, табынсыннар», — ди ул.

Шунысы бераз сәер: ислам диненә, кешеләргә игелек кылуга багышлап зур эшләр эшләгән бөтендөнья «Әхмәди» җәмгыяте турында Татарстанда бөтенләй диярлек белмиләр. Бу җәмгыятьнең тарихына, бүгенге эшенә багышланган китаплар чыгарып, аны милләттәшләребез арасында тарату изге гамәл булыр иде. Республика мөфтияте бөтендөнья «Әхмәди» җәмгыяте башлыгы Хозурны Татарстанга эш сәфәре белән чакырса, бу ике як өчен дә файдалы булыр. Хозур әфәнде татарларның кемнәр икәнлеген үз күзләре белән күреп китәр иде.

Төркиягә барып кайту хәзер Мәскәүгә барып кайту белән бер чама. Уңайлы. Безнең халык анда нигездә ял итәргә йөри. Культура багланышлары да ныгый бара, әлбәттә.

Рүзәл Юсуповка да анда берничә мәртәбә булырга туры килә. Күбрәк эшлекле сәфәрләр кылып. Шундыйларның берсе аның өчен аеруча истәлекле була.

Татарстан парламенты дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул иткәннән соң, Төркия дәүләте җитәкчелеге Татарстанга мөстәкыйль дәүләт кебегрәк итеп карый башлый. Һәм менә Төркия парламенты Рүзәл Юсуповны, Югары Совет депутаты һәм милли мәсьәләләр комиссиясе председателе буларак, үзләренең иң зур бәйрәмнәре — Республика көне тантаналарында катнашырга чакыра. Анда элекке союздаш республикалар — хәзерге мөстәкыйль Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан дәүләтләреннән парламент членнары да килә.

Бәйрәм тамашалары бик зурдан, бик тантаналы була, әлбәттә. Элекке СССРдан чыккан мөстәкыйль дәүләтләр вәкилләре Төркия республикасы көненә багышлап уздырылган тантаналы утырышта, аннары хөкүмәтнең кабул итү мәҗлесендә катнашалар.

Табигый ки, алар өчен, андый нәрсәләрне күрмәгән кешеләр өчен, мондый тамашалар бик мәһабәт, гаҗәеп күренешләр була. Ләкин Рүзәл Юсупов өчен аеруча әһәмиятлесе Төркиянең премьер-министры (соңыннан ул Президент була) Сөләйман Демирелнең чит ил кунаклары, журналистлар өчен оештырылган пресс-конференциясендә катнашу була.

Сөләйман Демирел урта яшьләрдәге, зур пеләш башлы, акыллы (бераз хәйләкәррәк) карашлы, зирәк кеше булып күренә. Ул инде җитди генә җитәкче эшләрдә эшләп өлгергән көчле сәясәтче була.

Сорау-җаваплар төрле темаларга, бигрәк тә соңгы вакытларда дөньядагы сәяси вакыйгалар, шул исәптән Россиядәге хәлләр турында да бара. Рүзәл үзе өчен бик тә әһәмиятле соравын бирә: «Хөрмәтле премьер-министр әфәнде, Төркия дәүләте Татарстанның дәүләт суверенитетын танырга җыенмыймы әле?» Сөләйман Демирел аңа карап хәйләкәр генә елмая да: «Сабыр итегез, Рүзәл бәй», — ди. Аңлашыла: Төркия ул чагында (һәм хәзер дә) Татарстан өчен Россия белән мөнәсәбәтләрен кискенләштерергә теләми.

Рүзәл Абдуллаҗановичның Төркиягә ул баруында булган тагын бер гыйбрәтле хәл.

Аларны, төрле республикаларның парламент членнарын, самолётка утыртып, Кипрга — аның төрекләр яшәгән өлешенә алып китәләр. Анда ул чагында Төркиянең сәяси тормышында дәрәҗәсе буенча икенче урында торган Ана-ватан партиясе съезды буласы, һәм элекке Союз кунаклары шунда катнашырга тиеш икән.

Кипрның төрек өлеше (Төрек Кипры дип әйтү уңайлырак һәм дөресрәк булыр) аерым дәүләт дип атала гына, чынлыкта ул Төркиянең бер өлеше кебек. Хәлбуки, рәсми статусы буенча ул — үзенә бер кечкенә генә мәмләкәт, аның бөтен дәүләт атрибутлары бар. Шулай да кунаклар самолётка, таможня процедураларын узып тормыйча, җиңел генә утырып китәләр. Төрек Кипрының халкы — саф төрекләр, әлбәттә. Территориясендә берничә урында төрек гаскәрләре гарнизоннары урнашкан.

Төрек Кипры, Төркиядән башка, бер дәүләт тарафыннан да танылмаган. Элекке СССРның парламент депутатларын — ул чагында инде бәйсезлек алган төрки дәүләтләр вәкилләрен (шулар арасына, янәсе, суверен Татарстан вәкиле булып Рүзәл Юсупов та кереп кала) — Ана-ватан партиясе чарасында катнаштыру өчен Кипрга чакыруның да сәяси эчтәлеге була: янәсе, яңа мөстәкыйльлек алган төрки республикалар Төрек Кипрын таныйлар.

Депутатлар анда өч көн булып, конференция эшендә катнашалар, Кипр буйлап сәяхәт кылалар. Конференция барышында Р.Юсуповка партия председателе Масүт Йылмас белән (соңрак ул бер срок Төркиянең премьер-министры булып тора) берничә мәртәбә әңгәмә корып утырырга туры килә. «Күркәм кеше булып исемдә калды», — ди Р.Юсупов аның турында.

Р.Юсупов конференциядә Татарстандагы хәлләр турында төрекчә чыгыш ясый. Кызыксынып тыңлыйлар. Аннары докладчыга истәлекле сувенирлар бүләк итәләр.

Ул конференциядә төрки дөньяда мәгълүм зат — Төркиядәге Мәрмәр универ-

ситетының татар профессоры Надир Дәүләт тә катнаша. Соңыннан ул күп тапкырлар Казанга килеп йөри, Татарстан белән әһәмиятле мөнәсәбәтләрдә тора. Соңрак аны Татарстан Фәннәр академиясенең почётлы члены итеп сайлыйлар.

Ул чагында Төрек Кипрындагы абруйлы Америка университетында Татарстан кызы Зөлфия Бәйрәмова (Кадырова) укый. Ул, әлбәттә, беренче көннән үк Р. Юсуповны эзләп табып, киткәнче, аның тирәсендә була, аңа төрле ярдәмнәр күрсәтә. Уңган, күркәм, белемле кыз.

Соңрак Р.Юсуповка ике тапкыр Кипрның грек өлешендә дә булырга туры килә.

Әйтеп үткәнемчә, академик Рүзәл Юсупов — дөньяны шактый күп гизгән шәхес. Үзе күргән илләр арасында һәрьяктан да башкаларга үрнәк булырлык ил дип Японияне, иң күркәм халык дип японнарны саный. Япониядә булып кайтканнан соң, ул «Мәдәни җомга» газетасында зур гына мәкалә бастырган иде. Мәкаләнең исеме аның идеясен тулысынча ачып бирә: «Кемнәр дөрес яши? Японнар!» Язуына караганда, Рүзәл Юсупов андагы тормышны күреп сокланып йөргән. Японнар — гаять культуралы, искиткеч хезмәт сөючән, югары әхлаклы, әдәпле, тәртипле, инсафлы халык, ди галим. Табигый байлыклары булмый торып та, Япония тормышның иң югары дәрәҗәсенә ирешкән. Җитәкчеләребезнең андагы яшәү, эшләү, җитештерүне оештыру, транспорт, көнкүреш тәртипләреннән уңай үрнәкләрне безнең илгә кабул итеп алмаулары гаҗәпләндерә. Алар японнар тормышындагы өстенлекләрне күрмиләрме, әллә тормышны, эшләрне андагыча оештырырга сәләтле түгелме?!

Япониядә сине һәркайда һәм һәрчак елмаеп, үзенчәлекле итеп баш иеп каршы алалар, анда бер-берсенә тупас эндәшү гадәте юк. Бер җирдә дә чүп, пычрак күрмәссең, хәтта тузан да юк дип әйтергә була. Идеаль чисталык. Егерме миллионнан артык кеше яши, миллионлаган автомобиль йөри торган Токия урамнарында пробкалар юк диярлек, чөнки юллар бик яхшы тәртиптә, икешәр-өчәр катлы. Машина йөртүчеләр культуралы. Шуңа күрә аварияләр юк дәрәҗәсендә. Шәһәр урамнарында һәркайда агачлар, газоннар, чәчәкләр. Япониядә җинаятьчелек бик аз, булганы да японнарның үзләренеке түгел, чит илләрдән килеп эшләүчеләр арасыннан. Халык бик тыйнак, әдәпле, байлык туплау белән мавыкмый. Укучылар бер төрле формада йөри. Балаларны мәктәпкә үз машиналарында озатып кую гадәте юк. Бер тирәдә яшәгән балалар, җыелып, бергә җәяү генә баралар. Өлкәнрәге башкалары өчен җаваплы була. Аларга куркыныч янамый: җинаять күренешләре юк диярлек.

Япония — фән-техника казанышлары буенча да могҗизалар иле!

Рүзәл Юсупов үзенең истәлекләрендә Америка Кушма Штатларында булуы турында яза. Ул анда Вашингтон университеты профессоры чакыруы буенча бара.

Бу университет Вашингтон штатының административ үзәге Сиэтл шәһәрендә урнашкан. Профессор Р.Юсупов университет укытучыларына һәм аспирантларына «Татарстан Республикасында социаль-сәяси хәл» дигән темага лекция укый. Кызыксынып тыңлыйлар, сораулар бирәләр.

Сиэтл уртача зурлыктагы шәһәр булса да, андагы кешеләрнең күбесе үз йортларында тора. Бездәге кебек өчәр-дүртәр катлы коттеджлар түгел. Өч-дүрт, дүртбиш бүлмәле, ике катлы гади генә йортлар. Өй янында кечерәк кенә бакча, агачлар, чәчәкләр... Чит илләрдә, гомумән, бездәге кебек зурдан кубу, зиннәтлелек белән башкаларны шаккатырырга тырышу күренеше юк. Чама хисен саклыйлар.

Р.Юсупов биредә милләттәшләребезне дә очрата. Башта Кытайда, аннары Япониядә яшәп, ниһаять, Америкага килеп төпләнгән данлыклы Акчуриннар нәселеннән булган бер гаилә белән таныша. Үз йортларында матур гына яшәп яталар. Йорт янында бакчалары, аккошлар йөзеп йөри торган бассейннары бар.

Шәһәр буйлап сәяхәт кылып йөргәндә, бер кафеда эшләүче ике хатын-кызның татарча сөйләшүен ишетеп ала Рүзәл Абдуллаҗанович. Ул да алар белән татарча исәнләшә. Гаҗәпләнәләр дә, куаналар да тегеләр. Тиз генә ирләрен чакырып алалар. Кич, эшләре беткәч, галимне үзләренә кунакка чакыралар. Төп хуҗа Фәндүснең язмышы нәкъ Рудольф Нуриевныкы кебек икән. Фәндүс Пермь өлкәсеннән. Хореография училищесында укып белем алгач, Пермь дәүләт җыр-бию ансамблендә эшләгән. Армиядә хезмәт итеп кайткач та, эшен шунда дәвам иттерә. Бервакыт ансамбль Америкага гастрольгә китеп бара. Концертлар куеп йөри торгач, Сиэтл шәһәренә килеп чыгалар. Ул арада инде боларның кире Россиягә кайтыр вакытлары да җиткән була.

Фәндүснең башында авантюристик план барлыкка килә. Ул, группасыннан аерылып, Сиэтлда кала. Күрәсең, бик тәвәккәл кеше була егет. Бөтенләй тел белмәгән килеш берүзең генә чит илдә кал әле син! Тәвәккәл таш яра, ди. Шунда яшәгән рус кешеләре белән танышып, тормыш корып җибәрә. Тел дә өйрәнә, эш тә, торыр урын да юнәтә һәм тиздән Пермьнән хатыны белән баласын да алдырта. Бераздан ире, балалары белән хатынының сеңлесе дә килеп төшә. Шулай итеп, Сиэтлда кечкенә генә татар диаспорасы барлыкка килә.

Татарлар дөньяның кайсы почмагында яшәсәләр дә югалып калмыйлар. Фәндүс үз кафесын ачып җибәрә. Хатыны белән аның сеңлесе шунда эшли. Үзе тагын икенче бер урынга эшкә урнаша. Фатир сатып алалар. Балаларын дәүләт бушлай инглиз теленә өйрәтә. Көн саен автобус белән килеп, мәктәпкә алып китәләр, кайтарып куялар.

Билгеле, туган җирендә туганнары, дус-ишләре янында тормыш бик рәхәт булса, берәү дә читкә китеп бармас иде. Җитәкчеләргә «Ни өчен халкыбыз эмигра-

циягә күп китә?» дигән сорауны ешрак куеп, бу хакта ныклабрак уйланырга кирәк.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтик: бүген кайсы илдә нинди күренекле милләттәшләребезнең яшәве хакында мәгълүматлар бик аз. Моны барлау белән махсус шөгыльләнүче аерым оешмалар да, махсус кешеләр дә юк.

Рүзәл Юсупов язмаларында шундый бер эпизод тасвирлана: «Австралиядән кире кайтканда, Сидней аэропортында самолёт көтеп утырабыз. Минем бер коллегам белән сөйләшеп утыруымны күреп, безнең янга шактый өлкән яшьтәге бер абзый килеп утырды. «Сез Россиядәнме, Мәскәүгә кайтасызмы?» — дип сүз башлады русча. Без уңай җавап биргәч, сөйләп китте. Шул ачыкланды: моны, ялгыз бабасын, оныгы Мәскәүдән үз янына алдырган. Австралия дәүләте берүзенә ике бүлмәле фатир биргән, зур суммада пенсия билгеләгән. Ләкин бабай чит җиргә ияләнә алмаган. Ватанын бик сагынып, яшәү өчен рәхәт илне ташлап кайтып китәргә карар кылган. «Нишлим мин берүзем ике бүлмәле фатирда, нигә миңа шуның кадәр пенсия? — дип сукрана абзый. — Сөйләшергә кеше юк, урамда эт тә күрмисең, ишегалларыннан чыгармыйлар...» Абзый сөйләшергә шулкадәр сусаган булган, самолётта кайтып җиткәнче, әле беребез, әле икенчебез белән бертуктаусыз гәпләшеп барды. Ә юл ерак, 24 сәгатьлек иде».

Күренекле галимебез Әбрар Кәримуллин Кытайның Хайлар, Харбин, Мукден, Даирен, Шанхай, Тян-Өзинь шәһәрләрендәге, Кореядәге, Япониядәге татарлар турында бай материаллар туплап калдырды. Ул әйткәнчә, афәт җилләре татар баласын кайларга гына илтеп ташламаган да нинди генә газапларга салмаган. Шулай да хезмәт сөючән, намуслы татар халкы вәкилләре бервакытта да югалып калмаган, үзләрен бары яхшы яктан гына күрсәткән, телләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен саклап калганнар. Мәчетләр салганнар, мәктәпләр ачканнар, сәүдә иткәннәр, газета-журналлар чыгарганнар.

Ректор булып эшләгән чорда Рүзәл Юсупов Кытайда ике тапкыр була. Икесендә дә университет эшләре белән.

Беренче тапкыр, ике проректор белән бергә, Кытайның иң көньягында, Вьетнам чигендә, Гуанси провинциясенең Гуйлинь шәһәрендә, андагы педагогика университеты ректоры чакыруы буенча булалар.

Гуйлинь педагогика университеты Кытайның иң зур һәм абруйлы югары уку йортларыннан санала. Казан кунаклары анда үзебез өчен уңай үрнәк алырлык нәрсәләрне шактый күп күрәләр.

Беренчедән, университет, зур территориягә урнашып, койма белән әйләндереп алынган үзенә күрә бер посёлок кебек. Анда уңышлы уку һәм укыту өчен кирәкле бөтен нәрсә дә (инфраструктура) бар. Уку бикалары, спорт мәйданчыклары, студентлар өчен тулай тораклар, укытучылар өчен квартиралар, ашханә, кибетләр һәм

башка нәрсәләр. Гомумән, Кытайның барлык уку йортлары да, башка күп илләрдәге мәктәпләр һәм югары уку йортлары да нигездә аерым посёлок рәвешендә корылган: яшәү, уку-укыту процессына бәйләнгән эшләрне башкару өчен кирәкле барлык нәрсәләр дә шунда, бер урында тупланган. Бу бик уңайлы, акыл белән эшләнгән.

Кунаклар университет капкасыннан кереп ректоратка таба барганда, бер бинаның ачык тәрзәләреннән «Катюша»ны җырлауларын ишетәләр. Гаҗәпләнеп, елмаеп куялар. Баксаң, студентлар моны алар килешкә махсус оештырганнар икән. Кунакларның күңелләре була, әлбәттә.

Соңрак шул ачыклана: Гуйлинь педагогика университетында барлык студентларга да башлангыч музыка белеме бирелә икән. Рүзәл Абдуллаҗановичка бу бик ошый, һәм, кайткач, тиздән Казан педуниверситетының бөтен факультетларында да «Музыкаль тәрбия нигезләре» дигән курс укыта башлыйлар: һәр студент берәр төрле музыка коралында уйный белергә, музыка нотасын аңларга һәм хорда җырлый белергә тиеш, дигән таләп куялар. Бу идеяне тормышка ашыру өчен, махсус кафедра оештырыла, музыка кораллары сатып алына, моның өчен өстәмә вакыт та табарга кирәк була. Мәскәүдән министрлыктан җибәрелә торган уку планында мондый курс булмый: Рүзәл Абдуллаҗанович, тәвәккәлләп, үз җаваплылыгына алып эшли боларны.

Соңрак әле тагын, чын укытучы музыка коралында уйный, җырлый белеп кенә калырга түгел, бии дә белергә тиеш, дип, хореография кафедрасы ачалар һәм барлык студентларны да биергә, танцыга өйрәтә башлыйлар. Монысын да (ректор инициативасы белән) үз ихтыярлары, үз белдекләре белән эшлиләр.

Гуйлинь университетында Казан кунакларын бик җылы каршылыйлар һәм зур хөрмәт күрсәтәләр. Уку йортының эчтәлеге, казанышлары, уку процессын оештыру үзенчәлекләре белән якыннан таныштыралар. Бу эшләрне оештыруда университетның уку эшләре бүлеге мөдире Чжань әфәнденең хезмәте зур була. Ул, Казан педуниверситетында педагогика буенча стажировкада булып, андагы уку процессын оештыру тәртибе белән танышып китә. Шунда аның белән якыннан аралашып калган булалар. Русча да ярыйсы гына белә. Казан кунаклары өчен бу уңайлы була: аларның анда яшәүләрен турыдан-туры Чжань әфәнде оештыра һәм аларны һәр җирдә озатып йөри.

Казанлыларны гаҗәпләндерерлек нәрсәләр шактый күп була монда. Мәсәлән, Татарстанда информатика техникасы әле керә генә башлаган, Китайда инде аны киң кулланалар. Университет посёлогында берничә спорт мәйданчыгы бар, физкультура дәресләрен шунда гына уздыралар. Ә Казан педуниверситетында андый мөмкинлек юк: студентларны физкультура дәресенә төп укыган биналарыннан әллә кайларга йөртергә мәҗбүр булалар.

Әлбәттә, Казанда да укытуны, фәнни эшләрне оештыруда һәм башка өлкәләрдә уңай яклар, казанышлар һичшиксез бар. Ике якның да уңай тәҗрибәсен исәпкә алып, Гуйлинь педагогика университеты белән Казан педагогика университеты арасында студентлар, укытучылар алмашу, аспирантурада укыту һәм башка мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлек килешүе (договор) төзиләр.

Кытайның көньягында, Вьетнам чигендә, табигать бик матур һәм үзенчәлекле: андагы кебек зур чүмәлә рәвешендәге таулар тагын башка берәр җирдә бармы икән; таулар арасыннан агып килә торган чиста сулы сай елгалар; Гуйлиньнан ерак түгел гаҗәеп бер мәгарә бар, үзе матур, үзе зур, эчендә шундый күл бар, хәтта коенырга һәм көймәдә йөрергә мөмкин.

Гуйлинь тирәсендә ялпак төпле теплоходта елга буйлап сәяхәт кылганда, бер кызык күренешкә тап булалар. Елга буенда чирәм чүпләп йөргән буйволлар вакыт-вакыт елгага кереп китәләр дә суга чумалар. Шактый гына торгач, авызларына бер тотам суүсем эләктереп, аны яр буена алып чыгып, җайлап кына ашыйлар. Ашап бетергәч, тагын кереп китәләр...

Икенче тапкыр Рүзәл Юсупов Кытайга Пекиндагы чит телләр институты чакыруы буенча, аларның вузы белән Казан педуниверситеты арасында студентларның стажировкаларын оештыру турында договор төзергә бара. Беренче баруыннан алты-җиде ел гына узуга карамастан, Кытайда уңай якка зур үзгәрешләр булып өлгергән. Бигрәк тә Пекинда яңалыклар күп була.

Пекинның чит телләр институтында рус теле факультеты, Казан педагогика университетында чит телләр факультеты бар. Бу факультетта Р.Юсуповның ректорлыгы чорында Көнчыгыш телләре, шул исәптән кытай теле өйрәтә башлыйлар. Чит телләрне ныграк үзләштерү өчен, ул телләрнең ияләре яшәгән илдә берникадәр торып, укып, өйрәнеп кайту мәгъкуль. Шуны истә тотып, Казан педуниверситеты, кытай студентларын рус теленә өйрәтү өчен, аларга бер еллык стажировка оештыра; Пекин институты исә безнең студентларны кытай теленә өйрәтү өчен, шул ук срок белән үзләрендә стажировка оештыра башлый.

Бу система белән эшләү әйбәт нәтиҗәләр бирә. Казан педагигика университеты студентлары, инглиз һәм тагын берәр европа теленнән тыш, кытай телен дә ярыйсы ук өйрәнеп чыгалар, һәм кайберләре хәзер уңышлы гына Кытайда яшәп эшли.

Кытай халкының тырышлыгы һәркемгә мәгълүм. Аларның соңгы 30 — 40 елда халык хуҗалыгының һәр тармагында ирешкән уңышлары таң калдыра.

Кытайлыларның гомумән тырыш булуы студентларының укуында да чагыла. Казанда стажировка узганнарының үҗәтләнеп укулары үрнәк булырлык. Ә Кытайның үзендә, Пекин чит телләр институтының рус филологиясе факультетында укы-

ганнарын кунаклар анда баргач күреп китәләр. Анда алар хөрмәтенә рус телендә махсус мини спектакль һәм концерт күрсәтәләр. Шактый әйбәт килеп чыга, рәхмәт төшкерләре!

Пекин институты белән Казан университеты арасында договор төзеп, аңа рәсми рәвештә кул кую процедурасын уздыргач, кунакларны бөек Кытай стенасына алып баралар. Моннан берничә мең ел элек корылган бу могҗиза — кытай халкының бүгенге искиткеч зур казанышларының символы.

Рүзәл Юсуповның экзотикалы илләргә сәяхәтләре турындагы истәлекләреннән өзекләр:

*«Мин булган илләрдән Гарәп Әмирлекләре үзенә бер аерым урында тора. Бу — чүл уртасындагы оазис — әкият иле. Моңа ничек гаҗәпләнмәскә мөмкин: ярты гасыр чамасы вакытта ком чүлендә чәчәк атып утырган дәүләт төзеп кую! Кеше акылы, кеше куллары белән төзелгән могҗиза бу. Бу дәүләтнең уңышларын, зур казанышларын сурәтләп тормыйм: моның хакында хәзер күп сөйлиләр, язалар һәм күрсәтәләр. Безнең ил һәм Татарстан халкы да йөри анда. Тик шуны гына әйтер идем: бу гаҗәеп казанышлар, шактый дәрәҗәдә, дәүләтнең акыллы җитәкчесе — шәех аркасында барлыкка килгән. Дәүләт башлыгына күп нәрсә бәйләнгән: ул акыллы һәм юньле булса, ил чәчәк ата, акылсыз һәм юньсез булса, ил артка кала, халык җәфа чигә.*

*Миндә Малайзиягә, Индонезиягә һәм Сингапурга сәяхәтемнән матур тәэсирләр калды. Бу илләрдә соңгы еллардагы күп кенә уңай үзгәрешләрне күрмәскә мөмкин түгел. Алар югары темплар белән алга бара: җитештерү арта, фән-техника, мәгариф алга китә, халыкның тормыш хәле яхшыра бара.*

*Миңа Малайзиянең башкаласы Куала-Лумпур бик ошады. Соңгы елларда оригиналь архитектуралы матур-матур биналар калкып чыккан. Шәһәр тыныч яши, җинаять, һәлакәтләр сизелми.*

*Мин малайзиялеләрнең киң күңеллелек, миһербанлылык, ягымлылык кебек сыйфатларга ия булуларына игътибар иттем. Отельләрдә, җәмәгать урыннарында елмаеп, якты чырай белән каршы алалар, түбәнчелек белән әдәп саклап эндәшәләр һәм сөйләшәләр. Мин бу милләт кешеләренең үз-үзләрен тотышларында, үзара аралашу рәвешләрендә, сөйләмнәрендә, кием-салымнарында һәм көнкүрешләрендә безнең татарларга хас сыйфатлар күрдем. Телевизордан милли спектакльләрен карап утырганда, сөйләмнәренә бик игътибар итмәсәң, татар спектакле бара икән, дип уйларсың: охшашлык шулкадәр зур. Бик ихтимал: бу халык белән татар халкының телләрендә, яшәү рәвешендә, гореф-гадәтләрендә дә охшашлык бардыр. Халыкларның күп җирләргә күчеп йөрүләре, борынгы төрки кабиләләрнең, һуннарның һәм Үзәк Азиядәге башка халыкларның якыннан*

*аралашуы табигый күренеш бит. Һәрхәлдә, бу халыкларның багланышларын, этнографиясен һәм телләренең үзенчәлекләрен өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерер иде.*

*Гаҗәеп дәүләтләрнең дә иң гаҗәебе ул — Сингапур. Андагы тәртипле, акыллы яшәү турында озак сөйләргә мөмкин. Мин берничә нәрсә хакында гына әйтеп китәм. Башка илләр белән чагыштырганда кыйпылчык кына зурлыктагы бу шәһәр-илдә тормыш дәрәҗәсе бик югары. Моның төп сәбәпләре: дәүләтне идарә итү системасында гаделлек, тәртип һәм нык уйлап эш итү. Анда, бездәге кебек, гади эшче, укытучы, врач — биш-алты, ун-унбиш, иң күбесе унбиш-егерме мең сум, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр исә йөзләрчә мең һәм миллионнарча сум хезмәт хакы алып эшләү күренеше юк. Шуны да искәртеп китим: Япониядә дә, мәсәлән, иң аз алып эшләүче белән иң күп алып эшләүче арасында аерма уртача алты-җиде тапкырдан артмый.*

*Сингапурда законнар, тәртипләр барлык кешеләр өчен, кемнең кем булуына карамастан бертигез кулланыла. Хәер, бу — югары цивилизацияле илләрнең барысында да, шул исәптән Көнбатыш Европа илләрендә һәм Америкада да шулай дип беләм мин. Бу фикерне расларлык, Сингапурда ишеткән бер кызык хәл исемә төште. Англиядән турист булып килгән бер егет Сингапурда җәмәгать урынында, стеналарга сызып, пычратып, хулиганлык кылып йөргән. Чит ил кешесе дип тормаганнар, тотып алып ябып куйганнар һәм тиешле җәзага тартканнар: ничәдер тапкыр (санын тәгаен хәтерләмим) чыбык белән суктырганнар. Англия дәүләте, бу хәлне ишетеп, Сингапур губернаторына зур канәгатьсезлек белдергән: янәсе, хәзерге заманда чит ил гражданына карата нинди кыргыйлык гамәле кылу бу? Губернатор бу рәсми протестка: «Мондый җәза бирү — бездә сез хакимлек иткәндә кертеп калдырылган тәртип ул, һәм без аны әшәкелек эшләгән һәркемгә карата да бертигез кулланабыз», — дип җавап биргән.*

*Сингапурда җәмәгать урыннарындагы, урамнардагы чисталык, тәртип һәм пөхтәлек искиткеч. Анда чүп ташлау гына түгел, төкергән өчен дә ярыйсы ук суммада штраф салалар икән.*

*Сингапур — океан буенда урнашкан, зур портлы матур шәһәр-дәүләт. Фән, мәгариф алга киткән. Халыкның тормышы мул, җитешле. Хезмәт хаклары югары. Әлбәттә, чагыштырмача нindidер проблемалары бардыр, бәлки. Кешеләрне торак белән тәэмин итү цивилизацияле хәл ителә. Социаль ипотека гадел, кешелекле системага корылган: аз хезмәт хакы алып эшләгәннәр квартира өчен өлешчә генә түлиләр яки бөтенләй түләмиләр, уртача алып эшләүчеләргә квартира бик аз гына процент (дүрт-биш процент) белән бирелә, зур хезмәт хакы алучылар өчен кредит алу проценты сигездән артмый. Нәтиҗәдә барлык граж-*

*даннар да уңайлы, яхшы торак белән тәэмин ителгән: яшәргә юньле урыны булмаган кешеләр юк.*

*Сингапурдан, башка күп алдынгы илләрдән дә, безнең ил өчен үрнәк алырлык нәрсәләр күп, һәм алырга кирәк тә. Соңгы вакытларда җитәкчеләрдән анда барып йөрүчеләр ешайды кебек. Әмма бездәге тормышны оештыруда андагы тәртипләр бик күренми әле...*

*Үзәк Америкадагы илләрдән миндә Мексика матур тәэсирләр калдырды. Монда сәяхәт кылучылар өчен кызыклы һәм гыйбрәтле нәрсәләр күп. Мексика — борынгы майя культурасы, өч-дүрт мең еллык пирамидалары, матур милли биюҗырлары, джунглилары белән истәлекле ил. Соңгы елларда аның экономикасы үсә бара. Бай илләрдән саналмаса да, хәерчелек юк. Халык әкренләп тормышын җайга сала.*

*Мине шунысы бигрәк тә кызыксындырды: майя халкында төрки халыклар белән охшашлык шактый нык күзгә ташлана. Галимнәрнең, Беринг бугазы районында кайчандыр Азия материгы Америка материгы белән кушылган булган һәм төрки халыклар белән индеецлар аралашып яшәгән, дип фараз итүе ышандырырлык. Моның бер ачык дәлиле — хәзерге төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, майя һәм башка индеец халыклары телләре белән охшашлык булу.*

*Ял итү өчен, Кариб бассейнында урнашкан Доминикан республикасы бик әйбәт. Миңа анда аеруча нык тәэсир иткән нәрсә — Зәңгәр лагуна (Голубая лагуна). Шул урында американлылар шундый исемдә әйбәт кенә кинофильм төшергәннәр. Табигать искиткеч матур.*

*Доминикан республикасы — зур сынаулар үткән, тормышы яңа җайланып килә торган дәүләтләрнең берсе. Сәяхәт кылу өчен истәлекле урыннар шактый күп. Кешеләре киң күңелле, көләч йөзле. Материаль хәле ярыйсы, үзләрен тәртипле тота белә торган кешеләр барсыннар, үкенмәсләр.*

*Әлбәттә, мин «чит илләрдә бары да ал да гөл» дигән фикердән ерак торам. Аларның да һәркайсының үз проблемалары бардыр. Халыклары бик яхшы яшәгән дәүләтләр дә, күпчелек халкы авыр яшәгән илләр дә бар. Мин булган илләрдән, мәсәлән, Мисырда һәм Һиндстанда ярлы кешеләр күп. Моның объектив та, субъектив та сәбәпләре һичшиксез бар. Бу — сөйләшү өчен үзе бер зур тема.*


*Мин, чит илләргә кылган сәяхәтләремә нәтиҗә ясап, шуны әйтер идем: чит илләргә барып, яхшысыннан да, яманыннан да гыйбрәт алу файдалы».*




*Мисырда*



*Һиндстанда*



*Кытай стенасында*



*Мексикада*





*Татагропромстройның генераль директоры*
*И.М.Закиров белән Япониядә*

*Зөлфия Кадыйр*
*(Халыкара Америка университеты*
*студенткасы) белән (Кипрда)*







*Профессор Чарльз Карлсон белән*
*Германиядә*

*Хозур белән әңгәмә*
*(Лондонда)*





*Лондонда (сулдан беренче — Равил Бохараев)*



*Кретей университеты (Франция) белән Казан педагогика университеты арасында хезмәттәшлек договорына кул кую*



*Пекин университеты ректоры белән әңгәмә*





Майя кабиләсе вәкиле белән (Мексика)




Этна вулканы каршында (Сицилия)



*Доминикан республикасында*



*Зәңгәр лагунада (Доминикана)*



*Мисырда*

# НӘРСӘ УЛ БӘХЕТ ҺӘМ НИЧЕК БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА?

## НӘРСӘ УЛ БӘХЕТ ҺӘМ НИЧЕК БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА?

Узган гасырның шаулаган-гөрләгән туксанынчы еллары әле генә иде кебек. Баксаң, чирек гасыр узып та киткән. Бу чорда инде яңа буын үсеп җитте. Буыннар элемтәсе өзелмәсен өчен, яшьләргә кумирлар, үрнәк булырлык геройлар, яңа җиңүләргә өндәрлек шәхесләр кирәк. Бар безнең андый шәхесләребез. Тик вакыт үтү белән онытылмасыннар гына иде.

Күренекле галим, җәмәгать эшлеклесе Рүзәл Юсупов — менә шундый шәхесләребезнең берсе. Ул бөтен гомерен милләтенә багышлады, халкының якты киләчәге турында хыялланып, татарларның телен, мәдәниятен саклап үстерү өчен үзен аямыйча яшәде. Р.Юсупов фәнни эшенең төп юнәлеше итеп туган тел, аның башка телләр белән бәйләнеше, тәрҗемә, сөйләм культурасы мәсьәләләрен сайлап алды. Гомере буе шул проблемалар белән шөгыльләнүдән туктамады.

«Гыйльми тикшеренүләрнең бер кызыклы ягы бар: үзең кызыксынган өлкә сине тәмам биләп ала, тирәнгәрәк керә барган саен, тармак ишәя, колачлылык киңәя төшә, — дип язды профессор Фоат Галимуллин. — Р.Юсупов белән дә шулай булды. Ул «рус һәм татар телләренең лексик-семантик һәм фразеологик системаларындагы гомумилек һәм үзенчәлек» дигән проблеманы аерып чыгара. Шул темага докторлык диссертациясе дә яклый».

Олыгая барган саен һәркем гомер юлы турында уйлана, аңа анализ ясый. Ул үз алдына «Ничек яшәгәнмен икән?» «Башкаларга игелек күрсәтә алганмынмы, зыян китермәгәнменме икән?» «Мин бәхетле булдыммы?» кебек сораулар куя. Академик Рүзәл Юсупов кылган хезмәтләре өчен тыныч була ала. Чөнки канәгать булырга нигез бар. Әмма көчле җилләргә каршы күкрәк куеп барырга күнеккән кеше бер урында тукталып кала алмый. Рүзәл хәзер дә җиң сызганып эшли. Афәрин! Яшәүнең мәгънәсе һаман хәрәкәттә булуда, иҗтиһат итүдә бит. Үткәннәргә борылып карауның алга барудан тукталмаска ният иткәндә генә мәгънәсе бар.

*«Мин гомумән алганда үземне бәхетле кеше дип саный алам. Хәлбуки, минем тормышымда авыр, драматик, хәтта фаҗигале хәлләр дә, бәхетсезлек күренешләре дә аз булмады. Ләкин мин үземне гомумән алганда бәхетсез дип әйтә алмыйм: сау-сәламәт туганмын, бала һәм яшүсмер чакта туклану начар булу сәбәпле, кайбер авырулар булгаласа да, җитди генә операцияләр кичерсәм дә, Аллага шөкер, чирләшкә булмадым, чагыштырмача сәламәт булып яшәдем. Хәер, булган сәламәтлегемне озак вакытлар югалтмыйча яшәвем шактый дәрәҗәдә үземнән дә торгандыр. Кулдан килгәнчә, дөрес яшәргә тырыштым, азмы-күпме физик эш белән шөгыльләндем, инде сигезенче дистәмне ваклап бетереп килсәм дә һәм җиңел булмаса да, берникадәр физик эшләрне әле дә башкарам. Җәйләрен бакчада булырга, табигатькә чыгарга, су коенырга ты-*

*рышам. Кышын чаңгы шуам. Һәр көнне кичләрен йоклар алдыннан берәр сәгать җәяү йөрим. Яңгыр, кар яуса да, салкын, буран булса да чыкмый калмыйм»,* — дип сөйли Рүзәл Юсупов.

Кешенең бәхете аның тырышлыгына, яшәү рәвешенә, иҗтиһат итә алу сәләтенә нигезләнгән. Мондый сәләт күпчелек кешегә тумыштан ук, ата-анасыннан бирелә. Юсуповлар гаиләсендә дә биш малай ата-анасыннан тиешле тәрбия алып, эшкә өйрәнеп үсә. Мәчет картлары яшенә җитсәләр дә, Рүзәл Абдуллаҗан улының абыйлары да, энеләре дә — барысы да исән, сау-сәламәт, һәркайсының үз гаиләсе, уллары-кызлары, оныклары һәм хәтта оныкларының балалары бар. Туганнар аралашып яшиләр.

«Бәхет» сүзе, аңлатмалы сүзлекләрдә билгеләнгәнчә, тулысынча канәгать булу халәтен һәм хисен, шулай ук уңышка ирешү, җай килү кебек мәгънәләрне аңлата. Сөйләмдә ул, болардан тыш, тагын төрле өстәмә мәгънәләр дә белдерә. Шулай да тормыштан тулысынча канәгать булып яшәгән кешеләр бармы икән бу дөньяда? Мөгаен, юктыр, булса да бик сирәктер. Кеше — табигате белән һәрвакыт һәм бөтен нәрсәдән дә тулы канәгать була алмый торган җан ияседер ул. Диалектика фәне, кешенең, ирешкәненнән генә канәгать булып утырмыйча, һаман да яңадан-яңа нәтиҗәләргә ирешергә омтылуы үсешкә, алга баруга этәргеч ясый, дип тәкрарлый. Димәк, адәм баласының тулысынча канәгать була алмавы халәтенең философик нигезе дә бар кебек. Әмма шулай да кеше, югары акыл иясе буларак, аңлы рәвештә канәгать була, нәфесен тыя да белергә тиештер. Канәгать була белмәгән, үз-үзен кулда тотарга сәләтсез кеше җәмгыять өчен зыянлы гамәлләр кылырга да мөмкин.

Р.Юсуповның «Нәрсә ул бәхет һәм мин бәхетле кешеме?» исемле мәкаләсе бар. *«Үзеңне бәхетле итеп тоя, ягъни тормыштан канәгать була белү — кеше өчен бик әһәмиятле сыйфатларның берсе,* — диелә мәкаләдә. — *Кайбер кешеләр булганына шөкер итеп, ирешкәннәренә шатланып яши белә, кайберәүләр исә бервакытта да бернәрсәдән дә канәгать булмый, аларга һәрвакыт нәрсәдер ошамый, кемнәндер гаеп табалар, нәрсәдәндер зарланалар, сукраналар. Ирешелгән уңышларга, булганына риза булып, шатланып яшәмәүчеләрнең үзләренә дә, тирә-юнендәге кешеләргә дә рәхәт булмый, гел зарланып яшәүчеләрнең үзләренә дә күңелле түгелдер, андый кеше тирә-юнендәгеләр өчен дә кызыклы булмый».*

Тормышта теге кеше бәхетле яшәгән, ә бусы бәхетсез булган, дигән сүзләрне шактый еш ишетергә туры килә. Әмма кеше гомере буе бәхетле яки бәхетсез булган, дип сөйләү чынбарлыкка туры килеп бетми. Әгәр кеше сау-сәламәт туып, җитди авырмыйча, гарипләнмичә яшәсә, аны «бәхетле» дияргә мөмкин. Чөнки сәламәтлек — иң зур бәхет ул. Вакытлыча кыенлыкларны кешенең бәхетсезлеге дип санап булмый. Иң зур бәхетсезлек — зур физик кимчелек белән туу, озак вакытлар җитди авырып яшәү, яки һәлакәткә очрап, гарип булып калу. Дөрес, күп кешеләр сәламәт чакта моның кадерен белмиләр, таза-сау булуның зур бәхет икәнен онытып җибәрәләр.

Рүзәл Юсупов фикеренчә, кешене бәхетле итә торган факторлар күп. Шуларның берсе, барыннан да бигрәк үзеңнән тора торганы — куйган максатыңа ирешү. Кеше, физик һәм акыл ягыннан үсеп, өлгереп җиткәннән соң, үзенә хәленнән килерлек ниндидер максатлар куеп, шуларга ирешә барып, игелекле, файдалы гамәлләр кылырга, иҗат итәргә тырышып яшәргә тиеш. Максатсыз яшәү — мәгънәсез яшәү, буш яшәү югары цивилизацияле кешегә хас күренеш түгел.

Бәхетне күпмедер дәрәҗәдә шартлы төшенчә дип тә санарга мөмкин. Хәтерлим әле, сугыш чорында һәм сугыштан соңгы елларда туйганчы ашау безнең өчен зур бәхет иде. Яңа, матур кием кигән кешене күрсәк тә, аны бәхетле санадык. Кайберәүләр бай кешене бәхетле дип уйлыйлар. Ләкин андый кешеләрнең борчылырлык сәбәпләре күп була. Мәсәлән, алар банкротлыкка чыгудан куркалар. Мөлкәтләренең күпчелек өлеше гадел юл белән табылмаганлыктан, хөкемгә тартылу яки көндәшләре тарафыннан һөҗүмгә дучар булу куркынычы да бар. Яшәвенең мәгънәсен чамасыз байлык артыннан кууда, чиксез байлык туплауда гына күргән кеше бәхетле була алмыйдыр.

*«Әйбәт яшәү, бәхетле булу өчен, тырышлык, һичшиксез, үзеңнән тора торган иң әһәмиятле шартларның берсе,* — дип яза Рүзәл. — *Минем тормышымда азмы-күпме уңышлар, казанышлар булган икән, аларның нигезе үз алдыма максат куеп, бөтен көч-куәтемне сарыф итеп, үземне аямыйча, шул максатка ирешә барып яшәүдә. Шулай яшәү минем гомеремнең төп принцибы булды. Болай эшләү кешедән зур ихтыяр көче, фидакарьлек, аяусызлык һәм хәтта ниндидер мәсьәләләрдә күпмедер дәрәҗәдә үзеңнән корбан да таләп итә. Шул рәвешле үз алдыңа куйган бурычны үтәү үзеңә зур мораль канәгатьләнү, димәк, бәхет китерә».*

Әлбәттә, бәхетең булу-булмауда кайбер очраклылыклар да билгеле дәрәҗәдә роль уйный. Халык телендә ниндидер уңайлы нәтиҗәгә китерерлек очракны «җай чыгу» диләр. Сөйләвенә караганда, Рүзәл Абдуллаҗанович тормышында да була андый очраклар. Шуларның берсе — институт ректоры Мирфатыйх Зәкиевнең эшеннән китеп баруы һәм партия өлкә комитетында ул тәкъдим иткән кандидатура белән килешмәүләре. Нәтиҗәдә ректорлык вазифасына Р.Юсуповка керешергә туры килә.

Билгеле, тормышта ректор булу максатын куеп яшәмәгән Р. Юсупов. Бу урында философиядәге очраклылыкның ихтыяҗга әверелүе кануны чагылыш тапкан. Уйламаганда гына яңа җаваплы эшкә керешергә туры килә профессор Юсуповка. Шулай итеп, моңарчы тупланган тормыш тәҗрибәсен, акыл сәләтен, көчен тулы күләмдә эшкә җигәргә мөмкинлек туа. Хәер, «очраклылык» төшенчәсе бу урында күпмедер дәрәҗәдә шартлылык белән бәйле. Төптән уйлап карасаң, бу бик үк көтелмәгән хәл дә түгелдер. Монда, һичшиксез, Рүзәл Юсуповның элеккеге күркәм эшләренең нәтиҗәләре, табигатендәге, холкындагы уңай сыйфатлары сәбәп булгандыр.

Язмасында Рүзәл Абдуллаҗанович тагын бер очраклылыкны мисал итеп китерә. *«Минем 2007 елда Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты итеп сайланып куелуым — очраклылык, алдан уйлап, ягъни максат куеп кылынган гамәл түгел. Бу вазифаны күренекле галим академик Миркасыйм Усманов башкара иде. Көннәрнең берсендә ул үз теләге белән бу эштән китте, вакансия барлыкка килде. Ул урынга мине тәкъдим иттеләр. Бу, беренче карашка, очраклылык. Ләкин, икенче яктан караганда, бик үк очраклы хәл дә түгел. Моңа минем кылган нәтиҗәле гамәлләрем, фәнни-педагогик, административ, җәмәгать эшемдәге шактый зур тәҗрибәм, уңышларым нигез булгандыр».*

Зур шөһрәтле Казан дәүләт университетында укып, анда күренекле галимнәрдән сабак алуы белән дә үзен бәхетле саный Рүзәл. Бу уку йортында белем алган һәркемгә мәгълүм: университет галимнәренең акыллы сүзләре гомергә хәтердә кала, онытылмый, дөрес яшәргә ярдәм итә.

Күп еллар ректор булып эшләү чорында Р.Юсуповка ил һәм дөнья күләмендә танылган галимнәр, зур җитәкчеләр белән очрашырга, аралашырга, фикерләрен тыңларга туры килә. Мондый бәхет тә, билгеле, һәркемгә туры килми. *«Минем Татарстан парламентында эшләвем гомеремдә зур эз калдырган, истәлекләргә бай чор, гыйбрәтле тормыш мәктәбе булды. Мин анда сәяси яктан өлгердем, халкымның, милләтемнең азатлыгы, мөстәкыйльлеге өчен көрәшче сыйфатларын үзләштердем. Югары Советның даими комиссиясе рәисе, президиум әгъзасы буларак, миңа республикабазның күп кенә абруйлы кешеләре, җитәкчеләре белән якыннан аралашырга, хезмәттәшлек итәргә насыйп булды,* — дип искә ала ул елларны Рүзәл Юсупов. — *Әлбәттә, барыннан да бигрәк, башта Югары Совет рәисе, соңрак республика президенты М.Ш.Шәймиев белән шактый якыннан торып эш итәргә туры килде. Ул Татарстан өчен хәлиткеч көннәрдә үзен тәҗрибәле, мәсьәләләрне төптән уйлап хәл итә, сак эш итә торган, зирәк җитәкче итеп танытты, республикада гына түгел, бөтен Россиядә дан казанды. Уңай сыйфатларын күреп, аның зур эшенә тиешле югары бәя бирү белән бергә, мин анда совет чоры җитәкчеләренең күбесенә хас сыйфатларны — үз кул астындагыларга карарын көчләп тагу, кирәк чакта башкалар сүзен тыңлап, фикерен үзгәртә алмау һәм үзенә каршы чыккан кешеләр белән килешеп тора алмау сыйфатларын да күрдем».*

Инде бу китапта әйтелгәнчә, Рүзәл Юсупов белән без үткән гасырның алтмышынчы еллары ахырында Казан телевидение студиясендә бергә эшләдек. Шул чордан бирле аралашып яшибез. Шуңа күрә бер-беребезнең тормышын да, характерларын да шактый яхшы беләбез. Һич тә икеләнмичә әйтә алам: Рүзәл Юсупов гаиләсендә дә бик бәхетле булды. Хатыны Дилара ханым белән тату яшиләр. Кызлары Диләфрүз белән кияүләре Айдарның да тормышлары матур. Акыллы, тырыш оныклары үсеп җитеп килә. Кода-кодагыйлары белән дә даими аралашып, дус яшиләр.

Рүзәл Юсуповның тормыш юлын күздән кичереп, уйланып утырам. Күпме юл үтелгән, никадәр хезмәтләр язылган, күпме кешеләргә игелек кылынган. Һич шикләнми әйтергә мөмкин: галимнең гомере халык өчен, республика өчен намуслы хезмәт итеп узган. Бу юлларны язып утырганда, күренекле якташым, Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәшировның күңелемә уелып калган сүзләре хәтеремә төште: «Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар кырудан саклап, мең еллар буена үстереп килгән, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә китергән».

Рүзәл Юсупов — халыкның менә шушы өлкәдә җиң сызганып, яман җилләргә каршы торып, нәтиҗәле итеп эшләгән вәкиле. Республикада телләр турында законның һәм телләрне үстерү программасының кабул ителүенә инде шактый вакыт үтсә дә, аларны гамәлгә ашыру буенча эш җитәрлек әле. Республиканың премьер-министры урынбасары, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, якташым Марат Әхмәтов та юкка гына шундый юлларны язмаган: «Кытай, фин татарлары татар телендә чип-чиста итеп, безгә караганда күпкә камилрәк сөйләшәләр, югыйсә аларга яши торган илләрендә татар теленең кирәге дә юк кебек. Аларның күңелендә, йөрәгендә утыра ул туган телләре. Әгәр дә без халкыбызга шушы инануны сеңдерә алсак, булганын да югалтмыйча, тормышны ыгы-зыгыларга, дөнья куугa гына әйләндереп калдырмыйча, бөтен кыйммәтләрне саклап кала алырбыз».

Зур тел галиме, олуг шәхес Рүзәл Юсупов киләчәктә дә бу изге бурычны уңышлы үтәүгә үзеннән өлеш кертер, милләтебезне нәтиҗәле хезмәт җәүһәрләре белән куандырыр әле. Ни чәчсәң — шуны урырсың, ди халык. Рүзәл яхшы сыйфатлы орлыклар чәчәргә күнеккән, шунлыктан аның гамәлләре күркәм, иртәгеге көне өметле.

Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы»ндагы герой кебек, Рүзәл Юсуповның үз юлы, үз сукмагы бар. Дөресрәге, ул юлны үзе ярып бара, курыкмыйча, йөкнең авырын күтәрә.

Милләтпәрвәр якташым Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов турындагы язманы университет буенча сабакташы, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның шигъри юллары белән тәмамлыйк:

Артта кала бара
Бик күп еллар.
Күмелмәсме
Безнең узган юллар?
Чал тарих ул
Үзенекен ала.
Һәм аңарда
Безнең эз дә кала...




*Без әнкәйнең биш баласы идек*



*Биш туган*




*Гаиләбезнең түгәрәк чагы. Сулдан уңга: улыбыз Фәнис, хатыным Дилара, Фәниснең хатыны Рәмзия, оныгыбыз Фәридә, Рүзәл, кызыбыз Диләфрүз*



*Шатлыклы мизгелләр*



*Улыбыз Фәнис*



*Кызыбыз Diләфрүз белән*





*Хәрәкәттә — бәрәкәт*



*Кодалар Ирек Закиров белән Рүзәл Юсуповның уртак куанычы — оныклары Ислам*




*Оныкларыбыз – Фәридә, Ислам, Кәрим*



*Кызыбыз Диләфрүз, киявебез Айдар оныкларыбыз Ислам һәм Кәрим белән үз йортлары янында*




*Оныгыбыз Ислам Закиров*



*Оныгыбыз Кәрим Закиров*



*Онығыбыз Фәридә Юсупова —*
*Санкт-Петербург финанс һәм экономика университеты магистры*



# РҮЗӘЛ ЮСУПОВ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР ҺӘМ ФИКЕРЛӘР

## ЯШЬЛЕК ХАТИРӘЛӘРЕ

Без — Рүзәл белән бер авылда туып, бер чишмә суын эчеп, бер партада утырып үскән егетләр. Үсмер чагыбыз авыр сугыш елларына туры килде. Авылда күп йортларда ачлык хөкем сөрә иде. Яз башында — черек бәрәңге, чирәм чыккач — кузгалак, кычыткан, акбаш, акы, сәрдә яфрагы, тагын әллә нинди үләннәр безнең өчен гадәти ашамлык иде. Шушы авырлыкларга карамастан, без, бер көн дә дәрес калдырмыйча, Кышкар мәктәбенә укырга йөрдек.

Беренче сыйныфта ярты ел укыгач, безнең класска Рүзәл Юсупов килеп керде. Тиз арада шул ачыкланды: аның ул вакытта әле укырга керү өчен яше җитмәгән булган. Без, малай-шалай, нәрсәгә ул вакытыннан алда үзенә камыт кидертә икән, дип аптырап калдык. Әмма ул безгә караганда акыллырак та, белемлерәк тә булып чыкты. Без, ярты ел укып, юньләп саный да, укый да белми идек әле. Ул беренче көннән үк безнең өчен үрнәк булып китте.

Югарырак сыйныфларга киткәч, кызык та, кызганыч та хәлләр була торган иде. Математика фәнен үзләштерүдә проблемалар күп булды. Монда Рүзәл барыбыздан да аерылып тора иде. Шундый дәресләр күңелдә уелып калган. Математика укытучысы үткән дәрестә өйрәнгән материалны башта такта янына чыгарып, аннары парта янына баскан килеш барыбыздан сорап чыга. Беребездән дә дөрес җавап ала алмагач, мәсьәләне Рүзәлдән чиштерә һәм үткән теманы сөйләттерә дә, барыбызны да өстәмә дәрескә калдырып, Рүзәлнең үзен генә кайтарып җибәрә торган иде.

Мәктәптән кайткач, бигрәк тә башлангыч классларда, без, өйдә дәрес әзерләү урынына, тизрәк урамга уйнарга ашкынабыз. Бәлки, белемебезнең сай булуы шуның белән дә аңлатылгандыр. Ә Рүзәл буш вакытын әрәм-шәрәм итми, җиң сызганып дәресен әзерли. Үзеңне мәҗбүр итә алу, ихтыяр көченә ия булу кебек сыйфатлар Рүзәлгә ул вакытта ук хас булган, күрәсең. Яшьлегенә карамастан, ул шул вакытта ук, яхшы укырга, белемле кеше булырга дигән максат куя белгән.

Җәйге каникул вакытларында бөтен мәктәп балалары, көчләре җиткәнчә, колхоз эшләрендә катнашалар иде. Рүзәлгә бик җаваплы эш — төнлә ат көтү эшен тапшыралар иде. Ул вакытта бөтен авыл хуҗалыгы эшләре тик атлар ярдәмендә генә башкарылды. Мин хәтерләгәнчә, бөтен Әтнә районына бер комбайн бирәләр, һәм ул Кышкар басуларына бик сирәк килә иде.

Мәктәп җыелышларында Рүзәлнең исеме гел яхшы яктан телгә алынып килде.

Яхшы сыйфатлар беренче чиратта гаиләдә тәрбияләнә, әлбәттә. Рүзәлнең әти-әнисе тәртипле һәм уңган биш егет үстерделәр. Алар безнең авыл кешеләре өчен үрнәк булдылар. Минем әни ике сүзнең берендә: «Әнә Йосыф Габдуллаҗаны малайларыннан үрнәк ал!» — дип әйтә торган иде.

Ата-аналары колхоз эшеннән бушамаганлыктан, өйдәге бөтен эш балалар җилкәсендә булды. Мал-туарны туйдыру ул вакытларда зур проблема иде. Хәзер генә ул колхоз хайван тоткан колхозчыга теләгән кадәр ашлыгын, печәнен, саламын бүлеп бирә. Без үскән заманда, кул арбасына салып, авылдан 5—6 чакрым ераклыктагы кырлардан чүп үләне, сусән, елгалардан камыш чабып ташый идек. Җитмәсә, еш кына бригадир Чапай (Габделбәр), сагалап торып, шулай җәфаланып җыеп алып кайткан печәнне колхоз фермасына бушаттыра иде.

Яз көне бәрәңге бакчасын казырга һәм бәрәңге утыртырга беренчеләрдән булып Рүзәлләр (абыйлары белән) чыга. Аларның бакчалары авылда төрле яктан күренеп тора. Бу хәл — авыл халкы өчен беренче сигнал, һәм бөтен бакчаларда эш кайный башлый.

Авырлыкларга карамастан, уку еллары бик тиз үтеп китте. Җиденче сыйныфны тәмамлап, төрлебез төрле якка таралыштык. Классташлар арасында тик Рүзәл генә бөтен предметлардан имтиханнарны гел «бишле»гә бирде һәм, яхшы укуы аркасында, русча да белмәгән килеш, Казандагы кооперация техникумына барып кереп, аны уңышлы тәмамлады. Безнең Рүзәл белән дуслык бервакытта да өзелеп тормады. Ул техникумда укыган чорда, мин, һөнәр училищесын тәмамлап, авиация заводында эшләдем. Рүзәлнең ул вакытларда матди хәле бик авыр иде. Шуңа күрә мин аңа бераз ярдәм дә итә торган идем. Безнең очрашулар, күңелле әңгәмәләр мин яшәгән тулай торакта уза иде.

Армиядән соң Рүзәл университетта, мин авиация институтында (КАИ) укыдым. Студент еллары да үтеп китте. Без Рүзәл белән атна саен очрашып, киләчәк тормыш турында планнар корып, киңәшләшеп яшәдек. Билгеле, яхшы киңәшләр, акыллы фикерләр күбрәк Рүзәлдән чыга иде.

Университет студенты буларак, Рүзәл икенче курслардан башлап лекторлык вазифасын үти башлады. Ул, лекцияләр укып, Әтнә, Арча районнарының күп кенә авылларын йөреп чыкты. Кышкы каникулның бер көнендә Рүзәлне кичке сәгать җидегә Симетбаш авылына чыгыш ясарга чакырдылар. Симетбаш белән Кышкар арасы өч чакрым. Иптәш итеп Рүзәл мине дә алды. Без, чаңгы киеп, ярты сәгатьтә Симетбаш клубына барып җиттек.

Рүзәл уңышлы чыгыш ясады, алкышлап, рәхмәтләр әйтеп озатып калды аны халык. Бәхетсезлеккә, без кайтырга чыгуга, бик каты буран башланды, һәм без юлдан язып адаштык. Төне буе авылны эзләп, тәмам хәлдән таеп, таң атканда гына Кышкарга кайтып кердек. Бер уйлап карасаң, нәрсәгә кирәк булган болай җәфаланып йөрү Рүзәлгә, җитмәсә әле бушка, бер тиенсезгә. Бөтен хикмәт шунда: ул бөтен тормышын халыкка хезмәт итүгә багышлады, фидакарь зат булды.

Кызганыч, яшь вакытлар бик тиз узып китә икән. Шулай минем өчен көтмәгәндә генә Рүзәл өйләнеп тә куйды. Зур итеп туй ясадылар. Мин хәзер берүзем

калдым. Шулай итеп, миңа да башлы-күзле булырга вакыт җитте. Озак та тормыйча, мин дә үземә ошаган бер кыз таптым, Асия исемле. Кечкенә генә туй ясап (ул вакытта мин дә, Асия да студентлар идек), без дә тормыш итә башладык. Хәзергә кадәр без Рүзәлләр белән дус булып яшибез.

Бүгенге көндә Рүзәл — киң эрудицияле, танылган галим, татар халкы, аның теле, мәдәнияте өчен җанатып йөргән кешеләрнең берсе. Күпсанлы дәүләт бүләкләре, фәнни дәрәҗәләр, мактаулы исемнәр — аның күпьеллык намуслы, фидакарь хезмәте нәтиҗәсе. Киләчәктә дә зур уңышлар насыйп булсын аңа.

**Фоат ГОМӘРОВ,**
ТАССР торак-коммуналь хуҗалыгының
атказанган хезмәткәре

## ЭШТӘ КАЙНАП ҮСТЕК

Абыйның дуслары миңа «Рүзәл Юсупов турында китап чыгарырга уйлыйбыз» дип хәбәр иткәч, аның белән бергә үткән балачак һәм яшүсмер елларыннан бер-ике истәлек язып бирергә булдым.

Без гаиләдә биш малай үстек, Рүзәл абый — уртанчы, мин аннан кечерәге — дүртенчесе.

Безнең авыл яшәү өчен бик уңайлылардан түгел: болыны да, урманы да юк, елгасы да инеш кенә. Кырыс географик шарт сугыш елларындагы һәм аннан соңгы кыен тормышны тагын да катлауландыра иде. Рүзәл абый белән минем яшь арасы якын булганлыктан, авырлыкларны без аның белән бергә кичердек.

Башлангыч классларда укыган чакта ук, без җәй буена, көненә икешәр мәртәбә, кул арбасы белән печән алып кайта идек. Болын, урман булмаганлыктан, бер кул арбасы печән җыеп алу да безнең өчен җиңел эш түгел иде. Ерак басуларга барып, ерганак төпләреннән, тау кырыйларыннан, кырдагы сука тимәгән җирләрдән уч-уч кына чабып җыя идек без аны. Ашлык арасыннан чүп үләне җыеп та тутырырга туры килде арбаны. Колхоз җитәкчеләре шулай җәфаланып тапкан печәнне алып кайтуны да тыялар, шуңа күрә аны өйгә кача-кача гына алып кайта идек. Бер сыерны, ике-өч сарыкны кыш буена туйдырып чыгарга җитәрлек итеп печән әзерләү күбрәк ун яшьләрендәге Рүзәл абый белән минем өскә йөкләнгән иде. Бу бурычны үтәү бездән күп тырышлык таләп итте, җитмәсә, ул вакытта тамак та тук түгел, гел ашыйсы килеп, эч суырып тора.

Көндезләрен һәм кичләрен казан астына ягып, суын кайнатып, әнинең, эштән кайтып, берәр нәрсә пешергәнен көтеп торабыз. «Берәр нәрсә» дигәне гадәттә

бәрәңге яки сепаратордан чыккан (аертылган) сөттән пешерелгән аш була иде. Итмай, күкәй кебек ризыклар зур бәйрәм көннәрендә генә, әле анда да бик аз гына эләгә торган иде.

Ипине бәрәңге кушып салдылар. Ул чи, лыҗырдап тора һәм саф оннан пешерелгән ипидән күпкә тәмсезрәк була иде, әлбәттә. Бер мич ипигә тимерче алачыгында эшләткән ике зур чиләк бәрәңге уабыз. Бу эш Рүзәл абый белән Наил абыйга йөкләнгән була. Наил Рүзәлдән дүрт яшькә олырак булганга, аңа җиңелрәк килгәндер. Әмма Рүзәл абыйга бик кыенга туры килә иде. Аның, бәрәңгене кадак белән тишеп ясалган угычтан уганда, бармаклары умырылып, ертылып бетә иде. Бер атналар узып, бармаклар тазарып кына килгәндә, ипи бетә, яңадан бәрәңге уар вакыт җитә. Гаиләдә кызлар булмаганлыктан, бөтен өй эшләре безнең өстә булды. Ул эшләрнең аеруча истә калганы — идән юу. Хикмәт шунда: ул чакта авылда малайларның идән юу гадәте юк иде, алар безнең идән юганга көлеп карыйлар. Шунлыктан абый белән (ул өй идәнен юса, миңа өйалды белән баскыч эләгә), идән юганда, кеше килеп кереп күрмәсен дип, капканы бикләп куя идек. Без өй эшләренең барысын да диярлек Рүзәл абый белән бергә башкардык.

Тыштагы эшләргә килгәндә, иң истә калганнары — җылы абзардан (кыш көне бик салкын булганда, бозау белән сыер, бәрәннәре белән сарыклар шунда торалар иде) тирес чыгару, бакча казу, бәрәңге утырту, төбенә өю һәм аны алу.

Бура абзардан тирес чыгару иң авыр эшләрнең берсе булгандыр. Тирес кыш буе таптала, куптарып алуы бик авыр — көч җитми. Олырак булгач, абый тиресне сәнәк белән куптарып, мин носилкага төяп торам, аннары аны лапас артына чыгарып, пөхтәләп өеп куябыз.

Ул арада бакча да кибеп җитә, унбиш сутый җирне көрәк белән казып чыгарга кирәк. Бу да безнең өстә: әти белән әни колхоз эшендә, олы абыйлар ул чакта авылдан китеп барганнар иде инде.

Безнең бакча тау кырыенда булганлыктан, һәрвакытта да аны кул белән эшкәртәбез: кул белән казыйбыз, бәрәңгене утыртабыз, кул белән төбенә өябез, казып алабыз. Шул нык истә калган: абый мине эшкә үгетләп-юмалап алып чыга иде, әйдә, энем, күршеләр эшләп бетерәләр, безгә алардан калышырга ярамый, дип. Мин абыйны тыңлыйм, бергәләп тырышып эшлибез һәм бакча эшләрен күршеләргә караганда алданрак тәмамлап куябыз. Әти-әни, Рүзәл абый мине кечкенәдән үк шулай эшкә өйрәтмәгән булса, мин, ихтимал, тормышта зур уңышларга ирешә алмаган булыр идем.

Авылда бөтен эшләр дә ат белән башкарыла иде. Кыш көне кырдан чанага төяп салам ташу, яз җиткәч, колхоз фермасыннан кырга тирес чыгару, җәен, су буеннан вак таш җыеп, юл төзәтү, саман кирпеч сугу, привод («приват» ди идек)

белән ашлык суктыру, басудан әвенгә көлтә ташу, эскерт өю кебек эшләрнең күбесендә (укудан буш вакытларда) Рүзәл абый белән миңа да катнашырга туры килде.

Җәйге каникул вакытында без башкарган колхоз эшләренең берсе — көндезләрен, ә кайчакта төннәрен дә ат көтүе көтү. Кич эштән бушагач, атларны төнге көтүгә чыгаралар. Без бервакыт Рүзәл абый белән төнге ат көтүенә йөрдек. Абый үзен ничек хис иткәндер, әмма мин бик курка идем, чөнки төн караңгы, күреп бетереп булмый, кайчак атлар таралыша, көтүдән качып та киткәлиләр. Ул елларда авыл тирәсенә еш кына бүреләр дә килә иде. Көтүгә колынлы атларны да чыгаралар. Аларга бүреләр ташлану хәлләре дә булгалады.

Менә без шулай Рүзәл абый белән эштә чыныгып үстек.

Бу малайлар, өйдә генә ятмыйча, нигә колхоз эшенә дә йөргәннәр, дигән сорау туарга мөмкин. Ул вакытта колхозда хезмәт көненә эшлиләр иде, әти белән әни эшләгән хезмәт көне биш малайны туйдырырга җитми, шуңа күрә җәйге каникулда, укудан буш башка вакытларда колхоз эшләренә катнашып, безнең гаиләгә тигән хезмәт көненең санын арттыра идек. Ә бу — көз көне ашлык җыеп алгач, һәр хезмәт көненә бүлеп бирелгән арыш яки бодайга ярыйсы гына өстәмә дигән сүз.

Җиде классны тәмамлагач, Рүзәл абый Казанга укырга китте. Бергә уйнап, эшләп үскәнлектән, ул киткәч, күңелсезрәк, авыррак булып калды. Шуңа күрә абыйның кышкы һәм җәйге каникулда авылга кайтуын мин бик көтеп ала идем. Безнең йортка өстәп эшләнгән бик кечкенә генә өебез бар иде. Утын җитмәгәнлектән, аны кунаклар килгәндә генә җылыттык. Рүзәл абыйның кышкы каникулга кайтыр вакыты җиткәч, әниләрдән рөхсәт сорап, мин кечкенә өйне җылыта башлыйм. Ул кайткач, якын дуслар, малайлар белән шунда очрашып утыра торган идек. Абый Казан, укуы турында сөйли, бу бик күңелле, шатлыклы көннәр булып истә калган.

Рүзәл абый кечкенәдән үк инициативалы, сәләтле оештыручы булды. Техникумның беренче курсын тәмамлап, җәйге каникулга кайткач, абый әйтә: «Әйдә, дус малайларны җыеп, буа буып куйыйк», — ди, һәм без, арба белән вак таш, чыбык-чабык, чирәм кантарлары ташып, инешнең тар һәм тирән урынын сайлап, зур гына буа буып куйдык. Инеш суыбыз үзенә күрә кечерәк бер күлгә әверелде. Әлеге эшне без малайлар башкарып чыкканга олыларның ышанып та бетәселәре килмәде. Бу бөтен авыл халкы өчен бер шатлыклы вакыйга булды.

Рүзәл абыйның күркәм сыйфатлары турында күп сөйләргә мөмкин. Аның тормышы бик гыйбрәтле. Мин аның белән горурланам, иң якын күргән, булдыклы, кешелекле абыем, дип мактанып сөйлим мин аның турында.

**Әнәс ЮСУПОВ**,
икътисад фәннәре кандидаты

## КООПЕРАТОР ҺӨНӘРЕН ҮЗЛӘШТЕРГӘНДӘ

Язмыш мине Рүзәл Юсупов белән 1952 елның августында Казан кооперация техникумына укырга кергәч таныштырды.

Безнең үзара яхшы мөнәсәбәтебез тиздән дуслыкка әверелде. Рүзәл татар мәктәбен тәмамлап килгән, ә мин рус мәктәбендә укыган идем. Шунлыктан мин аңа, кайбер предметларны үзләштергәндә, русчадан татарчага тәрҗемә итеп булыша торган идем.

Без укыган товароведлар группасында Рүзәлгә аерым бер ягымлы караш хөкем сөрде, аны яраталар иде. Бу шуның белән дә аңлатылгандыр: ул безнең арада иң яше иде, аңа техникумга укырга кергәндә 14 тә тулмаган булган. Безнең арада 16, 18 яшьтәгеләр, хәтта армиядән кайткан егетләр дә булды. Марҗа кызлары аңа, иркәләп, «Юсупчик» дип дәшәләр: яшь булуы өстенә, ул буйга кечкенә, ябык та иде. Павлодардан (Казахстаннан) килеп укучы Раил Нигъмәтуллин аны «жаксы малай» дип йөртте. Бу сыйфаты аның бүгенгәчә үзгәрмәгән.

Икенче курста (IV семестр) укыганда, безне производство практикасы узарга Татпотребсоюз системасына караган сәүдә предприятиеләренә һәм оешмаларына җибәрделәр. Без анда кибетче һәм сельпо председателе ярдәмчеләре булып эшләп карадык. Рүзәл практиканы Красный Борда үтте. Ул прилавка артында торганда, сатып алучыларның күбесе, кибетче ханымның улы әнисенә ярдәм итә, дип уйлаган. Һәрхәлдә без ул практикадан бераз олыгайган кебегрәк, җитдирәк булып кайттык.

Ә өченче курс практикасын Рүзәл инде Азнакай районында райпотребсоюз товароведы ярдәмчесе сыйфатында узды.

Безнең техникум Югары Ослан районының Куралово совхозына шефлык итә иде. Безне вакыт-вакыт анда урак өстендә һәм бәрәңге алганда совхозга ярдәм итәргә җибәргәләп тордылар. Рүзәл бу эшләрдә үзен иң тырыш малай итеп танытты, башкаларга, бигрәк тә шәһәрдә туып үскәннәргә үрнәк булды. Ул анда төрле эшләрдә эшләде, без аның бер җирдә дә ялкауланып яки зарланып йөргәнен күрмәдек.

Без культура тормышында да катнаштык. Даими рәвештә театр түгәрәге эшләп торды. Аның җитәкчесе В.И.Качалов театрының күренекле актёры А.И.Гришин булды. Рүзәл сәхнәгә менәргә кыймады, әлбәттә. Ләкин бию сәнгатен үзләштерүдән баш тартмады. Аңа безнең группаның үтә дә чая кызы (сорвиголова) Люба Краснова шефлык итте. Ул аны «Рио-Рита»га каты әйләндерә иде.

Рүзәл рус телен тиз һәм әйбәт үзләштерде. Бу эштә аңа бик теләп, күңелен биреп, рус теле укытучысы Тамара Лазаревна Чудновская ярдәм итте. Ул безгә Рүзәл белән күбрәк русча сөйләшергә куша торган иде. Һәм без аның бу теләген үтәп килдек.

Менә шулай итеп, безнең техникум тормышы тәмамлануга да килеп җитте. Дәүләт имтиханнарын тапшырып, күптән көткән дипломнарыбызны да алдык. Чыгарылыш кичәсе булды. Күңелләребездә бер яктан шатлык, икенче яктан аерылу сагышы иде.

Безгә соңгы стипендиябезне (40 сум) бирделәр. Аңа һәркайсыбыз үзенең иң кирәк әйберләрен сатып алды. Рүзәлнең дә әти-әниләренә, туганнарына ниндидер күчтәнәчләр алып йөргәнен хәтерлим.

Безнең группада укып бетергәннәрне эшләргә Россиянең төрле өлкәләренә билгеләделәр. Без Рүзәл белән икебез Курган өлкәсенә җибәрелдек: мин — Лебяжьево районына, Рүзәл — Усть-Уйка районына. Тырышып эшләп йөри икән, дигән хәбәрләрне ишеткәләп тордым аның турында. Мәгълүм булганча, Рүзәл, армиядә хезмәт иткәннән соң, потребкооперация системасына кире әйләнеп кайтмады. Аның каравы ул зур галим, республиканың күренекле җәмәгать эшлеклесе булып китте. Афәрин!

Без, Казан кооперация техникумында укып чыккан, хәзер инде җитди урыннарда эшләгән кешеләр, Рүзәлебез белән хаклы рәвештә горурланабыз: «Күрегез, әнә кемнәр белән укыдык без!» — дип сөенешәбез.

**Г.Г. ШӘРИФУЛЛИН**,
Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре

## ТЫНГЫСЫЗ СТУДЕНТ

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керү имтиханнарын тапшырып йөргәндә, урта буйлы, җитди йөзле бер абитуриент егет игътибарны җәлеп итте. Имтиханнары гел «бишле» белән бәяләнеп бара. Егетнең исеме Рүзәл икән. Бу исемне беренче мәртәбә ишетүем. Безнең Буа якларында андый исем юк иде, һәрхәлдә, ишеткәнем булмады. Шуңа күрә мин аңардан исемен дөрес әйтү-әйтмәвем турында сорадым. Ул да яңарак кына армиядән кайткан булып чыкты. Хезмәткә киткәнче, кооперация техникумын тәмамлап, ике ел эшләп алырга да өлгергән. Ә хәрби хезмәте Урта Азиядә узган. Шулай без үзара якынаеп киттек.

Чыгышы белән Рүзәл Юсупов Казан артындагы Кышкар авылыннан икән. Ләкин без әле ул вакытта бу авылның данлы мәдрәсәсен дә, анда укып чыккан мәшһүр шәхесләрне дә белми идек. Элегрәк бу турыда белгәннәреңне сөйләү дә җинаятькә тиң гамәл саналган. Әле соңрак чорда да галим һәм язучы Мөхәммәт Мәһдиевне Буби мәдрәсәсе турында мәкалә бастырганы өчен күпме эзәрлекләделәр.

Кышкар мәдрәсәсе һәм аның атаклы шәкертләре турында без беренче тапкыр кемнән ишеткәнбездер — хәтеремдә калмаган. Бәлки, аларны сүз арасында гына университетның ул вакыттагы хөр фикерле укытучылары Якуб Агишев яки Җәвад Алмаз телгә алгандыр, яисә бу турыда әдип һәм галим Нәкый Исәнбәт сөйләгән булгандыр...

Шулай итеп, без тиздән студентларга әвереләдек. Укуда алдынгы шәкерт булып чыкты безнең Рүзәл дигән егетебез. Аның активлыгы бигрәк тә семинарларда күренә иде. Ул теге яисә бу предмет буенча тиешле әдәбиятны гына түгел, өстәмә чыганакларны да тирәннән үзләштерә һәм үзенең җаваплары белән укытучыны гына канәгатьләндереп калмый, безне — сабакташларын да сокландыра иде.

Рүзәл яшьтән үк «егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» дигән кагыйдә белән аңлы рәвештә яшәгәндер, мөгаен. Моны мин менә ни өчен әйтәм. Узган гасырның 60 нчы елларында шәхси машиналар бик аз иде әле. Машиналы булу уе ул чакта безнең кебекләрнең төшенә дә керә алмый иде, әлбәттә. Әмма заман — техника заманы. Рүзәлебез алга карап эш иткән булып чыкты. Мин аның: «Хәзерге вакытта техникадан хәбәрдар булмасаң, әйтик, машина да йөртә белмәсәң, нинди ир буласың инде», — дигәнен хәтерлим, һәм беркөнне ул, үзе белән берничә студентны ияртеп, автотүгәрәккә алып китте. Арабызда хәтта кызлар да бар иде. Нәтиҗәдә, 1 май бәйрәмен без права алып каршыладык. Бу 1962 ел иде. Алгарак китеп әйтеп узыйм: соңрак Рүзәлнең чыннан да шәхси машинасы булды һәм ул аны бик тәвәккәл йөртте. Калганнарыбызның машиналары булмады бугай, әмма машина детальләренең исемнәрен белү дә бер гыйлем ич!

Инициативалы кеше күзгә бик тиз ташлана бит ул. Уку елы башланып күп тә үтмәде, Рүзәл факультет комсомол оешмасының секретаре итеп сайланды. Әлеге вазифадан тыш, аның тагын байтак җәмәгать эшләре булды, һәм бу йөктән Рүзәл Юсупов студент елларында бер көн дә арынып тормады бугай.

Тагын бер нәрсә истә калган. Рус филологиясе бүлегендә укучы шәһәр кызларының кулларында сәнгать өлкәсенә караган төрле әсбаплар, рәссамнарның зур форматтагы альбомнары күренгәли иде. Алар үзара кызып-кызып сәнгать мәсьәләләре турында әңгәмә коралар, бәхәсләшәләр. Әмма безнең өчен бу өлкә караңгы. Рүзәл аларга сүзсез генә сынап карап йөри дә бервакыт әйтеп куя: «Без нигә әле алардан ким булырга тиеш, алар белгәнне без дә белә алмыйбызмыни?» Шуннан соң фәнни китапханәнең уку залында семинарларга әзерләнеп утырганда, аның өстәлендә сәнгать өлкәсенә нисбәтле шундый ук әсбаплар күренә башлады. Шөгыльләнә торган төп эшеннән беразга аерылып, башны ял иттергән арада, ул әлеге альбомнарны, буклетларны актара торган булды. Бу «чир» башкаларга да йокты. Мин дә, абонемент алып, Татарстан Дәүләт музеенда уза торган бер сәнгать чара-

сына йөри башладым, ягъни культура университетының чит телләр сәнгате курсы буенча актив тыңлаучысы булып киттем. Анда белгечләр антик заманнардан алып бүгенге көнгә чаклы вакыт эчендә яшәп иҗат иткән атаклы рәссамнар һәм сынчылар: Леонардо да Винчи, Микеланджело, Тициан, Рубенс, Рембрандт, Веласкез, Бидструп һәм башкалар турында лекция укыйлар, әсәрләренең репродукцияләрен күрсәтәләр, әлеге бөек шәхесләрнең тормышыннан кызыклы фактлар китерәләр... Безнең тулай торактагы тумбочкабыз сәнгать брошюралары, төрле открытка җыелмалары белән тулды. Рәссамнарның күргәзмәләрен дә карамый калмыйбыз. Нәтиҗәдә без авыл балалары да үзебезне бу өлкәдән хәбәрдар итеп сизә башладык. Белмим, мәгълүматыбыз теге кызларныкы хәтле булып җиткәндерме, юкмы, әмма канәгатьлек хисе бар иде.

Шулай итеп, бу мәсьәләдә дә Рүзәл инициатор булды.

Беренче курсны тәмамлагач, без, 25 студент, фольклор экспедициясенә (фольклор практикасы), ә икенче курсны тәмамлагач, диалектологик экспедициягә чыгып киттек. Татарстан районнарында йөргәндә, безнең төркем эш мәнфәгатьләрендә еш кына ике отрядка бүленә иде. Беренчесендә җитәкче укытучыбыз үзе булса, икенче отрядка башлык итеп, әлбәттә инде, Рүзәл Юсупов билгеләнә торган иде.

Фольклор буенча экспедиция җитәкчебез доцент Зәет Мәҗитов булды. Ул үзенең шәкертләрен туган ягына — Актаныш районына алып китте, ә диалектология буенча практикабыз доцент Әнвәр Ахунҗанов җитәкчелегендә Казан артында узды.

Авылларда без халыкка мәдәни хезмәт тә күрсәтеп йөрдек: төрле темаларга лекцияләр сөйләдек, концертлар куйдык. Авыл халкы бигрәк тә халыкара хәлләр турында тыңларга ярата иде. Бу инде Рүзәл темасы. Ул бик тырышып материал җыя, үзәк матбугат басмаларын күздән кичерә. Шуңа күрә аның лекцияләре һәркем өчен кызыклы һәм файдалы була иде. Лекциядән соң концерт куябыз. Концертны үзебезнең шагыйрьләребез Шамил Маннапов яисә Фарсель Зыятдинов башлап җибәрә. Интермедияләр күрсәтү һәм концертны алып бару миңа йөкләнгән иде. Сатирик һәм юмористик шигырьләрдән соң берәр скетч күрсәтәбез һәм кичәбезне аерым музыкаль чыгышлар белән дәвам иттерәбез. Лениза Галиева матур итеп җырлый, ә гармунчыбыз — әлеге дә баягы Рүзәл Юсупов. Дәртләнеп китеп, ул еш кына, сәхнәгә ялгызы гына чыгып, хромкасын да сайратып ала. Ә менә егетләрдән биючебез юк иде. Биючесез концерт чәчәксез гөл кебек бит инде ул. Бер биюче егет мотлак кирәк иде, һәм ул табылды да. Биючебез шул ук Рүзәл булды.

Безнең сәхнә тамашабыз дәрәҗәбезне шактый күтәрде: бер авылда колхоз рәисе хәтта филармониянең концерт бригадасын кабул итмәгән, дип ишеттерделәр, ул, янәсе: «Бездә артистлар бар инде», — дип, тегеләрне кире борган.

Рүзәл бүгенге көн белән генә яши торган кеше түгел, ул — киләчәкне күздә тотып гамәл кыла торган зат. Мәсәлән, студент елларында ук үзенең торак мәсьәләсен хәл итеп куйды. Аларның ишле гаиләсе Казан каласының Северный бистәсендә үз йортында яши иде. Әмма егет кеше гомер буе әти-әнисе янында яшәмәс бит инде, аның үз куышы булырга тиеш, киләчәктә үз гаиләсе дә булыр... Һәм Рүзәл, Наил исемле абыйсы белән бергә җир кишәрлеге алып, туганнары ярдәме белән, силикат кирпечтән менә дигән йорт салып керде. Соңрак шушы йортка кәләшен дә алып кайтты.

Без, берничә студент, өч курстан соң, шул дәвердә кертелгән яңалык буенча индивидуаль план белән укыдык. Нәтиҗәдә, 4 нче курста барлык имтиханнарны да тапшырып бетердек, 5 нче елга диплом яклау эше генә калды. Шунлыктан, 4 нче курсны тәмамлагач, барыбыз да эшкә кердек. Рүзәл белән мин Татарстан радиосына урнаштык. Безгә кадәр шул ук радиода төркемдәшебез Фарсель Зыятдинов төпләнеп өлгергән иде инде. Шулай итеп, без, укытучы булырга әзерләнсәк тә, журналистлар булып киттек. Бу 1964 ел иде. Ә 1965 елның язында, диплом эшләрен яклап, кулга «диплом» дип аталган документ алдык. Әмма шунда бер үзенчәлек күзгә ташланды: безнең дипломнар зәңгәр төстә булса, Рүзәл Юсуповныкы — кызыл. Аның дипломындагы билгеләрнең барысы да «бишле» иде.

Рүзәл радиода тәрҗемәче булып эшләде. Өлгерлеге һәркемне сокландыра иде, кыска гына вакыт эчендә бер китапны татарчага тәрҗемә итеп, бастырып та чыгарды. Әмма биредә ул озак тормады, аны телевидениегә редактор итеп күчерделәр.

Радио-телевидениедә эш кайный, кызык, әмма фән күңелдән чыкмый. Әнә төркемдәшебез Шәрифҗан Асылгәрәев шул ук елны аспирантурага кереп калды да фән кыясын кыю гына штурмлый да башлады. Безнең хыялда да бар иде ул аспирантура.

Менә беркөнне, җәйге ялдан соң вузларда укулар башлангач, Рүзәл шалтырата: «Әйдә, кандидатлык имтиханнарын аспирантурага кергәнче үк тапшырып куйыйк. Быел пединститутка чит тел дәресләренә йөрергә була, киләсе елда — философия дәресләренә. Аспирантлар белән укырга рөхсәт тә бар», — ди.

Хәл иттек. Дәресләргә йөри башладык. Шул уку елында чит телдән, икенче елны философиядән кандидатлык имтиханнарын тапшырдык.

Шулай итеп, бу мәсьәләдә дә Рүзәл инициатива күрсәтте, һәм шуның белән безнең вуз аудиторияләрендәге гамәлләребез дә тәмамланды, юлларыбыз аерылды. Әмма кызыклы, нәтиҗәле очрашулар, еш булмаса да, дәвам итте.

Рүзәл Юсупов — бөтен барлыгы, асылы белән фән кешесе. Алга таба ул аспирантурада укыды, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклады, профессор, атказанган фән эшлеклесе булды, Татарстан Фәннәр академиясенең мөх-

бир әгъзасы, янә дә Татарстан Дәүләт Советы депутаты итеп сайланды, бик күп җәмәгать эшләре алып барды. Әмма ул һәрвакыт үзе булып калды, үзгәрмәде, кешеләргә, үзеннән түбәннәргә өстән карамады, кирәксә, ярдәм кулын сузды, акыллы киңәшләрен бирде. Шуңа күрә бу игелекле кешене сабакташлары һәм дуслары аеруча нык ихтирам итәләр, яраталар.

**Ленар ҖАМАЛЕТДИНОВ**,
ТФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
әйдәп баручы хезмәткәре,
Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

## САБАКТАШЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ

Без Рүзәл Юсупов белән 1960—1965 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегендә бер группада укыдык. Ул чакта бу бүлеккә абитуриентларны да бик сайлап, «җиде иләктән үткәреп» кенә алалар иде. Без, имтихан биргәндә, бер урынга биш кеше булдык.

Ул елларда мин группабызда гел «бишле»гә генә укый торган, тормыш тәҗрибәсе белән дә, тырышлыгы, ихтыяр көче ягыннан да үземнән күпкә югары торган Рүзәл Юсуповка сокланып, аның кебек булырга омтылып яшәдем. Ул Ленин стипендиаты иде. Сессия вакытларында имтихан-зачётлардан, нинди генә авыр предметлар булмасын (мәсәлән, авылда татарча гына укып килгән яшь кешегә русча «Чит илләр әдәбияты» — «Зарубежная литература» кебек предметлар), Рүзәл һәрвакыт «бишле» алып чыга иде. Укуда күпчелегебез аңа таянды. Әгәр без — «яшьрәкләр» — берәр нәрсәне аңлап җиткермичә, «өлкәннәрдән» ярдәм сорасак, алар безне: «Әнә Рүзәлдән сора», — дип кенә җибәрәләр иде. Миңа хәтта кайчакта ул сессия вакытларында имтихан һәм зачётлардан гына торган «транспортёрга» берсе артыннан берсе «бишле»ләр генә салып торучы хикмәтле бер кеше кебек күренгәндәй була иде. Әлбәттә, бу «бишле»ләр аңарга гаять зур тырышлык, тирән белем алырга юнәлгән үҗәтлек һәм ихтыяр көчен куллану нәтиҗәсе буларак килгән.

Укудан тыш, Рүзәл әле бөтен тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретаре вазифасын да башкарып килде. Безнең группа студентлары өчен бу шулай ук горурлык иде. Чөнки берәр авырлык яки хәл итеп булмаслык нәрсә килеп чыкса, читкә барасы юк, секретаребыз яныбызда гына. «Ул хәл итәр әле», — дип, артыбызда таянычыбыз барлыгын тоеп-сизеп яшәдек. Аның безнең группада укуы безгә җаваплылык та өсти иде: шундый дәрәҗәле кеше дәресләрдә синең белән

янәшәдә лекцияләр язып, семинарларда катнашып утырсын да, син ничек инде начар укый аласың, ди?! Бөтен группабыз тырышып укыды, һәм бу үзенең уңай нәтиҗәсен дә бирде: безнең группа, бөтен университет күләмендә призлы урын алып, бүләккә лаек булды: без җәй көне университетның Идел буендагы спорт лагеренда бар ай бушлай ял иттек.

Безнең студент тормышы гөрләп торды. Икенче-өченче курсларда тарих-филология факультеты студентларының Ирнис Хәкимуллин җитәкчелегендәге татар хоры түгәрәгендә җырладык. Үзебезнең группа көче белән генә концерт номерлары әзерләп, җәй көне Казан тирәсендәге авылларда концертлар да куеп йөрдек. Гармунчыбыз Рүзәл булды. Хор белән «Казан кичләре» җырын башкара идек. Ул җыр безнең группаның «визит карточкасы»на әверелде. Тагын шуны әйтергә кирәк: бер тапкыр без дүртәүләп — Рүзәл, мин, рус-татар төркеме студенты Нәбиуллин Сирин һәм тагын бер кыз (исеме хәтеремдә калмаган, Нәзифә иде булса кирәк) — «Батраклар» дигән бию әзерләдек һәм шул бию белән университетның төп бинасындагы актлар залында да чыгыш ясадык. Бу биюнең соңгы моментын төшереп алган фото минем альбомда әле дә саклана.

Шулай итеп, шаулап-гөрләп торган студент еллары узып та китте. Без төрле якларга таралыштык. Чыгарылыш кичәсенә безнең төркемнең кураторы Диләрә апа Тумашева, безне укыткан башка остазларыбыз да килгән иде. Ул кичәдә укытучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең чыгышы ап-ачык булып исемдә калган.Үзенең чыгышында ул, безнең һәрберебезгә аерым-аерым тукталып, укуыбыз һәм үз-үзебезне тотышыбызга үз бәясен биреп, киләчәктә безнең кайсыбызга нинди өметләр баглавын әйтеп чыккан иде. Шөкер, без аның өметләрен акладык шикелле.

Университетны тәмамлагач, Рүзәл, үзенең тырышлыгы аркасында, зур уңышларга иреште: 1970 елда — кандидатлык, ә 1982 елда докторлык диссертациясе яклады. Бик җаваплы урыннарда эшләде: 1986—2002 елларда Казан педагогика университеты ректоры, 1990—1995 елларда Татарстан Югары Советы депутаты, Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларация кабул итү, 1992 елның 21 мартында референдум үткәрү өчен көрәшнең алгы сызыгында булды, «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон проектын әзерләүдә актив катнашты, Татарстанның Республика партиясен төзеде, аның эшен җитәкләде һ.б. Фән өлкәсендә дә бер-бер артлы яңа биеклекләр яулап ала барды: ул — 60тан артык монография, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре, 500гә якын мәкаләләр авторы. Бу кадәр хезмәткә сокланмыйча мөмкин түгел.

Тормыш юлында миңа да, Рүзәл Юсупов кебек, фән өлкәсендә эшләргә туры килде. Университеттан соң берничә ел без бер үк шәһәрдә — Казанда яшәдек. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән елларда

(1971—1978) без Рүзәл белән төрле җыелыш-конференцияләрдә очрашып, бер-беребезнең яңалыклары белән уртаклаша идек. Ә инде мин 1978 ел азагында Алабуга институтына укытырга китеп баргач, безнең очрашулар, әлбәттә, сирәкләнде. Шулай да Рүзәл Абдуллаҗанович Алабуга пединститутына чыгарылыш имтиханнарына берничә тапкыр Дәүләт комиссиясе рәисе сыйфатында килде. Шул арада да без очрашып, хәл белешеп ала идек. 2001 елда мин дә докторлык диссертациясе якладым.

Рүзәл Юсупов Казан педагогика университетында «Тарихи, типологик һәм чагыштырма тел белеме» дигән фәнни юнәлеш буенча докторлык диссертацияләре яклау советын ачып, аның рәисе булды һәм мине дә шул совет әгъзасы итеп алды. Шуннан соң мин 5—6 ел буе (совет ябылганчы), Чаллыдан килеп, бу советның утырышларында катнашып йөрдем. Бу утырышларда диссертацияләр буенча фикер алышу, кайчакта оппонент булып чыгышлар ясау минем фәнни иҗатыма яңа төсмерләр өстәде: мин олы фән дөньясындагы яңалыклар белән дә танышып бардым. Ул гына да түгел, Рүзәл минем совет утырышына Чаллыдан һәр килүем белән чын күңелдән кызыксынып торды: мине педагогика университетының тулай торагына урнаштырды, хәтта, юл расходларын да түләп барып, материаль яктан да ярдәм итте. Моны бары тик башкалар турында ихлас күңелдән кайгыртучан кеше генә эшли ала. Шундый ярдәмчеллеге, кешелеклелеге өчен мин Рүзәлгә бик рәхмәтлемен!

Бер тапкыр Рүзәл белән телефоннан сөйләшкәндә, мин аңа «Рүзәл Абдуллаҗанович» дип эндәшкән идем. Ул шунда ук моны эләктереп алды да: «Нигә минем белән рәсми сөйләшәсең? Без бит чит кешеләр түгел. «Рүзәл» дип кенә әйт! «Рүзәл абый» дисәң дә ярый», — диде. Шуннан соң мин аның белән гел «Рүзәл» дип кенә сөйләшә башладым.

Тагын бер нәрсәгә тукталып китәсем килә. Яшьлек чорыннан ук мин укыган китапларымнан үземә аеруча ошаган зирәк, акыллы фикерләрне куен дәфтәремә язып барырга күнеккән идем. Һәм менә әле соңгы елларда гына Рүзәл Юсуповның бер хезмәтеннән аның шундый сүзләрен куен дәфтәремә теркәп куйдым: «Хәзерге вакытта безнең җәмгыять кешеләренең күбесенә бер сыйфат җитми. Бу — кыю фикерле булу, мәсьәләгә үз карашыңны, тартынмыйча, җитәкчеләргә, түрәләргә ошамаса да, курыкмыйча әйтә белү... Туры сүзлелек, кыюлык, үз фикереңне әйтә белү, принципиальлекне ата-аналар балаларында кечкенәдән үк тәрбияләсен иде: мондый сыйфат аларга гомер буена кирәк булачак». Миңа, бала чактан ук кыюсыз һәм күндәм булып тәрбияләнгән кешегә, болар киләчәк тормышым өчен маяк булды.

Әле күптән түгел генә «Татарстан Яңа гасыр» каналының «Ком сәгате» тапшыруында академик Рүзәл Юсупов белән әңгәмә үткәрделәр. Анда ул хәзерге педаго-

гика, бигрәк тә бүгенге шартларда мәктәпләрдә татар балаларына да, рус телендә сөйләшүче балаларга да татар телен укытуның торышы, татар теленең киләчәге турындагы үз фикерләре белән уртаклашты, милли республикаларда БДИны бары рус телендә генә бирүнең дөрес түгеллеген, бик зыянлы гамәл икәнлеген дәлилләп күрсәтте. Монда да без аның үз фикерен ачыктан-ачык, кыю рәвештә әйтүенә тагын бер тапкыр сокланып утырдык.

Менә шундый ул безнең сабакташыбыз, миңа күп игелекләр эшләгән чын Кеше, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, милләтебезнең киләчәге өчен җанатып яшәүче дөньякүләм дәрәҗәдәге олы галим! Без аның белән хаклы рәвештә горурланабыз!

**Әнвәр ШӘРИПОВ**,
филология фәннәре докторы, профессор,
Татарстанның атказанган укытучысы,
Энциклопедик фәннәр академиясенең академигы
һәм почётлы докторы, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы

## ТЕЛ ХӘЗИНӘСЕ САГЫНДА ЯРТЫ ГАСЫР

Татарлар гасырлар дәвамында аң-белемгә омтылып яшәгәннәр, уку-укыту эше белән шөгыльләнгән кешеләрне олылап, аларга зур хөрмәт, ихтирам белән караганнар. Шөкер, милләтебез мәгърифәт өлкәсендә күренекле шәхесләргә һәрвакыт бай булган. Шундыйларның хәзергеләреннән берсе — олуг галим, укыту-тәрбия эшен нәтиҗәле итеп оештыручы, икетеллелек мәсьәләләре буенча зур әһәмияткә ия булган күпсанлы монографияләр, фәнни-популяр хезмәтләр, дәреслек, кулланма, программа һәм мәкаләләр авторы, хөрмәтле галим-мөгаллим, укытучыбыз — филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов.

Язмыш Рүзәл Абдуллаҗановичка җиңел тормыш әзерләп куймаган, аның гомер юлында авырлыклар һәм киртәләр күп була. Шуңа да карамастан, ул мәгънәле, җәмгыятькә файдалы, игелекле эшләр башкара, фән һәм мәгариф дөньясына күпләргә үрнәк булырлык итеп хезмәт итә.

Р.А.Юсупов җитәкчелек иткән чорда (1986—2002 еллар) Казан педагогика институты (университеты) зур үзгәрешләр кичерә: уку-укыту процессының сыйфаты күтәрелә, факультет һәм кафедралар, доктор һәм профессорлар саны бермә-бер арта, яңа белгечлекләр ачыла, уку планнары заман таләпләренә җавап бирердәй итеп үзгәртелә. Мәсәлән, илебездә беренче булып, барлык факультетларда да му-

зыка һәм хореография фәннәре укытыла башлый, матди-техник база ныгытыла, АКШ, Англия, Германия, Франция, Кытай, Төркия һәм башка чит илләр белән тыгыз бәйләнешләр урнаштырыла һәм иң мөһиме — 1996 елда институт, Россиядә беренчеләрдән булып, университет статусы ала. Әлбәттә, бу эшләрнең барысы да — коллективның ректор җитәкчелегендә башкарылган уртак хезмәте.

Профессор Р.А. Юсупов — контрастив лингвистика, тәрҗемә теориясе һәм сөйләм культурасы проблемаларына караган 600 дән артык басылып чыккан хезмәт авторы. Бу хезмәтләрнең 60 тан артыгы — монографияләр, дәреслекләр һәм төрле методик кулланмалар — Татарстанда гына түгел, Россиянең төрле регионнарында да тел галимнәренә һәм туган тел укытучыларына яхшы таныш.

Тәрҗемә теориясе буенча Р.А.Юсупов төзегән программа СССР Мәгариф министрлыгы тарафыннан илебездәге барлык педагогика югары уку йортларына тәкъдим ителә, Мәскәү һәм Ленинград нәшриятларында басылып чыга.

Соңгы берничә дистә елда сөйләмебезнең сафлыгын, аның дөреслеген һәм әдәби нормаларын саклауга багышланган хезмәтләр әллә ни күп түгел. Шулар арасында Рүзәл Юсуповның фәнни эшләре аерым бер урын алып тора. Ул шушы мөһим юнәлешне — сөйләм культурасы мәсьәләләре белән бәйле хезмәтләр язуны гыйльми эшләренең кыйбласы итеп сайлый: «Тәрҗемә һәм тел культурасы» (1978), «Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү» (1983), «Двуязычие и культура речи» (2003), «Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи» (2005), «Мәгълүмат чаралары теле һәм сөйләм культурасы» (2007), «Тәрҗемә һәм эфир теле» (2017) һ. б.

Р.А.Юсупов татар һәм рус телләренең үзара бәйләнеше нәтиҗәсендә барлыкка килә торган уртак һәм аермалы якларны типологик нигездә тикшерә. Бу юнәлеш бигрәк тә узган гасырның 90 нчы еллар башында үзенең бик актуаль булуын бөтен кискенлеге белән күрсәтте, чөнки көн тәртибенә телебезне башка милләт вәкилләренә укыту кирәклеге дә килеп баскан иде. Бу уңайдан шуны да әйтик: Р.А.Юсупов — Татарстан Республикасының Югары Советы депутаты, андагы комитет рәисе буларак, әлеге мәсьәләне беренчеләрдән булып күтәреп чыккан кеше. Аның бөтен хезмәтләре дә шушы юнәлешне үстерүнең бик әһәмиятле булуын исбатлады. Шуңа күрә күп меңләгән мәгариф һәм фән хезмәткәрләре генә түгел, бәлки журналистлар, радио һәм телевидениедә эшләүчеләр, тәрҗемәчеләр, галимнәр һәм укучы яшьләр — студентлар аның хезмәтләренә таянып эшләүләрен дәвам иттерәләр.

Чагыштырма тел белеме өлкәсендә Р.А.Юсуповның үзенең фәнни мәктәбе тулысынча формалашты. Аның җитәкчелегендә 35 кандидатлык һәм докторлык диссертациясе якланды, ул 25 елдан артык докторлык диссертацияләре яклау советы

рәисе дә булды. Аның күпсанлы шәкертләре республикабызда һәм аннан читтә фән өлкәсендә уңышлы эшлиләр.

Профессор Р.А.Юсупов чит илләр белән тыгыз хезмәттәшлек итә, бу аның халыкара конференцияләрдә һәм симпозиумнарда катнашып ясаган күпсанлы докладларында ачык чагылыш таба (Чехия, Германия, Америка Кушма Штатлары, Кытай, Франция, Төркия, Швейцария, Австралия һ.б.). Ул Татарстан Фәннәр академиясенең академигы һәм вице-президенты итеп сайланды, 1997 елда Американың һәм Англиянең Кембридж Халыкара биография Институтлары тарафыннан «Ел кешесе» дигән мактаулы исемгә дә лаек булды.

Тагын бер нәрсәне искәртик: республикабызда дәүләт телләре турындагы законның тормышка ашырылуы да укытучыбызның көндәлек эшенә, күпсанлы хезмәтләренә барып тоташа.

Узган гасырның 90 нчы еллар башында киң җәмәгатьчелек Рүзәл Абдуллаҗан улын Татарстан Югары Советының иң актив депутаты буларак исендә калдырды. Шушы чорда аның «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон проектын эшләүчеләрнең берсе булуы аерым искә алуга лаек. Аннан соң ул — фикердәшләре белән бергә төзегән Татарстанның Республика партиясе рәисе, Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты әгъзасы, «Татарстан — гарәп илләре җәмгыяте» рәисе булды һәм башка күп төрле җәмәгать эшләрен армый-талмый, җиренә җиткереп башкарып килде.

Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның чын галим-педагогка хас төп сыйфатларыннан бигрәк тә аның кешелеклелеге, нинди генә эшкә алынуына карамастан, аны намус белән, бик яратып, ахырына кадәр җиткерүче, киңкырлы белемле педагог-мәгърифәтче буларак үзе эшләгән уку йортына 50 елдан артык намуслы хезмәт итеп, аның үсүешенә зур өлеш кертүче, оста оештыручы һәм җитәкче булуын, республикабыз тормышында актив катнашучы булуын әйтергә кирәк.

Р.А.Юсупов — кешеләргә игътибарлы һәм үзе дә зур ихтирамга ия шәхес, кызын, оныкларын кайгыртучы гаилә башлыгы. Хатыны Дилара Мәгъсүм кызы — озак еллар буе җитәкче урыннарда эшләгән филолог — иренең фикердәше, ышанычлы терәге. Кызлары Диләфрүз — чит телләр белгече, ире Айдар Закиров белән матур гаилә корып, ике тырыш, акыллы ул үстерәләр.

«Тел дигән дәрья бар, төбендә энҗе-мәрҗән бар; белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр», — дип халкыбыз бик дөрес әйткән. Р.А.Юсупов күп еллар буе укучыларны, галимнәрне һәм журналистларны телебезнең хикмәтле серләрен ачарга, кыйммәтле энҗе-мәрҗәннәрен эзләп табарга өйрәтүен дәвам иттерә.

Академик Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов — хезмәт сөючәнлек, фидакарьлек һәм үзе сайлаган эшенә тугрылык символы да. Ул киләчәккә зур өметләр белән

караучы оптимист кына түгел, бәлки көндәлек тормышта тырышлык, сабырлык, тәвәккәллек таләп итә торган хезмәт нәтиҗәсенә үз куллары һәм акылы белән ирешүче дә. Шуңа да ул иң зур бүләккә — хезмәттәшләренең, киң җәмәгатьчелекнең олы ихтирамына һәм мәхәббәтенә ия.

**Ф.Ф. ХАРИСОВ**,
КФУ профессоры,
Россия югары белем бирү системасының мактаулы хезмәткәре,
Татарстанның атказанган фән эшлеклесе,
Татарстанның атказанган укытучысы

## БЕРГӘ ҖИГЕЛЕП ТАРТТЫК

Рүзәл Абдуллаҗанович Юсупов турында язу уңайсыз да, күңелле дә. Уңайсызлыгы шунда: беренчедән, сине дөрес аңламаска мөмкиннәр; икенчедән, ул күп еллар безнең ректорыбыз булды, һәм нәрсәнедер онытып калдыру яки ялгыш әйтү куркынычы бар. Күңелле булуы исә шуннан гыйбарәт: без — тарих-филология факультеты деканы Р.А.Юсупов, партбюро секретаре Ф.Ю.Әхмәдуллина, профбюро председателе Л.В.Мирошниченко — йөкне бергә җигелеп тарттык, бер сафта бардык. Нәкъ менә шул чакта бер-беребезне якыннан белдек, һәм шуңа күрә минем аның турында сөйләргә хакым бар.

Рүзәл Абдуллаҗанович белән эшләү кызык та, җаваплы да иде. Аның сыйфатларының иң әһәмиятлесен аерым күрсәтим дисәң, зиһенгә Ф.Вольтерның «кешенең гомере хезмәттән тора» дигән сүзләре килә. Әйе, җитәкче Юсуповта хезмәт сөючәнлек сәләте артыгы белән. Инициативалы, актив, тәвәккәл һәм башкалардан да шуны таләп итә. Аның бу сыйфатлары кешегә күрсәтү өчен генә, ягъни ясалма түгел, бәлки үзенә йөкләнгән эшне җиренә җиткереп, чын күңелдән бирелеп эшләве белән бәйләнгән. Аның эчкерсезлеге, нечкә күңелле, кешеләргә миһербанлы булуы да шуннан килә. Бервакытны миңа бер укытучының Рүзәл Абдуллаҗановичка студентларның аның дәресләренә начар йөрүләренә зарланып, хәлне ничек яхшыртырга икән дип, аннан киңәш соравын ишетеп торырга туры килде. Декан, елмаеп: «Тырышыбрак эшләргә киңәш бирәм», — диде. Аның бу сүзләрендә үзенең эшкә мөнәсәбәте чагыла иде. Тулысы белән бирелеп, булсын дип эшләү — аның яшәвенең принцибы шундый.

Рүзәл Абдуллаҗановичның, декан чагында да, ректор булып эшләгәндә дә, ниндидер дә булса мәсьәләне, төптән уйламыйча, тота-каба гына хәл иткәнен хәтерләмим. «Әйдәгез, киңәшләшик әле, коллегалар», — дип башлый торган иде ул сүзен һәрвакыт, безнең белән очрашып сөйләшкәндә.

Ул җитәкчеләр өчен бер бик әһәмиятле кагыйдәгә таянып эш итте: бергә эшләгән, син җаваплы кешеләр өчен үзеңне аямаска, аларны аңларга һәм ярдәм итәргә. Тормышка аек карый торган кешеләрне үз тирәсенә туплап, Рүзәл Абдуллаҗанович коллективка вуз алдында торган җитди бурычларны хәл итәргә кирәклекне төшендерә һәм шуңа күндерә алды. Мәсәлән, булачак укытучыларны әзерләүнең сыйфатын күтәрүнең гаять әһәмиятле бурыч икәнлеген истә тотып, ул безнең барыбызны да вузда укыту программаларын камилләштерү һәм яңартып төзү, аларны мәктәпкә якынайту, укытуның яңа ысулларын эзләп табуга җәлеп итте. Бу уңайдан коллективның, университет статусына ирешү өчен, бик зур эшләр башкаруын искәртеп китү мәгъкуль. Студентларның җитди гуманитар әзерлеге булмаса, педагогика уку йортының үз бурычын уңышлы үти алмаячагын аңлап, ректор эстетика, музыка тәрбиясе нигезләре, хореография кебек яңа курсларны укыту өчен яңа кафедралар ачу, төгәл фәннәр факультетларында «Сөйләм культурасы», «Риторика» кебек дисциплиналар укыту инициативасын күрсәтте. Тормыш бу яңалыкларның бик кирәк икәнлеген раслады. Студентлар бу предметлар турында бик уңай фикердә.

Рүзәл Абдуллаҗановичка киң күңеллелек, гадилек, итагатьлелек, игелеклелек кебек уңай сыйфатлар хас. Мин аның кемнең дә булса ярдәм сорап килүен игътибарсыз калдырганлыгын хәтерләмим. Зыялы, нәзәкатьле, музыка ярата торган кеше ул. Үзе дә гармунда, баянда уйный.

Дуслары, якыннары аны йорт җанлы, хуҗалык эшләренә кулы ята, бакчасында эшләргә ярата торган кеше буларак беләләр.

Ул кешеләргә хас бернәрсәдән дә йөз чөерми.

**Ф.Ю.ӘХМӘДУЛЛИНА**,
профессор, Татарстанның атказанган укытучысы

## АСПИРАНТУРАДА УКЫГАН ЕЛЛАР ХАТИРӘСЕ

Сүзем — күренекле шәхес Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов турында, аның белән дәвамлы дуслык, хезмәттәшлек хакында.

Хәтеремдә, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында III курста укыганда, безне Питрәч районының Петровка авылына бәрәңге алырга җибәрделәр. Һава хәлләре әйбәттән түгел: көнаралаш коеп яңгыр явып тора. Ул чагында студентларны бер тиенсез, тамак ялына колхозга эшкә җибәрү өчен, обком яисә горкомнан, телефоннан шалтыратып, ректорга әмер бирү җитә, ә җитәкчелек, партия, комсомол оешмалары аны шундук гамәлгә ашыра иде. Менә шул Петровка авылында бәрәңге алып ятканда (аны көрәк белән казып алырга кеше саен буразналап бүлеп бирделәр), безнең янга ниндидер комиссия составында II курс студенты

Рүзәл Юсупов килеп чыкты. Ул Ленин стипендиаты, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, факультетның комсомол секретаре иде.

Петровка авылында эштән соң кечкенә генә клубта концерт куябыз, төрле телләрдә шигырьләр сөйлибез, җырлар җырлыйбыз. Безне берничәшәр итеп аерым йортларга урнаштырганнар иде. Комсомол җитәкчеләре студентларның яшәү шартлары белән кызыксынып йөрделәр, безнең йортта да булдылар. Кич чәй янында Рүзәл Юсупов белән җылы гына сөйләшеп утырдык.

Укыганда без тулай торакта яшәдек, ә Рүзәл әти-әниләре белән Северный бистәсендә торды, берничә транспортка күчеп утыра-утыра, көн саен сәгать сигезгә дәрес, лекцияләргә килеп җитә иде. «Бишле»гә генә укыды, җәмәгать эшләрендә катнашырга да вакыт таба иде.

Рүзәл белән очрашулар, дуслык җепләренең ныгуы күбрәк аспирантурада уку елларына туры килә. Мин, университетны тәмамлагач, мәктәптә алты ел буе чит тел укытучысы булып эшләдем, Горький чит телләр институтына инглиз теле бүлегенә читтән торып укырга кердем. Югары белемле кеше буларак, тизләтелгән программа белән укыдым һәм, ниһаять, аспирантурага керергә дигән карарга килдем.

Мин аспирантураның I курсында укыганда, Рүзәл аспирантураның II курсында укый иде, ә фәнни җитәкчебез икебезнеке дә бер үк кеше — Казан дәүләт педагогика институты ректоры, доктор, профессор, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев (хәзер Татарстан Фәннәр академиясе һәм чит илләр фәннәр академияләре академигы).

1968—1970 елларда без Рүзәл белән еш очраша идек. Ул бу вакытта Северный поселогында студент елларында җыелган Ленин стипендиясе акчаларына туганнары ярдәме белән җиткерелгән йортта хәләл җефете Дилара ханым, улы Фәнис белән яши иде. Аның йортында күп тапкырлар булуым, Рүзәл һәм Дилара ханымның дустанә мөнәсәбәте, кунакчыллыгы матур истәлек булып саклана.

Рүзәл Юсупов, университетны кызыл диплом белән тәмамлагач, радиода, телевидениедә журналист булып эшләде, аннары аспирантурага укырга керде. Ә мин — университетны, диплом эше язмыйча, дәүләт имтиханы гына биреп тәмамлап, мәктәпкә укытырга киткән кеше. Шуңа күрә язу сәләтем, фәнни фикерләү рәвешем «ташка үлчим» генә иде. Диссертациягә керешеп китү хакында (мин чит телләр белән бәйләнешле «Татар телендә интернациональ терминология» дигән теманы алдым) Мирфатыйх Зәки улы белән киңәшә идек, әмма ректор вазифасын башкарганга, аның эше бик күп булды. Шунлыктан мин күбрәк Рүзәл белән аралаша, фикер алыша идем: ничек материал тупларга, язарга һ.б.ш. Рүзәл Юсуповның зур ярдәме белән кандидатлык диссертациясен тәмамладым (ул аны өч тапкыр укып, төзәтеп чыкты). Иҗат йортында эшләгәндә, кандидатлык дис-

сертациясен тәмамлап, остазым Мирфатыйх агага күрсәттем. Ул эшемне яклауга куярга киңәш итте. Аны яклау вакыты килеп җиткәч, җитәкчем М.З.Зәкиев путевка белән санаторийга китеп барды, ә мине Рүзәл Юсуповка тапшырып калдырды. Әгәр шул вакытта дустым Рүзәл булмаса, белмим, эш ничек тәмамланган булыр иде икән?! Ул минем авторефератымны язарга булышты. Яклауга аз гына вакыт калган, совет әгъзаларын өйләренә шалтыратып җыю дисеңме, башка төрле оештыру эшләре — барысы да аның ярдәме белән эшләнде. «Һичнидән курыкма, авыр вакытта миңа таян», — дип әйтә торган иде ул миңа.

Ул вакыттан бирле күп еллар үтте. Дустым Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов доктор, профессор, академик булды, әмма безнең арадагы самими мөнәсәбәт, эчкерсез дуслык, хезмәттәшлек һич тә үзгәрмәде. Нинди генә ярдәмгә, киңәшкә мохтаҗ булсам да, аңа барып сыенам, аннан яклау табам.

**М.Б.ХӘЙРУЛЛИН**,
филология фәннәре докторы, профессор

## ТЕЛЛӘР БЕЛҮ — БАЙЛЫК УЛ

1991 елның июнендә, Пекин университетының филология факультетын тәмамлаганнан соң, мин Казанга килдем. Казан педагогика институты ректоры Р.А.Юсупов, кемнәндер бу турыда ишетеп белеп, минем белән очрашу оештырды һәм үзләренең вузларында кытай теле укытучысы булып эшләргә тәкъдим итте.

Миңа Россия студентларына туган телемне өйрәтү ошый иде, әлбәттә. Бу минем кулдан килмәслек эш түгел, чөнки мин, кытай теленнән тыш, рус телен дә ярыйсы гына белә идем.

Аңлашыла ки, уңышлы эшләү өчен әйбәт шартлар: торыр урын, яхшы хезмәт хакы да кирәк. Һәм тиздән, ректорның тырышлыгы белән, минем өчен мондый шартлар булдырылды. Мин Казан дәүләт педагогика институтының контрастив лингвистика кафедрасының өлкән укытучысы (соңрак доценты һәм профессоры) булып киттем.

1992 елда мөстәкыйль Көнчыгыш телләре кафедрасы оештырылды. Монда эшләүче укытучылар студентларны, кытай теленнән тыш, гарәп, төрек, фарсы, һинди, япон телләренә өйрәттеләр. 2005 елда шушы кафедра нигезендә Көнчыгыш телләре факультеты төзелде.

Бу телләр буенча белгечләр әзерләү (укытучыларга хезмәт хакы түләү, дәреслекләр, күрсәтмә әсбаплар, укыту өчен техник чаралар һ.б. белән тәэмин итү) күп кенә финанс чыгымнары таләп итә. Моның өстенә, югары сыйфатлы белем бирү

өчен, студентларны теге яки бу чит телдә сөйләшүче халык яши торган чит илләргә практикага җибәрергә кирәк.

Бу бурычлар гамәлгә ашырыла барды, һәм студентларны Көнчыгыш телләренә өйрәтү эше тиешле дәрәҗәдә башкарылып килде.

Бу эшләрне оештыру өчен, ректор Р.А.Юсуповка нинди кыю, тәвәккәл гамәлләр кылырга туры килгәнлеген мин соңыннан гына аңладым. 90 нчы еллар югары уку йортлары, бигрәк тә педагогика вузлары өчен икътисад мәсьәләсендә бик авыр чор булды бит. Россия Мәгариф министрлыгы вузларны бары тик минималь суммада гына финанс белән тәэмин итеп торды. Көнчыгыш телләренә өйрәтү өчен акча бөтенләй бирелмәде, чөнки Казан techинституты тарафыннан Көнчыгыш телләре белгечләрен әзерләү Мәскәүдән җибәрелгән укыту планнарында каралмаган (планлаштырылмаган) иде. Димәк, Көнчыгыш телләре бүлеген ачу ректорның үз ихтыяры белән генә башкарылган, һәм бу телләргә өйрәтү процессын финанс, материаль ресурслар һәм кадрлар белән тәэмин итү тулысынча аның үзенә йөкләтелгән булган.

Шулай да кыенлыкларны җиңеп чыгалар. Казан дәүләт педагогика университетында Көнчыгыш телләрен үзләштергән белгечләр әзерләү әһәмиятле, абруйлы эшкә әверелә.

Хәзер КДПУда кытай теле бүлеген тәмамлаган белгечләр, башка Көнчыгыш телләре бүлекләрендә укыган белгечләр кебек үк, Татарстанда гына түгел, бәлки Кытайда, Германия, Америка, Франция, Венгриядә һәм башка илләрдә дә уңышлы хезмәт итәләр.

Рүзәл Абдуллаҗанович Юсупов, ректор буларак, Көнчыгыш телләре укытучыларының эшләрен оештыру, яшәү урыннары белән тәэмин итү, нормаль хезмәт хакы түләү һ.б. мәсьәләләрен кайгырта.

Минем үземә һәм минем гаиләмә ул бик нык булышты. Мин аның ярдәме белән ул җитәкчелек иткән докторлык советында диссертация якладым, ә соңыннан профессор булдым. Безнең кызыбыз Казан мәктәбен тәмамлап һәм Казан педуниверситетында кытай, рус, инглиз телләреннән югары белем алып, хәзер Кытайдагы абруйлы фирмаларның берсендә уңышлы эшли. Иремнең дә эше бар. Шулай итеп, Татарстан Республикасы минем икенче ватаныма әверелде.

Мин ректор Р.А.Юсупов һәм факультеттагы, кафедрадагы коллегаларым аркасында зур уңышларга ирештем. Алар турында якты истәлекләр, рәхмәт хисләре йөрәгемдә гомергә сакланыр.

**ХЕ ХУА**,
профессор

## ЯШЬ ПЕДАГОГЛАР ТЕАТРЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫ

Казан педагогика университетының «Мизгел» яшьләр театры үзенең эшен 1996 елның 1 сентябреннән башлап җибәрде. Әле дә хәтеремдә, 27 август көне иде. Мине университетның ректоры Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов үзе янына чакырып алды да: «Якташ, әйдә, без дә үзебездә театр учагы дөрләтеп җибәрик әле, — диде. — Авыл хуҗалыгы институтында яшьләр театры күптән эшләп килә. Нигә ул бездә булмаска тиеш? Ул безгә аларга караганда да кирәгрәк. Булачак укытучыга театр дөньясында катнашып, кайнашып йөрү бик кирәктер ул, минемчә. Укытучы класска утызлап бала алдына кереп баса. Үзеңне тота белергә кирәк, чөнки син — укытучы. Хәсрәтләрең булса — яшерергә, авырсаң — түзәргә... Балаларның күңелләренә миһербанлылык, мәрхәмәтлелек орлыкларын сала белергә кирәк. Һәм боларның барысын да тәрбияләргә, әлбәттә, театр сәнгате ярдәм итә. Тукай әйтмешли: «Театр яктылыкка, нурга илтә, кире юлга җибәрми, уңга илтә». Шулай диде Рүзәл әфәнде. Ул һәрвакыт безнең хәлебезне белешеп, ярдәм итеп торды.

Ректор, эше бик күп булуга карамастан, безнең ун ел буена куелып килгән спектакльләребезнең берсен дә калдырмады, һәркайсына килеп, карап, тамаша тәмамлангач, артистларны котлап чәчәкләр бирә, һәркайсын кабинетына чакырып чәй белән сыйлый, соңыннан премия бирә иде.

Без төрле пьесалар куйдык. Тәүге эшебез — Туфан Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» әсәре булды. Аннары Әнгам Атнабаев, Хәбиб Фәтхуллин, Хәй Вахит, Әмирхан Еники әсәрләре куелды, күбесе республика телевидениесендә кабат-кабат күрсәтелде.

Спектакльләребездә, татар филологиясе факультеты студентларыннан тыш, физика, музыка, математика факультеты укучылары һәм укытучылары да бик теләп катнашалар.

Театрыбызның шулай гөрләп яшәп ятуында иң беренче чиратта олуг рәхмәтебезне аңа нигез салган академик Рүзәл Юсуповка әйтәсе килә.

**Марсель ҖАББАРОВ**,
Россиянең атказанган,
Татарстанның халык артисты,
«Мизгел» театры җитәкчесе

## ОСТАЗЫМА РӘХМӘТЛЕ МИН

Мин — Рүзәл Абдуллаҗанович Юсуповтан фәнгә хәер-фатыйха алган күпсанлы шәкертләренең берсе. Академик Р.А.Юсупов җитәкчелегендә Казан дәүләт педагогика университетының аспирантурасына кергән вакытларымны сагынып искә алам. Фән юлында беренче адымнарым: көннәр буе китапханәләрдә утырулар, кочак-кочак китаплар укып чыгу, фәнни мәкаләләр һәм диссертация язу, конференцияләрдә докладлар сөйләү җиңел булмады. Бу катлаулы, ләкин кызыклы юл профессор Р.А.Юсупов җитәкчелегендә узылды. Ул миңа һәрвакыт кайгыртучан, ягымлы мөнәсәбәттә булды, гыйльми тикшеренүләремне оештыру, диссертация язу буенча файдалы киңәшләрен биреп килде, вакытын кызганмады.

Рүзәл Абдуллаҗанович минем кандидатлык диссертациясен «Инглиз, рус һәм татар телләрендә төсләрне белдерә торган компонентлы фразеологизмнар» дигән темага язарга тәкъдим итте. Бу тема кызык та, актуаль дә: беренче мәртәбә төрле төзелешле, генетик яктан кардәш булмаган телләрдә төсләрне белдергән фразеологик берәмлекләрне чагыштырып өйрәнүгә багышланган иде.

Мин җитәкчемә бу фәнни хезмәтне яклауга әзерләүдә булышуы өчен рәхмәтле. Ул, һәр бүлекне игътибар белән укып, камиллек дәрәҗәсенә җиткергәнче төзәтеп чыкты. Аның әһәмиятле киңәшләре эшне әйбәт итеп башкаруда ярдәм итте.

Профессор Р.А.Юсуповның Казан педагогика университетында тарихи, типологик һәм чагыштырма тел гыйлеме буенча докторлык диссертациясен яклау советы оештыруы һәм җитәкчелек итүе аның зур казанышы булды. Бу советның ике дистәдән артык ел эшләве дәверендә анда 500дән артык кандидатлык һәм докторлык диссертациясе якланды.

Яклау советы составына Россия һәм дөнья күләмендә мәгълүм академик Ә.Р.Тенишев кебек филолог галимнәр керде. Шундый абруйлы советта диссертация яклау минем өчен шатлыклы да, җаваплы да иде, әлбәттә. Совет členнары минем диссертациям белән кызыксынып танышып чыктылар, үземә карата да игътибарлы һәм итагатьле булдылар. Аларның мондый мөнәсәбәте мине канатландырып җибәрде. Совет председателе Р.А.Юсупов үтенече белән, минем беренче оппонентым булырга Россия Фәннәр академиясе академигы, Россия тюркологиясенең шаһы Әдһәм Рәхимович Тенишев ризалык бирде. Аның белән танышып очрашуларым минем гомеремдәге иң бәхетле һәм бер дә онытылмаслык вакыйгаларның берсе булды. Әдһәм Рәхимович, бик күп җитди эшләрен читкә куеп торып, минем диссертациямне яклауда катнашу өчен, Мәскәүдән Казанга килде һәм совет утырышында хезмәтемә уңай бәя бирде. Рәхмәтем чиксез аңа. Аның үзенә генә хас ягымлы елмаюлары һәрвакыт күз алдымда.

Рүзәл Абдуллаҗанович, диссертация яклаганнан соң да, мине игътибарыннан читтә калдырмады, кызыксынып, хәлемне белешеп торды. Аның акыллы киңәшләренең хәзерге фәнни-педагогик һәм административ эшләремдә файдасы тия. Аңа дәреслекләремнең һәм уку ярдәмлекләремнең редакторы булуы өчен дә рәхмәтем зур.

Рүзәл Абдуллаҗановичның табигатьтән бирелгән бер кыйммәтле сыйфатын әйтми кала алмыйм: ул күренекле галим, җәмәгать эшлеклесе һәм сәләтле оештыручы булуы белән бергә кешелекле, гади һәм эчкерсез кеше булып кала бelә. Мин моны күп фактлар белән раслый алыр идем. Минем күңелемдә аның белән очрашуларыбыз, аның фатирында тугрылыклы тормыш юлдашы Дилара ханым әзерләгән тәмле ризыклы табын янындагы җанлы әңгәмәләре кадерле хатирәләр булып саклана. Рәхмәт аларга!

Мин үземне Остазым, Гыйлем иясе һәм чын Кеше Рүзәл абый Юсупов белән очраштырган язмышымны бәхетле дип саныйм.

**Р.Р. ЗАКИРОВ**,<br>
Россиянең ислам академиясе проректоры

## БЕЗНЕҢ ЗУР РӘХМӘТЕБЕЗ

Казан педагогика университеты Урал һәм Идел буе халыкларына, шул исәптән чуваш халкына да, аң-белем бирүдә зур роль уйнады. Казан узган гасырда ук күп милләтле культура үзәгенә әверелә. Монда чуваш телендә беренче әлифба басыла, беренче чуваш газетасы «Хырпар» дөнья күрә, беренче профессиональ чуваш театры оештырыла.

Чуваш халкының күп кенә күренекле әдәбият һәм мәдәният эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты Казан белән бәйле. Монда А.С.Пушкинның дусты И.Бичурин укыган, чуваш халкының мәгърифәтчесе И.Я.Яковлев белем алган, чуваш теле галиме, 17 томлы чуваш сүзлеге төзегән Н.И.Ашмарин яшәгән һәм эшләгән. Революциядән соңгы чорда педагоглык эше белән профессор Н.В.Никольский, күренекле лингвист В.Г.Егоров, тарихчы Г.И.Комиссаров-Вантер шөгыльләнгәннәр. Татарстанның уңдырышлы җирендә бер төркем талантлы язучылар — Таэр Тимкки, И.Ю.Юркин, халык шагыйрьләре Педер Хузангай, Н.Полоруссов-Шелебы, Александр Алга һәм башка шундый кешеләр үсеп чыккан.

Беренче татар ректоры Г.Х.Камай югары квалификацияле милли кадрлар әзерләү, чуваш теле һәм әдәбияты бүлеге ачу турында сүз алып барган. Әмма мондый хыялларга тормышка ашу насыйп булмаган.

Һәм менә, ниһаять, бу авыр йөкне үз өстенә Казан педагогика университеты алды. Татарстандагы чуваш диаспорасы — 140 мең кеше — Р.А.Юсуповка чуваш бүлеге ачуы өчен бик зур рәхмәтле.

Бөтен чуваш җәмәгатьчелеге бу хәбәрне бик шатланып каршы алды. Без университет администрациясенә чуваш теле һәм әдәбияты кабинетына бина бирүе өчен дә рәхмәт әйтәбез.

Казан педагогика университеты Татарстандагы чуваш мәктәпләре өчен педагогик кадрлар әзерләү традицияләрен яңартып җибәрде.

Мин КДПУда чуваш бүлеге ачуда академик Р.А.Юсуповның аеруча зур роль уйнавын билгеләп үтәр идем. Монда аның Татарстанның башка халыклары арасында лаеклы урын тоткан чуваш халкының мәгърифәтен һәм мәдәниятен торгызу эшен сүздә генә түгел, чын-чынлап кайгыртуы күренә. Рүзәл Абдуллаҗановичка, Казан педуниверситеты коллективына зур рәхмәт!

**В.ТИХОНОВ**,
чуваш газетасы «Сувар»
редакторы урынбасары

## КЕМ ӨЧЕН ТАВЫШ БИРЕРГӘ?

Тиздән без хакимиятнең республика, шәһәр һәм район органнарына депутатлар сайлап куячакбыз.

Һәр сайлаудан соң, депутатларның сайлау алдыннан биргән вәгъдәләре үтәлмәвен күреп, без бит аларны үзебез сайлап куйдык, дип үкенәбез. Димәк, кемгә тавыш бирәсеңне яхшылап уйлап куярга кирәк. Менә хәзер квартираларга депутатлыкка кандидатларның биографияләре белән программалары бастырылган листовкалар таратып чыктылар.

Кайберәүләр, административ урын биләп, районны җылылык, электр энергиясе һ.б.ш. белән тәэмин итәргә тиешле кешене тәкъдим итәләр. Әгәр дә ул моны эшләмәсә, нигә ул андый администратор, һәм ни өчен ул зур хезмәт хакы алып утыра? Андый листовкаларны укып, без, кемгә тавыш бирергә икән, дип уйга калдык.

Икенче бер төрле листовкада безнең игътибарны менә нәрсә җәлеп итте: республиканың Дәүләт советына депутатлыкка 5 нче номерлы Мәскәү административ-территориаль округ буенча кандидат Казан педагогика университеты ректоры Юсупов Рүзәл Абдуллаҗанович үзенең программасында, Татарстан анда яшәүче барлык халыклар өчен дә үз ватаннары булып калырга тиеш, ди. Димәк, ул, бездә икенче Карабах та, икенче Чечня да булырга тиеш түгел, дип әйтә.

Ул, Татарстанның үткән чакырылыш Югары Советы депутаты булганда да, шундый ныклы караштa торды, безнең республикада ике дәүләт теле турында закон кабул итү яклы булды. Безгә аның программасындагы депутатлар корпусы турындагы карашы ошый. Депутатлар гадел, тормышны һәм закон чыгару практикасын белгән, кабул иткән закон һәм карарларның үтәлүенә ирешү өчен тырыша торган кешеләр булырга тиеш.

Без менә шундый кешеләрне сайлап куярга кирәк дигән карарга килдек.

Без ышанабыз: Р.А.Юсупов ветераннарны, пенсионерларны, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният хезмәткәрләрен социаль яклый торган законнар кабул итү өчен тырышачак. Профессор Р.А.Юсуповка сайлау алды көрәшендә уңышлар телибез! Тик ул көрәш тигез һәм гадел булсын иде.

Берәр җыелышта бу округ кандидатларын тыңлап карасаң яхшы булыр иде. Кемнең кем икәнлеге менә шунда күренер.

Мәскәү районы сайлаучылары:
**А.И. ДАВЫДОВА**, Бөек Ватан сугышы ветераны;
**З.А. НЕФЕДЬЕВА,** шәфкать туташы;
**Т.Н. ПАНЯЕВА,** хезмәт ветераны;
**Л.Н. СМИРНОВА**

## ЗАКОН ӘЗЕРЛӘҮ — БЕЛЕМЛЕ КЕШЕЛӘР ЭШЕ

Татарстан Республикасының Дәүләт Советына депутатлыкка 5нче номерлы Мәскәү сайлау округы буенча кандидат итеп Казан дәүләт педагогика университеты ректоры Р.А.Юсуповның күрсәтелүе хәбәрен мин зур канәгатьләнү белән кабул иттем.

Рүзәл Абдуллаҗанович — республика парламенты депутатына лаеклы кандидат. Ул — күренекле галим, академик, күп китаплар, дәреслекләр авторы. Дәүләт бүләкләре бар.

Р.А.Юсуповның сәяси һәм оештыру тәҗрибәсе зур. Ул күп еллар дәвамында төрле дәрәҗәдәге җитди эшләр башкарган. ТР Югары Советы депутаты буларак, ул берничә бик әһәмиятле законны төзүдә һәм кабул итүдә актив катнашты. Р.А.Юсупов — «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы законның проектын әзерләгән кеше.

Минемчә, законнар белән күренекле галимнәр, юристлар, сәясәтчеләр шөгыльләнергә тиеш. Р.А.Юсупов — шундый галим һәм сәясәтче.

Администрация башлыклары, вакытларын янәсе законнар әзерлибез дигән бу-

лып парламентта үткәрмичә, көчләрен һәм акылларын күбрәк районнардагы көндәлек тормыш мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлтсәләр, дөрес булыр иде. Законнарны тиешле белемнәре булган кешеләр чыгарсын.

Мин районыбызда яшәүчеләрне тавышларын Р.А.Юсупов өчен бирсеннәр дип өндим! Аны сайлап куйсак, безнең мәнфәгатьләребезне яклаучы кеше булыр.

**Е.В. МАЛЯВИНА**,
Мәскәү районында яшәүче

## ИҢ ЛАЕКЛЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ

Яңа парламент, республика халыкларының язмышы өчен борчыла торган принципиаль, үз эшләрен яхшы белгән, актив кешеләрдән торса, җәмгыятьне яңарту бурычларын уңышлы хәл итәр.

Борынгы акыл иясе Платон (безнең эрага кадәр V—VI гасырлардагы Грециядә) «хакимият философлар, зур акыл ияләре кулында булырга тиеш, чөнки чын гыйлемлек һәм изгелек бары шушы сирәк кешеләргә генә хас» дип әйткән.

Татарстанның Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат, безнең Казан дәүләт педагогика университеты ректоры Рүзәл Абдуллаҗанович Юсупов нәкъ менә шундый кешеләр исәбенә керә, дип, нык ышанып әйтергә мөмкин. Аңа мондый сыйфатлар хас:

— төпле аналитик фикерләү һәм галимнәрдә була торган киңкырлы белем;

— инициативалылык һәм ТР парламенты депутаты булып эшләвенең бай тәҗрибәсе;

— зур активлык һәм киләчәк буынны тәрбияләүче педагогларны әзерләүгә багышланган зур оештыру эше.

Университет ветераннары исеменнән академик Р.А.Юсупов кандидатурасын яклыйбыз һәм университет студентларына, укытучыларына һәм сотрудникларына, мәгариф хезмәткәрләренә, Мәскәү районында яшәүче барлык кешеләргә тавышларын Рүзәл Абдуллаҗанович Юсуповка бирүләрен үтенеп мөрәҗәгать итәбез.

Ветераннар:
**АСЕЕВА Н.К., ЛЕБЕДЕВА Л.А., ЛУКМАНОВ Г.Л., МОРОЗОВ М.И., МУНЬКОВ Н.П., ПЕТРОВА Н.И., ХУДЯКОВ В.П., БИКМЕТОВА Р.М., ГАЗИЗОВ Б.Г., ГАТАУЛЛИН Р.В., ИСХАКОВА М.С.**

## ТӘҖРИБӘЛЕ, АБРУЙЛЫ, УКЫМЫШЛЫ

Мәскәү районындагы безнең 5нче номерлы административ-территориаль округ буенча Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп Рүзәл Абдуллаҗанович Юсупов күрсәтелде. Мин турыдан-туры аның үзе белән таныш түгел, ләкин без якташлар — бер республиканың бер районыннан. Мин аның зур гаиләдә кече яшьтән үк авыр эшләр, җитешсезлек, кыенлыклар күреп үскәнлеген беләм. Шуңа күрә ул күп балалы гаиләләрнең, пенсионерлар, ялгыз карт кешеләрнең, ярлы студентларның тормыш хәле авыр икәнлеген яхшы аңлый. Бу аның республика телевидениесе, радиосы һәм матбугатында ясаган чыгышларында ачык күренә.

Минем танышларым һәм дусларым арасында Казан педагогика университеты студентлары һәм укытучылары, шулай ук Рүзәл Абдуллаҗановичны парламенттагы эше буенча белгән кешеләр бар. Шулардан ишетеп, мин аның хезмәт сөючән, гадел, миһербанлы кеше, яхшы педагог, зур галим һәм инициативалы, иҗади, абруйлы җитәкче буларак беләм. Мин якташымның хезмәте һәм сәяси эше белән күптән кызыксынып киләм. Һәм аның үз көче һәм акылы белән зур уңышларга ирешүенә шат.

Миңа аның Югары Совет сессияләрендә чыгыш ясаулары ошый. Алар һәрвакытта да сәяси яктан уйланылган, дөрес, ышандырырлык һәм конструктив тәкъдимнәр белән баетылган була. Рүзәл Абдуллаҗанович дәүләт телләре турында закон проектын әзерләүдә катнашты һәм аны парламент сессиясендә кабул итүне оештырды. Хәзер безнең республикада ике тигез дәүләт теле — татар һәм рус телләре булуда Р.А.Юсуповның роле зур.

Хөрмәтле гражданнар! Тиздән булачак сайлауда тавышыгызны башка кандидатлар арасында аеруча тәҗрибәле, абруйлы, укымышлы академик Р.А.Юсуповка бирергә өндим. Мин ышанам: ул безнең яхшы яшәвебез, республикабызда тынычлык һәм дуслык өчен тырыша торган депутат булачак. Без тавышыбызны Р.А.Юсупов өчен биреп, балаларыбыз һәм оныкларыбызның киләчәге якты булыр, аларны укыту һәм тәрбияләү системасы яхшырыр дигән өмет белән калабыз!

**Т.Б. БОРҺАНОВ**

## ТУГРЫ ХЕЗМӘТ ИТӘР!

Без, Татарстан Республикасының мәдәният, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, академик Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелүен чын күңелдән яклыйбыз. Ул халыкка Казан дәүләт педагогика университеты ректоры, күренекле галим, дистәләгән китаплар авторы буларак

кына түгел, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе буларак та яхшы билгеле. Аның парламент сессияләрендәге, матбугат битләрендәге, радио-телевидениедәге актуаль мәсьәләләргә багышланган күпсанлы чыгышлары принципиаль, төпле фикерле, шул ук вакытта нык уйланылган була. Р.А.Юсупов һәрвакыт халыклар дуслыгын ныгыту, аларның мәдәният, тел һәм диннәрен үстерү өчен тигез шартлар тудыруны яклый.

Без ышанабыз, Рүзәл Юсупов яңа парламентта да республикабызга тугры хезмәт итәр һәм Татарстан халыкларының бәхетле яшәве өчен белемен, көчен һәм бай тәҗрибәсен кызганмас.

**Гомәр БӘШИРОВ**, Татарстанның халык язучысы, Тукай бүләге лауреаты;
**Туфан МИҢНУЛЛИН**, драматург, Тукай бүләге лауреаты;
**Әнвәр БАКИРОВ**, композитор, Тукай бүләге лауреаты;
**Фасил ӘХМӘТОВ**, композитор, М.Глинка һәм Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләкләре лауреаты;
**Илһам ШАКИРОВ**, Татарстан һәм Россиянең халык артисты, Тукай бүләге лауреаты;
**Рафаэль ИЛЬЯСОВ**, Татарстанның халык артисты;
**П.П.БЕТЕВ**, Россиянең халык артисты;
**Г.С.ИШКОВА**, Россиянең халык артисты;
**М.И.МӘХМҮТОВ**, академик;
**Ф.М.ПАНТЮШИН**, Татарстанның халык артисты;
**Г.М.ПЕРВИН**, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе;
**Г.Н.ПРЫТКОВ**, Татарстанның халык артисты;
**А.Я.СЛАВУТСКИЙ**, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе

## ШАРТЛАР БЕРТИГЕЗ БУЛМАДЫ

Закон буенча депутатлыкка кандидатларның барысы өчен дә шартлар бертигез булырга тиеш... Ләкин безнең Мәскәү округында закон баштан ук бозылып килде. Бу тәртипсезлек 5нче Мәскәү административ-территориаль округта депутатлыкка кандидатлар күрсәтүдән башланды. Мин моны ике кандидат мисалында раслый алам. Аларның берсе — Мәскәү районы администрациясе башлыгы И.Б.Фаттахов, икенчесе — Казан дәүләт педагогика университеты ректоры Р.А.Юсупов. И.Б.Фаттаховны яклау өчен, бөтен район администрациясе аппараты, барлык предприятиеләр эшкә җигелде.

Мәктәпләрдә ашыгыч рәвештә ата-аналар җыелышлары уздырылды. Моннан тыш, укытучылар, йортлар буенча кереп, имзалар җыйдылар. Заданиене үтәмәсәң нәрсә буласын яхшы беләләр алар.

Ә менә Р.А.Юсупов кандидатурасын күрсәтү барышында кешеләрне 65нче мәктәпкә кертмәүләрен үзем күреп тордым, хәлбуки анда кандидат күрсәтү буенча җыелыш үткәрү турында алдан килешенгән булган. Шактый нык тарткалашканнан соң, җыелыш барыбер булды, тик ашханә бинасында гына: башка бүлмәләрне бикләп куйганнар иде. Очрашу вакытында Фаттахов кешеләре аны өзәргә маташып карадылар.

Шулай да алар җыелышны туктата алмады, чөнки сайлаучылар Р.А.Юсуповны моңарчы булган депутатлык эшеннән яхшы беләләр, аның республика халыкларының тормышын яхшырту өчен тырышуын югары бәялиләр иде. Җыелыш үткәрелде. Кандидатура күрсәтелде.

Мин үзләрен хөрмәт иткән барлык сайлаучыларны да тавышларын Рүзәл Абдуллаҗанович Юсуповка бирергә өндим.

**Т.Х.НИЗАМЕТДИНОВА**

## ЫШАНЫЧ КАНАТЛАНДЫРА

Кече яшьтән үк укытучым Александр Анатолевич Павлюхин (ул безнең факультетта укып чыккан) минем өчен үрнәк булды. Мин һәрвакытта да бераз гына булса да аңа охшарга, «акыллылык, изгелек чәчеп» яшәргә тырышып йөрдем. Педагогика институтында уку, чит тел укытучысы булу теләге күңелемә кереп, тынычлык бирмәде. Ләкин безнең мөмкинлекләр теләкләребезгә туры килеп бетми икән шул: авыл мәктәбендәге шартлар, дәреслекләр булмау, яраткан инглиз телендә сөйләүчене тыңлап кына карап та булмау хыялларымны тормышка ашыруга комачаулап килде.

Бәхетемә, безнең авылга Казан педагогика институтыннан бер укытучы килеп чыкты! Минем өчен нинди зур шатлык булды ул! Мин институтка керү таләпләрен белдем, кабул итү имтиханнарына әзерләндем һәм... керә алмадым. Балларым җитмәде. Ничә еллар хыялланып йөрүләрем җилгә очты. Ләкин бик тырышсаң, мәсьәләне хәл итү өчен мөмкинлек табыла. Институтка договор белән кереп була икән. Бу турыда абитуриентлар җыелышында институт ректоры Рүзәл Абдуллаҗанович Юсупов сөйләде. Бу кешене мин беркайчан да онытмам. Ул минем хәлне аңлап, мине договорлылар группасына кертеп, студент итеп алды. Ләкин уку өчен акча түләргә кирәк бит. Ә ул минем юк, һәм мин, ректор янына кереп, аңа үзем-

неӊ кайгымны сөйләдем. Һәм минем өчен өмет уты күренде: мине бер елдан соӊ түләү шарты белән договорлы группага керттеләр. Беренче курста, миӊа күрсәткән ышанычны аклау өчен, бөтен көчемне биреп тырыштым. Башта билгеләрем төрле булды: «өчле»ләр дә, «дүртле»ләр дә бар иде, әмма азакка таба төп фәннәрдән «бишле» билгеләре дә ала башладым.

Бер ел узып китте. Мин яӊадан ректор янына әӊгәмәгә кердем. Бу юлы ул мине яхшы укуым өчен мактап алды һәм, ышанычны аклаган студент буларак, договорсыз группа исемлегенә кертте.

Ул миӊа, минем тырышлыгыма ышанды. Ә ышаныч кешегә мораль яктан көч бирә, канатландыра. Һәм мин ректорның ышанычын институтта бик яхшы укып һәм мәгариф өлкәсендә уӊышлы эшләп акладым. Зур рәхмәт һәм изге теләкләр Сезгә, хөрмәтле Рүзәл Абдуллаҗанович!

**Алевтина ГОРБАЧ**

## ЯРДӘМЧЕЛ КЕШЕ

Институт бусагасын әле күптән түгел генә атлап кергән идек кебек. Һәм менә дүрт ел үтеп тә киткән инде. Шулай тиз уза икән вакыт... Күпме үзгәрешләр булган бездә бу елларда! Иӊ зурысы — пединститут университетка әверелде. Дүрт ел элек безнеӊ 7нче бина нинди хәлдә иде?! Ярым черек идәннәр, бина каршында ярым җимерек койма, буяулары, штукатуркалары купкан стеналар... Кыскасы, кәефне җибәрә торган ямьсез күренеш. Бу елларда безнеӊ бина, аудиторияләр бөтенләй үзгәрде: матур итеп буядылар, агарттылар, вестибюльдә мәрмәр идән җәйделәр. Бик яхшырды уку урыныбыз. Бу — ректорыбыз Рүзәл Абдуллаҗанович Юсуповның зур хезмәте нәтиҗәсе.

Болары — бөтен факультет өчен эшләнгән эшләр. Рүзәл Абдуллаҗановичның студентларны кайгыртып, проблемаларын хәл итәргә тырышу, кирәк чакта аларга булышу сыйфатын да әйтеп китәргә кирәк. Минем үземә, ярдәм сорап, ректорыбызга берничә тапкыр мөрәҗәгать итәргә туры килде. Һәм ул миӊа мораль яктан гына түгел, материаль яктан да ярдәм итте.

Зур рәхмәт аӊа һәм сәламәтлек, уӊышлар телим!

**Юлия ЯКИМОВА**,
рус филологиясе
факультеты студенты

# ТӘБРИКЛӘҮЛӘР ҺӘМ ТЕЛӘКЛӘР


1 декабря 2008

## БӘХЕТЛЕ ҺӘМ ӨЛЕШЛЕ БУЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Исемеңә җисемең туры килешле:
Рүзәл — фарсыча бәхетле, өлешле.

Бәхетле дә, өлешле дә булгансың,
Башкаларны да бәхетле кылгансың.

Тормышың сиратларын кичә-кичә,
Шөкер, имин җиттең бу көннәргәчә.

Хөсетлеләр дә очрады юлларда,
Теләделәр берчак төртеп егарга.

Шөкер, сираттан егылып төшмәдең,
Саклагандыр кылган изге эшләрең...

Әйе, язмыш сынап тора безләрне,
Юлда арып егълап кала кемнәрдер...

Көчле рухлылар сынмый еласа да,
Торып баса кайвакыт егылса да.

Әнә шундый сирәкләрнең берсе Син,
Ил агасы — зирәкләрнең күрке Син.

Ходай биргән гомерне ахыргача
Кичәр өчен ныклык кирәк ласа.

Бәхетле һәм өлешле булыйм дисәң,
Син халкыңа игелекләр кыл икән...

Казан университетында
бер группада гыйлем эстәгән
сабакташың, дустың **Шамил МАННАПОВ**

## ПРОФЕССОР РҮЗӘЛ АБДУЛЛАҖАН УЛЫ ЮСУПОВКА

«Алтмыш яшь ул — егет чак!» дип,
Сез яулыйсыз фән үрен.
Кем дип дәшик: ректор дипме?..
Аннан да зур Сез бүген.

Халык депутаты булып,
Ирек яулап йөрисез.
Фәннәр академиясенең
Әгъзасы да бүген Сез.

Үрнәк әти, тугры ирне
Гаиләгез сәламләр.
Мөгаллимнәр йөрәгендә
Сез кабызган дәвам бар.

«Без бит Арча яклары» дип,
Хаклы горурланасыз.
Нурны исә Сәйдәшләрдән,
Тукайлардан аласыз.

Республика партиясенең
Еракка китә даны.
Сездәй ир-егетләр шулай
Абруйлы итә аны.

Кешенең кешелеклелеген
Билгели кылган эше.
Кыйблабыздан тайпылмабыз
Булсак без Сезнең ише.

«Илле биш яшь — егет чак!» — дип
Дәшәләр Сезгә бүген.
Хезмәтегез гел шулай
Балкытсын илем күген.

**«Татарстан Республикасы»**
**газетасы редакциясе коллективы**

## РҮЗӘЛ АБЫЙГА ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН

Рәт-рәт еллар, текә юллар булып,
Үрдән үргә чөйгән егетен,
Зәһәрлегең, егәрлегең җитсә,
Әйдә, эзлә, диеп, бәхетең.

Ләззәт табып кылган гамәлләрдән
Гомер итү иде өмете,
Акыл белән килгән биеклекләр
Бөек итте Кышкар егетен.

Дусларына тугры була белә,
Ул аера агын-карасын!
Лә Иллаһу, Тәңре саклый күрсен,
Лабиринтсыз күңел хуҗасын.

Азмы юллар тау-таш аша ятты,
Җан канаты килде ярдәмгә,
Академик, шәхес, ил агасы —
Намын язды язмыш галәмгә.

Уй-фикере — чумып чыгалмаслык,
Ләм утырмас тирән дәрьядай,
Ышанычлы, әйткән сүзе — казык!
Юсуповлар шундый дөньяда.

Сөләйманнан булсын, дип, бер ядкәр,
Укучыгыз булып, мең санлап,
Пакь хисләргә төреп язган юллар
Озын гомер бирсен, Иншалла.
Вә әйтсеннәр: «Шәхес — машалла!»

**Җәүдәт СӨЛӘЙМАНОВ**,
Татарстан Республикасының
Фәннәр академиясе академигы

## ГОМЕРНЕҢ ҮЗ МАТУРЛЫГЫ

*Рүзәлгә юбилей уңае белән*

Күзләрнең үз матурлыгы,
Моңайма җәең узганга.
Учакларның чал көлендә
Кузлар куя кузгалып...

Озакламый ярты гасыр менә
Сабакташлар яши җанында.
Дусларыңа шулай тугры калу —
Лотфикамал апа каныннан.

Биш баһадир биргән әнкәеңнең
Гамәлләре хәйран калырлык.
Һәрбер улы — изге җанлы татар,
Һәммәгездән үрнәк алырлык.

Күпме шәкерт каршы ала сине:
«Рүзәл абый!» — диеп, үз итеп.
Кандидаттан доктор ясыйсың да,
Рәхмәт ява аннан күп итеп.

Фән юлы ул акча юлы түгел,
Табынмадың малга, алтынга.
Бар хезмәтең — фәнгә, кешеләргә,
Яшәвең дә халкың хакына.

Дәртләреңә дәрман булсын еллар,
Акыллыдан чыга ул хикмәт.
Гомер озынлыгы бергәлектә,
Безнең бергәлекләр, һай, кыйммәт!

Күзләрнең дә үз матурлыгы,
Үзенчә бит гүзәл бу көннәр...
Бәхет кошың белән гомерлеккә
Берексеннәр сезнең күңелләр.
Саулык, шатлык, бәхет,
Тигез тормыш теләп бу көндә
Бүләк итәм Сезгә ак гөлләр...

**Фарсель ЗЫЯТДИНОВ**

## РҮЗӘЛГӘ МӘДХИЯ

***Рәгъде Халит** музыкасы*
***Әхмәт Гадел** шигыре*

И бөек, кабул кыл бу сүзне,
Мактыйбыз иң лаек кешебезне:
Син барда милләт тә саф йөзле,
Күрәсең һәрдаим эшебезне.

Кушымта:
Мөгаллим, Син — зур галим, Рүзәл,
Нур чәчә күңелең яктысы.
Самими сәламле һәм сәлим,
Бер йолдыз — кояшның чаткысы.

Чын егет — татарның нык улы,
Син лаек мактауга һәм хөрмәткә.
Син нурлы — ил нурлы, җир нурлы,
Синдәйләр юл куймас зөлмәткә!

Гомерең диңгезен гизгәндә
Сүнмәсен елмаю йөзеңдә.
Син нурлы булганда — без нурлы,
Шатлыктан балкы Син, и Рүзәл!

## ЯНЫП-КӨЕП ЭШЛӘДЕК

Миңа затлы, олы шәхес Рүзәл абый белән бер коллективта, аның белән бергә бер командада эшләү бәхете насыйп булды. Аның ректорлыгы чорында миңа татар факультетының деканы, кафедра мөдире булып хезмәт куярга туры килде. Без аның белән бергә эш өчен, сыйфат өчен янып-көеп эшләдек. Рүзәл абый һәрвакыт кешеләрдәге эшлекле сыйфатларны күрә, бәяли белә, ул потенциалны ачарга, андыйларны үстерергә тырыша. Ул кешеләргә ышана. Коллегаларыннан эшне — зурмы ул, кечкенәме — нинди генә эш булмасын, чын-чыннан җаваплылык, тырышлык, намус белән, сыйфатлы итеп башкаруны таләп итә. Рүзәл абыйны мин эш өчен, аның сыйфатын күтәрү, яңарту, камилләштерү өчен ихлас күңелдән тырышып, жа-

ны-тәне белән бирелеп, борчылып, вакытын, сәламәтлеген, сәләтен, үз-үзен жәлләмичә, бөтен барлыгын биреп эшли торган фидакяр зат дип беләм.

Рүзәл абый ул — якты кеше, якты шәхес. Аның күңеле якты, уйлары, теләкләре якты! Аннан ниндидер бер илаһи яктылык, матурлык бөркелеп, сирпелеп тора! Ләкин шул ук вакытта Рүзәл абыебыз бик нечкә күңелле кеше. Күңеле нечкә, уйламыйчарак әйтелгән бер сүз, бер җөмлә, уйламыйчарак кылынган бер гамәл аның күңелен шундый кырырга мөмкин: ул күңел сиңа ничек ачылса, шулай ябыла да ала. Ләкин барыбер ул кешеләрне кичерә, аларга ачык, хәерхаклы булып кала, кешеләрне ярата. Киң күңелле кеше ул Рүзәл абый!

Никадәр зур кеше булса, шулхәтле үк кечелекле дә була белә ул. Коридордан үткәндә очратып, тукталып, шушы чал чәчле олы шәхес, ачылып китеп, елмаеп, эчкерсез синең хәлеңне сораша, эшләрең, гаиләң, балаларың белән кызыксына, проблемаларың белән уртаклаша.

Тагын шуны әйтер идем: Рүзәл абый — кешеләргә игелекле кеше. Нинди ярдәм, киңәш сорап килсәң дә, үзенә авырлык килсә — килә, барыбер җаен табарга, сиңа ярдәм итәргә, яхшылык кылырга тырыша.

Хөрмәтле Рүзәл Абдуллаҗанович! Кадерле Рүзәл абыебыз! Телебездә «егет кеше» дигән гыйбарә бар. Сез һәрвакыт, һәр эштә, һәр җирдә, һәркайчан егет кеше булдыгыз! Бүген дә Сез егетләрчә җитез, энергияле, сау-сәламәт, чибәр, күркәм, эшлекле! Шулай булсын алга таба да!

**Э.Р. ГАЛИЕВА,**
профессор

## ВАЖНЕЙШИЕ ДАТЫ ЖИЗНИ Р.А.ЮСУПОВА

14.09.1938. Родился в селе Кышкар Атнинского (ныне Арского) района Татарстана.

1946—1952. Ученик Кышкарской семилетней школы.

1952—1955. Учащийся Казанского кооперативного техникума.

1955—1957. Товаровед Усть-Уйского райпотребсоюза Курганской области.

1957—1960. Военнослужащий пограничных войск.

1960—1965. Студент Казанского государственного университета.

1964—1967. Переводчик и редактор Комитета по радиовещанию и телевидению при Совете Министров ТАССР.

1967. Вступление в Союз журналистов СССР.

1967—1970. Аспирант Казанского государственного педагогического института.

1970. Защита кандидатской диссертации.

1970—1983. Ассистент, старший преподаватель, доцент Казанского педагогического института.

1982. Защита докторской диссертации в Институте русского языка Академии наук СССР.

1983—1986. Профессор, декан историко-филологического факультета Казанского педагогического института.

1986—2002. Ректор Казанского педагогического университета.

1986—2012. Заведующий кафедрой татарского языкознания КГПУ, ТГГПУ, КФУ.

1986. Награждён медалью «За трудовую доблесть».

1987—2003. Член редколлегии республиканского журнала «Магариф».

1988. Делегат Всесоюзного съезда работников народного образования.

1988. Награждён Почётной грамотой Татарского обкома КПСС и Совета Министров ТАССР.

1989—1990. Депутат Казанского городского совета народных депутатов, председатель постоянной комиссии по образованию.

1989. Член комиссии Верховного Совета Татарстана по подготовке проекта «Закона о языках народов Татарстана».

1989. Награждён медалью «Ветеран труда».

1989. Присвоено почётное звание «Заслуженный деятель науки Татарской АССР».

1990—1995. Депутат Верховного Совета Татарстана, председатель постоянной комиссии по национальным вопросам и культуре, член президиума Верховного Совета Татарстана.

1990. Член Конституционной комиссии Татарстана.

1992. Член Исполкома Всемирного конгресса татар.

1992. Избран членом-корреспондентом Академии наук Татарстана.

1992. Председатель общества дружбы «Татарстан — Арабский Восток».

1992—1995. Председатель Республиканской партии Татарстана.

1992—2002. Председатель научно-методического совета по преподаванию на татарском языке и татарского языка в высшей школе.

1992. Учреждена газета Республиканской партии Татарстана — «Татарстан Республикасы».

1992—2003. Член редколлегии республиканской газеты «Мәгърифәт».

1992—1995. Член редколлегии республиканской газеты «Заман».

1993. Присуждена первая премия братьев Кашаповых (по результатам конкурса на лучшие публикации).

1994. Избран действительным членом Международной Академии информатизации.

1995. Назначен председателем совета по защите докторских диссертаций.

1995. Присвоено звание действительного члена (академика) Академии гуманитарных наук.

1995. Почётный председатель Республиканской партии Татарстана.

1996. Присвоено звание действительного члена Международной педагогической академии.

1996. Удостоен звания «Человек года—95» по результатам опроса читателей газеты «Шәһри Казан».

1997. Международным биографическим институтом Америки и Международным биографическим центром Кембриджа (Англия) присвоено почётное звание «Человек года—97».

1997. Член редакционного совета научно-информационного журнала «Фән һәм тел» («Наука и язык»).

1998. Лауреат премии «За укрепление межнационального согласия», учреждённой газетой «Республика Татарстан».

1998. Присуждена Государственная премия Республики Татарстан в области науки и техники.

1999. Награждён нагрудным знаком «За заслуги в образовании» Министерства образования РТ.

2001—2002. Член редколлегии журнала «Татарстан».

2001 — по наст. время. член редколлегии журнала «Милли мәдәният».

2002. Награждён нагрудным знаком «Почётный работник высшего профессионального образования» Министерства образования Российской Федерации.

2005. Указом Президента РФ от 30.06.2005 г. награждён медалью «В память 1000-летия Казани».

2007. Избран действительным членом (академиком) и вице-президентом Академии наук Татарстана.

2008. Награждён медалью «За доблестный труд».

2008. Присвоено звание «Почётный профессор Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета».

2013. Присвоено звание «Заслуженный профессор Казанского федерального университета».

# Р.А.ЮСУПОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕҢ ИСЕМЛЕГЕ

## Монографияләр

1. *Тәрҗемә мәсьәләләре*. — Казан: Татар. китап нәшр., 1975. — 128 б.

2. *Тәрҗемә һәм тел культурасы*.— Казан: Татар. китап нәшр., 1978. — 128 б.

3. *Лексико-фразеологические средства русского и татарского языков*. — Казань: Таткнигоиздат, 1980. — 256 с.

4. *Икетеллелек һәм сөйләм культурасы.* — Казан: Татар. китап нәшр., 1987. — 214 б.

5. *Инсафлының теле саф*. — Казан: КДПИ, 1993. —164 б.

6. *Җылы сүз җан эретә.* Дөрес сөйләм турында язмалар. — Казан: Татар. китап нәшр., 1996. — 159 б.

7. *Әдәп башы — тел.* Икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре. — Казан: КДПУ, 2000. — 218 б.

8. *Икесен дә яхшы бел*. — Казан: Мәгариф, 2000. — 191 б.

9. *Синтагматические отношения лексических единиц русского и татарского языков*. — Казань: КГПУ, 2002. — 178 с.

10. *Икетеллелек һәм сөйләм культурасы.* Фәнни-популяр язма. — Казан: Татар. китап нәшр., 2003. — 222 б.

11. *Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода*. — Казань: ТГГПУ, 2005. — 227 с.

12. *Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи.* — Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. — 384 с.

13. *Мәгълүмат чаралары теле һәм сөйләм культурасы*. — Казан: ТДГПУ, 2007. — 193 б.

14. *Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы.* — Казан: Татар. китап нәшр., 2008. — 239 б.

15. *Общее и специфическое в разноструктурных языках*. — Казань: ТГГПУ, 2009. — 298 с.

16. *Теория и практика перевода*. — Казань: ТГГПУ, 2010. — 366 с.

17. *Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре*. — Казан: ТДГПУ, 2011. — 312 б.

18. *Тәрҗемә мәсьәләләре.* — Казан: КФУ, 2012. — 254 б.

19. *Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре*. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. — 287б.

20. *Дөрес тәрҗемә итик*. — Казан: ТФАнең Тарих институты, 2015. — 216 б.

21. *Телебезне ялгыш тәрҗемәдән саклыйк.* — Казан: ТФАнең Тарих институты, 2016. — 291 б.

22. *Матбугат һәм эфир теле.* — Казан: ТФАнең Тарих институты, 2017. — 318 б.

## Дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре

1. *Көтәбез сезне, укытучыбыз*. — Казан: Тат. китап нәшр., 1968.

2. *Тәрҗемә теориясенә кереш* (Методик кулланмалар). — Казан: КДПИ, 1972. — 88 б.

3. *Теория и практика перевода*. Программа для студентов отделения «Русский язык с педагогикой». — Казань: КГПИ, 1978. — 20 с.

4. *Төрле структуралы телләрдәге гомумилек*. Махсус курс буенча методик ярдәмлек. — Казан: КДПУ, 1981. — 32 б.

5. *Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү*. Укытучылар өчен ярдәмлек. — Казан: Татар. китап нәшр., 1983. — 136 б.

6. *Төрле структуралы телләрдә гомуми элементлар*. Махсус курс буенча методик күрсәтмә. — Казан: Казан пед. институты, 1984. — 29 б.

7. *Теория и практика перевода.* Программа. — М.: Мин-во просвещения СССР, 1984.

8. *Теория и практика перевода*. Программа для педвузов. — Л.: Просвещение, 1985. — 20 с.

9. *Введение в теорию и практику перевода.* Учебное пособие. — Казань: КГПИ, 1988. — 96 с.

10. *Рус мәктәпләренең I—X класслары өчен татар теле һәм әдәбияты про-*

*граммасы*. — Казан: Татар. Мәгариф министрлыгы, 1989. — 49 б. (автордашлар: Н.Х.Нәбиуллина, Х.Г.Фәрдиева).

11. *Татар теле*. Унберьеллык урта мәктәпнең 5 классы өчен дәреслек (Татарский язык. Учебник для 5 класса средней школы). — Казан, 1991. — 214 б. (автордашлар: К.З.Зиннәтуллина, Т.М.Гайфуллина).

12. *Задачи совершенствования учебно-воспитательного процесса*. — Казань: КГПИ, 1991. — 23 с.

13. *Итоги и перспективы*. — Казань: КГПИ, 1992. — 21 с.

14. *Новые подходы к преподаванию литературы*. — Казань: КГПИ, 1992. — 23 с.

15. *За повышение уровня подготовки педагогических кадров*. — Казань: КГПИ, 1992. — 23 с.

16. *За подготовку высокоэрудированных специалистов.* — Казань: КГПИ, 1994. — 20 с.

17. *Татар теле.* Унберьеллык урта мәкт. 5 сыйныфы өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 1995. — 214 б. (автордашлар: К.З.Зиннәтуллина, Т.М.Гайфуллина).

18. *Татар теле.* Рус мәкт. 8 сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 1995. — 238 б. (автордашлар: Р.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

19. *Татарский язык в русскоязычной аудитории.* Пособие для старшеклассников русских школ. — Казань: Магариф, 1995. — 503 с. (соавтор — А.Ш.Асадуллин).

20. *Программа для практических занятий по татарскому языку в русскоязычной аудитории*. — Казань: Магариф, 1995. — 24 с. (соавтор — А.Ш.Асадуллин).

21. *Программа по татарскому языку для V—XI классов русских школ*. — Казань: Магариф, 1995. — 24 с. (соавторы: З.Н.Хабибуллина, Р.А.Асылгарева, К.З.Зиннатуллина).

22. *Татарский язык в русскоязычной аудитории.* — Казань: Магариф, 1995. — 206 с. (соавтор — А.Ш.Асадуллин).

23. *За новое качество подготовки педагогов*. — Казань: КГПИ, 1996. — 35 с.

24. *Рус мәктәпләрендә татар балалары өчен татар теле программасы (I—XI сыйныфлар)*. — Казан: КДПУ, 1997. — 54 б.

25. *За повышение уровня подготовки специалистов.* — Казань: КГПУ, 1997. — 23 с.

26. *Задачи по усилению воспитательной работы со студентами.* — Казань: КГПУ, 1998. — 19 с.

27. *Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре.* Укытучылар өчен ярдәмлек. — Казан: Мәгариф, 1998. — 150 б. (автордаш — Ш.Ә.Әсәдуллин).

28. *Задачи по усовершенствованию учебно-воспитательного процесса*. — Казань: КГПУ, 1998. — 22 с.

29. *Татар теле.* Рус урта гомуми белем мәкт. 8 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 1999. — 207 б. (автордашлар: Р.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

30. *О задачах по совершенствованию системы подготовки педагогических кадров.* — Казань: КГПУ, 1999. — 32 с.

31. *Татар теле.* Татар урта гомуми белем мәкт. 5нче сыйныфы өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2000.—167 б. (автордашлар: К.З.Зиннәтуллина, Т.М.Гайфуллина).

32. К*азанский государственный педагогический университет за 5 лет*. — Казань: КГПУ, 2002. — 20 с.

33. *Сөйләм культурасы курсыннан мөстәкыйль эшләр өчен методик кулланма.* — Казан: КГПУ, 2004. — 24б.

34. *Сөйләм культурасы: Әдәби тел нормалары.* Студентлар өчен программа. — Казан: КДПУ, 2003. — 12 б.

35. *Татар теле.* Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 8 нче сыйныфы өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2005. — 232 б. (автордашлар: В.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

36. *Сөйләм культурасы.* Методик кулланма. — Казан: ТДГПУ, 2005. — 37 б.

37. *Татар теле.* Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2006.

38. *Татарский язык для 8 класса.* — Казань: Мәгариф, 2010.

39. *Татар теле.* Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек. — Казан: Татар. китап нәшр., 2011. (автордашлар: Р.Ә.Асылгәрәева, М.К.Зиннуров).

40. *Мәгърифәт үзәкләре тарихыннан (Из истории центров просвещения).* — Казан: «Сүз», 2014. — 226 б.

41. *Хатирәләремне яңартып*. — Казан: «Сүз» нәшрияты, 2016. — 253 б.

*Җыентыкларда, газета-журналларда басылып чыккан 500 гә якын фәнни мәкалә.*

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. *Зыятдинов Ф.С.* Яшәү мәгънәсе. — Казан: «Матбугат йорты», 1998. — 168 б.

2. *Зиятдинов Ф.С.* Через тернии к звёздам . — Казань: «Дом печати», 1999. — 272 с.

3. Рузаль Абдуллазянович Юсупов. Биобиблиография ученых Татарстана. — Казань: Академия наук РТ, 2006. — 135 с.

4. Академик Рузаль Юсупов. Биобиблиография учёных Татарстана. — Казань: Академия наук РТ, 2007. — 333 с.

5. Возвращаясь к дням минувшим. — Казань: «Слово», 2011. — 332 с.

6. *Р.А.Юсупов.* Воспоминания через размышления. — Казань: Таткнигоиздат, 2013. — 287 с.

7. *Р.А.Юсупов*. Тормыш сынауларын узып. — Казан: ТФАнең Тарих институты, 2013. — 152 б.

8. *Р.А.Юсупов*. Жизнь и деятельность на страницах печати. / Тормыш мизгелләре матбугат битләрендә. — Казань: «Слово», 2015. — 420 с.

## ЭЧТӘЛЕК

### ОЛЫ ЮЛНЫҢ БАШЫ

Мөстәкыйльлеккә тәүге адым .......... 4
Кышкар — тарихи авыл .......... 5
Без — сугыш чоры балалары .......... 11
Шәкерт абый .......... 16
Түзәргә, чигенмәскә .......... 23
Себер киңлекләрендә .......... 31
Әфган чигендә .......... 39
Альма-матер сабаклары .......... 49
Эфир журналистикасын үзләштерү .......... 58
Хуш, телевидение, исәнме, институт... .......... 65

### ФӘН ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ ДӨНЬЯСЫНА НЫКЛЫ АДЫМНАР

Фән һәм мәгърифәт дөньясына ныклы адымнар .......... 71
Җитәкчелек эшендә көч сынау .......... 80
Көнләшү — яман чир .......... 93
Кешеләргә яхшылык эшләүдән куркырга кирәкми .......... 99

### ТЕЛ ГАЛИМЕ — ПУБЛИЦИСТ

Тел галиме — публицист .......... 111

### ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЭШЛӘР

Иҗтимагый-сәяси эшләр .......... 125
Суверенлыкка ирешү — изге гамәл .......... 129
Референдум — халык фикере .......... 141
Конституция — хокукый дәүләтнең нигезе .......... 143
Телләр турында закон кабул итү .......... 149
Халыкчан партия төзү .......... 154

**ЧИТ ҖИРЛӘРНЕ КҮРЕП ГЫЙБРӘТ АЛ** ........ 163

**НӘРСӘ УЛ БӘХЕТ ҺӘМ НИЧЕК БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА?** ........ 185

## РҮЗӘЛ ЮСУПОВ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР ҺӘМ ФИКЕРЛӘР

Яшьлек хатирәләре ........ 198
Эштә кайнап үстек ........ 200
Кооператор һөнәрен үзләштергәндә ........ 203
Тынгысыз студент ........ 204
Сабакташым белән горурланам ........ 208
Тел хәзинәсе сагында ярты гасыр ........ 211
Бергә җигелеп тарттык ........ 214
Аспирантурада укыган еллар хатирәсе ........ 215
Телләр белү — байлык ул ........ 217
Яшь педагоглар театрына нигез салучы ........ 219
Остазыма рәхмәтле мин ........ 220
Безнең зур рәхмәтебез ........ 221
Кем өчен тавыш бирергә? ........ 222
Закон әзерләү — белемле кешеләр эше ........ 223
Иң лаеклыларның берсе ........ 224
Тәҗрибәле, абруйлы, укымышлы ........ 225
Тугры хезмәт итәр! ........ 225
Шартлар бертигез булмады ........ 226
Ышаныч канатландыра ........ 227
Ярдәмчел кеше ........ 228

## ТӘБРИКЛӘҮЛӘР ҺӘМ ТЕЛӘКЛӘР

Бәхетле һәм өлешле булыйм дисәң... ........ 230
Профессор Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповка ........ 231
Рүзәл абыйга юбилее уңаеннан ........ 232

Гомернеӊ үз матурлыгы ........ 233
Рүзәлгә мәдхия ........ 234
Янып-көеп эшләдек ........ 234

**ВАЖНЕЙШИЕ ДАТЫ ЖИЗНИ Р.А.ЮСУПОВА** ........ 236

**Р.А.ЮСУПОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕӉ ИСЕМЛЕГЕ**

Монографияләр ........ 239
Дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре ........ 240
Файдаланылган әдәбият ........ 243

Литературно-художественное издание

**Әгъзам Фәйзрахманов**

**ШӘКЕРТ АБЫЙ**

Редактор-корректор *Н. К. Нотфуллина*
Верстка *Э. Ф. Нурмухаметова*

Подписано в печать с оригинал-макета 3.05.2017.
Формат 70×100 1/16. Печать офсетная. Гарнитура «Times NR».
Усл.печ.л. 15,5. Тираж 000 экз. Заказ

Издательство «Магариф — Вакыт»: http: magarif-vakyt.ru
e-mail: valeevmx@mail.ru

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного
электронного оригинал-макета в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА»
«ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.
E-mail: idelpress@mail.ruE-mail: idelpress@mail.ru